www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Марсель ГАЛИЕВ. Мәңгелекнең бер мизгеле... *Шигырьләр*. ....3
Хисам КАМАЛ. Каһәр. *Роман*. ....8
Рәшит БӘШӘР. Алда – биек тау түбәсе... *Шигырьләр*. ....88
Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. *Хикәяләр*. ....92
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Җыйдым бәхет тамчысын... *Шигырьләр*. ....108
Резеда ВӘЛИЕВА. *Хикәяләр*. ....112
Рифат СӘЛАХ. Җилләр исә кыйбла ягыннан... *Шигырьләр*. ....125
*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....128

ЯҢА ИСЕМНӘР

Лилия ВӘЛИШИНА. Җиңү язы килгәндә... *Хикәя*. ....130

«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Рәфкать ШАҺИЕВ. Аяк ялы. *Хикәя*. ....142

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Туплар гөрселдәгәндә туган шигырьләр. ....148
Зиннур МАНСУРОВ. Йөрәккә сыйган дөнья. ....152

ЮБИЛЕЙЛАР

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Хакыйкать эзләү юлында *(Зөфәр Рәмиевкә 80 яшь)*. ....160

ШИГЪРИ ХӘТЕР

Рифкать ЗАКИРОВ. Безнең балачак. *Шигырьләр*. ....163
Фәннур САФИН. Сез кемнәр? *Шигырьләр*. ....167

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Флүс ЛАТЫЙФИ. Аяклы каза. *(Камил Кәримовның кереш сүзе белән)*. ....171
*Шәхесләр сагындыра:* Самат ШАКИР. Мәрхәмәтсезлек. ....178

ШАЯН СӘХИФӘ

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде*. ....180
*Печән базары:* Алмаз ГЫЙМАДИЕВ. Замана хикәяләре. ....182

АК ҖИЛКӘН

Алинә ХӘБИБУЛЛИНА. Мизгел. *Хикәя*. ....187
Илүзә ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА, Әнисә МИРЪЯКУПОВА, Регина НОГМАНОВА *шигырьләре*. ....189
«Казан утлары» архивыннан. ....140
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*
: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.05.2018, график буенча 30.05.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-1305. Тираж 4200.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел



Марсель
Галиев

# МӘҢГЕЛЕКНЕҢ БЕР МИЗГЕЛЕ...

## Куш бәхетле мизгел

Чык бөртеге саен
зеңли Кояш,
Таң тибенә
урман сиртмәсендә.
Үтте дәме төне
мәхәббәтнең
Куш бәхеттән үргән ятьмәсендә?!

Әйләнәли алан,
түгәрәк күл,
Яр сагында
шау каеннар явы.
Төне буе
шалаш түбәсенә
Учма-учма йолдыз көле яуды.

Төне... Тәне...
Тәме... Таңы нинди!
Бер ялкында –
ике мәҗүси җан.
Мең авазлы
урман сонатасын
Оеп тыңлагандыр мәэюс җиһан.

Әнә бит – Ул!
Шалаш чыбылдыгын
Ачып чыкты,
иркә аваз салып.

---

Марсель ГАЛИЕВ (1946) – *Татарстанның халык язучысы; «Догалы еллар», «Рух», «Талисман» һ.б. исемдәге утыздан артык китап, алты томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Казанда яши.*

Сәламләде таңны,
куллар – канат,
Бар хәятне кочты алгысынып.

Яп-ялангач,
бәллүр фонтан сыман!
Раббы көнләшерлек
буй-сыныннан.
Бөтерелә алан,
ятсынмыйча,
Алиһанә назлы җир кызыннан.

Менә ул – Син!
Чыклы үлән өсләп
Спай гына атлап
киләсең дә...
Чәчләреңнең
куе шарлавыгын
Иңнәреңә җилпеп
сибәсең дә...
Курку җенен җиңеп,
нәзакәтле итеп,
Кулларыңны өскә чөясең дә –
сикерәсең!
Текә яр өстеннән,
киерелгән җәя угы сыман.
Чәлпәрәмә килә
су көзгесе,
Күл уяна, дертләп, йокысыннан.

Алкаланып
тарала да дулкын,
Бер мизгелгә
дөнья тынып кала.
Сине җуйсам...
дигән хәтәр бер шом –
Уйда гына бары, уйда гына...
Мин ташланам!
Сине йоткан дулкын уйдыгына.

Ыргыла су,
кыргый дәрте ташып,
Биләүли ул,
тәнне-тәнгә кушып,
Мәҗүси хис
күчкән безгә судан...
Ачыл әйдә,
ачыл, Су капусы!
Яралганбыз ласа бер догадан.

Күл төбеннән
калка төнбоеклар,

Кояш бии
каен очларында.
Иң әүвәл дә,
иң соңгы да булып,
Тирбәләбез
дулкын кочагында...

## Синең бүлмәң

*Бар иде бит Федосеев урамы,*
*табалмаслар шул аны...*

Чаттагы йорт, синең ялгыз тәрәз.
Үпкәчел Ай көйри өлгедә.
Бикле ишек тынын кысып тора,
Күпме гаҗиз сорау күңелдә.

Синең бүлмәң – яшел аквариум
Кебек кенә иде,
иде шул...
Монда бүтән кайтмасыңны беләм,
Әмма никтер килдем,
килдем шул.

Янган еллар хәрабәсе сыман
Сукмакларда шомлы шәүләләр.
Тартылган бау калган болдырларда,
Ак керләрен анда кем эләр?..

Чыктан авырайган үрмә гөлләр,
Төнге күбәләкләр уянган.
Казансуның иркә җиле кайда –
Толымнарың сүтеп уйнаган?

Сызлан әле, сызлан, дигән сыман
Торасың күк ишек артында.
Ачылмый шул җиз тоткалы ишек,
Онытылып шакы-шакыма.
Кабатлану булмый кабат яну –
Бер кычкыра хәтер, бер тына.

Синең бүлмәң – яшел аквариум...
Яшәү төсен күңел тансыклар.
Язмыш ярларына сикердеме
Хыялдагы алтын балыклар?..

## Ут алма син шәмдәлләргә

Күзләреңдә – төнге учак,
Җылыт, әйдә, арган җанны,
Мин оныттым бугай инде
Бәхет юрап узганнарны.
Тәрәзәгә сарыла җил –
Җылыт, әйдә, арган җанны...

Бүген безгә бирелгәнме
Мәңгелекнең бер мизгеле:
Гөнаһлардан арган җанны
Кочып алсын бер изгелек.
Пышылда син ягымлы сүз,
Мәңгелекнең бер мизгеле!..

Ут алма син шәмдәлләргә,
Кагылма син шәүләләргә,
Ай нурында коенсыннар.
Мәхәббәткә соңардык, дип,
Кыенсынма, кыенсынма...
Еллар аша төбәлик бер
Үкенечләр коесына.

Безгә дигән үксез бәхет
Айның туңган ягындамы?
Пышылда син ягымлы сүз,
Җылыт, әйдә, бу дөньяны.
Тәрәзәгә сарыла җил –
Сары яфрак явымнары...

## Дәһшәтле чибәрлек

Кәттә атлап килә!
Нәзакәтле бармаклары арасында
Җем-җем көйри сигаретның көлсу күзе.
Кызыл-кучкыл иреннәрдән, бөдрәләтеп,
Бoжра-божра төтен чөеп килә үзе.

Көмеш ука – зәһәр озын тырнаклары,
Колагында – киергедәй алкалары.
Ничә илнең байрак төсе – чәчләрендә,
Сокланыймммы бу замана чәчәгенә?!

Бар да кебек, юк та кебек – кыска итәк,
Көязлекнең тантанасы – чая ботлар...
Чыкы-чыкы чукып бара үкчәләре,
Хәтта, туктап, тынын көйли чал ир-атлар.

Калку-текә күкрәгенең ядрәләре
Тетрәп тора муенсалар арасыннан.
Сискәнер дә кояш нуры кире чигәр
Назы качкан тәкәббер, боз карашыннан.

«Шоу» дигән шау, иблис көе – металл шаңы
Яшьлегеннән эчке моңын савып алган.
Узган гасыр комсомолы – әбисенең
Бер әчмуха татарлыгы йогып калган...

Чибәр үзе, каһәр!
Мондый килеш-килбәт
Халыкара модаларны тез чүктерә.
Асылында – нинди фасыл?..
                                        Сүз камчысын
Селти язып, тыелалдым чүт-чүт кенә.

Яшь әни бу!
                Парк буйлап этеп бара –
Фаэтондай купшы-матур бала арбасы.
Хакыйкатькә күзне ачыйк, менә нинди –
Милләтенең сөтен җуйган чор анасы...
..................................................................

Шакып уятты да...
Хатирәләр купты тамырыннан.
Әнә ул – мин, ята сабый, күккә карап,
Имезлеге – арыш камырыннан.
Кабык арба тартып әнкәм бара
Рәшәле басу камылыннан.

Кинәнәме тургай, нинди моңнар саркый,
Талир тәңкә чыңы – толымыннан.
Елату да шуннан, юату да шуннан –
Буыннардан күчкән үз моңыннан.

Әнкә сөте белән, үлән суты белән
Ныгып, ялантәпи җилдергәнбез!
Туган телдән тәлгәш-сүзләр өзеп,
Тәм-сихәтен җанга сеңдергәнбез.

Тынма, хәтер... Йодрыклана үҗәтлегем:
Искермәгән әле иске көйләр!..

Бәхилләшә кырыс заман аръягыннан
Айлы алка таккан чын әниләр.
Җырда яшәү тапкан инәкәйләр...
..............................................................

Үтеп китте әнә!
Чәнти бармак белән
Этеп кенә затлы бала арбасын.
Үткен тояк – биек үкчә, чыкы-чыкы,
Узып бара, чәнчеп... үз А л л а с ы н...

## Эчтән сызып җылады ир

Алтын Мөгез култыгында
Шаулы кафе – яр читендә.
Моңын сыгып, савылып, бер
Кыз уйный виолончельдә.

Яшьсез җылый ир аһәңе
Виолончель кылларында.
Нинди тылсым бармакларда,
Нинди әрнү моң багында?
Өзгәләнә ир сагышы
Виолончель кылларында...

Җан тарыга. Шундый моңсу
Бу гомернең чал мизгеле.
Ярга таба дулкын арты
Дулкын кага Босфор җиле.
Җете утлар балкышында –
Төрек күге, Төрек җире.

Гөрли кафе. Табыннар мул.
Һәр өстәлнең үз кадере.
Виолончель кылларында
Актарыла ир бәгыре.

Исән бул, дим, хуш, Истанбул!
Бәлки кабат күралмам да...
Эчтән сызып, җылады ир
Виолончель кылларында.

Нәфис куллар тәлгәшеннән
Агылган моң тылсымына
Әсир төшеп, бөтен кафе
Сихерләнде, тына-тына...

Моң кылларын, гүзәл кызкай,
Соң чиккәчә инәлдереп,
Йә ярсытып, йә әрнетеп,
Үкендереп, үсендереп,
Әле чөеп, әле иеп,
И уйнады, алкышларга
Коенганчы, и уйнады!

Өзелмәде, түздe кыллар,
Ир йөрәген моң сынады.
Ә дулкыннар, сыктап килеп,
Ярны тешләп сулкылдады.

Хисам
Камал

# КАҺӘР

РОМАН

## XV

Нил Сергеевич Шачин үзенә бер ягымлы кеше иде. Укымышлы, культуралы. Кайсыдыр ки әйбәт укытучы шикеллерәк. Хәер, башта ул, чыннан да, укытучы булган, аннары партия эшенә кереп киткән. Шачинның нур бөркеп торган йөзе, хәерхаһ мөгамәләдә сөйләшүе бик тиз үзенә җәлеп итә, сине үз орбитасына бөтереп ала. Сизмичә дә каласың. Нәрсәсе белән шулай итә торгандыр. Кайчак син хаклы, ә ул хаксызрак булса да, аңа ташламага барасың. Ул сине ышандыра, көчләп мәҗбүр итми, тормышның барлык якларын тирәнтен белә, анализлый.

– Мин ни өчен синең яныңа килдем? – дип сорады ул Отто Зингердан. – Башка кешеләр юклыктан түгел. Һич тә. Кешеләр күп, ләкин яхшы кешеләр аз. Менә мин синең яхшы кеше икәнлегеңне сизеп килдем. Яхшы кеше иллюзор нәрсәләргә алданып харап булмасын дип килдем. Яхшы кешеләрне без сакларга тиеш. Без барыбыз да тышкы шартлар кушканча йөрибез. Теге яки бу карарны кабул итәбез, теге яки бу якны сайлыйбыз. Шул мәлдә кеше җанында тәрбияләнгән, урнашкан әхлак законнары мәсьәләне хәл итүдә катнаша. Кем күңелендә нәрсә әхлак законы булып ныгыган, менә шул бик мөһим. Без бергә аралашып йөргәндә, мин синең әхлаклы кеше булуыңны сиздем. Нинди генә хәлдә дә моңа таянырга була икән дигән нәтиҗәгә килдем. Һәм менә бик кискен, авыр хәлдә калгач, сине искә төшердем. Ни өчен? Чөнки синең хакта минем күңелдә әйбәт фикер калган. Ышанычым акланыр дип өметләнәм. Каян шундый өмет, каян шундый ышаныч – үзем дә тәгаен генә әйтә алмас идем. Бары күңел сиземе, аң тоемы белән шушы юлны сайладым. Белмим, нәрсә булып чыгар? Мине биздерерлек, гайрәтемне чигерерлек эш кылмассың шикелле. Һәрхәлдә, син андый монафикълыкны булдыра алмассың. Андый эшкә сәләтсез син.

Әйе, сине, бәлки, немецларның вакытлыча җиңүгә ирешүләре борчыгандыр. Ул сине генә түгел, күпләрнең уй-фикерләрен какшатты, карашларын үзгәртергә мәҗбүр итте. Билгеле, ныгымаган, утырмаган карашларны. Әнә шул утырмаган карашлылар немец ягына чыкты да. Андыйларны син үзең дә күрәсең, беләсең. Ләкин үз карашларын күлмәк алыштырган шикелле алмаштырган затлар бик нык ялгышты. Немецларның җиңүе вакытлы гына ул. Ә Советларны юк итү Көнбатыш империалистларының күптәнге максаты иде. Аларның бар кыҗраганы – Россияне тез чүктерү, аның табигый байлыкларын

*Ахыры. Башы узган санда.*

бүлгәләү, талау. Һәм шулар немецларның дисциплиналы, сугышырга, басып алырга ыргылып торган халык икәнен белеп, аларга төрле яклап ташлама ясый башлады. Хәрби заводлар төзергә кредит бирде. Милләтләр лигасында политик ирекләрен арттырды, кулларын чиште. Германия бик тиз арада гаять нык көчәйде. Үзенә ташлама ясаучы илләргә хәтта куркыныч тудыра башлады. Нәкъ теге шәрык әкиятендәге кебек: шаһлар җыелган да, берсе – акшарлы стенага күмер белән арыслан рәсеме, икенчесе – аңа тешләр, өченчесе аякларына бик үткен тырнаклар ясаган, дүртенчесе мыеклар, күзләрен куйган, бишенчесе, арысланга җан кертергә кирәк, дигән һәм аңа җан өргән. Шуннан арыслан, киерелеп, тешләрен ыржайткан да куркыныч аваз чыгарган. Һәм шунда теге шаһларның берсен кабып та йоткан. Икенчесе качмакчы булган, анысын да тотып ашаган. Гитлер да шулай. Германиягә күтәрелергә булышкан илләргә ябыша, аларны берәм-берәм тотып ашый башлый. Кечерәк илләрне бер законсыз үз империясенә буйсындыра. Зур илләр куркуга төшә. Нишләргә? Бу канга сусаган, котырган арыслан тиздән аларның үзләренә ташланачак бит. Һәм алар политик йөреш ясый: Милләтләр лигасында Чехословакияне, Польшаны Германиягә сата. Котырган арысланның аппетитын котырту һәм аның игътибарын Көнчыгышка таба юнәлтү өчен. Чөнки теге зур илләр Германияне һәм Советлар Россиясен үзләре өчен потенциаль афәт дип саный. Менә шушы ике коточкыч гыйфрит, үзара бәрелешеп, бер-берсен кырып бетерсен. Бөркет белән куян сугышканда, ябалакка йон кала дигәндәй, империалистларның максатлары әнә шундый була. Бар җирдә дә максатлар, мәнфәгатьләр идарә итә бит. Ләкин империалистларның ниятләре барып чыкмаячак, алар төп башына утырып калачак. Берни дә тәтемәячәк. Бу сугыш безнең ил өчен зур фаҗига булса да, аның файдасы да тими калмаячак. Бәхет юк иде, бәхетсезлек ярдәм итте, диләр бит. Сугыш авыр промышленностьны бар яклап үстерергә, яңа технологияләр кертергә этәрә. Ә бу исә илнең ныгуы, көчәюе өчен гаять әһәмиятле нәрсә. Бездә үле капитал булып яткан бик зур ресурсларны әйләнешкә кертергә юл ачыла. Авыр промышленностьны фән казанышлары белән бергә бәйләү илнең мускулатурасын гаять көчәйтәчәк. Хәзер барча совет халкы, бердәм булып, тылда һәм фронтта тиңсез киеренкелек белән хезмәт куя, каһарманлык кыла. Ә зур көч куеп башкарылган эшләр нәтиҗәсез калмый. Экономик база ныгыячак. Ә сугышта, ике көчнең физик бәрелешендә кемнең материаль базасы нык, шул җиңә. Бу – мәңгелек закон. Гитлерчылар, үзләренең материаль базасы сай икәнен белеп, «Блицкриг»ка исәп тотты. Ләкин аларның планнары барып чыкмаячак! Юк!..

Шачинның сүзе өзелеп калган кебек булды, ул, урыныннан торып, йөренә башлады. Каршысында тик кенә утырып уйга калган Оттога карап-карап алгалады. Шул чакта бүлмәгә, поднос белән озынча кофе чәйнеге күтәреп, Рита килеп керде. Шачинның бу йортта элек тә булгалаганы бар иде. Рита аны ошатып калды. Һәм ире әйтүе буенча гына түгел, Шачинның ягымлылыгы аны да битараф калдырмаган иде. Хәзер исә ул аны яхшы танышы итеп каршы алды.

Кофе эчкәндә, Шачин хәзер нәрсә эшләргә кирәклеге турында сөйләде. Тиздән немецлар шәһәрдәге полиция идарәсе белән бергә төнлә облава ясаячак, шуның өчен шәһәрдән чыгып тору хәерле икән. «Отто, син мине хутордагы абыеңнарга сыендыра алмассыңмы?» – дип сорады ул Зингердан.

Отто Шачинның бая сөйләгән сүзләрен сеңдереп, миендә кайната иде, шуның өчен бу сорау аңа кинәт бирелгән шикелле тоелды. Югыйсә Стубе Шачинның гозерен әйтеп киткән иде ич инде. Ул, ни әйтергә белмичә, Ритага

карады. Бу сорауга ул җавап бирсә, ышандырырлык булыр төсле иде. Рита иренең уйларын аңлады һәм әйтте:

– Абыйсы, бигрәк тә апасы – тиз кызып китүчән кешеләр, – диде. – Шуңа күрә дип әйтимме, алар бик үк ышанычлы булмас кебек.

– Шулайрак шул, – дип мыгырданды Отто. – Кызыллар бераз җирләрен тартып алып, кемнәргәдер биргән иде. Шуннан күңелләрендә нәфрәт укмашып калды.

– Нүжәли сатарлар? – дип аптырады Шачин. – Миңа бит аларны сабыр холыклы дигәннәр иде.

– Кискен мәлләрдә ычкынып куймагайлары... – Рита моны үзе теләмәүдән түгел, ә реаль хәл шулай булганга күрә әйткәнлеген чырае, тавышы белән белгертте.

– Җирләрен алгач, булмас шул, – дип күңелсезләнде Шачин. – Җир – җан дигән сүз ул... – Аннары бераз уйланып торды да, башын күтәреп, карашын Оттога төбәде. – Йә, син нәрсә әйтәсең, бүтән ышанычлы кешең юкмы?

– Тагын бер туган тиешле кешебез бар, ләкин ул еракта. Унсигез чакрымнар булыр, – дип куйды Отто.

– Ераграк шул... – диде Шачин, гаҗиз кыяфәттә. – Шулай да беренче мәлләрдә ярап торыр, булмаса...

Алар бүген төнлә шәһәрне калдырып китәргә дип килеште. Митавада подполье үзәге эшли башлаган. Якындагы ике айга шундый боерык бирелгән. «Сиңа, Рита, аеруча сак булырга кирәк, – диде Шачин. Нигә ичмаса Отто фамилиясенә күчмәдең? «Мейзер» дигән фамилияң дә, йөзең-битең дә яһүдә икәнеңне кычкырып тора. Бер карау белән беләчәкләр. Полициядә моның өчен махсус белгечләр куйганнар, ди. Миндә Туркалы фамилиясенә паспорт бар, фотосын үзең ябыштырырсың. Килештекме?..»

Шачин, сүзен тәмамлап, китәргә җыенды. Иң элек яңагын яулык белән бәйләп куйды (янәсе, авыру кеше кыяфәтенә керә), борын төбенә шактый калын мыек ябыштырды, аннары кәкре башлы таягына таянды да, бер аягына аксаклап, ишеккә таба титаклады. «Кичкә кадәр!» – диде ул, бусагадан атлап чыкканда.

Ир белән хатын юлга җыенырга кереште. Кыйммәтлерәк кечкенә әйберләрне идән астына яшерделәр. Затлы кием-салымнар, табак-савытлар, келәмнәр дә шунда сыеп бетте.

Төн караңгы иде. Отто юлны яхшы белә, дөресрәге, юлсыз җирдән – межалардан, урман эченнән атладылар. Күңелсез булмасын өчен, Шачин үз башыннан кичкән хәлләрне сөйли башлады, чөнки Отто күңелендә ышаныч тудыру өчен дә җаныңны ачып салу кирәк иде. Үзең ихлас булмыйча торып, башкалардан ихласлык көтә алмыйсың. Шачин Оттога болай ышанса да, аны тулаем инанган кеше дип санамый иде. Дөрес, ул кешелеген саклап калу өчен дә Шачин яклы булды, аның сүзенә иярде. Ә подпольеда эшләү өчен бу гына җитми. Отто аларны мөшкел хәлгә куймасмы? Ул бит аны эштә сынап карамады. Нәрсә булып чыгар? Юк, тегенди-мондый кырын эш булырга тиеш түгел. Билгеле, урыннарда полиция участоклары төзелгән. Шымчылар да яллангандыр.

Күңелсез уйлардан бераз арыну ниятеннән, Шачин тагын сүзгә кереште.

– Утыз җиденче елда мине партиягә кандидат итеп алдылар, – диде ул. Заводта комсомол секретаре идем. Сүз уңаеннан әйткәндә, миңа өлкән партия хезмәткәре, латыш укчысы Смилга рекомендация бирде. Ул совет властен урнаштыруда актив катнашкан, Ленин янында эшләгән. Әти аның ышанычлы йомышчысы булып торган. Смилга райком инструкторы иде. Комсомол эшләре

белән гел аңа мөрәҗәгать ителәә. Мине эштә күреп, сынап белә иде. Партиягә дә үзе тәкъдим итте. Болай мөгамәләдә әйбәт кеше иде. Булышырга әзер тора. Бик аз сүзле. Ул чакта кешеләр бер-берсе белән очрашып сөйләшергә курка иде. Икәү сөйләшә башласаң, өченче берәү янына килә дә баса. Йә тәмәке сорап, йә урам сорап... Мәскәүдә коточкыч хәбәрләр йөри. Астан гына ишетелә. Ә өстә тантана артыннан тантана оештырыла. Ул конференцияләр бәйрәм төсендә уздырыла. Метро төзүчеләрне сәламләү, ударникларны котлау, аларны Сталинның кабул итүе бөтен дөньяга шаулый иде. Шулай ике үлчәмдә яшәү, ике тормыш барлыкка килде...

Бервакыт ишетәм, Смилга кулга алынган. Имеш, бухаринчылар яклы булган. Алар оешмасының Советка каршы боерыкларын үтәгән. Мин, билгеле, моңа ышанмадым. Иптәшләр миннән сорашканда да, Смилганың «халык дошманы» булуына ышанмыйм, дидем. Каян килгән миңа шулай мөстәкыйль фикер йөртү – белмим. Ул чагында кешеләр фәкать гомуми фикергә генә кушылырга тиеш иде. «Бу ник болай?» дигән сорау туа, әмма син аны тышка чыгара алмыйсың. Сораулар күп туа һәм, баш миенә җыелып, тупикка китереп җиткерә иде. Шул фикер кысанлыгында үзең эчтән бәргәләнәсең, сукранасың. Әмма хәлең белән килешергә мәҗбүр буласың. Башка чараң юк. Адәм баласы башына төшкән бик күп авыр хәлләргә җайлаша. Нинди генә шартларга җайлашмый ул! Эчтә шом, курку. Мине дә кулга алмагайлары дигән уй бер дә тынгылык бирми, җанны кискәләп-телгәләп, эчне пошыра, кулдан эш төшә. Яраткан кызым бар иде, ә мин аңа берни сөйли алмыйм, чөнки аңардан да шикләнә башладым. Ул мине күзәтә кебек һәм төрле көтелмәгән сораулар биргәндә, эчтән сагая идем. Моны үзем дә сизмим. Хәтта аны миңа махсус җибәрүләрен сизсәм дә, сизмәмешкә салышырга тиешмен. Валлаһи, бер уен кебек иде бу. Син аңларга һәм аны ачуланмаска бурычлы. Шулай булгач, син дә уйнарга тиешсең. Ул да синең белгәнне белеп тора, ләкин белмәмешкә салына. Беребез алдында беребез уйный, ягъни икебез дә уйныйбыз. Шул вакытта «тормыш уены» дигән сүз чыкты. Һәрберебез шулай уйнагач, дөреслек кайда була соң? Дөреслек юкка чыга. Без ялганны чын дип кабул итәбез. Сәхнәдә артистлар уйный торган тормыш та чын түгел бит. Чынбарлыкта эш, хезмәт һәм кеше белән кеше арасындагы чын мөнәсәбәтләр бар. Алар нишли? Бу хәлләр эшкә дә зыян китерә иде. Хезмәтне оештырырга, аңа юнәлеш бирергә кирәк. Бик күп проблемалар алга килеп баса. Биредә политика белән хәл итмичә булмый торган ситуацияләр туа. Экономик яктан нигезләргә кирәк. Бездә бары тик политик нигезләр генә хөкем сөрә. Ә экономик яктан нигезләргә куркалар иде. Күп эшләр кул белән башкарыла, күп көч сарыф ителә. Әгәр шул хакта берәр сүз ычкындырсаң, эшең харап.

Мине метро төзелешенә җибәрделәр. Бетон ташый торган бер тәгәрмәчле арбалар бар иде. Калын тактадан авыр итеп ясалганнар. Кулбашың калмый инде, эштән соң кыйнап ташланган кебек ятасың. Мин җиңел тележка ясадым, теге эт үләтен ташладым. Бригадир миңа, ник ташладың, дип бәйләнде. Ул – зэклар тележкасы, алдынгы совет кешесенеке түгел, дидем. Телдән тагын нәрсәләрдер ычкынгандыр, хәтерләмим...

Бераз вакыт үтте, минем рәсемне Мактау тактасына куйдылар. Димәк, кешене эше буенча бәялиләр, дим, шулчаклы шатландым. Йөргән кызыма суынып бара идем, тагын тансык хисләр җанга кайта башлады. Мине мактап газеталарга яздылар. Миңа өйләнергә кирәк дигән уй килде. Канатланып йөрим, норма ярым бирмичә, эш урыныннан китмим. Тирләп-пешеп эшлим.

Ләкин бер төнне, үлеп йоклап ятканда, ике милиционер килеп керде дә мине кулга алырга ордер күрсәтте.

Коточкыч хәлләр башланды. Аяк астында җир убылды да, мин упкын төбенә мәтәлдем. Бар нәрсәнең асты өскә килде... Мине бухаринчылар арасында элемтәче булуда гаеплиләр. Әллә нинди дәлилләр уйлап чыгарганнар. Чәчең үрә торырлык иде.

– Ничек котыла алдың? – дип сорап куйды Отто, гаҗәпләнеп. – Ул чагында немецча газеталарда «Канлы Сталин» дип мәкаләләр язалар иде...

– Кит әле, безнең дошманнар пропагандасы! – диде Шачин, барган җиреннән туктап һәм Оттоның иңенә кулын куйды. Отто да аңа таба борылып, адымын кире алды. Ул Шачинның бик нык куркып калганын чамалады. Караңгы булса да, күз ияләнгәнгә күрә, аның йөз сызыклары аермачык күренә, иреннәре селкенә, күз аклары зурайган иде. Сталинны шулай атау гына да аның өнен алган, зиһенен чуалткан. Ул, ни әйтергә белмичә, тәмам телсез калган иде. Кара син аны, Сталиннан ничек курка, ә? Алладан курыккан кебек... Отто да ни әйтергә белмичә, Шачинның кинәт үзгәрүенә, шыр җибәрүенә гаҗәпләнде. Ә Шачин үзе куркак зат түгел, аны райкомда иң кыю кеше дип санаганнары Оттоның ничектер хәтерендә калган иде.

– Нигә бу нәрсә сезгә шултикле тәэсир итте? – дип, Отто Шачинның беләгеннән тотты.

– Сталин бит ул! Нигә, имеш! Бөек зат! – дип мыгырданды Шачин, исен җыеп.

– Ул бөек зат хатынын атылырга мәҗбүр иткән, соңгы чиккә җиткергән. Шулай ук газетадан укыдым...

– Адәм ышанмас нәрсәне дөрес булса да сөйләмә, дигәннәр. Дошманнар аны күралмый инде! Отто, син ул уйдырмаларның берсенә дә ышанма, яме! Гайбәтнең кайчан хак булганы бар?..

– Утсыз төтен булмый, диләр.

– Бу инде утсыз төтен җибәрү очрагы. Безгә каршы котырту өчен! Явыз ният белән эшләнә ул...

Шачинның тавышында, ярар, ул хакта сөйләшмик дигән төсмер чагылды. Отто сүзне ялгап алып китмәде, тынып калды. Алар сүзсез генә юлны дәвам итте. Аяк астындагы коры үлән генә кыштырдап тавыш чыгара иде. Бу кыштырдауны искәреп алып, алар сулга, сөргән җиргә каерды. Ә аннан, тавыш чыкмаса да, атлавы авыр. Чыннан да, сак булырга кирәк иде, хәзер алар зур күл янында утырган Аукосмуйжа бистәсенә якынлашып килә иде. «Минем анда булганым бар, – диде Шачин. – Кулакларны бетерү вакытында безнең бер активистны үтерделәр. Усал халык яши анда. Иген дә игәләр, балык та тоталар».

– Бистәне читләтеп үтәргә кирәк, – диде Отто. Шачин дәшмәде. Риза булганлыгы аяк тавышыннан беленде. Алар барасы хутор посёлоктан ерак түгел, таш җәйгән юлга чыгып барырга мөмкин, шулай җиңелрәк булачак.

– Сез Стубега ышанасызмы? – дип куйды Отто капылт кына.

– Нигә алай әйтәсең, ул – сыналган иптәш, – диде Шачин.

– Үзенә карьера ясар өчен, миңа күп нахак бәлаләр такты ул.

– Шулаймы? Нәрсәдер бар бугай шул аңарда. Мин-минлеге дә хәттин ашкан.

– Нигә җитәкче итеп әйбәтрәкләрне куймыйсыз? Рядовойларның язмышы җитәкчеләрдән тора бит!

– Ул – безнең авырткан җиребез. Кеше башта әйбәт күренә, ә властька менеп алгач, танымаслык булып үзгәрә дә куя. Начар якка. Власть кына кешенең чын йөзен ача, ахры.

Алар ятьмәләр элгән киртә буена килеп чыкты. Каршы яклардагы йортларда да ут юк иде. Авыл үлгән кебек. Оккупантлар килде дә көнне бетерде, төнгә әйләндерде.

– Мин Советларны канәгатьлек белән каршы алдым, – дип пышылдады Отто, авыл турысыннан узып киткәч. – Мин – хуҗага эшләгән кеше, Советларга да эшләдем. Механик эше политикага кагылмый. Ләкин Советлар килүгә, кешеләр бер-берсеннән курка башлады. Нилектән? Шул сорау борчый иде. Райбашкармада да кешеләр бер-берсеннән шүрли иде. Эш белән баргач сиздем. Стубе да үзе белән эшли торган иптәшләренә шикләнеп карый: маңгаена язылмаган, каян беләсең аны, дия иде.

Оттоның бу сүзләренә җавап кайтармыйча, Шачин озак кына барды. Мәсьәлә катлаулы һәм тирәндә ята. Моны ничек аңлатып бетерәсең? Әйе, теге елларда кешеләр җанында курку нык оялап калды. Кешене бер куркытсаң, шул гомер буена бара, хәтта балаларына да күчә, ди. Дөньяда яңа тормыш төзү, моңарчы булмаганны кору шактый чыгымнар таләп иткәндер. Матди һәм рухи югалтулар. Югалтмыйча гына берни дә табып булмый. Моңарчы беркем эз салмаган юлдан бару шундый корбаннар таләп иткәндер. Яңа юл ярып барганда, читкә тайпылулар, ялгышулар, адашулар булмый калмый. Капиталистик чолганышта яшәү безгә һәрчак уяу булырга кирәклекне кисәтеп тора. Әгәр яшәргә телисең икән, һәртөрле тайпылышларга каршы көрәшергә бурычлысың. Юкса капиталистлар безне изеп китәчәк. Аларның корбаны булмас өчен әнә шундый гадәттән тыш чаралар кулланылгандыр... Дөресен әйткәндә, бездә куркытып тору галәмәте көчле булды. Арттырып җибәрүләр дә байтак иде. Ул вакытлар үткәч, менә ялгышлар хәзер ачыграк аңлашыла. Боларны Оттога ничек аңлатып бетерәсең? Кичермәгән – төшенмәгән, диләр бит.

Гравий җәйгән юлга төшеп, шуннан атлый башладылар. Шачин, Оттога ничек җайлап аңлатырга дип, фикерләр, дәлилләр туплап барды. Тормыштан бер-ике мисал китерәсе килеп, хәтерен эшкә җикте. Ләкин кинәт, һич искәрмәгәндә, аның җилкәсенә авыр әйбер белән китереп суктылар, Шачинның күзләреннән очкыннар чәчрәде, аягында басып кала алмыйча, алга таба сөрлекте дә ике кулы белән җиргә таянды. Шулчак аңа тагын китереп суктылар, ул егылды... Янәшәдә Оттога да ике кеше арттан килеп ябышкан, алар каты алыша, ләкин тегесе бирешми иде. «Засада» дигән уй йөгереп узды Шачинның башыннан. Шунда Оттоның чигә турысына нәрсә беләндер китереп суктылар, ул ахылдап юл өстенә ауды. Вак ташлар чәчрәп киткән тавыш ишетелеп калды. Юлбасарлар бер сүз сөйләшми, фәкать куллары һәм аяклары гына хәрәкәт итә. Кулларында кара перчаткалар, перчатка эчендә ниндидер тимер кисәге булырга тиеш. Оттога шулай тоелды, шул мәлдә ул аңын куе томан сарганын сизде...

## XVI

Шачин, аңына килгәндә, куллары бәйләнгән килеш бричка арбасы төбендә ята иде. Җилкәсе белән ул Отто гәүдәсен дә сизде, борылырга һич мөмкин түгел, муены кисеп авырта иде. Ми тартмасында, лепкә сөягенә бәрелә-бәрелә, уйлар йөгерешә, чуалган фикерләрнең бер очын тапмакчы була. Моны ничек аңларга? Алдан көтеп торганнармы? Әллә аларны башка берәүләр белән бутадылармы? Башкалар урынына аларны эләктерделәрме? Болар – җирле полицайлар – әллә аерым күрсәтмә алганнармы? Әллә һәр төн шулай кизү торалармы? Әгәр шулай булса, аларны очраклы корбаннар частьларына алып барып сорау алырлар да, бәлки, җибәрерләр. Шайтан алгыры, ничек шулай килеп чыкты соң бу? Әгәр эш зурга китсә? Подпольеда эшли башлаганнарына да әле биш кенә айдан артык

вакыт үтте югыйсә. Әле кешеләр дә тиешле җиргә урнаштырып бетерелмәгән. Кадрлар җитешми. Шачин Оттоны подпольега җәлеп итә алган иде, хәзер ул үзен ничек тотар икән? Җирле полициядән ничек тә ычкынып булыр анысы, ләкин гестапога гына эләкмәскә кирәк. Аннан ычкыну мөмкин түгел. Дөрес, аларның Добелә полициясе биргән документлары тәртиптә. Икесе дә завод эшчеләре санала. Цехлары электр булмау аркасында вакытлыча туктатылды. Алар, шуңардан файдаланып, фәлән хуторга бара. Үзләре белән икешәр шешә көмешкә һәм берничә кисәк шпик та алды. Нигә төнлә йөрисез, дисәләр, чөнки төнлә куркынычсызрак, дип җавап бирергә була.

Чү, аларны кая алып баралар соң әле? Шәһәргәме? Әллә бүтән җиргәме? Нишләптер үзләре юлчыларның кайдан икәнлекләрен дә сорамыйлар, кәгазьләрен дә карамыйлар. Бу хәл исә эшнең алдан искәртелүе һәм шул рәвешчә тозак корылуы турындагы фикергә этәрә. Аларның юлга чыгып киткәнен кем белә иде соң? Рита һәм Стубе. Башка беркем дә. Юкса бит алар, Зингерлар утарына барырга тиешбез, дип әйтеп чыгып китте, әмма юлда маршрутны үзгәртте. Кыскасы, нинди пунктка баруларын беркем дә белми иде. Димәк, бу тотылу очраклы нәрсә генә. Эш гестапога ук барып җитмәсен өчен, теләсә нинди әмәл белән ычкынырга, качарга кирәк, башка юл юк иде. Оттоның хәле ничек икән соң? Аларга хәзер тәмам бетерешкән кыяфәт чыгарырга кирәк. Моны аның үзенә дә белгертергә иде. Хәер, ул үзе дә сизәдер, мөгаен. Әгәр аңына килгән булса. Ул да астан гына план корып ятадыр. Дәшәр идең, як-якта дүрт полицай басып тора.

Юк, аларны шәһәргә түгел, станциягә китерделәр, Глуда станциясенә. Шәһәргә терәлеп диярлек тора. Полиция идарәсе биредә микәнни? Әһә, дөрес, тимер юл полициясе. Бу хакта мәгълүмат булган иде.

Яктырып килә иде, офык читендә кызыл тасма сузылган. Тиздән кояш та чыгар. Ләкин бүген кем башына чыгар ул? Нишләп аларны бирегә китерделәр икән? Отто нишләп уянмый? Әллә каты ук сукканнармы? Әмма сорау алмыйча расходка чыгару алар мәнфәгатендә түгел ич.

Менә аларны икешәр полицай, култыклап, вокзалдагы элеккеге полиция бүлмәсенә алып керде. Отто аска караган, бик мескен кыяфәттә иде. Ни өчендер Шачинга күз салмый. Әллә уңайсызланамы? Ни сәбәптән? Бу хәлгә аның катнашы юктыр бит? Фу, шайтан, бәлагә юлыксаң, бар нәрсәгә шикләнеп карый башлыйсың.

Эчтәге бүлмәдән немец офицеры киемендә таза гына бер адәм чыкты. Шачин җимерелгән кашлары, күзен каплаган чәч бөртекләре аша астан гына аны күзәтте. Анасын сатыйм, таныш кеше түгелме соң бу? Ничек, кай арада тазарган, җилкәләре киңәйгән. Офицер чинын ни өчен биргәннәр? Немецларга күп файда китергәндер, күрәсең. Дәрәҗә ярата торган кешеләргә җай килде хәзер. Хезмәткә керә дә, немецлар боерганча, үз туганнарын да җәзага тарттыра. Немецлар аның чинын күтәрә. Менә нинди механизм. Хәер, баштагы елларда анысы бездә дә шулай иде инде. Ә немецларда аеруча кырыс административ власть. Раса теориясе белән тагын да кискенләштерелгән, бернинди юл калдырмый торган итеп эшләнгән.

Начальник, мундирының муен төймәсен эләктерә-эләктерә, өстәл артыннан чыгып, арестантлар янына килде. Үзе полицайга кул болгап китәргә кушты.

– Тукта, Шачин иптәш, бу син түгелме соң? Ә? Ә? Әллә күземә күренәме? Төш түгелдер бит! Ә? Зингер, ә син ничек бирегә килеп эләктең, ә?

– Тотып китерделәр бит, – дип телгә килде Отто, авыз кырыендагы канны учы белән сыпыра-сыпыра. Ул бик нык югалып калган иде булса кирәк. Рухи

катастрофа кичерә, шуңардан айнып җитә алмый кебек. Шачин исә мондый катастрофага бераз әзер иде. Әмма болай ук булыр дип башына да китереп карамады.

– Нил Сергеевич Шачин, бу, чыннан да, синме? – диде начальник, аңа таба иелеп, һаман да үз күзләренә үзе ышанып җитмәгән шикелле.

– Мин, мин, – дип мөгрәде Шачин, ияген күкрәгенә терәгән килеш.

– Болай булса, язмыш сине төп башына утыртты бит, ә? Язмыш синнән көлә түгелме, ә? Нинди борылыш, ә? Прәме фантастика! Шачин минем кулга килеп эләксен, имеш. Безнең элеккеге гаилә дусты, ә бераздан этине сатучы...

– Умантны мин сатмадым! – диде Шачин, акланырга теләмичә.

– Анысын инде син шыр җибәреп шулай әйтәсең, – диде кече Умант. Аның битләре бүртенде. Муен тамырлары кабарынды, тар китель якасыннан бүселә башлады. Ул тизрәк тамак астындагы сәдәфләрен ычкындырды. Үз өстенлеге белән масаю аның бөтен кыяфәтенә чыккан иде. Ул кулларын – артка, бер аягын алгарак куйды.

– Нишләп китмәдең, ә? Сине киткән дигән мәгълүмат бар иде. Димәк, ялган булган. Ә гаиләң ничек? Анысын озатырга өлгергәнсең. Белештем. Бик кызганыч. Сезнең бирегә эләгүегез бик кызганыч. Ләкин язмышка сылтап, адәм баласы үзен юатучан була. Ә сезнең бирегә килеп кабуыгыз – гап-гади очраклылык, бернинди язмыш түгел. Сез соң нишләп архивларыгызны озата алмадыгыз, ә? Мин этинең «эш»ен табып алдым да укыдым. Башта тикшерүчеләр сорау алган, аннары «тройка» хөкем иткән. Ә «тройка»ның берсе син, Шачин. Ничек син аны хөкем итә алдың? Ул бит синең дустың иде. Бездә аның туган көнендә син тост әйттең, озын гомер, уңышлар теләдең. Бераздан шул кешене хөкем иттең. Йә, әйт, моны нинди җан белән эшләргә мөмкин? Моңа акыл ышана алмый, әмма фактны танымыйча да булмый. Шачин, әйт әле, нинди принцип, нинди сәбәп белән үзеңнең якын дустыңнан, бер коллективта эшләгән, яхшы белгән иптәшеңнән шулай дошман ясарга мөмкин? Сыйнфый көрәш принцибыннан чыгыпмы? Эти миңа соңгы очрашуда әнә шулай аңлатты, һәм аның сиңа бер ачуы да юк иде кебек. Бәлки, миңа белгертәсе килмәгәндер. Ачуы булмыймы соң?! Дус дип йөргән кешесе хыянәт итсен әле!

– Ул яшерен буржуаз оешмада торган, – дип кычкырып куйды Шачин. – Үзе таныды, сөйләп бирде. Аны шуның өчен кулга алдылар. Мин аңа бернинди гаеп такмадым...

– Тәк, тәк, телең ачылдымы? – дип, начальник бер-ике адым алга атлады да кире әйләнеп килде. – Беркетмәне укыдым, син әйткәнсең: минә шундый-шундый сүзләр сөйләде, дигәнсең. Эти инкяр иткән, син «сөйләде» дип раслагансың. Эти белән аралашкан кеше буларак, сине «тройка»ның берсе иткәннәр, син өстәмә күрсәтмә биргәнсең. Шулай да беләсем килә: этигә нинди ачуың бар иде синең?

– Бернинди ачуым юк иде, – диде Шачин, үзен бер гаепсез санаган төстә.

– Алайса, принциптан чыгыпмыни?

– Әйе, ул яшерен оешмада торганын ачарга тиеш булган. Ә ул аны яшергән, шул көнгә чаклы яшерен очрашуларга йөргән, финанс ярдәме күрсәткән. Совет строена каршы, мөстәкыйль Латвия өчен көрәшкән. Соңыннан совет органнарына кереп оялаган. Мондый кешене теләсә кайсы партия хөкем итәр иде. Большевиклар партиясе дип кенә әйтмим. Монда шәхсән мин хөкем итмәдем, ә партия хөкем итте... – Шачин үзен тәмам кулга алып өлгерде. Бер дә курыкмый сөйләргә кереште. Теге ерткычланган саен, ул да үз позициясен ныграк яклый иде.

– Бар әшәкелегеңне партия җилкәсенә аударасың, Шачин. Партия иптәшеңне сатарга кушамыни? Шулайдыр шул, кушадыр...

– Без партия мәнфәгатьләрен шәхси мәнфәгатьләрдән өстен куябыз, – диде Шачин. – Шуңа күрә мондый очракларда сату дияргә ярамый, партия сафлыгы өчен көрәшү дияргә кирәк. Шул принциптан чыгып, мин Умантны яклый алмадым. Юк, мин аңа хыянәт тә итмәдем. Ялгышасың. Үз властеңнан файдаланмакчы буласың. Бел, кече Умант, бу вакытлы гына нәрсә. Хәзердән акылыңа килмәсәң, бик каты оттырачаксың. Бел шуны: гомереңне оттыруың мөмкин. Немецлар килә дә китә... Әллә син бу хәлгә ышанмыйсыңмы? Иллюзияләр белән яшәр чак түгел, егет, йә теге, йә бу якны сайла. Кулың канга батып өлгергәнче. Мин сиңа шундый киңәш бирәм...

– Синең миңа киңәш бирергә хакың юк, – диде Умант, ныклы адымнар белән идән буйлап йөренә-йөренә. Аның адымнарында, кулын тотышында каударлану галәмәте сизелә иде. Шачинның сүзләре аның миенә тәэсир итте шикелле. – Ник дигәндә, син – кешелексез адәм. Әтине утыртканда, аның биш баласы калганын син яхшы белә идең. Шулар хакына аз гына миһербанлы булырга мөмкин иде. Юк, сез кансызлар. Немецлардан нинди аермагыз бар соң? Нинди? Сез дә килеп басып алдыгыз да үз тәртипләрегезне кертә башладыгыз. Юньле, рәтле тәртип булса, бер хәл иде. Бер сүз өчен төрмәгә утыртасыз да куясыз. Немецлар сүз өчен утыртмый, кырын эш өчен генә җәзалый. Сүздән курыккан власть нинди власть инде ул? Курка, димәк, үзенең хаклы түгел икәнен белә. Шуңа күрә бар җирдә күзәтеп, шымчылык итә. Ә хаклы адәм бернидән дә курыкмый.

– Немецлар хаклымы әллә? Совет властена карата син күңелеңдә бары ачу гына йөртәсең, син аның асылын аңламыйсың.

– Мин немецлар хаклы, димим. Алар килде дә аса-кисә башлады. Кеше җиренә баш булды, байлык таларга кереште. Ач тәреләр. Менә хәзер дә биш йөз мең эре терлек җыеп озатырга боерык биргәннәр...

– Менә шуннан үзең чамала инде, – диде Шачин. – Алар, үзләренең вакытлы булуын белеп, тизрәк талап калырга ашыга.

– Мөстәкыйль ил булсак, алай талый алмаслар иде...

– Дуслар таламады бит, анысын әйтә алмыйсың, юк! – дип, Шачин һаман үзенекен тукыды.

– Талауларын күрмәдем, әмма байларның җирләрен тартып алып, ярлыларга бирделәр. Налог салдылар... – дип кул селтәде Умант, өстәл янына утырып. Шул чакта телефон шылтырады. Немецча нидер сорыйлар иде, Умант немец телендә вата-сындыра аңлатырга маташты, әмма аңлатып җиткерә алмады. Тәрҗемәчеләре юк микәнни, дип уйлап куйды Шачин, үзе Оттога карап алды. Ниһаять, Умант кызарып-бүртенеп трубканы куйды, үзалдына нидер уйлап утыра башлады.

– Совет властеның нинди гаделсез эшен күрдең, йә? – дип, Шачин кабат тегеңә кадалды. – Йә, әйтеп кара. Байларның җирен тартып алып ярлыларга бирү – бу иң зур гаделлек!

– Ә бер сүз өчен кешене төрмәгә утырту гаделлекме соң? – дип, Умант үзе дә үҗәтләнде.

– Әйе, гаделлек түгел, ләкин вакытлыча гына булган чара...

– Сез бар гаделсезлекләрне вакытлыча, дисез. Ә кеше бер генә тапкыр яши бит...

– Тукта, байларның җирен тартып алып ярлыларга өләшү гаделлекме, түгелме? Шуны әйт син!..

– Кеше милкенә кагылу бервакытта да гаделлек булмый, – диде Умант кырыс тавыш белән. – Байлыкны тир түгеп тапкан ул. Ә ярлы ялкаулыктан яки башка сәбәптән ярлы булган. Моңа бай гаепле түгел. Ялкауга җир бирсәң дә, барыбер ярлы булачак, үзе эшләргә теләмичә, җирен сатачак ул... Шулмы гаделлек? Эшләсен, ярлы булмас... Сезнең гаделлек адәм баласын боза торган нәрсә. Чөнки ул табигатькә каршы килә, шуңа күрә аның мәгънәсе булмаячак.

– Сүзләреңдә хаклык ярлыгы бар, – дияргә мәҗбүр булды Шачин. – Син акыллы кеше икәнсең, җилбаш түгел. Шундый фикерле, акны карадан аера белүче була торып, ни өчен немецларга эшкә ялландың? Просто гаҗәп! Болай син харап булачаксың, үз башыңа үзең җитәчәксең. Кулларың канга буялганчы, ташла бу эшеңне. Әтиең дә хупламас иде сине, юк!

– Әтигә тел тидермә, аны син бетердең, аның белән мине какшата алмассың, Шачин! Юк! Кеше җинаять кылса, аңа җәза бирелергә тиешме, юкмы? Ә? – Умант урыныннан сикереп торды, күзләре акаеп китте. – Йә, тиешме, юкмы?

– Мин җинаять эшләмәдем, – диде Шачин, тыйнаклана төшеп.

– Минем әтинең башына җитүчеләрнең берсе син! Кешене харап итү җинаять саналмыймыни? Йә, саналамы, юкмы?

– Соң бит мин үз ихтыярым белән түгел. Җәмгыять үзенә каршы элементлардан арынмый яши алмый...

– Менә мин дә хәзер сине гестапога озатам. Үз ихтыярым белән түгел, ә җәмгыятькә зарарлы булганың өчен. Мин җәмгыять ихтыярын гына үтәүче...

– Немецлар каршында безнең бер гаебебез дә юк, – дип аваз бирде Отто.

– Синеке юктыр, Зингер, ә Шачинныкы бар. Анда тикшерерләр...

– Без Шачин белән немец колонистына эшкә ялландык, – диде Отто бик тыныч һәм юкка рәнҗетелгән кыяфәттә. – Әнә бездән алган кәгазьләрне укып карагыз.

– Гестапода укырлар, анда белгечләр утыра.

– Миннән үч алырга телисезме? – диде Шачин, бик җитди генә. – Аның сиңа кыйбатка төшүе мөмкин.

– Куркытма, Шачин! Әтинең нахакка өзелгән гомере синең намуста. Нүжәли шуны каның белән юарга теләмисең? Бүтәннәр хакына яшисең. Нүжәли шуны аңламыйсың, ә? Коммунистлар башкаларны аңларга, белергә теләми, бары үз мәнфәгатьләрен генә кайгырта, диләр иде. Хак, ахрысы. Намус белән үлә бел, ичмаса! Кешеләрнең башларын кисәләр, ә чират үз башларына җиткәч калтырыйлар... Башта әти чираты иде, хәзер синең чират, Шачин! Ә моның нәрсәсе гадел түгел?

– Әтиеңнең үлеме минем намуста була алмый, Умант, – диде Шачин, тавышын күтәрмичә генә. – Аны вазгыять бетерде, ул – вазгыять корбаны... Син аңсыз фашист түгелсең...

– Тукта, син, вазгыять бетерде, дисең. Синең бетүең дә минем өстә була алмый, сине вазгыять гамәлдән чыгара. Шул гына, син җавап бирмисең икән, мин дә синең үлемең өчен җавап бирмим. Мин сине һич тә үз кулым белән үтермим. Әмма котылырмын дип уйлама! Бернигә дә өмет баглама! Юк!

– Сезнең фашист гамәле белән Советлар гамәле бер түгел!..

– Ә кеше язмышына карата алар икесе дә бер: тегесе дә, бусы да үзенә ярамаган шәхесләрдән арына. Әйтәм бит, вазгыять ота, ә кеше оттыра. Тегендә әти оттырган иде, хәзер син оттырасың. Гаделме? Гел отып кына булмый, андый кагыйдә юк. Һаман отып кына бару үзе үк оттыруга китерә.

– Немецлар дөньяны алга илтми, артка өстери! – диде Шачин. – Сиңа хәзер җай килде, отып калыйм, дисең. Ләкин син немецларның авантюристлыгын аңларга

тиешсең! Алар вакытлы гына. Әйтәм бит, канга буялганчы, берәр эш кыл...

– Менә, әйтик, син әтиеңне үтергән кешене кулга алдың ди. Минем урында нәрсә эшләр идең? «Канга – кан» принцибын тотар идең. Башкача әмәл юк. Нишләп мин әтине үтергән кешедән үч алмаска тиеш? Нинди кагыйдәдән чыгып? Бу үч – изге үч! Аны әтиемнең хәләл каны таләп итә.

– Мин үтермәдем аны, вазгыять, тәртип юк итте. Шул тәртипкә каршы торганга күрә, – диде Шачин, кыюлыгын бер дә киметмичә. – Мин аңардан бернинди файда күрмәдем.

– Күргәнсең, чиныңны күтәргәннәр! Яхшы урынга куйганнар! Нигә ялганлыйсың?

– Мин булмасам, әтиеңне башкалар барыбер юк итәр иде...

– Шуңа күрә, Шачин, син мине үзеңнән артыграк итеп саный алмыйсың. Мин булмасам, башка берәү сине барыбер тотып бирер иде. Син әти каныны кулыңны буягансың, ә мин синең каныңа буялырга теләмим. Әнә гестапо хәл итсен. Менә шул.

– Гестаподан берәүнең дә котыла алмаганын яхшы белеп эшлисең, ә? Минем канга барыбер кулың буяла бит. Умант, барыбер намусыңа тап төшә!

Шачинның сүзләрен бүлеп, телефон шылтырады. Умант тагын, бик азапланып-азапланып, барлы-юклы немец теле белән аңлата башлады. Кул ишарәсен күп ясаса да, ярдәм итмәде, ул бүртенеп чыкты, буыла башлады. Маңгаена бөрчек-бөрчек тир тамчылары типте. Тырыша торгач, тегендә канәгатьләнделәр, ахры, йа, йа, дия-дия, Умант трубканы куйды. Өстәл яныннан җәһәт кенә кузгалып, Зингер каршына килеп басты.

– Зингер, әйдә, безгә тәрҗемәче булып урнаш! – диде ул боерулы тон белән. Битендәге кызыл-көрәнлек әкренләп кими төште. Башына ургылып менгән кан ургылып аякларына кире төшеп китте, күрәсең.

– Юк, минем абый белән апа авырып ята, аларны һәрчак карап торырга кирәк. Беркемнәре дә юк... – Зингерның кыяфәте бик пошаманга төшкән кешенекенә охшаган иде.

– Ә бит эшкә яллангансың.

– Таш карьеры безнең кырыйда гына. Эш арасында да кереп, асларын алыштырып чыга алам.

– Эшләргә теләмисеңме? Күренеп тора...

– Теләмим түгел, ә мөмкинлегем юк...

– Син үз немецларыңа ни өчен хезмәт итүдән куркасың, ә без хезмәт итәбез, ә? Димәк, без ахмаклар, ә? Син үз халкыңа булышырга тиеш бит, ә?

– Физик мөмкинлегем юк, күрәсез ич...

– Әйе, сизәм, физик түгел, идеологик мөмкинлегең юк! Рас син Шачин белән бергә икән! Мин сине коткарам, әгәр безгә эшкә керсәң, абыйларыңны карарга да кеше табарбыз.

– Абыйлар чит-ят кешедән ояла, миннән башканы танырга теләми. Кеше куеп карадым инде...

– Мин сине чын күңелдән коткарырга теләгән идем. Шачин белән бергә гестапога китәргә телисеңмени? Киңәш итмәс идем...

– Бу эшкә барырга Шачинны мин алып чыккан идем, Умант, шуның өчен бар гаеп минем өстә. Син аны харап итсәң, каны миңа ягылачак, намусымны пычратачак. Мин синең аек акылыңа ышанам, син аны гестапога бирмәссең. Немец властьлары каршында бер гөнаһы да юк аның.

– Һе, таптың ахмакны! Шачинның подпольеда эшләр өчен калдырылуы

турында бездә кире каккысыз дәлилләр бар. Беләсең килсә, подпольеда калдырылган кеше бу хакта үзе килеп әйтте. Хатыны мәҗбүр иткән икән, соңыннан ачылып, анысын да чиште. Ул документ гестапода. Нигә соң сезне үз коммунистларыгыз сата? – диде Умант, ачуына буылып. – Нигә? – Ул Шачин алдына килеп басты. – Ну, без начар кешеләр дә булыйк ди. Ә коммунистлар үзләрен бар яктан да камил дип фикер йөртә, үзләре барыбер берсен-берсе сата. Барча кешеләр кебек үк хыянәт тә итә. Бернинди аерма юк. Хикмәт нәрсәдә? Трибуналда. Күкрәк суга-суга әтәчләнгәндә, ничек кенә сөйләмиләр, ничек кенә башкаларны гаепләмиләр. Ә катмарлы ситуациягә килеп эләккәч, барыбер үз мәнфәгатьләрен кайгырталар.

– Коммунистларның да төрлесе бар, – диде Шачин, Умантка ярар өчен генә. – Бер фашист әйтүгә карап кына коммунистларның үз идеяләренә тугрылыгы кимеми ич. – Кем булды икән соң бу үз астына кәкәй иткән куян җан? Кайсы группадан? Рас аны да белгәч?.. Шушы сорау Шачинның җанын, уйларын үзенә бөтереп алды һәм бик нык газаплый башлады... Әллә провокация ясар өчен юри әйтәме бу халуй, тәлинкә ялаучы эт?! Мөгаен, шулайдыр. Кара, нинди эт каешына әйләнеп беткән. Нишләргә инде, моңардан ничек котылырга? Бар эшне җимереп ташлаячак бит бу кабахәт җан. Ничек алар болай бик тиз һәм ансат кына килеп капты соң әле? Әллә тозак корган булганнармы?

– Әйе, коммунистларның башкалардан бернинди аермаларын күрмим, – дип куйды Умант. Аннан тагын Зингер каршына авышты. – Зингер, йә безгә эшкә керәсең, йә Шачин белән бергә гестапога китәсең, – диде ул тыныч кына.

– Властьлар каршында гаебем юк, ни өчен гестапога? – диде Зингер, башын күтәреп.

– Шачин белән булган өчен! Бу бит ике икең дүрт кебек...

– Моңарчы Шачинны белми идем, эшкә ялланганда таныштык.

– Монысына тамчы да ышанмыйм. Шачинның кем икәнен мин яхшы беләм. Син койрык болгама! Шачин белән бергә сез. Мәрхәмәт көтмә! Милләттәш дип тормаслар. Ну, ризамы син?

– Уйларга ирек бирсәгез иде, – дип, Зингер Умантның күзенә карады. Шул мәлдә ишек артында бик каты чырыйлаган тавышлар, үкереп елаулар ишетелеп китте, һәм бүлмәгә ике полицай килеп керде.

– Начальник әфәнде, тагын китердек, – дип, берсе Умантка хәбәр җиткерде. Умант алар ягына таба атлады, кемнәрнедер чакырырга боерды. Полицайның берсе тиз генә чыгып, тагын ике кораллы солдатны алып керде. Умант, Шачин белән Зингерга ымлап, аларны подвалга ябарга һәм ашарларына бирергә кушты. Полицайлар ялт итеп тоткыннар янына килеп басты, җилкәләренә асылган автомат көпшәсе белән тегеләргә төрткәли башлады.

Подвал бик сасы, тын алырлык түгел иде. Бу – вокзал янындагы элеккеге төрмә бинасы булып чыкты. Хезмәт күрсәтүче персоналы да үзгәрмәгәндер, элеккегедер әле. Аларга кайсы властька хезмәт итсә дә барыбер ич. Буржуаз Латвия властьларына эшләгән персонал, власть алышынгач, тулысы белән совет органнарына хезмәт итәргә күчкән, дип сөйләгәннәр иде. Җәзалаучы һөнәренә кешеләр бик теләп бармый, ә инде шул эштә эшләп, тәмен татыганнар аны ташлый алмый. Совет органнары өчен тир түккәннәр хәзер немецлар өчен тырыша торгандыр. Адәм баласы теләсә нинди шартка да җайлаша, чөнки аңа ничек тә яшәргә кирәк.

Подвалның бу бүлегендә ике катлы нарлар сузылып киткән. Анда аерым камераларга ишекләр бар. Ишегалдына караган якта да бер тимер ишек. Аның төбендә параша мичкәсе тора. Сасы ис шул мичкәдән тарала икән.

Шачин белән Отто арырак китеп, астагы нарга барып ятты. Янәшәдә тагын ике адәмнең сәләмәгә уралып ятканы күренде. Бераздан ишектәге кечкенә уем ачылды, һәм аннан яңа кертелгәннәрнең фамилияләре яңгырады. Дәшүгә, Отто торып барды һәм берәр кружка су, берәр телем ипи күтәреп килде. Теге сәләмә киемнәргә уралып ятучылар ничектер боларга дикъкать итә кебек иде. Шачин, сизенеп, Оттога пышылдады: «Болар Умант кешеләре булырга тиеш», – диде. Шуннан соң, авыздан колакка ишетелерлек итеп, күп сүзләрне ымнар белән генә аңлатып сөйләшә башладылар. «Нишләргә? Әллә Умант тәкъдименә риза буласыңмы?» – дип пышылдады Шачин. Ләкин Отто шундук аны кире какты. «Рита минем белән араны өзәчәк, малайны үзе белән алып китәчәк, – диде. – Ул гына түгел, минем үземнең дә җан тартмый андый эшкә. Анда комсыз, аяусыз булырга кирәк. Юк, күз алдыма да китерә алмыйм, мөмкин түгел...» Шачин: «Әгәр дә подполье үзәге тарафыннан йөкләсәк?» – диде. «Юк, булмый, – дип, тагын кырт кисте Отто. – Ничек мин ике якка да эшли алыйм?..» «Үзәк кушкач, эшләми хәлең юк. Ул андый вариантны да күз алдында тоткан иде, – диде Шачин. – Менә үзләре үк тәкъдим итеп тә торалар. Әгәр хәзер син Умант тәкъдименә риза булсаң, бәлки, ул мине дә гестапо кулына бирмәс, ә?»

Отто исә һаман да карышуын белде. Шачин да үз сүзендә нык торды. Кызык, Отто туктаусыз бер сүзне кабатлый, Ритадан куркам, ди. Һаман Ритага сылтый. Бәлки, курка да торгандыр. Хатынының холкын яхшы беләдер. Ләкин хәзер хатын белән санлашып торыр чакмы? Отто моны үзе дә аңлый, баш тарту өчен дәлилләре йомшак булганга күрә, хатынын төп аргумент итеп китерә. Аның үзенең пычранасы килми, чөнки немецларның вакытлы гына икәнлегенә мотлак ышана. Төрле яклап уйлаганнан соң, шундый иман ныгыган аңарда. Полиция бүлегендә тәрҗемәче булып эшләп тә пычранмый, буялмый калу мөмкин түгел, билгеле. Подполье үзәге боерыгы буенча эшләсәң дә, соңы ничек бетәсен белеп булмый. Кызыллар килгәч, немецка әз генә ярдәм иткәннәргә дә бернинди мәрхәмәт күрсәтмәячәк.

Аларны сорау алырга аерым-аерым йөртә башладылар. Сорау алучы – латыш, ә Умант, ачыклау өчен, төпченә торган сораулар бирә иде. Шунда ук тузбаш еланны хәтерләткән йөзле, погоннарына караганда шактый чинлы тагын бер немец утыра. Ул гаепләне һәм сорау алучыны бик нык күзәтә. Аларның эчке дөньяларына үтеп кермәкче була. Инспекторлык эшләре белән Митавадан килгән. Ул штурмфюрер Баурих иде. Үзәктә бик зур абруй казанган. Кешеләрнең психологиясенә басым ясап, гаеплеләрдән мөһим мәгълүматлар алу – аның төп эш ысулы. Ул психоанатом Фрейд практикасыннан алынган тәҗрибәләргә таянырга, шуларны төп дәлил итәргә ярата. Сорау алганда, физик җәзаларга каршы. Баурихның бу сәерлегеннән көләләр, син, барон Мюнхгаузен кебек, күктә очып йөрисең, диләр. Тик ул – бик зур начальник баласы, шуңа күрә түзәләр иде.

Баурих Оттоны төрлечә сындырырга тырышты. Ул чикләвекне ватып, аның эчендә нәрсә бар икәнен белү теләге белән яна иде.

– Син ариец бит, руска ышанма, – диде Баурих, ямьсез йөзенә мөлаемлык чалымнары чыгарып. – Әнә Шачин сине әләкләде: немецлар биредә вакытлыча гына, аларга ышанмыйм, дип әйткәнсең икән. Шуның өчен немецларга эшләргә теләмим, дип тә өстәгәнсең. Ә үзе синең дус булып та йөридер әле. Син генә аның турында бер сүз әйтергә куркасың. Нигә куркасың син Шачиннан? Ул безнең өчен беркем түгел, ә без сине зур кеше итеп күтәрәчәкбез.

– Мин Шачинны белмим, – диде Отто. – Ул минем турында теләсә ни әйтсен, аның үз иркендә.

– Ә ул сине төрмәгә утыртырга тели, немецлар бирелә вакытлы гына, дигән сүз өчен гестапо хөкем итә. Син аның хакында берни әйтергә теләмисең. Ул сиңа яла яга, синнән арынырга ниятли.

– Белмим, белмим, – дип, Отто Баурихның барча тыкшынуларын кире кага барды.

Шачинны кабат сорау алырга китергәч, Баурих алдан әзерләнгән бер бит кәгазьне аңа укырга бирде. Анда Отто кулы белән түбәндәгеләр язылган иде: «Шачин – большевиклар партиясе тарафыннан подпольеда эшләргә, үзәк төзергә һәм агентлар аша немецларга каршы пропаганда алып бару максаты белән калдырылган кеше. Ул подполье үзәге төзеде, хәзер шуның тармакларын төрле урыннарда җәелдерү бурычын үтәп йөри. Шачин элек райкомда эшли иде. Аңа шундый бурыч йөкләп калдырулары гаҗәп түгел...» Шачин укый, ләкин күзләренә ышанмый, чөнки Оттоның язу рәвешен белми иде ул.

Баурих Шачинның икеләнүен йөзеннән сизеп алды да, Оттоның паспортын, ике хатын чыгарып салды. Мә, чагыштырып кара, язулар охшаганмы, юкмы, янәсе? Әйе, бу язма Отто кулы белән язылган иде. Шачин үзе мондый провокациягә башта ук әзер иде. Юри ышанган булып уйнап маташты ул.

– Юк, – диде Шачин, – монда язылганнар чеп-чи ялган, бер сүзе дә дөрес түгел.

– Отто немец ягына чыкты, Шачин әфәнде, – диде Баурих, кечкенә башын аңа таба сузып. – Менә безгә язган гаризасы. – Баурих зур канәгатьлек белән аңа тагын бер бит кәгазь сузды. Ул да Отто кулы белән язылган, имзасы да нәкъ аныкы иде. Гаризасында ул, немецлар минем кан кардәшләрем, шуңа күрә алар белән эшләргә телим, дип язган иде.

– Сезгә эшли икән, үз ихтыяры, – диде Шачин. – Минем кешедә эшем юк.

– Ничек эшең юк, ул сине немецларга каршы көрәшергә калдырылган, дип гаепли, ә син бер җавапсыз калырга тиешме?

– Нишләргә тиеш соң мин? Алайса, күзгә-күз очраштырыгыз. Менә шунда Отто мине гаепләп карасын, барча дәлилләрен пыран-заран китерәчәкмен, чөнки барысы да ялган, провокация... – Шачин ачу белән кызып сөйләде.

Шуннан соң Баурихның бүтән соравы булмады. Шачинны подвалга төшереп яптылар. Караса, анда Отто юк иде. Кая киткән? Менә хәзер сөйләшергә, провокациягә бирелмәс өчен, ихтыяр көчен туплап, фикер ныгытып куярга иде бит. Сорар кеше дә юк. Шачинны бер кешелек камерага яптылар. Нишләргә? Оттоны бутарлар, адаштырырлар микәнни? Хәер, «төрмәдә эшкәртү» турында ул үзе дә искәрткән иде. Менә «эшкәртә» дә башладылар. Әйе, бик ахмакларча килеп чыкты бу. Бигрәк көлке, малайларча килеп чыкты. Әллә ул Оттога ышанып алданды микән? Әгәр Отто да Шачин алдады дип уйласа? Аңа да әллә нинди ысуллар, чаралар белән басым ясыйлардыр. Чыдый алмавы, сынуы да бар, билгеле. Хәзер нишләргә? Отто белән күзгә-күз очраштыруларын таләп итәргә! Башка чара юк. Үзләренең хәлен үзәккә дә җиткерергә кирәк иде. Үзәкнең биредә берәр кешесе булырга тиеш. Ул моны белә, ләкин аңа кем икәнен әйтергә өлгермәделәр. Үзәк белсә, аларга ничек тә ярдәм итәргә тырышырлар иде. Моннан качарга да җай чыгуы мөмкин. Гестапо кулына эләккәнче, нәрсә дә булса майтарып карарга кирәк. Шайтан алгыры, биредә безнекеләрдән, һичшиксез, берәү бардыр, ләкин ул нигәдер үзен белгертми. Ярдәмгә килми. Ашыкмый. Тегендә озатсалар, эш хәтәр булачак.

Тукта, кем сатты икән аларны немецларга? Умант сүзләре провокация дә булсын ди. Әмма вак-төяк детальләргә кадәр беләләр. Анысы каян? Әллә

чынлап та хыянәт булды микән? Андый детальләрне Стубе гына белә иде. Юк, тагын ике кеше белә. Соңгылары үзләрен бер елсыз да белгертмәскә тиешләр иде. Бер елдан соң гына үзәк белән элемтәгә керергә, аның боерыкларын үти башларга тиешләр. «Перестраховка» өчен шундый чара күрелгән иде. Әллә алар белән дә бер-бер көтелмәгән хәл килеп чыктымы?

Кыскасы, Умант Шачинны үз кулыннан ычкындырмаячак иде. Бу мәсьәләдә бернинди өметкә урын юк. Сентябрьдә Сталинның боерыгы килде: дошман тылында партизан отрядлары төзергә, оккупантларны һәм, иленә хыянәт кылып, немецларга хезмәткә кергәннәрне аяусыз юк итәргә, диелгән иде анда. Умант немецларга хезмәт итә. Шуның өчен ул юк ителергә тиеш! Бу бик законлы булачак. Әйе, бик җитди нәрсә алга килеп басты: йә Шачин, йә Умант...

Сорау алырга китергән саен, ул Отто белән күзгә-күз очраштыруларын таләп итә иде. Әмма бу хәл шик уятырга да мөмкин иде, шунлыктан Шачин ул хакта башка сүз кузгатмаска булды.

Шактый вакыт үтте. Умант үзе сорау алмый, полицай утыра, йөзне, кыяфәтне күзәтә. Сорау алу һаман иске эздән бара, элеккеге сорауларны бераз үзгәртеп кенә бирәләр. Шачин исә бар сорауларга да гел бертөсле җавап биреп барды.

Беркөнне аны душка керттеләр. Күлмәк якасының теккән җөйләрендә ак төрткеләр күренә башлаган иде. Душ астында басып торганда, Шачин плёнка аша Оттоны күреп алды. Ул да күреп, аңа таба килде. Шачин аны күрүенә бик шатланды, ә Оттоның сөенгәне сизелми иде. Киресенчә, аның йөзендә ниндидер сагаю, читләшү галәмәте күренде Шачинга. Ул шундук Оттога аңлатырга тотынды, ничек итеп провокация ясаулары турында сөйләде.

– Синең немец властьларына язган гаризаңны миңа укырга бирделәр. Анда синең үз имзаң тора иде, әмма мин барыбер ышанмадым. Сине дә миңа каршы котырткannнардыр, – диде.

– Безне Стубе саткан булырга тиеш, – диде караңгы чырайлы Отто. – Умант миңа үзе әйтте. Кыйнауга чыдый алмыйча, чишелергә мәҗбүр булган.

– Чираттагы провокация! – диде Шачин. – Тиздән безне Ригага җибәрәчәкләр, гестапога. Ычкынсаң, шул чакта ычкынып калырга кирәк, башка мөмкинлек булмаячак. Сине нигә чыгармыйлар соң?

– Стубе күрсәтмәләре буенча, хәзер Умант мине үзенә эшкә чакырмый башлады. Теге чагында риза буласы калган, ахрысы, ә?

– Мин дә, хәлне анализлап, шундый фикергә килдем. Беләсеңме, Умант мине кулдан ычкындырмаячак. Әмма мине гестапо кулы белән бетерәчәк. Минем үлемне үз җаваплылыгына алмас, үч кайтаруны яшерер өчен. Мәхкүм кешедән үч алу түбәнлегенә төшмим, янәсе... Шайтан алгыры! Безнең бәхетсезлеккә каян бу Умант килеп чыкты? Аны юк итмичә булмас, ахрысы, ә?

– Аның муенын ничек борасың? – дип, зәһәр кинаяле итеп әйтте Отто.

– Мәскәүдән яңа боерык килде, дип әйткән идем бит. Анда аеруча басым ясап кисәткәннәр: оккупантларга сатылып хезмәт итүче затларны аяусыз бетерергә, диелә. Безгә үзәкнең әмере шундый. Умантны ничек булса да тончыктырырга кирәк! Син сизмәдеңме, бездән кемдер булырга тиеш иде бит бу идарәдә? Мин монысын төгәл беләм. Минем параша чиләгендә менә шушы тимер кисәге ята иде, аңлыйсыңмы? – Шачин сүс җеп белән култык астына җилкә аша төшереп бәйләп куйган тырма теше кебек тимер күрсәтте. Үзенең күзләре очкынланып яна иде. Бу арада, Шачин тәмам икенче кешегә әйләнгән, дип уйлап куйды Отто. Кара, нинди нәрсәләр турында фикер йөртә. Элеккеге юл куючан, тыйнак кеше кая киткән? Шартлар әнә ничек үзгәртә адәм баласын!

Бер дә батыр сыман түгел иде, өй кешесе, канцеляриядә эшләп, кояш төшми торган җирдә үскән зәгыйфь сабакка әйләнгән иде, әнә хәзер нинди сүзләр сөйли! Искитмәле! Чынлап торып курыккан, ахры. Сәбәбе дә бик җитди шул. Ныклап уйланган булса кирәк.

– Тырма тешен кайда, ничек файдаланырга соң? – дип сорады Отто.

– Кайда җае килә – шунда, – диде Шачин.

– Ә җае килмәсә? Ригага озатсалар, Умантны күреп булмаячак. Юк, безгә качу ягын карарга кирәк. Качкан очракта Умант бездән ычкына алмас...

– Параша ишегалды ягына чыгарыла. Анда биек койма, әмма сикереп чыкмаслык түгел. Гомуми камерада хәзер кеше күп. Әгәр безне шунда күчерсәләр, параша мичкәсен икәү алып чыгабыз. Полицай берүзе генә була.

– Төн урталарына туры килсә... Барысы да хыял гына шул, шайтан алгыры!

– Юк, ничек кенә булса да, без котылырга тиеш!

– Ул тырма тешен кем куеп китте икән, ә? Әллә бередә Умантны күралмаучы берәрсе бармы? Әллә безнекеләрдәнме?

– Холкы бик кырку аның, үзен үзе бетерә торган начар холык...

Шулчак ишек ачылды, анда полицай күренде, чыгарга дип ашыктыра башлады.

Шачин белән Оттоны икесен ике камерага яптылар. Сорау алырга да чакырмадылар. Шачин теге тырма тешен күн итеге балтырына яшерде. Кием астына яшерсәң, кергәндә-чыкканда туктаусыз тентеп кенә торалар.

Берничә көннән соң аларны төн уртасында алып чыктылар. Кичә подвал тәрәзәсеннән караганда, җирне ап-ак кар каплаган иде. Хәзер исә вак яңгыр пыскый. Ерак түгел паровозның, нечкә көпшәләреннән пар бөркеп, чыбыркы шартлаткан тавыш чыгарганы ишетелә. «Алып китәләр» дигән уй Шачинның баш миенә китереп суккан кебек булды. Ул әллә нишләп китте. Әллә курыктымы? Юк, бу курку түгел иде. Эш куркудан узган иде инде. Ниһаять, хәлиткеч вакыт килеп җитте дип, аның бар вөҗүденең теләсә нинди тәвәккәллеккә барырга карар кылуы иде бу. Оттоны да алып китәләр микән, дигән уй Шачинның җанын тырный-тырный сызып узды. Аның белән ничектер ышанычлырак төсле иде. Перронга чыккач кына, ул ике полицайның Оттоны да алып килгәнен күрде. Товар вагонына башта Шачинны, аннан Оттоны, тагын кемнедер менгерделәр. Вагон эчендә кырыклы фонарь яна иде. Аның бер башы калын такталар белән бүленгән. Ишеге дә җиңел кулдан гына ясалган, ике ягына кораллы ике полицай баскан иде. Тоткыннарны шул аралыкка керттеләр. Шачин полицайларны күзәтте: тазалармы, көчлеләрме, егып булырлыкмы, янәсе. Берсе озын буйлы, какча гәүдәле, шинеленнән җилкә сөякләре беленеп тора. Эченә бер төртсәң, урталай бөгелеп төшәр төсле. Яшь, тәҗрибәсез күренә. Күптән түгел генә эшли башлаган булса кирәк. Ә менә икенчесе имән төбе кебек нык гәүдәле иде. Монысы да яшь, ләкин тәҗрибәлегә охшаган. Монысына тырма тешен кулланырга туры килмәгәе. Ике генә полицай саклый микәнни? Алар бит өчәү. Менә бераздан полицай кемнедер кулыннан тартып менгерде. Карасалар, Умант. Портфель тоткан, бил каешында пистолеты бар. Нужәли ул да аларны озата бара икән? Немецлар алдында үзен күрсәтәсе киләдер инде. Үз кулы белән илтеп тапшырырга телидер. Әллә шеф чакыртканмы үзен? Әллә юл уңаендагы берәр җиргә генә барамы? Юктыр, аны ялагайлык йөртә булыр.

Вакыт уза торды, вагонга бүтән менүче булмады. Күрше вагонда әллә немец солдатлары да барамы? Әмма бернинди тавыш ишетелмәде.

Вагон уртасында берничә ватык әрҗә бар иде. Умант шуларның берсенә килеп утырды. Бер полицай вагон ишеген шылдыратып япты, келәсен эләктерергә дә онытмады.

Шачин белән Отто бер почмакка барып, идәнгә чүмәште. Җил тынган, әкрен генә яңгыр ява. Ә таныш түгел тоткын бертуктаусыз йөренә иде. Кем булыр бу? Алар өстеннән шымчылык итәргә билгеләнгән адәмме? Ләкин ул үзе безнең солдат киемендә иде. Монысы да сагайта. Юри киендергән булулары мөмкин. Билгеле, ул солдат белән сөйләшеп китү өчен өс киеме менә дигән визит карточкасы. Мондый исәп белән эш йөртүләр еш була торган хәл. Шуның өчен сак булырга туры килә.

Менә паровоз вагоннарны тартып куйды. Аларның бер-берсенә бәрелгән тавышлары алдан артка таба килде. Димәк, мәхбүсләр соңгы вагоннарның берсендә иде. Качар өчен җайсыз булмаячак. Ләкин бу өченче кешенең кем икәнен белергә иде. Провокатор түгелме? Менә вагон тәгәрмәчләренең рельслар тоташкан төшкә бәрелүе ишетелде, ул ешайганнан-ешая барды. Шачин белән Отто янына теге кеше дә килеп ауды. Шачин аңа сүз катты. Ни өчен монда эләгүен сорады. Тегесе ишек ягына ымлады, начальник ишетә күрмәсен, янәсе. Шунда ук беленде – латыш икән. Хутордан. Немецлар аның атын тартып алган. Ул аларга каршылык күрсәткән. Шуның өчен кулга алганнар икән. Дөрескә охшаган, ник дигәндә, оккупантлар сентябрь аенда ук Германия өчен эре терлек, җылы киемнәр җыярга кереште. Икмәк налогы салды. Беренче җыемда мал-туар шактый күп иде. Барысын да Любава аша Пруссиягә озаттылар. Ләкин барыбер дә бу кешегә ышанып булмый. Сөйләгәннәре өйрәтеп куелган версияне хәтерләтә. Бәлки, алай да түгелдер, әмма сыналмаган чит кешегә исәп тотарга ярамый иде.

Паровоз кузгалып китүгә, Умант үз кул астындагы ике полицайны никтер ачулана башлады. Тик тәгәрмәчләр тавышы сүзләрне төгәл ишеттерми, шуңа күрә начальникның тузыну сәбәбен дә чамалавы кыен. Әллә сак өчен ул теләгән полицайлар булмаганмы? Ничектер шулайрак сизелә. Ике сакчы белән генә Умант юлга чыгар иде микән? Бу хутор мужигы да аның кешесе булырга тиеш.

Шундыйрак фикергә килделәр. Умант бераз кычкырынып алгач тынып калды. Әрҗәләр өстенә йокларга ятты шикелле. Полицайлар, мылтыкларын култык астына кыстырып, алга төбәгән килеш, ишек янында йөренергә керește. Менә берсе фонарь янындагы әрҗәгә килеп утырды, сигарет чыгарып, куыктан кабызды да тарта башлады. Икенчесе, мылтыгын бот арасына кыстырып, янчык алып, тәмәке төрде. Шулай ук куыктан кабызды. Тегеңә йөзен чытып карап алды. Алар дус түгелләр иде кебек. Бер-берсенә сүгенгән тон белән генә дәшәләр, мыскыллы сүзләр әйтәләр. Ни өчен Умант мондый кешеләрне алган соң? Бусы табышмак иде.

Шачин белән Оттоның исә бар кайгысы шул иде: һөҗүм итсәк, көч җитәрмеюкмы? Кайчан, ничек һөҗүм итәргә? Иң элек Умантка ташланыргамы, әллә полицайларгамы? Әйе, башта башлыкны бетерү отышлырак булыр шикелле. Башлыктан башка полицайлар мөстәкыйль хәрәкәт итә алмас кебек иде. Отто юлны яхшы белә, Шачинга да бу юл шактый таныш. Әлбәттә, дошманга кинәт ташланырга, моны ярты төн узгач, күзгә тәмам йокы элегәч эшләргә кирәк. Тик Умантның ниндидер мәкере бар бугай, нишләп ул тыныч кына ята? Юкса күрше вагонда запас сакчылар да тотмый бит. Бу ике сакчыга нык ышанамы? Әллә нидер сизенеп, әзер булып ятамы? Аларны провокациягә этәреп, шул рәвешле «җим» ташлыймы, ымсындырамы?

Паровоз Митавага таба ашыгып чаба иде. Бу тирәдә юлдан ерак түгел урманнар башлана. Вакыт чама белән төнге өчләргә якынлашып килә иде шикелле. Йә мал, йә җан дип, ыргым ясарга кирәк. Шачин яткан җиреннән сикереп торып басты. Кан тамырларындагы дулкын колагын чыңлата, йөрәген дөп-дөп типтерә иде. Нәкъ шул мәлдә тегендә нәрсәдер шап итте, һәм Умантның карлыккан тавышы ишетелде. Ул, урыныннан торып, фонарь янып утырган әрҗә тирәли йөренергә кереште. Дагалы күн итегенең кадагы чыккан, ахры, идәнгә баскан саен чырт итеп тимер тавышы килә иде.

Форсатны кулдан ычкындырдык, дип үкенеп, тешен кысты Шачин. Менә ниндидер станциягә килеп җитеп, паровоз туктады. Бер-ике минуттан ишеккә шак-шок бәрә башладылар. Умант полицайларга кабат җикеренде дә ишекне шылдыратып ачты. Аннан кемдер Умантка латышчалап кире борылырга кирәклеген әйтте. «Ни өчен?» – дип сорады Умант. «Юлда авария, – дип аңлатты тегесе. – Бандитлар поезд составын шартлаткан...»

Ул киткәч, Умант сүгенергә тотынды. Шачин бандитларның кем булуын тиз аңлап алды. Урманнарда төркем-төркем булып партизан отрядлары хәрәкәт итә, немецлар аларны бандитлар дип атый иде.

Умант кызып китте һәм, тәбәнәк буйлы булса да, көчле күренгән полицайны уңлы-суллы яңаклап алды. Икенчесенең артына типте. Әйтерсең, юлдагы авария алар аркасында килеп чыккан, әйтерсең, алар гаепле. Бандитлар турында ишеткәч, әллә Умантның нервлары чыгырыннан чыктымы? Бик мөмкин. Умант уйсыз кеше түгел. Нәрсәдер аны эчтән кимерә һәм борчый иде шикелле. Әллә аны Шачинның сүзләре уйга салдымы? Шачин баштарак, Умант үзе генә сорау алганда, аңа тәкъдим итте: «Мине коткар, – диде. – Безнекеләр килгәч, бу эшең югары бәяләнер...» Шунда Умант, көлә-көлә: «Әһә, алыш-биреш тәкъдим итәсеңме?» – дип ыржайды. Бик канәгать кыяфәттә, үзенең өстенлегенә кинәнеп, арлы-бирле йөренде. Әмма хәзер аның кыяфәтендә теге чактагы һавалык юк. «Һавасы» ниндидер ярыктан чыга башлаган, ахрысы. Әллә совет армиясенең Мәскәү янындагы зур җиңүләре хафага салганмы аны? Хафаланырлык та шул: немецның мактаулы гаскәрләре Мәскәү тирәсеннән дүрт йөз, өч йөз илле чакрымнарга алып ташланган. Моңарчы һәрвакыт җиңеп кенә килгән, күп илләрне баш идергән, кукрайган гаскәр өчен бу хәл зур катастрофа иде, билгеле.

Таң беленер-беленмәс эңгер-меңгер вакыт иде. Тоткыннар тышка чыгарга сорадылар. Тәбәнәк полицай Умантка мөрәҗәгать итте: рөхсәтме, юкмы? Умант тиз генә җавап бирмәде. Кире борылу аның зиһенен, планнарын чуалткан иде шикелле. Умант, тоткыннарга ымлап: «Куллары бәйләнгәнме?» – дип сорады. «Юк», – диде озын полицай. «Ник бәйләмәдегез?» – «Андый боерык булмады». «Түмәр баш, син аны үзең белергә тиеш, ул бит синең беренче эшең, – дип, Умант сүгенергә тотынды һәм, янына килеп, тегенең яңагына бер-ике менеп тә төште. – Кулларын бәйләп чыгарыгыз!» Полицайлар бау эзли башлады. Шуннан исләренә төште: «Кулларын бәйләгәч, алар ничек тышка чыга алсын соң?» – диде озын полицай. Тагын Умантка карадылар. Тегесе әйтте: «Берәм-берәм төшереп пес иттерегез», – диде. Полицайлар башта теге тоткынның хаҗәтен үтәтеп менгерде. Шул арада Шачин белән Отто, бик кысталганлыкларын белгертеп, эчләрен тоткан килеш бөгелеп, ухылдарга тотынды. Полицайлар аста, болар икесе дә ыңгырашып ишек янына килде. Берәм-берәм төшегез, дип әйтүче булмады. Умантның исә кәефе кырылып, өмете тәмам өзелгән, шуңа ачуыннан нишләргә белми иде кебек.

Шачин белән Отто бер-бер артлы җиргә сикерде. Яңгыр туктаган, куе томан төшкән, аяк асты бозлавык иде. Шачин озын полицай торган якка сикерде дә, шул тизлектә иелә төшеп, башы белән тегенең иягенә тондырды. Полицай чалкан авып төште, кулыннан мылтыгы ычкынды, ул шундук Шачин кулына күчте. Ул шуның белән тегенең маңгаена сукты да вагон астына кереп юкка чыкты. Отто да ике куллап тәбәнәк полицайның бугазына ябышты, тегесе мылтыгын ычкындыргач, аны юл кырыена атып бәрде. Нишләптер алар берсебер тавыш чыгармады. Бу гаҗәп тоелды. Күз ачып йомганчы, Отто да вагон астына шылды. Ул Шачинны томан эчендә күрми, аяк тавышы буенча чаба иде. Бәхетләренә, Митава ягына таба товар поезды китеп бара иде, алар шуңа барып ябыша алды. Куе томан аларны үзенә яшерде.

Барысы да бик тиз эшләнде. Әмма башта уйланылганча килеп чыкмады. Шачин ничек тә Уманттан үч алырга ниятләгән иде. Ләкин вагон идәнендә уйланып ята торгач, ул уеннан кире кайтты. Шул хакта Оттога да әйтте. Ычкынып буламы-юкмы, анысы да билгесез иде. Әгәр Умантны яраласалар йә үтерсәләр, аларны немецлар бик ныклап эзләргә керешәчәк. Эзли торгач, эзләренә төшүләре дә бик ихтимал. Өстәвенә икесен дә биредәге кешеләр яхшы белә. Ә болай бар гаеп Умант өстенә төшә. Бу хакта ул эчтән тыначак. Әгәр әйтсә, үзенә кырын карый башлаячаклар. Умантның башына тай типмәгән. Болай да ул хәзер икеләнеп яши булыр. Шачин аңа бик ныклап аңлатты: кулың кеше канына буялганчы, бу эшеңнән кит, диде. Гомереңне генә әрәм итәсең, безнекеләр барыбер киләчәк, дип, ике төрле уйларга урын калдырмады.

Томан эченнән поезд артык кызу бармый иде. Тиз барса да, төшеп калу кыен түгел. Байтак кына ара үткәч, икенче станциягә җиткәнче, Отто якынча чамалады һәм поезддан сикерергә ым какты.

Сөт кебек куе томанның таралырга һич исәбе юк кебек. Отто, сул якта урман булырга тиеш, диде. Шул тарафка авыштылар. Аяк астын юка гына боз каплаган. Бик сак булырга тырышып атладылар. Әмма урман Отто исәпләгән турыда булып чыкмады. Узып киткәннәр икән. Кирегә борылмый чара юк иде.

Бу чаган урманы иде. Аяк астында калын чыпта кебек яфрак түшәлгән. Аннан атлаганда, бик нык тавыш чыга, әллә кая хәтле ишетелә. Урман кырыеннан бераз баргач, бер ешкынлыкка керделәр. Азрак аякларны ял иттерергә һәм киңәш-табыш итәргә кирәк иде. Хәзерге хәлне һәрьяклап тикшерергә, алга таба нишләргә, кая барырга кирәклеген төгәл билгеләү мәслихәт, шунсыз бер хәрәкәт тә ясарга ярамый иде.

Яфрак-түшәккә аудылар. Аларның бар уен әле генә үзләре кылган эш биләгән иде. Умант тырнагыннан болай җиңел генә котыла алуларына берара хәтта ышана алмыйча да тордылар. Әйе, һәрчак менә шулай тәвәккәлләргә кирәк икән. Йә мал, йә җан дип, үз теләгеңә ирешү өчен ташланырга кирәк. Башсызланып, куркынычның күзенә керергә...

Хәзер Умант аларга һәр җирдә капкын куячак. Бу эшкә ул тагын да ныграк үч һәм үҗәтлек белән тотыначак. Шачин белән Оттога бер генә чара кала: тиз арада аның үзен хәл кылырга кирәк. Шунсыз аларга көн бетә. Йә алар, йә ул – өченче юл юк. Умант – явыз, мәкерле бәндә. Ул капкын куеп өлгергәнче, алар аны юк итәргә тиеш.

Элеккеге квартирага кайтып булмаячак. Бүтән урын табарга туры киләчәк. Әллә Митавага күчәргәме? Ләкин биредә хәрби шәһәрчек бар, анда немец частьлары һәрвакыт мыжлап тора. Өстәвенә өлкә жандармериясе, гестапо бүлекчәсе дә шунда. Юк, Митава кулай түгел. Ауцеда ничек булыр? Тик ул

да ярамый, чөнки анысы олы юл өстендә урнашкан. Әллә Вента урманнарына китеп торыргамы? Әмма Оттога анда китәргә ярамый. Аңа хәзер яңа фамилияле паспорт белән эшкә керү муафыйк булыр. Шачинның запас квартирасында паспортлар бар. Полиция участогында «Рус-вайс»ка алмаштырырлар.

Алар озак сөйләшеп ятты. Ничек йоклап киткәннәрен сизмәделәр дә.

## XVII

Митавада Отто авторемонт мастерскоенда эшли башлады. Тиздән аны биредә эшләүче латышларга башлык итеп билгеләделәр. Оттоның тел белүе сәбәпче булгандыр, мөгаен. Әмма ул исем-фамилиясен үзгәрткән иде. Эш авыр түгел, квартирага мастерскойдан ерак түгел генә урнашты. Ирле-хатынлы латышлар, нишләптер балалары юк. Әллә булып та, хуторларга озатканнармы? Хуҗалар Оттога шикләнеп карый, аралашырга курка иде.

Мастерскойда аның фанера белән кадакланган будка сыман нәрсәсе бар. Эш кәгазьләрен шунда яза, төрле документларны тутыра. Беркөнне Отто янына эшче киеменнән таныш түгел бер кеше килеп керде. Куен кесәсеннән кечкенә генә соры кенәгә чыгарып күрсәтте. Немецларның СД органы кешесе икән. Хәл-әхвәл сораштырырга тотынды. Аны аерым эшчеләр турында кайбер мәгълүматлар кызыксындыра иде. Шактый озак төпченеп утырганнан соң, ул куеныннан тар гына кәгазь кисәге алып, Отто алдына куйды. Ымлап, укы, дигән ишарә ясады. Отто кәгазьгә язылган сүзләрне күздән кичерде. Анда «СД органнары белән хезмәттәшлек итәргә ризамын» дип язылган һәм имзага урын калдырылган иде. Оттоның маңгаена тир бәреп чыкты. Агент аның хәлен шунда ук аңлап алды һәм телгә килде: «Әгәр, – диде ул, – баш тартсаң, концлагерьга эләгүең мөмкин. Сәбәпләр тиз табылыр...» Отто башын күтәреп агентка карады. Теге тагын сүз катты: «Без, – диде, – сине бригадир итеп куйдык, сиңа хуҗалыкны ышанып тапшырдык, әмма аның белән генә эш бетми, һәрбер эш түләүне сорый. Безнең белән хезмәттәшлек итсәң, шул безне канәгатьләндерә...» «Мин нәрсә эшләргә тиеш соң?» – дип сорады Отто, исен, фикерен туплый алмыйча. «Без ни боерсак, шуны эшләрсең», – диде агент. Отто уйларга вакыт сорады. Теге: «Юк, – диде, – кулыңны куй...» «Әгәр куймасам...» – диде Отто. «Ул чакта концлагерьга китәсең», – дип, агент тар кәгазь кисәген бармаклары белән аңа таба шудырды. Отто күзләрен аска төбәде, ә башында уйлар чәбәләнде. Нишләргә? Әмма кул куймыйча да булмый иде. Икеләнүне дә сиздерергә ярамый. Һәм ул, нервланып, имзасын салды. Агент, шуны гына көткәндәй, кәгазьне, ерткыч кош кебек, тырнакларына эләктереп алды һәм, торып басып, Оттога, чамала, парин, дигән сыман кисәтеп карап алды. Һәм, пальто якасын торгызып, йөзен шуңа чумдырган килеш, ишеккә таба атлады.

Оттоны борчу, икеләнү кимерергә тотынды. Моны тизрәк Шачинга белдерергә кирәк иде. Ләкин аңа үзең бара да, хәбәр дә итә алмыйсың. Адресы билгесез. Әйтми дә. Ул аларның кайда яшәгәнен белә, ә алар анықын белми. Кайчан телисең, шунда очрашып булмый. Аның үз расписаниесе бар. Барысын да үзе эзләп таба һәм җыелыш вакытын билгели. Менә хәзер аны көтеп ят инде. Ни өчен Шачин үз очрашу урынын белгертми? Аларга ышанып җитми, ахрысы. Ул очрашу урыннарын да еш алыштыра, бәлки, шулай саклану тиештер дә, чөнки бер кешегә дә азагына кадәр ышанып булмый. Әнә Стубедан да берничә очрашу урынын әйттергәннәр һәм төнлә килеп тентү дә үткәргәннәр. Ярый әле анда беркем дә юк вакыт туры килде. Ник Стубе адресларны дөрес әйтте икән? Күрәсең, аны бик нык җәзалаганнардыр, кыйнаганнардыр, андый чакта

кешенең теленнән ни ычкынмас. Моның өчен кешене гаепләргә ярыймы? Ә бит бар төштә дә гаеплиләр. Үзләре шундый хәлгә калмаганнарга гаепләү ансат ул. Ә менә бүген теге агент тәкъдимен кабул итмәсә, ул Оттоны концлагерьга озатачак иде. Кем соң концлагерь тоткыны булырга тели? Адәм баласының ничек тә яшисе килә. Анасын корт чаккыры! Ник яшисе килә, ник? Тормышта да бернинди яхшы нәрсә булмаячак ич, газап өстенә газап кына тезелеп барачак. Хәтта өмет тә калмады бит. Ул Рита, Виктор белән бергә үлде, бетте.

Газаплы уйлары Оттоны тагын җаны кебек якыннарына китереп чыгарды. Йөрәген ниндидер бик үткен нәрсә кисеп үтте. Авыртудан күзләре яшь белән тулды. Бу газап хәзер еш кабатлана башлады.

Ремонттан чыккан машинаны сынап карадылар. Полицай булып йөргән теге кеше хәзер икенче фамилия белән шулай ук биредә эшли иде. Яз килде, почкак бәрән тиресе шикелле ала-кола агарып торган юка карлар эреп бетте. Отто тагын өмет белән яши башлады. Аның әле Рита белән улы гәүдәләрен һаман да тапканы юк иде. Аларны аткан карьер чокырына ике тапкыр барып тикшереп-эзләштереп тә йөрде ул. Әмма бернинди эз шәйли алмады. Шуннан инде, бәлки, исәннәрдер дигән сүнгән өметкә тагын җан кергән кебек булды. Тагын кыймылдый, бәгырьне кискәләргә тотынды. Ул ниндидер хәрәкәт таләп итә, нәрсәдер эшләргә куша иде. Ә нишли генә ала соң ул?

Отто мастерской начальнигыннан шәһәрнең аргы ягына күпер аша чыгарга пропуск алды. Исәбе – сынала торган машина белән урман эчендәге карьерны тагын бер тикшереп кайту иде. Аннары Клара белән Андрейны табып булмасмы дигән теләк тә күңелен тырнап тора. Елганың аргы ягына болай гына чыгармыйлар иде. Теге як та, бу як та йозакта. Немецлар йозаклауны бик ярата икән. Кая гына килсәләр дә, бар төшне йозаклап-тозаклап куялар. Һәрнәрсә яшеренгә әйләнә. Ни өчен? Җавап бер генә: юньле эш эшләми болар. Хәер, кызыллар килгәч тә, бар нәрсә яшеренгә әйләнгән иде. Эшләрне яшерен итмичә торып, бер власть та яши алмый, ди Шачин. Бер караганда, шактый сәер кеше. Үзен утыз җиденче елда кулга алып, күпме мыскыллаганнар, чит ил шпионы, дип атаганнар. Сорау алганда кыйнаганнар, мәсхәрәләп бетергәннәр. Шулай булса да, партиягә бернинди ачу сакламый, аңа тугры булып кала. Моны ничек аңларга? Шәхес буларак, чыдам, сабыр затмы? Әллә большевикларның үзгә тарту көче, берәр могҗизасы бармы? Киләчәкне күздә тотып, шулай корбан булуны берсүзсез күтәрәләрме? Юк, бу гына түгел, башка сере дә бар, ахрысы. Шачин, бер ачылып киткәндә, әйтеп куйган иде: «Мин, шәхес буларак, көчсез кеше, әмма үземнең көчле буласым, уңышка ирешәсем килә, – дигән иде. – Уңышка ирешергә физик акыл көче таләп ителә. Миндә андый мөмкинлек юк. Үзеңнең шәхси мөмкинлегең булмагач, ни кала? Партиягә керергә, аңа сыенырга кала. Дөрес, партиядә җилкәңә өстәмә йөк салына. Син аны күтәреп барырга тиешсең...»

Моторны кабызып, аның ничек эшләвен тыңлап, уйланып торганда, Оттоның иптәше Калнинь да килеп чыкты. «Двигатель нормаль эшли», – диде Отто һәм кабина ишеген ачты. Үзе рульгә утырды. Йөк машинасы идарә итү өчен шактый авыр иде. Тизлек тартмасы да бик үк рәтле түгел, ахрысы. Әллә яңа деталь куйганга гына шулаймы?

Күпергә килеп җиткәч, аларны туктатып, документларын тикшерделәр. Барысы да тәртиптә иде. Сакчы рөхсәт бирде. Күпердән әкрен тизлек белән чыктылар. Аннары Зур Совет урамы башлана. Хәзер инде исемен алмаштырганнар, «Штрассе» дип язып куйганнар. Әмма кайбер йорт

стеналарына беркетелгән калайларда «Совет» дигән язулар да сакланган. Тик калайлар кубарылган, бер кадакта гына эленеп торалар. Күперне чыккач, Калнинь сүзгә кереште, чөнки монда качмыйча, пышылдамыйча да аңлашырга мөмкин.

– Ригада тагын безнекеләрне кулга алганнар, – диде ул. – Әллә Стубе сер биргәнме? Ул үзе нык мужик иде. Анда әллә нинди ысуллар кулланалар, ди. Ниндидер укол ясыйлар икән дә, шуннан кеше бар серен чыгарып селки, ди. Телне аң көче белән дә тыя алмыйсың икән. Немец врачлары адәм баласының нәрсә уйлаганын да белә, имеш. Нүжәли башта нинди уй йөргәнен чамаларга мөмкин? Юк, арттыралардыр. Немецлар үзләрен күпертеп, югары күтәреп күрсәтергә һәвәсләр. Милли сыйфатлары шундый, имеш. Дөресме? Арттыра торган гадәтләре булмаса, үзләрен өстен раса, «сверхчеловек» дип игълан итмәсләр иде. Шулай бит? Шул милли сыйфатларына муафыйк идея уйлап чыгарганнар. Шул идеяне принцип-закон иткәннәр. Менә ничек барлыкка килгән ул фашизм. Күпертелгән милли хис фашизмны тудыра. Кайсы илдә генә булса да. Әнә безнең латыш милләтчеләрен үзең күреп торасың. Ниләргә генә барып җитмиләр! Тәмам куллары чишелде. Барча гаделсезлекнең башы милли өстенлеккә омтылуда. Яһүдләр дә үзләрен өстен халык итеп исәпли бит. Шуның белән немецларның ачуын китергәннәр, чөнки немецлар үзләрен өстен итеп танытырга тели. Үзләрен өстен итеп санаган өчен яһүдләргә җәза бирәләр. Бер өстен икенче өстенлеккә түзеп тора алмый. Милли өстенлек хакына күпме кан коелган? Күпме газаплар кичерелгән? Җирнең бер катламын кеше каны һәм күз яше сугарган. Иелеп бер уч туфрак алып, шуңа химик анализ ясасаң, анда кан һәм күз яше элементларын күп табарга мөмкиндер. Ә ни өчен, ни сәбәптән? Нәрсәгә нигезләнеп? Милли өстенлеккә нигезләнепме? Шуңа инде башка сәбәпләр өстәлә. «Яшәү пространствосы» шикелле уйдырма нәрсәләр. Ягъни яшәү мөмкинлеге өчен көрәш кешелек тарихында законлы күренеш, имеш. Милли өстенлекне раслау өчен, ниләр генә уйлап чыгармыйлар. Уйлап чыгару – шулай ук немецларның бер сыйфаты. Иҗат – немецларның стихиясе. Алардан нинди зур философлар, галимнәр, музыкантлар чыккан. Иҗат артыкка китсә, әйбәт булмый икән шул. Әнә фикри иҗат аларны «сверхчеловек»ка кадәр китереп җиткергән. Болар бит барысы да кешенең миендә эшкәртелгән. Ә фикерне хис тудыра, хис көчләп тага...

– Бүген бигрәк матур сайрыйсың, әллә көмешкә йоттыңмы? – дип бүлдерде аны Отто. Шәһәрне чыгып киләләр иде. Хәзер юлның ике ягын да нык күзәтеп барырга кирәк. Юл буенча шактый арада яшь каеннар утыртылган. Алар тезеп куйган шәмнәр кебек утыра. Шуларның бер-икесендә шартлы билге булуы ихтимал. Каеннар кәүсәсенә зур гына учма саламны бөтереп урап куярга тиешләр. Ригадан килүче шофёрлар шулай хәбәр сала. Ике каенда салам бау булса, димәк, фәлән урамдагы кибеткә яшерен радиоалгыч китерелгән. Шуннан яшереп алып чыгу хәстәрен күрегез... Әгәр өч каенда шундый билгеләр булса, эшләр үз көе белән бара, дигәнне аңлата. Болар вакытлы шартлы билгеләр. Билгеле, бер операция төгәлләнгәч, алар үзгәртеләчәк.

– Безнең арада провокатор бар, ди. Сак булырга кирәк, – дип, тагын сүз башлады Калнинь.

Отто аның әлеге сүзләренә аеруча игътибар итте. Аны гына сынар өчен әйтмиме ул бу хакта? Аңардан һаман шикләнәләр бит. Калнинь моны үзе дә белә. Ул да Оттодан шикләнә. Моны аерым детальләрдән чамаларга була.

– Ә нигә фаш итмиләр? – диде Отто, ачуы килеп.

– Ничек итеп? Беркемнең дә маңгаена язылмаган... Бер комсомолдан шикләнәләр икән, ләкин дәлилләр юк, ди. Провокаторларны ачыклый торган тестлар кирәк. Үзәктә бер-ике кеше фәкать шул эш белән генә шөгыльләнергә тиеш. Безнең үзәктә ул эшләнми. Махсус кадрлар юк. Менә шуңа күпме кешене әрәм иттек. Шачинга мин бу мәсьәләдә тәкъдим иттем, ул, үзәк белән киңәшермен, дигән иде...

– Ничек шөгыльләнәсең андый эш белән?

– Иминлек хезмәте һәр төштә кирәк бит. Шунсыз мөмкин түгел. Немецлар иминлек эшен каты куйган. Ә без коралсыз. Коралга каршы корал таләп ителә.

– Латышлар арасында бердәмлек юк, шуңа сатлыклар да күп.

– Анысы хак. Хәзер сатлыклар азаячак, чөнки немецларның җиңүенә ышанучылар һаман кими бара. Хәтта немец солдатлары арасында да дезертирлар күренә башлаган. Рус әсирләре белән бергә лагерьдан качканнар. Газетада шундый хәбәр бар иде...

– Крестьяннардан икмәк, терлек җыйдылар, бу да оккупантларның чын йөзен күрсәтте. Талауны гына беләләр. Бөек Германия мәнфәгатьләре дигән булып...

– Бар эшләре биредәге байлыкны тизрәк озатуга корылган. Җиңәчәкләренә хәзер үзләре дә ышанып бетмиләр.

– Хәрәкәт итәргә җибәрелгән машина барыр әле, барыр...

– Инерциягә калгач, ерак бара алмый инде ул...

– Анысы хак. Ә шулай да провокаторларны белеп булса иде ул. Болай гел сукырларча бит...

– Мин дә, сукырларча, дим шул... Провокаторларны провокация ясап белергә буладыр, бәлки?

– Белмим, мин белгеч түгел.

– Минем дә андый һөнәрем юк иде, ләкин тормыш өйрәнергә мәҗбүр итә, шайтан алгыры...

– Өйрән, өйрән... – диде Отто һәм еракта, юл уртасында җиңел «Мерседес-Бенц» автомобиле торганын күрде.

– Әнә ике каенга салам бәйләгәннәр, – дип кычкырып җибәрде Калнинь, шул тарафка таба кулын сузып.

Отто да салам бәйләвечне күреп алды һәм:

– Төнгә калып кайтырга кирәк булыр, – дип куйды. – Кибет янында кеше-кара булмасын. Каравылчыга ни дип эндәшергә, онытмадыңмы?

– Истә. «Кибеткә кирәкләр китерделәрме?..»

Калниньның әйткәнен Отто колак артыннан уздырды, чөнки бар дикъкате алга төбәлгән иде. Ә анда машинадан икәү чыгып, юл уртасына басты. Отто иптәшенә терсәге белән төртте. Калнинь тегеләрне күреп алды да сүгенергә тотынды:

– Безне эләктермәкче булалармы әллә? – дип мыгырданды. – Чынлап та, безнең арада провокатор бардыр дигән уйга килерсең дә шул...

– Курыкма, документлар тәртиптә, – дип, Отто агарынган Калниньга тагын терсәге белән кагылып алды.

– Анасын корт чаккыры! – дип карганды Калнинь.

Ул арада машина тегеләргә тәмам якынайды. Офицер киемендәгесе туктарга ишарә ясады.

– Син кабинадан чыкма, – дип, Отто тормозга басты һәм, машинаны туктатып, җиргә сикереп төште. Немецлар янына барды.

Шофёр солдат гаепле, боек кыяфәттә, ә офицер бик ачулы, нишләргә белмичә,

арлы-бирле йөренә, шофёрын сүгә, әллә нинди сүзләр әйтеп яный иде. Шофёр, алгарак чыгып, Оттога хәлне аңлата башлады. Двигательләре кабынмый икән. Отто шунда ук, мерседесның копотын ачып, моторга иелде. Һәр узелны күздән кичереп чыкты. Әллә кай төшләрен борды, җиңен сызганып, эчке узелларын да капшап-тикшереп маташты. Аннары кабызып карадылар, ләкин моторга җан кермәде. Отто, хикмәт жеклерда түгел микән, дип аңлатты. Үзендә моңа ярый торган деталь барлыгын әйтте. Офицер машина алдына килеп басты. Оттога ул кай ягы беләндер таныш сыман тоелды. Кайдадыр күргәнем бар шикелле дигән уй башыннан елдырым кебек узып китте. Отто үз машинасы янына килде дә, кабинаны ачып, утыргычны алды, шундагы әрҗәдә казына башлады. Калнинь аңа таба иелеп, шыпырт кына: «Эрхард Труп!» – диде. Оттоның кулындагы деталь кинәт төшеп китте. Ул иптәшенә күтәрелеп карады. Чынлап әйтәме? Әйе, Калнинь ялгышмый иде кебек. Менә кем белән очрашу язган икән, шайтан алгыры! Күпме хыялланды Отто аны очрату турында, күпме планнар корды. Рита белән Викторны шушы хәшәрәт үз кулы белән атып үтергән бит! Халык арасында палач дип яманаты таралган һәм барча кешеләрне калтыратып тоткан бәндә менә аның алдында басып тора. Әллә хәзер үк эшен бетерергәме? Аның моңа көче һәм чослыгы һичшиксез җитәчәк...

Отто жеклерны алып килеп, аны моторга куя башлады. Үзе астан гына күзәтте, шулчак мерседесның арткы утыргычында тагын бер шәүлә барлыгы күзенә чалынды. Моторны янә кабызып карадылар. Кабына да шунда ук тагын сүнә, каһәр. Тагын сынадылар. Юк, булмады. Эрхард, арлы-бирле йөрүеннән туктап, болар янына килде.

– Нишләп син моторны бөтенләй белмисең? – диде ул, үзенең шофёрын һаман битәрләп. – Инде ничәнче тапкыр юлда бәлагә юлыгабыз!..

Шофёр гаять гаепле, куркынган кыяфәттә моторда казынды, үзе бер сүз дә эндәшмәде.

– Тизлек тартмасында хикмәт, – диде Отто, бик ышандырырлык итеп. – Май да салынмаган, шатуннары ашалып чыккан булырга мөмкин. Тавышыннан шул сизелә.

– Ник май салмадың, ә? – дип җикеренергә тотынды Эрхард шофёрның колак төбендә. – Соботажник! Мин хәзер белдем синең кемлегеңне!

– Машина үз хуты белән бара алмый, – диде Отто бик тыныч кыяфәттә. Ул, моторда казына торгач, үзен тәмам кулга алып, фикерләрен җайга салып өлгергән иде.

– Берәр попутка тотарга кала инде, – дип, көчкә аваз салды шофёр.

Эрхард, аны ишетергә теләмәгән кебек, йөзен чытты, бурлаттай кызыл битендәге иреннәре ачылып-ябылып алды. Ул ачуын көчкә тыя иде. Эре саргылт тешләре күренеп киткәләде. Бәрәңге борыны җыерылды. Шунда ул ниндидер еркыч җәнлекне хәтерләтеп куйды. Боз кисәге кебек салкын күзләре генә адәм заты икәненә ишарәле иде. Үтә дә канечкеч кеше дигәннәре шушы адәм актыгы, димәк?! Ни өчен ул үзе ише адәм затын шултиклем күралмый соң? Моның бит бик җитди сәбәпләре булырга тиеш. Ул нәрсәгәдер таянып эш итә ич. Көн саен диярлек тере җаннарны кыеп йөреп, адәм баласының ничек кешечә кыяфәте, йөзе сакланырга мөмкин? Аның рухы тәмам җимерелеп эштән чыккан булырга тиеш ләбаса. Тышкы дәрәҗә атрибутлары белән каплап кына рух җимерекләрен яшереп саклап буламы? Әллә моның рухы таза-саумы? Алай булса, ул инде нормаль кеше түгел. Әмма аңарда сәерлек галәмәтләре һич тә сизелми...

Оттоның тамырларында кан тагын кайнарланды һәм тәнен пешерә-пешерә йөгерә башлады. Ияк астының ут кебек янганы тоелды, куллары кызышып кычыта иде. Ач тамакка ашаганда, теш төпләре кызышып чәнчешкән шикелле. Әмма тыныч булырга кирәк. Ул эчтән үзенә, тыныч бул, тыныч бул, дип тәкрарлап торды.

– Нигә попутный? – диде Эрхард, муенын киереп. – Ә менә бу машина...

– Безнең маршрут теге якка... – дип аваз салды Отто һәм Эрхардка карады.

– Юк, рас мин боерам икән... – Эрхардның йөзе кинәт ташка әйләнгән кебек булды. Ул Оттога кырмыскага караган кебек, бик түбәнсетеп карый иде.

Шул мизгелдә Отто Эрхардның бер серен аңлаган кебек булды: канечкечкә әйләнер өчен, алдыңдагы корбанны бик түбән, юк дәрәҗәсенә куярга кирәк икән. Син аны бөҗәк итеп саныйсың һәм шуңа күрә җан кыюдан бернинди авыр хис кичермисең. Киресенчә, бер бөҗәкне үтерүдән дөньяга бары файда гына була дип уйлыйсың. Менә ничек икән...

– Безгә бүтән боерык бирелгән... – дип, Отто кешеләрчә бәйләнешкә керергә теләгән иде, тегесе кырт кисеп бүлдерде.

– Син кем, ә? – диде ул, тамак төбе белән акырып. – Кая документларың? Тиз бул! – Эрхард, кулын сузып, Оттога таба атлады. Отто кәгазьләрен чыгарып аңа тоттырды, Эрхардның боз кисәге төсле зәңгәр күз алмалары кәгазь өстендә яшен тизлеге белән як-якка чабышты. Әмма бәйләнерлек шикле нәрсә күрмәде, ахрысы, кәгазьләрне кире бирде. – Машина кабинаңда кем ул? Документы бармы? – дип, теш арасыннан ата каз тавышы чыгарып ысылдады Эрхард.

Отто машинасы янына чапты һәм Калниньның кәгазьләрен алып килде. Эрхард боларда да әллә ни тапмады. Тырт итеп кире суззы.

– Мин сиңа машинаны буксирга алырга боерам! – диде ул Оттога, тавышын тагын да күтәрә төшеп.

– Ә мин үз начальнигыма нәрсә дип җавап бирермен?

– Ну син батыр да соң! – диде Эрхард, аңа тагын якынаеп. – Миңа әле беркемнең каршы килгәне юк иде. Әллә синең башың икеме, әллә минем кем икәнне белмисеңме?

– Сезнең эсэс мундирыңдагы баш сөяге эмблемасы барын да аңлата, – диде Отто. – Сез – унтершарфюрер Эрхард Труп...

– Ничек немецча бу кадәр чиста сөйләшәсең? Син кайдан? – Эрхард җирәнгән кыяфәттә йөзен чытты. Отто моңа күптән әзер иде. Ул каушамыйнитми генә үзенең җирле немец икәнен әйтеп бирде. Тегенең йөзе барыбер үзгәрмәде, киресенчә, күзләрендә шик төерләре биешкән кебек булды. – Ник Доечландка кырыгынчы елда китми калдың? Димәк, большевиксың?

– Юк, унтершарфюрер. Кызыллар килгәч, минем хатынымны кулга алдылар. Ул бала көтә иде. Уралга сөргенгә озатканнар. Шунда малай тапты. Хәзер язмышларын белмим. Бала хакына калган идем... Кемдер донос язган...

– Син миңа ялганлама! – дип, тагын ерткыч тавышы белән ырылдады Эрхард. Кешегә кинәт каты бәрелеп, шул рәвешле аны сындыра торган иде ул, әмма Отто дошманы алдында ни боерасыз дигән кыяфәткә кермәде. Шулчак Эрхардның кулы уң касыгындагы сары кобурада капшанды һәм ул браунинг тартып чыгарды. – Син миңа ялганлама! Беләм мин сезне. Әйдә, тиз генә минем машинаны өйгә илтеп куй! Тиз! Тиз!

– Браунингсыз да мин шулай эшли идем, – дип, Отто машинасы янына таба атлады.

Алар шәһәргә төнлә генә кайтырга уйлаган иде. Барысы да җимерелде.

Кибеткә дә сугылып булмаячак. Шайтан алгыры, әллә, артыннан килеп, бу хәшәрәтне буып атаргамы? Хәзер Оттога Эрхардны юк итү берни тормый бит. Шофёр аны яклап ташланмаячак. Әмма машинада кораллы сакчы булуы ихтимал... Юк, нindidер башка җай табарга кирәк.

Эрхардның торагы мастерскойдан ерак түгел, урамның каршы ягында гына икән. Зур гына ишегалдында бер аерым йорт күренде. Шунда килеп туктадылар. Эрхард кабинадан зур портфель күтәреп чыкты, аның артыннан бик көяз, нәфис хатын-кыз төште. Ул, биек үкчәләре белән шак-шок атлап, туры капкага юнәлде. Отто мерседесны үз машинасыннан ычкындырырга тотынган иде. Үзе: «Нүжәли бу таш йөрәкнең дә хатын-кызларга күзе төшә?» – дип гаҗәпләнде.

– Тукта! – дип кычкырды шулчак Эрхард. Бу юлы аның тавышы ул хәтле үкерткычларча түгел иде. – Машинаны мастерскойга илтеп куй. Нарядны шофёр китерер...

– Миңа моның өчен начальник җәза бирәчәк, – диде Отто карусыз, тыныч тавыш белән.

Эрхард шунда кесәсеннән блокнот чыгарып, нидер язды һәм бер битен ертып алып Оттога сузды. Немецлар дисциплина ярата шул. Һәрберсе – дисциплина колы...

– Менә монысы гел башкача... – Отто, кәгазьне элэктереп, машинасына кереп утырды.

Бүгенге нияте тормышка ашмаса да, Отто күңелендә нигәдер канәгатьсезлек уянмады. Мерседес мастерской ишегалдына куелгач, уйларына канат үскән сыман булды. Ул төрле хәлләрне күз алдына китереп гөман итә башлады. Әгәр автомобильнең тапшыру коробкасын тагын тиз ватыла торган итеп ремонтласаң? Машина кабат аларга киләчәк. Аңарчы нәрсә дә булса уйлап та табылыр. Үзгәрешләр гел булып тора бит. Әгәр машинага сәгать механизмлы мина куеп җибәрсәң? Әмма андый минаны табып булырмы икән? Биредә нindidер тотынып сәбәп бар, моны кулдан ычкындырырга ярамас. Моңа дүрт куллап ябышырга кирәк. Бу хәлгә Шачин нәрсә әйтер иде икән? Андый-мондый көтелмәгән хәтәргә юлыккан очракта, ул аңа үзен Германиядән килгән немец итеп күрсәтергә кушкан иде. Пруссиядәге Гердауэн дигән шәһәрчектән килдем, дип әйтерсең, диде. Отто исә үзешчәнлек күрсәтте. Үзенең версиясе Эрхардта күбрәк ышаныч тудырыр дип уйлады. Ялгышмадымы икән? Әллә алдандымы? Бер яктан караганда, Германиядән килгән немецка Эрхард ныграк ышанырга тиеш, билгеле. Әмма ул биредәге кайбер халыкның немецларга бик теләп хезмәт күрсәтүен яхшы күрәдер, беләдер. Алар – буржуаз милләтчеләр вәкилләре. Немецлардан да рәхимсезрәк рәвештә үз милләттәшләрен эзәрлеклиләр һәм җәзалыйлар. Кайберләре шултиклем тырыша, кайчак таң каласың. Һәрбер зур милләт берәр кечерәк милләт өстеннән хакимлек иткәндә, бастыру, хөкем итүне шул милләт вәкилләре аша гына башкара. Бу бөтен дөньяда да шулай. Оккупантлар да яңа метод уйлап таба алмаган. Латышларны латышлар кулы белән җәзалыйлар, эзәрлекliләр...

Иртән шофёр наряд китерде. Отто аны һәм Эрхард биргән язуны начальник алдына китереп салды. Начальник, ни авыр кузгала торган, үшән башлы немец, кинәт сикереп торды, як-ягына каранып алды да машина янына ашыкты. Отто аның артыннан иярде, машинаның кай төше ватык икәнен аңлатты. Начальник шунда ук ремонтчыларны дәшеп китерде һәм машинаны тиз арада ремонтларга боерды. Ремонтчылар да ашыгып эшкә керeште, кайсы сүтте, кайсы башка

узелларын карады. Тапшыргыч коробкасы, чынлап та, эштән чыккан икән, яңаны куярга кирәк булды. Кайбер узелларын Отто тикшерде, алыштырды. Үзен бик сак тотты. Тиз ашала торган бер детальне алыштырмыйча калдырды. Озакка бармас, машина тагын шушы ишегалдында булыр... Хәер, моны гөман итүе кыен. Әмма Оттоның күңеле шулай тели иде, чөнки Эрхардка бер җеп очы шушы машина аша барып тоташа бит.

Кичкә машина әзер иде. Начальник, Эрхардка бик ярарга тырышып, тизрәк телефоннан шылтыратты. Әмма трубканы алучы булмады.

Теге юаш, пешмәгән шофёр иртән мастерскойда иде. Тиешле кәгазьләрне аңардан тутырткач, начальник мерседесны биреп җибәрде.

Әмма өйләгә таба теге шофёр тагын пәйда булды. Бу нихәл? Оттоның аркасы буйлап кайнар елдырымнар пешереп узды, аягыннан урап башына менде. Йөзенә кызыллык йөгерде. Әллә берәр нәрсә сизенгәннәрме?.. Шофёр салмак адымнар белән аның янына килде һәм әйтте: «Эрхард сине үзенә чакыра», – диде. Монысы тагын нәрсә? Отто, исенә килеп, шофёрга хәлне аңлатып бирде. «Начальнигым рөхсәтеннән башка бара алмыйм», – диде. Шофёр начальникка кереп китте, һәм тиз арада икесе дә болдыр баскычына чыгып басты. Начальник бик шат күренә иде: Эрхардка ярар өчен тагын бер сәбәп чыкты ич...

Отто баскыч янындагы югычта кулларын юды, өстен-башын тәртипкә китерде. Күн итеген сөрткәләде, кара галстугын рәтләде. Ә башында һаман бер уй бөтерелде: нигә чакыра икән? Шофёры, белмим, диде. Белә инде, әйтми генә. Начальниклар бит сөйләшми, белми-күрми торган кешеләрне генә үзләренә шофёр итеп ала. Бу Эрхард зобанидан барысын да көтәргә була. Судсыз-нисез, бер гаепсез кешеләрне атып үтереп йөри бит ул. Халыкның котын алып бетергән, аның исемен ишетүгә үк коелып төшәләр. Әллә үзен берәр ничек дөмектерер әмәл табаргамы? Каршысына килергә дә пистолеттан атарга? Әмма корал йөртергә рөхсәт юк. Пычак белән ташлансаң гына инде... Әмма моңа нык әзерләнергә кирәк. Ялгышлык җибәрергә һич ярамый. Шулай да бу очракта үзең берничек тә исән кала алмыйсың, бөтен бәла шунда.

Менә алар ике-өч катлы йортлар арасындагы тар гына тыкрыктан эчкә таба узды. Тимер челтәрле капкадан кергәч, күп тәрәзәле, акка буялган террасалы, ике катлы йорт күренде. Аны җимеш агачлары, декоратив куаклар чорнап алган.

Карасалар, каршыларына Эрхард үзе килеп маташа иде. Кара хром пальтодан, биек маңгайлы фуражкадан. Сул як бил туры бүлтәйгән, анда пистолет барлыгы беленеп тора.

– Кичә син миңа ошадың, – диде Эрхард, исәнләшми-нитми, гаять тәкәббер кыяфәт белән. – Миңа ерак пунктка барырга кирәк, ә бу тавык мие эчкән нәрсә юлны белми. Болай да инде ике тапкыр партизаннарга чак эләктермәде. Нишләргә? Син Виесите бистәсен беләсеңме?

– Барганым бар, – диде Отто кыюсыз гына.

Эрхардка аның бу сүзләре ошамады бугай, ул, начар ис сизгән кебек, борынын җыерды. Отто ул бистәгә агач материаллары әзерләү хәстәре белән барган иде. Анда бик көчле пилорама бар иде.

– Ялганлама, – диде Эрхард. – Мин сиңа ышанмыйм.

– Мәйлегез, әмма мин анда агач материаллары складында эшләдем.

– Туры юлдан бара беләсеңме? – Эрхард һаман җирәнүле кыяфәттә иде.

– Белермен шикелле.

– Ләкин мин ышанмыйм. Шулай да, әйдә, сынап карыйк.

– Мин шофёр буламмыни? – диде Отто, аңлап җитмичә.

Теге һаман сынап карап, теләр-теләмәс ияк какты. Оттоның кан тамырларында тагын утлы агым чабарга тотынды. Мастерскойда әллә берәр шымчысы аның теге начар детальне алыштырмаганын күзәтеп торганмы? Бу зобаниның күзәтчеләре бөтен җирдә дә бардыр. Юлда деталь сафтан чыккач, Оттоны гаепләргә фактик материал була. Шайтан алгыры! Моны каптырырга хыялланып, үзе килеп капты, ахрысы. Тизрәк берәр контр чара әмәлләргә кирәк.

– Син ризамы? – Эрхард тавышын күтәрде. Ул Оттоның каушавын, уйларының таралуын чамалады кебек.

– Юк, чөнки мастерскойда эш күп... – Отто эчке сиземләве белән тегенең психологиясен шәйләде. Әгәр «риза», дисә, ул аны алмаячак, чөнки Эрхард аңардан шикләнәчәк. Оттоның гөманы шулай да дөрескә чыкты бит.

– Әйдә, рульгә утыр, – диде Эрхард.

– Документларым үзем белән түгел, – дип, Отто үтенүле тавыш белән Эрхардка карады. Үзе, ялагайлану, сөенү галәмәте йөземә чыга күрмәсен дип, эчтән бөреште.

Теге ым кагып, таптанып торган шофёрына әйтте:

– Бар, мастерскойда аның урынына эшләп тор, – диде.

Отто шофёрны озата китте, үзе аңардан һаман төпченде: Эрхард ниндирәк адәм, нәрсә ярата, нәрсәне өнәми? Әмма шофёр су капкан кебек, «белмим»нән башка берни әйтмәде.

Ул тиз борылып килде. Килә-килешкә башыннан мең төрле уй йөгереп узды... Эрхардның фотосын Руталарда карап утырганда, ничек кыҗрап кызган иде бит ул: әгәр очратсам, бугазына ябышам да буып атам, дигән иде. Әмма сөйләү – бер нәрсә, конкрет эш бөтенләй икенче шул. Эш ансат бирелми, тиз генә башкарып булмый. Чынбарлык әкият түгел, үз башың хакында да уйлый башлыйсың. Эрхардның сакчысы да булырга тиеш. Ул кайдадыр яшеренеп күзәтә булыр. Барын да тәртип белән эшләргә кирәк. Берни белгертмәскә, беркатлылык күрсәтергә. Хәлиткеч һөҗүм әкренләп, җентекләп әзерләнә. Бернәрсәне дә истән чыгарырга, онытырга ярамый. Иң мөһиме – немец педантлыгы белән астан гына үз максатыңа юл арчырга...

Отто, кабина ишеген ачып, тиз генә сумкасын утыргыч астына куйды да, үзе дә менеп утырды. Өйдән портфель тоткан Эрхард, аның артыннан автомат аскан сакчы килеп чыкты.

– Мин сиңа ышанмыйм! – диде Эрхард, кабинага кереп утыргач.

Ул моны сынар өчен генә әйтә булыр дип, Отто каушамаска тырышты, ирен чите белән елмаеп кына куйды. Сакчы арткы утыргычта автомат көпшәсен аның калак сөягенә терәп диярлек якын тота иде. Әллә капкынга эләктемме, дигән уй йөгереп узды Оттоның башыннан... Ул куен кесәсеннән бер кечкенә катыргы кенәгә алып, Эрхардка сузды. Бу – оста эшчеләргә бирелә торган ИК (unabkömmlich – незаменимый – алыштыргысыз) карточкасы иде. Немецларда эшчеләрне тигезләү юк, табигый осталарны бик тиз аерып алалар һәм түләү дә югарырак була.

– Ышанычны моның белән генә яулап булмый, – диде Эрхард, җирәнгән төстә карточканы кире биреп. – Син моны, бәлки, ялагайланып алгансыңдыр.

– Андый гадәтем юк.

– Кызылларда нинди эштә эшләдең?

– Автослесарь идем. Тимергә политика кирәкми бит. Ә алар политика ярата...

– Руслар безгә басып керергә ниятләгән бит...

– Белмим. Ә нәрсәләре белән басып керсеннәр? Әнә Германия гаскәрләренә каршы тора алмыйлар ич...

Оттоның сүзләренә каршы Эрхард берни дә әйтмәде, чөнки кыш көне иң көчле гаскәрләре Сталинградта тар-мар ителгәч, немецларның кикриге шактый ук шиңә төшкән иде.

Машинаны кабызып, бер-ике минут эшләтеп торгач, кузгалып киттеләр. Виесите бистәсе ярыйсы ук ерак иде, караңгы төшкәндә генә барып җиттеләр. Эрхард гел ашыктырды, төнне бер дә яратмый икән. Ни өчен икәне аңлашыла инде. Жандармерия идарәсендә көтеп торганнар. «Яволь, яволь!» – дип, полицайлар Эрхардның бер алдына, бер артына төште. Менә власть адәм баласын нишләтә, дип уйлады Отто. Латышлар үз туган җирләрендә әллә кайдан килгән бер килмешәк алдында әнә ничек ләббәйкәләнә, аның олтырагы булырга тора. Нигә гаҗәпләнергә, ул үзе дә шундый түгелмени?!

Эрхардка югары каттан аерым бүлмә, ә боларга аста бер караңгы, сасы почмак бирделәр. Әмма әйбәт ашаттылар. Эрхард ике сәгать йоклап, ял итеп алды. Ярты төн авышкач, күрше йорт подвалындагы тоткыннардан сорау алырга төште.

Отто идәнгә, тәрәзә буена яткан иде, ләкин йоклый алмады, чөнки мотордагы теге үзе куйган, тиз ашала торган деталь сафтан чыгар дип коты алынып килде. Ярый, чыдады ул алка кебек божра. Отто машинасы янына чыкты, капотын ачып, аккумулятордан лампочка кабызды һәм теге детальне яңага алыштырып куйды. Шулчак теге подвалда хәтәр кычкырган, елаган тавышлар колагын ярып керде. Бигрәк тә хатын-кыз елаган аваз җанын уеп-уеп ала иде. Эрхард – власть кешесе, бурыч үтим дип юанадыр, ә менә полицайлар үз латышлары бит. Кереп яткач та, теге бичараларның ачыргаланган тавышлары колагыннан китми торды. Власть адәм балаларын әнә ничек утлы табага бастыра! Элек-электән шулай килгән. Яңа власть баш булып ала да үзенә ярамаганнарны кыра башлый.

Иртән аларны алып чыктылар. Берсе, кара чәчлесе, кояш ашаган аксыл гимнастёрка, галифе чалбардан, озын юка гәүдәле, битендә касмак-касмак кан оешып каткан, бер күзе имгәнгән, кыек карый иде. Нык кыйнаганнар. Полицайлар бик таза шул. Икенче тоткын җитү сары чәчле, уртача буйлы, ничектер укыганрак кеше төсле тоелды. Гимнастёркасы да алай ук иске түгел. Әллә комсоставтан микән? Ә хатын-кыз шундый юаш-күркәм йөзле, күз төпләре кара янып торса да, мөлаемлыгын җуймаган иде. Моңа кемнең кулы күтәрелә алды икән? Эрхард турында «ул хатын-кызларны аеруча күралмый» дигән сүз йөри иде. Әллә үзе кыйнаганмы? Полицайлар кыймыйчарак торган очракта, ул камчыны үз кулына ала икән дә, әле полицайга, әле тоткынга китереп суга икән...

Өчесенең дә кулларын артка каерып бәйләгәннәр. Кара чәчлесе ватык-сынык немец телендә:

– Хатынны калдырыгыз, ул гаепсез! Аның бер гаебе дә юк, аңлыйсызмы, сволочьлар! – дип кычкырды.

– Ул безне яшермәде, – дип, русча дәвам итте сары чәчлесе. – Без төнлә аның лапасына кереп качтык. Ул безне белмәде, күрмәде! Ишетәсезме? Кешеләрме сез, түгелме?!

– Безне тоткач кына күрдек без бу хатынны. Аның гаебе юк! Полицайлар, сез беләсез бит, безне, эзәрлекләп, сез куып керттегез ич ул хатынның утарына...

– Халуй-полицай, әйт аларга, син бит барысын да күреп тордың, безнең арттан куып килгәндә! Халуй, үзеңә типкән итекне ялаучы эт!

– Немецларга озакламый «крышка» булачак! Латышлар үз туганнарын кыра. Немецлар килә дә китә, сезгә бит биредә яшисе. Ник бер-берегезне сатасыз? Кызыллар килгәч, нәрсә дип җавап бирерсез?

– Без партизан түгел. Без – әсирлектән качкан солдатлар. Без Шталачка озатылырга тиеш! Бистәдә беркөнне үтерелгән немец интендантына безнең катнашыбыз юк! Юк!

Аның сүзләрен ишектән чыгып килүче Эрхард та ишетеп алды һәм өлкән полицайдан нидер сорады да кинәт кулын, өскә күтәреп, аска төшерде. «Юк итәргә и баста» дигән ишарә иде бу.

– Сез Митава перфекты начальнигы фон Медемның боерыгын белмисезмени? – дип кычкырды ул һәм кулын кабат югары күтәреп, түбән төшерде.

Полицайлар тоткыннарны, автомат көпшәләре белән төртә-төртә, тыкрыктан урам аркылы кырга таба алып китте. Эрхард белән сакчы машинага кереп утырды. Тоткыннар артыннан барырга кушылды.

Кырда җир кишәрлекләрен саргайган каудан белгертеп тора иде. Басудагы бер юлдан урманга таба киттеләр. Ул юка гына агачлык икән. Аны узгач, калкулык күренде. Барган саен, ул калкулыкның эче торф алыр өчен бик нык чокып керелгән булуы аңлашылды. Латвиядә карьер чокырлары бик күп. Немецлар кабер казып азапланмый, гүя, алар килүгә чокырларны махсус әзерләп куйганнар.

Тоткыннарны шул чокыр буена тезделәр. Полицайлар ыгы-зыгы килде. Өлкән полицай култык астына кыстырган катыргыны кулына алып җәйде дә укырга тотынды. Хөкем карары кыска иде: немец интендантын үтерүдә гаепләнүче ике партизан һәм партизаннарны яшереп ятучы хатын... перфект комиссары фон Медем боерыгы нигезендә атарга хөкем ителә...

Полицайлар эт кебек чәң-чәң өреп чабышырга тотынды, һәркайсы зур эш кырган кебек йөренде. Һәрберсе Эрхард алдында үзенең тырышлыгын, бирелгәнлеген күрсәтергә ашыга иде. Тоткыннарны йөзләре белән чокырга борып куйдылар. Шулчак Эрхард, җил-җил атлап, алар янына барды. Бишалты адым калгач, пистолетын чыгарып, кара чәчлегә төбәде. Тоткын нәкъ шул мәлдә артына борылып карады, пуля аның нәкъ йөзенә туры килгән сыман булды. Ул чокырга таба ыргылдымы, әллә пуля тиюдән сикереп куйдымы, Отто абайламый калды. Сары солдат исә нидер кычкырды һәм чокырга таба сөрлегеп бер адым атлады да юк булды. Шул минутта ук хатынның да ак кофтасы офыктан юкка чыкты...

Бик мөһим, зур эш башкарган кыяфәттә Эрхард машинага таба атлады. Берничә полицай мәетләр өстенә көрәк белән яр иште. Бер ишләре Эрхард тирәсендә чебиләр аналарына елышкан кебек бөтерелде. Һәрберсе аны мактап бер-ике сүз әйтүне мәртәбә саный иде. Эрхард бик күтәренке кәефле, ияген, борынын күккә чөйгән. Күз кырыйларында нечкә җеп төсле җыерчыклар, сары сөялле күз агы, бәбәкләре гүя яктылык белән өретелгән иде. Ул эчтән шатлана, әмма шуны тышка чыгарырга никтер уңайсызлана кебек тоелды. Моны ничек аңларга дип, үз-үзенә сорау бирде Отто. Димәк, кеше үтерү аңа рухи канәгатьлек бирә. Ә бит бу адәм заты өчен нормаль хәл түгел. Эрхард психологик яктан нормаль микән соң? Бу очракта аны нормаль дип әйтеп булмый. Әле иртән генә Эрхард йокысы туймаган кеше кебек сүлпән, боек иде. Хәзер ике йөз грамм коньяк кәгеп куйган сыман әнә ничек кәефләнеп алган...

Жандармериягә кайткач, арт ялаучылар аны, өскә алып менеп, бик шәп итеп

сыйлады. Кызылларда да начальниклар тирәсендә ялагайлар бик күп бөтерелә торган иде. Куштаннарны һәр төштә яраталар, шайтан алгыры!..

Эрхард алгы утыргычта юл буе газета укып кайтты. Бераз укый да канәгатьлек белән башын селки һәм рәхәт шатланып куя. Отто күз кырые белән генә чамалады: газетада Эрхардның рәсеме төшерелгән һәм аның турында мәкалә басылган икән. Билгеле, мактап язганнардыр. Түбәсе күккә тигән шикелле, Эрхардның кәефе үтә дә шәп иде. Бераз укый да, шатланып, газетага чиертеп ала һәм эчтән көлеп рәхәтлек кичерә. Аннан тагын укый, тагын, рәхәтлек тойгыларын тыеп кала алмыйча, эчтән кинәнә, башын як-якка чайкап ала... Ул мәкаләне ничәнче кат укый инде, һаман шатлык кичерүдән тыела алмый. Эчтәге шатлыгы артканнан-арта бара, ахрысы. Мактаганны шулчаклы ярата икән. Ватанга тугры хезмәт итә, Германиягә бик нык бирелгән, бөек Рейхның патриот улы, дип язганнардыр, мөгаен. Чынлап та, Эрхард үз иленең иминлеге, мул тормышы өчен фидакярләрчә хезмәт итәм дип ышанадыр инде. Шул ватаны хакына чит җирләрне басып алып, бу җирләрдә туып-үскән һәм аның гадел хуҗасы булган адәм балаларын үтереп йөрүен зур батырлыкка саныйдыр. Бу эшен ул Германия өчен генә түгел, ә Латвиянең үзе өчен дә башкарам дип беләдер. Кырыгынчы елда руслар килеп тә, Латвияне чит элементлардан тазартабыз, дип, халык исеменнән күп кенә латышларны Себергә озаткан иде. Барысы да халык исеменнән, шуңа аркаланып эшләнә. Эрхард та латышларга яхшылык эшлим, шуңа алар мине хөрмәт итә дип уйлый. Полицайлар аңа нинди генә ихтирам күрсәтмәде, чәчләре белән җир себерде. Син – бөек зат, дип мактый-мактый сыйладылар. Газетага шуларның берсе мәкалә язгандыр. Кешегә төрле яктан, син әйбәт, син акыллы, син – гали зат, дип, берөзлексез тукып торсыннар әле, аңа ничек ышанмыйсың?! Эрхардның да җаны бар лабаса, башта ул да мактауларга, бәлки, мыек астыннан елмаеп карагандыр, ләкин тора-бара, мин, чыннан да, аерым мөкәммәл зат икән дип ышана башлагандыр. Идоллар-потлар менә ничек барлыкка килә ул. Обывательгә исә табынырга пот булсын, власть булсын, шуңа аркаланып яшәргә баш исән булсын...

Оттоның уйлары арасына теге кара чәчле солдат та килеп кысылды. Ул бит Эрхард пулясы тигәнче үк алга иелеп ыргылды һәм пистолет аның башы тигезлегендә түгел иде. Шуңа күрә ул исән калган булырга да бик мөмкин. Полицайлар артык тырышмаган булса, билгеле. Тырышалар шул, шайтан алгыры!

Эрхард йортының капка төбендә аларны штаб йомышчысы көтеп тора иде. Унтершарфюрер машинадан төшүгә, ул, аякларын шалт-шолт китереп, честь бирде һәм аңа пакет сузды. Аны алганда, Эрхард тагын да ныграк кәпәренгән иде.

Отто утыргычта калган газетаны алып укырга тотынды. Чыннан да, анда унтершарфюрерны күккә чөеп мактап язганнар иде. «Тимер тәре» ордены белән бүләкләнгән... Чү, ул да бит Пруссиядән икән. Гердауэн шәһәрчегендә туып-үскән. Менә сиңа кирәк булса! Отто бит үзен дә шул шәһәрчектә туып-үстем дип әйтергә тиеш иде. Ничек әйтми калды әле, юкса бик шәп итеп кабасы булган...

...Эрхард Оттоны ошатты, кире мастерскойга җибәрмәде, үзенең шофёры итте. Берничә көннән ул Ригага врачларга сәламәтлеген тикшертергә барды. Үзен бик нык саклый торган адәм икән. Отто ул арада Ригадагы еврейлар геттосына китте. Шәһәрнең бер районындагы күпкатлы йортларны чәнечкеле

тимерчыбык белән уратып алганнар иде. Анда – күбесе хатын-кыз, бала-чага. Өсләренә карарга куркыныч – барысы да шыр сөяккә калган, шәүләләр кебек әкрен генә йөриләр. Ашарларына бирмиләр, бер җиргә чыгармыйлар. Отто шул шәүләләр арасыннан Рита белән улын эзләп йөрде. Ул аларның үткән ел тентү вакытында тотылып, карьерда Эрхард кулы белән атып үтерелүен Калнинь сүзләре буенча белә иде. Әмма җанында сакланып калган өмет чаткысы аңа һаман тынгы бирмәде. Аны бирегә шул чаткы алып та килде. Тик ул анда ник барганына үкенеп бетә алмады. Шундагы балаларның йөрәк өзгеч кыяфәтләре күз алдына килеп, Отто тәмам газапка чумды...

## XVIII

Ниһаять, Калнинь белән бергәләп эзли торгач, Отто Кларабы тапты. Ул бик нык үзгәргән, күз төпләрендә каз тәпие кебек җыерчыклар, авыз кырыйларында тирән сызыклар пәйда булган. Оттоны ул танымады. Гестапо кешесе дип бик курыкты. Отто аның куркуыннан көлеп җибәргәч кенә таныган кебек итте. Очрашу бик күңелсез булды. Клара елады да елады. Ул Рита белән Виктор турында теге вакытта ук ишеткән икән. Ританы үзе укыткан малайның әнисе барып, немецларга әйткәнен дә аңа җиткергәннәр. Ничек ул балага куллары күтәрелде икән, минем шуны һаман аңым кабул итә алмый, дия-дия яшь койды Клара. Добэледан бирегә качып килүчеләр байтак булган, шулардан сорашып белгәннәр...

Клара һаман Оттодан сагая иде. Текәлә дә күзенә карый, нидер сорамакчы була. Уңайсызлана, зарланудан тыела. Андрейның кайда икәнен дә син сорама, мин әйтмим, диде. Кыскасы, Кларабың Оттога элеккеге җылы мөнәсәбәте калмаган иде. Бу аның намусына тиде, һәм ул Кларага ачылды. Куркыныч адым ясады. Клара шаккатып калды. «Ничек ялгышмадың, адашмадың, каян акыл алдың?» – дип пышылдады, якын итеп, аның иңенә ябышты. «Башта иркәләндем, яшермим, – диде Отто, – Шачин атлы коммунист мине үзеннән ычкындырмады...» «Тукта, – диде Клара, – Андрей да шул фамилияне еш телгә ала иде...»

Алар озак аңлашты. Элеккеге якын кешеләр бер-берсен аңлый алмаслык дәрәҗәдә үзгәргән иде. Вөҗүдләре асты өскә килгән, бар элемтәләре өзелгән. Ә җанда кан саркып торган чи яра уелган. Ни генә сөйләшсәләр дә, шул яраларга килеп орыналар иде.

Ана өчен улы Радик язмышы да тоташ яра иде. «Килү белән, аны бик тәҗрибәле эсэсчылар үз кулларына алды, – диде Клара. – Бер тәҗрибәле кыз аша адаштырдылар, үз якларына аудардылар. Радик умырткасыз, сыер тизәге булып чыкты. Эсэсчылар аны партизан отрядларын ауларга йөрткән. Совет мәктәбендә тәрбияләнгән бит, ә кыланмышы бөтенләй акылга сыймый. Чын күңелдән сөйләшеп карадык, кызылларда дөреслек юк, үзегез дә ялганнан иза чигеп яшәдегез, дип кенә җибәрә иде. Андрей оккупантларның вакытлы гына булуын дәлилләп, исбатлап күрсәтә, ә ул, син гестаподан курыкмыйсың, дип, аны бүлдерә иде. Үзе кызмача була, эчеп килә иде. Андрей турында Радикның яшерен киңәшчесе Баурих нәрсәдер сизенгән булса кирәк. Әллә Радик ни булса да ычкындырганмы, чөнки Баурих аны бик еш эчертә-сыйлый иде. Безгә төн уртасында эсэсчылар бәреп керә, тентү уздыра. Өч мәртәбә шулай кабатланды. И-и, бу гынамы безнең күргәннәр?..

Андрей белән дә ниләр генә булып бетмәде! Ул немецлардан җыелган симулянтларны дәвалый торган больницада эшли иде. Агентлар СД белән

хезмәттәшлек итәргә кыстаган. Андрей, билгеле, баш тарткан. Шуннан үгез кебек таза пациентларны котыртып, Андрейны кыйнаталар. Бик белеп, фәкать бөер белән бавырына тибәләр икән. Өйгә китереп ташлаганда һушсыз иде. Көч-хәл белән үлемнән алып калдык. Өч айлап ятты. Ярый әле мин үзем эшли торган больницадан барысын да алып кайтып тордым. Әллә нинди түбәнлекләргә барырга туры килде. Шул мәлдә Андрейның астыртынлыгы ачылды. Ул, миңа әйтмичә, бер яралы НКВД политругын дәваларга йөргән икән. Төнлә китеп югала торган иде. Миңа әйтергә шикләнгән. Мине гестапо кулга алса, кыйнап, серне алулары мөмкин, янәсе. Шулай ир белән хатын бер-берсенә ышана алмый иде. Политрукның хәле начар, Андрей бара алмагач, миңа дәваларга туры килде. Канзафаров дигән егет. Казанныкы. Өзелер алдыннан әллә үлем исереклеге белән сөйләнде: «Намусым чиста түгел, – диде. – Утыз җиденче елда, халык дошманы дип, берничә кешене атарга туры килде. Ләкин алар намуслы кешеләр – бернинди дошман түгел иде. Безгә боерык булды – без башкардык һәм кулыбызны кеше канына буядык. Мин эчүгә сабыштым. Аракы бик әзгә генә тынычлык бирә иде... Менә шулар өчен җәза. Яраланып, бүленеп калдым... Бәлки, юри ташлап киткәннәрдер. Частьта минем бер абруем да калмады. Эчкәләгәч, боерыкны да төгәл үтәп булмый. Минем биографиядә казына башладылар, пычракларымны борыныма китереп төртеп иснәтергә тотындылар. Теге чакта кылган эшләремне гаепкә алдылар. Боерыкны үтәмәсәм дә, ул гөнаһлар өчен җавап бирергә кирәк иде... Ярый. Барысы да әйбәт, мин гөнаһларым өчен җәза алдым, тыныч күңел белән китәм...»

Бу кешенең язмышы Оттоны да тетрәтте... Гөнаһ, җәза турында үзе дә көнтөн уйлап йөри ул. Оккупантларга да җәза килер, җәзасыз калмаслар дигән уй аңа ышаныч бирә иде. Клара да шуны тукыды, шушы тиклем кан коючылар җәзасыз калмас дип нык ышана иде. Кеше каны җирдә ятмый...

Әнә Совет җәмгыятендә тәрбияләнгән кеше гөнаһ эшләр кылган да шуңа җәза көтеп яшәгән. Эчтән кичергән, тынычлык күрмәгән, ә менә шул гөнаһлары өчен җәза алгач, дөньядан чиста намус белән китүенә сөенә... Ә Эрхардның башына шундый уйлар килә микән? Әллә аның уйлау сәләтен бетергәннәрме? Кеше үтерү аңа берни тормый микәнни? Бу хәл адәм баласының табигатенә бөтенләй килешми бит. Аның психологиясенә ят, кире тәэсир генә ясый торган нәрсә. Ә Эрхардка уңай тәэсир итә. Пистолетын кешеләрнең күкрәгенә терәп ата, үтерә. Һәм шуннан соң бик нык кәефе күтәрелә, хәмер белән сыйланган халәткә керә. Нүжәли бу нормаль кеше? Ә менә Эрхардның нормаль түгеллеге көнкүрештә, шәхси мөнәсәбәтләрдә сизелми кебек. Болай ул ертлач, әшәке булырга тиеш иде. Әмма үзе бу үлчәмгә дә туры килми. Эрхард үз начальникларын бик ярата, дөресрәге, алардан бик курка кебек иде. Өстәгеләрнең һәр сүзе – аңа төп закон, яшәү чыганагы. Әллә начальниклардан нык куркудан бер тайпылышсыз үтергәнме ул партизаннарны? Аларны юк итмәсәм, минем үземне бетерәчәкләр дип уйлаганмы? Бу – иң уңайлы сәбәп. Элек-электән кешеләрне кыру өчен кулланылган...

Әмма кадрларның, бу очракта Эрхард ишеләрнең, шушы принципка һәрчак тугрылыгын ничек тәэмин итәләр соң? Адәм баласының бүген бер төрле булса, иртәгә икенче төрлегә әйләнүе ихтимал бит. Фикерләре дә, кәефе дә гел үзгәреп тора аның. Һәр кешенең шәхси мәнфәгате бар. Адәм баласы үзенең һәр эшенә шуны куша, ягъни шәхси мәнфәгате белән дә эш йөртә. Немец тәртипләренә буйсынмаган һәр кешене юк итүдә Эрхардның шәхси мәнфәгате бар микәнни? Бу галәмәтләрдән Эрхард шәхси файда күрәме? Әмма андый нәрсә сизелми.

Партизаннарны аткач, ул бик зур канәгатьлек кичерә. Монысы инде үзенә йөкләнгән бурычны үтәгәннән булсын ди. Тик моның белән генә кадрның идеологиягә тугрылыгын тәэмин итеп бетереп булмый. Ярый, начальниклардан куркудан кылсын да, ди, ул бу яман эшләрне. Ләкин адәм баласында мин-минлек тә бар, аны ничек канәгатьләндерәләр? Бүләкләр биреп торалар, шул мин-минлегенең нәфесен томалар өчен инде... Әмма кеше катлаулы, аңарда җан конфликты да туарга мөмкин. Әнә теге яралы политрукта туган шикелле. Юк, бу оккупантларда җан конфликты тумый, туа да алмый...

Беркөн тагын ерак шәһәрчек жандармериясенә бардылар. Эрхардтан башка эш итә алмыйлар, ахрысы. Бу айларда оккупантлар крестьяннардан икмәк, мал салымнары җыеп йөрде. Хәзер талау эшенә ныклап керештеләр. Эзлекле алып баралар. Таланган икмәк, хайваннарны Германиягә озатып кына торалар. Кайбер аңлырак крестьяннар властьларга каршылык күрсәткән. Менә шуларны полицайлар җыеп төрмәгә утырткан. Эрхард сорау ала һәм язмышларын хәл итә. Кайсын концлагерьга озатырга, кайсын юкка чыгарырга... Эрхард ике тәүлек буе сорау алды. Нерв киеренкелегенә чыдашлы түгел, шунлыктан ул да, полицайлар да эчә. Нык исергән килеш сорау алалар һәм кешеләрне вәхшиләрчә кыйныйлар. Эрхард, чыдый алмыйча, ике крестьянны атып үтергән... Аларны полицайлар, төнлә алып китеп, ниндидер карьер чокырына күмеп кайтты. Хәзер оккупантлар бар әшәкелекне яшертен эшли. Шәһәрләрдә төрле күңел ачу клублары ачкан булдылар. Барысы да әшәке эшләрен яшерү өчен, халыкның күзенә төтен җибәрү өчен иде, билгеле...

Бу юлы да Эрхард үзеннән бик канәгать кыяфәттә, дөрес, монысында ул яхшы ук кызмача иде. Ригада чыга торган «Твея» газетасын укый-укый кайтты. Укый-укый да авызын күтәреп көлеп ала. Аннан тагын газетага текәлә. Бераздан, башын артка ташлап, тагын шаркылдап ала...

Отто, машинаның фәлән җире сафтан чыкты, дип, Эрхардка ирештерде, ремонтларга рөхсәт алды. Ул аны үзе дә төзәтә алган булыр иде, ләкин Калниньны күрәсе бар иде. Шуңа күрә хәйлә корды. Оттога Калнинь аша Шачин сүзләре килеп ирешә: бу эшеңне хуплыйм, безне кызыксындырган кирәкле мәгълүматларны кулга төшерергә тырышырсың, дигән иде ул. Отто бер кечкенә пачка бланклар юнәтеп бирә алды. Башка эшләргә тотынырга кыюлыгы җитми иде әлегә. Эрхард һаман ышанмыйча карый, машинада үзе белән автоматлы сакчы йөртә иде. Дөрес, ул хәзер бераз йомшады шикелле. Хәер, төрле көнне төрлечә. Кемдер аңа телефоннан бүген ничек булырга кирәклеге хакында шылтыратып тора иде...

Машинаны рәтләп маташканда, Калнинь пышылдады: бүген фәлән-фәлән төшкә очрашырга барырга тиешсең, диде. Адресны кабатлады. Тукта, Клара яши торган йорт ич ул...

Отто, теш врачына барам, дип, начальниктан рөхсәт алды һәм елганың теге ягына юнәлде.

Йортны тиз тапты, кирәкле квартира икенче подъездда иде. Ярым караңгыда өченче катка күтәрелде, бераз тыңлап торды да шартлы сигнал буенча ишек шакыды. Тагын тыңлады. Тагын шакыды. Шунда ишеккә килгән аяк тавышы ишетелде. Һәм ишекнең бер каты ачылды да, ярыктан хатын-кыз тавышы «пороль» дип эндәште.

Бу Рута булып чыкты. Отто нишләптер аның тавышын танымады. Әллә тозакка эләктемме дип куркып калды. Эчке кесәсендә йөртә торган кечкенә пистолетын кулына тотып, эчкә атлады.

Ишекне япкач, Рута аңа таба борылды, прихожийда шәм яна иде, шуның тонык яктысында Оттоның куркып тартылган, шәмәйгән йөзен күреп елмайды.

Олы якка чыгып, палас җәйгән идәнгә утырдылар. Тәрәзә пәрдә белән ябылган, сыек кына яктылык төшә. Рута аякларын кырыйгарак куеп утырды, Отто кырын сузылды.

Башта Рута хәл-әхвәл сорашты. Оттога сынап карап торды. Аның шактый таушалган төксе йөзен күрде, күңеленә ышаныч билгеләре чыкты. Шикләре таралгандай булды, чөнки Оттоның бөтенләй үзгәрүе дә мөмкин иде бит. Ләкин Отто кәеф кешесе түгел икән, көн саен үзгәреп тормый, холык-фигыле нык, ышанычлы. Һаман элеккечә шикелле.

– Заданиене тыңла, – диде Рута. – Үзәк сатлыкҗан Ишкальнны юлдан алып ташларга карар чыгарды, чөнки, немецларга бирелеп, үз милләттәшләрен бик нык сата башлады. Оккупантлар салым җыйганда, крестьяннарны талаганда да үзен начар яктан күрсәтте. Балалы крестьяннарны да якламады. Кан-яшь түгеп, аягына тезләнделәр, шуларга да шәфкать күрсәтмәде... Ишкальнны немецлар кулы белән дөмектерергә, диелде. Ничек итеп? Аңа карата компромат әзерләргә, начальникларына төртергә... Барып җиттеме? – Отто, ияк кагып, аңлаганлыгын белгертте. – Компроматның эчтәлеге болай: фәлән җирдә партизаннарны тоткач, Эрхард сорау ала. Ике партизан да Ишкальн белән бәйле булуы турында сөйли. Немецларга каршы эшләгән эшләре хакында әйтеп бирә. Барып җиттеме? Син Эрхардтан пичәт, имза куелган буш бланклар кулга төшерәсең. Язуын килештереп язучылар табылыр. Мөмкин эшме бу, түгелме? Эрхардның сүзе тикшерелми, аңа ышаныч зур.

– Әйе, аның абруе зур, «алыштыргысыз» дигән карточкасы бар, – дип куйды Отто.

Рута моның нәрсә икәнен белә иде. Ияген генә какты. Отто да кызны аерым бер ымсыну белән күзәтә иде. Элеккеге вакытлар исенә төшеп китте. Ул вакытта ачуланышып, аңлашмый йөрүләр хәзер бары дусларча шаяру, яшьлек юләрлеге булып күренә. Кыз тулыланып киткән, пөхтәрәк киенгән. Әллә кияүгә чыкканмы, әллә берәрсенең мәгъшукасы булып торамы?..

– Монысы аңлашылды, – диде Рута. – Менә икенче задание. Эрхардны тизрәк дөмектерергә кирәк. Үзәк моңа бик зур әһәмият бирә. Ник икәнен әйтмичә дә беләсеңдер... – Рута, сүзен бетереп, Оттога карады. – Нигә эндәшмисең?

– Эрхард янында һәрвакыт сакчы, бер адым да калмый, – диде Отто. Һәм уйланып тора башлады. Шактый озак пауза булды. Отто телгә килде: – Әгәр мин Эрхардка финка белән кадасам, арттан автомат мине өзеп ташлаячак. Үземне дә, аны да бетерсәм генә инде. Задание шундыймы?

– Син нәрсә, Отто, ничек инде? Үзең исән калырга тиеш! Әгәр исән калырлыгың булмаса, тотынма! – Рута чын күңелдән Оттоны кайгырта иде.

– Тотынмасаң гаепләрләр, – дип куйды Отто.

– Шачин белән үзем сөйләшермен, синең башың ике түгел ич, аңларлар... Бүтән юл белән юк итү хакында уйларга кирәк булыр...

– Нинди юл тагын?

– Беткәнмени әмәлләр? Машинасына мина куярга, мәсәлән...

Рутаның сүзләреннән соң Отто тагын озак кына уйланып торды. Төрле вариантларны фикер бизмәненә куеп караганлыгы битендәге чак кына сизелерлек күләгәләр хәрәкәтеннән дә сизелә иде. Рута, кабат сүз башлап, аңа Ригадагы ике очрашу урынын әйтте.

Шуның белән әңгәмә тәмамланган кебек булды. Отто Шачин турында сорашты.

– Нишләп Стубе турында бер хәбәр дә юк, – диде.

– Аны концлагерьга озатканнар, – дип аңлатты Рута.

– Димәк, безнекеләрне сатмаган?

– Юк, бераз мәгълүматлар алганнар аңардан, – диде Рута. – Ситуацияне анализлагач, Шачин шундый нәтиҗәгә килгән...

Рута кухняга чыгып китте, анда шактый торып, керосинкада кофе кайнатып алып керде. Палас өстенә газета җәеп, чәйнекне, стаканнарны урнаштырды. Отто сумкасыннан тушёнка чыгарды, аны пәке белән ачты да уртага куйды. Ләкин ипи юк иде. Кофены тушёнка капкалап эчтеләр...

Кыз эшеннән зарланды. Яшь сыгып та алды. Оттодан ярдәм сорады, җайлырак эшкә урнаштыр, дип үтенде. Немецлар хәзер җиңәчәкләренә үзләре дә ышанмый, диде. Бу инде сер түгел. Отто кызга ярдәм итәргә теләвен әйтте...

Инде кич булып, караңгы төшеп килә иде. Ут элдереп тормадылар. Рута ниндидер ым белән «кунып кит» дигән ишарә ясаган кебек булды. Отто, кыз әйтмәсә дә, кунарга уйлап тора иде.

Рута чәйнек, стаканнарны газетага төреп алды да кухняга чыгарып куйды. Отто, аягөсте басып, күн тужуркасын салып тора иде. Рута килде дә, аның күкрәгенә башын куеп, ике беләге белән муеныннан кочаклап алды. Оттоның тәне буйлап электр тогы узган кебек булды. Аның бу кызга күптән күңеле тартыла иде, ул Рута хакында еш кына уйлана иде. Нилектән – үзе дә тәгаен генә белми. Шушындый куркыныч чорда бер җепкә бәйләнгән булудандыр, ахрысы. Отто кызны диванга таба этте.

Рута чишенгәндә, ул аңа карамаска тырышты. Кыз чырт-чырт итеп үзенең каптырмаларын ычкындыра, юка целлюлоз оекларын ботыннан ниндидер тансык кыштырдау тавышы чыгарып шудырып төшерә. Кара нинди кадерле кыштырдаулар, нинди күркәм, күңелгә якын икән. Аның чигәсенә йөрәк тибеше кечкенә чүкеч белән гүя суккалап тора башлады. Отто үзенә үзе аптырады: аңарда мондый хисләр ничек саклана алган соң? Ул бит упкын кырыеннан кыл өстендә йөри. Үзендә бернинди кешечә тойгылар калмагандыр дип уйлый иде. Отто кыз янына килде, аның биленнән кочып алды. Кыз, ут кебек кайнарланып, ялкын бөркеп тора иде. Ул шул ялкынга омтылды...

Башка чара юк, ахрысы, дип уй йөртте Отто. Эрхардны һәр адымда сакчысы каравыллап тора. Димәк, ул вәхшине бетергән очракта аның үзенә дә бетәргә туры килә. Ярар, шулай булсын, бу мәхшәр эчендә, канга буялып йөри-йөри, яшәүдән, кешеләрдән җаны тәмам бизде. Кешеләр бер-берсен уздырыштан сата. Шуның белән дан казана, үзләренең тормышларын кора, гаиләләрен тәэмин итә. Властьлар кешеләрнең шул йомшаклыгыннан оста файдалана. Шуңа гына исәп тота. Адәм балалары бер-берсен сатмаса, властьлар яши алмас иде... Әйе, башка әмәл табып булмас, ахрысы, кызыллар килгәч, аңа барыбер көн булмаячак, оккупантларга эшләгәнсең, дип гаепләячәкләр, Себергә озатачаклар. Шуңа күрә Эрхард белән бергә бетү хәерле булачак. Ә нәрсә җәлләргә? Җәлләрлек берни дә юк. Абыйсы белән апасы яшәячәк. Беркөн генә Калнинь аларда булып кайтты. Әйбәтләр әле, ди. Үзләрендә немец начальниклары тора икән. Оттоны эзләп, гестаподан өч мәртәбә килгәннәр, ди... Аның өчен хәзер җан асрауның бер мәгънәсе дә калмады. Иң яхшысы, бер тирән карьер чокыры яныннан үткәндә, кинәт кенә машинаны ярга таба борырга да түбәнгә мәтәлергә и бетте! Берсе дә исән кала алмый. Болай эшләү упкынга бик якын юлдан үткәндә генә мөмкин. Оттоның ни эшләргә теләгәнен тегеләр белеп өлгергәнче, җәһәннәмгә очарга. Сизенсәләр, аңа атарга өлгерерләр, һәм бар эш бозылыр.

Әйе, ул соңгы чиккә җитте бугай. Руслар килгәч, аны аяу булмаячак. Шачин якламасмы? Ул әллә исән кала, әллә юк. Икенче җиргә күчереп куюлары да бар. Аннары бөтенләй бетәргә генә кала. Немецларга каршы кылган гамәлләреңне беркем белми, шаһитлар юк. Оккупантлар кушкан эштә эшләгәнне күпләр күреп тора. Шаһитлар күп табылыр. Шуңа адәм баласының бер-берсенә бүре кебек каравын һәм сатуын кушсаң, бөтенләй рәт бетә. Кызыллар килгәч, күп кан коячаклар әле. Оттоларны түгел, әнә революция ясаган, Кышкы сарайны штурмлап алган латыш укчыларының кайберләрен дә Сталин аттырган. Белгән кешеләр хәзер астан гына сөйли, бер гаепләре дә юк иде, дип... Кычкырып әйтергә куркалар... Нәрсә ул үзен жәлләп тора, ичмаса, латыш җирен бер канечкеч палачтан коткарыр. Эрхард бетсә, аның урынына бүтәне килерме? Юк, Эрхард кебек үк явыз палач бүтән булмас. Һәр кеше дә палач булырга сәләтле түгел. Түгел! Аннары Отто үзен намус газапларыннан коткарачак. Бу тиклем рухи бөлгенлектә яшәү башкача мөмкинме? Ул бит тәмам череп таркалган хәлгә калды. Эчендә бер таянычы юк. Кешедә эчке таяныч булмаса, ул бетә инде. Оттоның барча таянычлары чәлпәрәмә килгән. Аны җыю, кабат төзәтү мөмкин түгел...

Отто очрашуга шундый кәеф белән килде. Кызылларның җиңүе көн кебек ачык, Шачин белән шул хакта сөйләшергә, аңлашырга кирәк. Аларны немецларга эшләделәр дип гаепләячәкләр. Шачин нинди гарантия бирә? Ул бит Үзәк кешесе, белергә тиеш. Нинди дер чара-таяныч булуы зарури...

Шачинны күреп, күңелен һәрчак кырып, борчып торган мәсьәләләргә ачыклык кертергә өметләнеп килгәч, анда, һич көтмәгәнгә, Рутаның гына булуы Оттоның бераз кәефен җибәрде. Ләкин сөйләшә-аңлаша торгач, ике арада җылы мөнәсәбәт урнаша башлады. Баштагы кәефсезлек ниндидер мөлаемлык, самимилек белән алмашына барды. Рутаның да җан сызлаулары Оттоныкы кебек иде. Киләчәк турындагы билгесезлек тә эчен нык пошыра икән. Ул, Шачин белән конкрет сөйләшеп, ниндидер гарантия таләп итәчәген әйтте. Уртак бәла кешеләрне тиз якынайта шул. Кискен шартларда бигрәк тә. Һәм үзендә әле дә кешечә хисләр сакланып калуына янә аптырады ул, Рутаның берни сиздермичә, басым ясамыйча, шул хисләр дөньясына алып керүенә бик тә сөенде. Бу исә кызның уңганлыгын, аңарда хатын-кыз мутлыгы булуын күрсәтә иде. Аның үзен жәлләмәвен, күңел юмартлыгын бәяләми һич мөмкин түгел. Менә ичмаса чын, эчкерсез хатын-кыз дип сокланды Отто. Юк, ул Рита белән улын бер минутка да исеннән чыгармады. Шулай да бу киртә Рута хисләренә җавап бирергә комачауламады. Ситуация башка, Рута үзе дә бүтән, Отто белән бер чылбырга бәйләнгән кеше...

Кичә генә ул дөньядан тәмам бизгән, яшисе килми иде. Ә Рута янында төн уздырганнан соң, гаҗәп хәл, бөтенләй үзгәреп китте. Аңа яшисе килү теләге кабат кайткан кебек булды. Тормыш белән ике арадагы рухи конфликт йомшарган, кискенлеген җуйган иде...

Машина ремонтланып беткән иде. Отто аны кабызды да Эрхард йортына килде. Каршы алырга, гадәттә, сакчы чыга торган иде, бу юлы никтер күренмәде. Нәрсә булды икән? Парадный ишектән керүгә, аның каршысына хезмәтче хатын килеп басты. Эрхардны иртәнге биштә комиссариатка алып киткәннәр. Ниндидер яшерен киңәшмә диме шунда... Ә Отто Эрнаны базарга алып барып кайтырга тиеш булып чыкты. «Миңа нәрсә, баш өсте, – диде Отто. – Эрхард ачуланмасмы соң?» Хезмәтче хатын, «юк» дигәнне белгертеп, ым какты. Ул арада өске кат баскычыннан Эрнаның төшеп килгәне күренде. Бик

модалы итеп киенгән, шоколад төсендәге йөзе, миндаль күзләре, сыгылмалы фигурасы аны бик тәэсирле итә иде.

Эрна арткы утыргычка кереп утыру белән, сөйләнергә, куштанланырга тотынды. «Мин сине күптән күзәтеп киләм, син әйбәткә охшыйсың», – диде ул, Оттога елмая-елмая. Аннары үзе турында да ачылды. Эрнаның бабалары шушы Митавада банк тоткан. Хәзер өлкә комиссариаты урнашкан бина аларныкы булган. Ләкин күп тә үтми, бу банкны Кёнигсбергтагы зур банк йоткан. Банклары бөлеп калган. Бераздан дөньялар үзгәргән. Латвия мөстәкыйль дәүләткә әйләнгәч, банк бинасы тагын аларга тиеш булып чыккан. Ә ул – бердәнбер варис, хәзер шул бинаны үз исеменә яздырырга йөри, аңа Эрхард та булыша икән. Әмма фронтта эшләрнең начарланып китүе варислык мәсьәләсен читкәрәк этәргән. Эрхард та аңа сабыр итеп торырга кушкан...

«Фронтта эшләр начарланды» дигән чакта Эрна Оттоның йөзенә, кыяфәтенә нык текәлеп торды. Отто моны сизде һәм төсенә берни чыгармаска тырышты. Бу хатын аны сүз саен сыный иде. Оттоны мактап алуы да шуңардан, билгеле. Хезмәтче хатынның да аны күзәткәне, сынаганы сизелә иде. Эрна да, сиздермәскә тырышып, читтән-читтән генә һаман аны сынап утыра. Немецларда шулай бер-берсен күзәтү хәрби һәм цивиль закон итеп кертелгән, ди. Отто немецлар белән бәйләнешкә кергәннән бирле моны күп сынады һәм бу хакта хәзер икеләнми иде. Ул һәрчак энә өстендә утырды.

Эрна базарда байтак йөрде. Ике сумка тутырып яшелчә, алмалар алган иде.

– Эрхардны вегетарианлыкка күнектермәкче булам, – дип аклангандай әйтеп куйды ул, ташкабакларны башка букчага җайлый-җайлый. – Ә ул һаман, erткыч кебек, иткә тартыла. Бер-ике көн генә яшелчә белән тора да аннары ит таләп итә. Ул әйттеме – бетте, үзенекен эшләми туктамый, кырыс холкын син дә үзеңдә татыгансыңдыр...

– Буйсындыручылар өчен гадәти хәл, – диде Отто.

– Ул үз персонажыннан башка беркемне танымый, – дип куйды Эрна, алгы утыргычта матур аякларын чалмаштырып утырып.

Отто аның сүзләреннән сагая калды, ни өчен әле ул Эрхардны яманлый? Аның да үзенә кушылып нидер ычкындыруына исәп тотамы? Отто аның сүзләрен колак артыннан гына уздырып җибәрде.

– Хәтта мине хатын-кыз буларак та танырга теләми, – дип дәвам итте Эрна. – Үз-үзен культка әйләндергән, шул культка табынып яши, ягъни үзенә һәм фюрерга гына табына. Вегетариан булырга теләве дә фюрерга иярүдән...

Эрна, бу сүзләрен әйткәндә, тагын Оттоның йөзен күзәтте. Нигә миңа шундый сүзләр сөйли икән бу, дип пошынды Отто, әллә провокация ясау максатыннан шулай эшлиме?

Кайтып җитәрәк, Эрна тагын да гаҗәпкә калдырды.

– Сине күптән күзәтәм, – диде ул. – Син әйбәт ир булырга охшыйсың. Әмма кызыллар сине бозмадымы икән?

– Мин алар белән аралашырга өлгермәдем, – диде Отто, бик ышандыргыч төстә.

– Ир-атның бар нәрсәсе тышта, шуңа аларны чамаларга була, ә хатын-кызның бар нәрсәсе эчтә...

– Бәлки, шулайдыр, – дип елмайды Отто. Бу чибәр хатын янында җансыз таш та елмаймый түзмәс иде дигән уй килде аңа. Шулай итмичә ярамый, Эрнада ничек тә ышаныч уятырга кирәк иде. Хуҗаның этенә дә елмаерга куша ачы тәҗрибә.

– Без аулакта очраша алабыз, – диде Эрна.

Отто, аны шаярта дип белеп, борылып карады, әмма хатынның йөзе җитди иде. Монысы тагын нәрсә? Аны капкынга эләктерергә исәплиме? Отто җавап бирмәде, хатынның сүзләрен шаяру дип кабул иткәнен белгерткән кыяфәт чыгарды.

– Мин чынлап әйтәм, – дип, Эрна озын керфекләрен сирпеп карап алды.

– Эрхард мине атып үтерер.

– Юк, белсә дә, рәхмәт кенә әйтер, ә без аңа белгертмәбез...

– Зинһар, мине андый кырын эшкә тартмагыз, мин Эрхардка хыянәт итә алмыйм. Аңа хыянәт итүне үземә түбәнлек саныйм! – Оттоның сүзләре катгый һәм каршы килмәслек тон белән чыкты. Бәлки, болай ук кырт кисеп баш тарту дөрес тә булмагандыр, һәрхәлдә, ничектер билгесезрәк, томанлырак итеп әйтергә кирәк иде. Отто моны соңрак аңлады, ләкин сүзне кире кайтарып алып булмый иде инде. Шул мәлдә хатын аны нindидер яшертен эшкә ялларга ниятләгән шикелле тоелды. Ә Эрхардка хыянәт итмәү турында дөрес әйтте ул. Эрна моны аңа, һичшиксез, җиткерәчәк.

Машинаны гаражга куйганда, Оттога бер уй килде: әллә Эрна белән, чыннан да, очрашып карargaмы икән, ул бит өлкә штабы тирәсендә чуала. Бәлки, берәр сер ычкындырып ташлар? Шачин моңа нәрсә дияр иде икән? Ләкин аны күрү хәзер мөмкин түгел. Немецлар җәза эшен бик нык көчәйтте. Җирле милләтчеләр дә активлашты, үзләренең туганнарын саталар...

Сәер хәл: немецлар ничек итеп үз кадрларында кеше үтерү теләген даими булдырып тора ала? Оккупантлар моңа ничек ирешә? Куркыту ашамы? Әйе, куркыту бик көчле аларда. Гестаподан дер калтырап торалар. Ә тагын нинди механизм кулланалар? Куркыту гына җитмидер, адәм баласы хәрәмләшә, өстән кушкан боерыкка, идеягә тугры гына кала алмый. Монда исә шымчылык хәрәкәткә килә. Немецларда һәркем күзәтү астында тотыла. Шымчылар өстеннән дә шымчылар куелган. Эрна, мөгаен, Эрхардка шымчы итеп җибәрелгән. Эрхард үз нәүбәтендә Эрнага шымчы ролендә булырга тиеш. Отто да үзен күзәтүләрен һәрвакыт сизеп, күреп тора.

Тагын ни белән кадрларның тугрылыгын тәэмин итәләр? Аларның хайвани инстинктларын канәгатьләндерепме? Төрле күңел ачу йортлары ачып, начальникларга кәнизәкләр тотарга рөхсәт бирепме? Бусы да шактый киң кулланыла. Аннары бүләкләү ысулы көчле стимул булып тора. Әнә Эрхардны бүләкләп кенә торалар. Эрна исә аны бик тәрбияле, һәр көйсезләнүен, тискәрелеген тизрәк төзәтергә ашыга.

Беркөнне Огре шәһәрчегенә жандармериясенә барганнар иде. Әмма анда Эрхардка эш булмады. Полицайлар бер генә партизанны да, салым түләгәндә властьларга каршылык күрсәткән бер генә крестьянны да тотып китермәгәннәр. Эрхард пистолетын эшкә җигә алмады. Әй ачуланды, әй күперенде. Тиресеннән чыгарлык дәрәҗәдә ярсыды. Полицайларны аерым-аерым тиргәп чыкты. Борын төпләрендә пистолетын болгый-болгый мыскыллады. Куркаклар, дип атады, фюрерга тугры булмауда гаепләде. Эрхардның артын яларга торган полицайлар аны сыйпап йомшартмакчы булды. Әмма Эрхард ул җимгә капмады, ачуланып, янап чыгып китте.

Юл буе ул хәтәр бүртенеп, күперенеп, беркемгә дә күтәрелеп карамыйча гына кайтты. Өйдә, ул ишектән керүгә, аның кәефе кырылганын сизделәр һәм кәефен күтәрергә теләп йөгерешә башладылар. Нервларын җан кыю белән тынычландырырга күнеккән Эрхард бүген, корбаннар булмагач, тәмам

чыгырдан чыккан иде. Бу хәл аның психологиясенә каты суккан булырга тиеш. Билгеле шартларда адәм баласы кан коюдан канәгатьлек, күңеленә тынычлык таба икән... Менә ул нинди хәлгә җиткән... Палач хезмәтен үтәүчеләр дә шулай була торгандыр. Һәр хезмәт кешедә үзенең мөһерен калдыра шул... Ике хатын-кыз Эрхардның итекләрен салдырды, йомшак башмаклар кигезде, үзләре иркәләп-назлап сөйләнә иде. Шулай юмалый-юмалый, аны өске кат баскычыннан алып менеп киттеләр...

Кухняда эшләүче яшьрәк хатын Оттога һәрчак ягымлы һәм хәерхаһ карый иде. Эрхард менеп киткәч, ул Отто янына килде дә, җиңеннән тартып, заговорчы төсле, күз кыскалады. Аны урындыкка утыртты, алдына бер чынаяк кофе китереп куйды. Отто, рәхмәт әйтеп, кофены уртлап-уртлап алды. Хатын тагын ияге белән өскә ымлап күрсәтте, аңа итеген салырга, башмак кияргә ишарәләде. Отто монысына да күнде. Хатын аны, җиңеннән тотып, веранданың караңгы хутыннан өске катка алып менеп китте. Шыпырт кына бер почмакка килеп бастылар да алга карадылар. Пәрдә ябылмый калган төштән яп-якты итеп яктыртылган зур гына бүлмә эче күренде. Анда, бүлмәнең ишек ягында, өстәл тора, кәнәфидә исә Эрхард җәелеп утыра иде. Өстәлгә озынча ак чынаяк белән кофе һәм бер шешә коньяк куелган. Эрхард башта чәшкесенә кофе агыза һәм шуңа коньяк өсти, шуны кинәнә-кинәнә йоткалап ала. Үзе ни өчендер күзлек кигән. Юкса ул үрәкарау түгел иде шикелле. Егерме метрдан кешеләрнең нәкъ баш лепкәсенә туры тидерә иде. Менә эчке бүлмәдән озын зәңгәр халат кигән Эрна килеп чыкты. Тәрәзә буендагы радиоланы кабызып җибәрде. Бик йомшак музыка агыла башлады. Отто аны таныды, бу мәшһүр «Төрек маршы» иде. Гаҗәп моңсу көй. Шул көй ритмына буйсынып, Эрна иң элек халатын салып урындыкка куйды. Ул сөттәй ак пляж костюмыннан калды. Көй уңаена тыйнак кына аякларын, тезләрен биеткәләде. Шоколад төсендәге аяклары төз һәм матур иде. Эрна музыка көенә ныграк буйсына барды, шул көй уңаена бюстгальтерын ычкындырды һәм бөтенләй салып ташлады. Хатынның күкрәкләрен дә кояш ашаган, алар яңа гына төртеп чыккан гөмбәләр төсле тыгыз һәм тураеп тора иде. Шул килеш Эрна тезләрен, күкрәкләрен биеткәләп юанды. Кыскасы, хатын, шул рәвешле, Эрхардның күңелен күрергә тырыша, бар байлыкларын тәкъдим итә иде. Менә ул ак тешләрен күрсәтеп елмайды да ак трусигын сала башлады. Эрхард исә, берни булмаган кебек, кофесына коньяк өстәп маташа иде. Күзләре Эрнада, ә кулы авызына китерә дә, әз генә уртлап куйгач, аны кире өстәл өстенә куя. Эрна, трусигын тәмам шудырып төшереп, кулына тотты да арты белән борылды. Аның аркасы, очасы да кырып ясалган кебек дөрес һәм матур иде. Ул көй ритмына бераз гына биләнеп, аякларын биетеп торды да бюстгальтерын кире киеп куйды, озаклап шыртлавыкларын каптырды. Аннары салмак хәрәкәтләр белән трусигын кияргә кереште. Башта бер аягын күтәреп эләктерде, тезенә чаклы китергәч, икенче аягына киде һәм югары тартып менгерде. Үрелеп халатын алды, йөзе белән Эрхардка борылды, тагын да ымсындыргыч итеп елмайды. Эрхардка таба сузылыбрак, нәрсәдер көтте, елмаеп карап торды. Әмма Эрхард, берни булмаган, күрмәгән кебек, кофелы коньягын уртлый-уртлый утыра бирде. Ул Эрнаның хәрәкәтләренә берничек тә җавап бирмәде, кәефе килгәнме-юкмы икәнен дә белерлек түгел иде. Ул инде, бәлки, исереп тә беткән булгандыр. Хәзер, Эрхард бүтән вакытта да хатын-кызларга бер дә дикъкать итми иде. Отто моны әллә ничә мәртәбә үзе сынады. Аңарда хатын-кызларга карата нindидер яшерен үч бар иде кебек. Полицайлар тотып китергән хатын-кызлардан сорау алганда,

Эрхард аеруча кансыз кылана иде. Нәрсәдән бу, дип, Отто гел аптырады. Менә хәзер дә аптырашта иде ул. Эрна, Эрхардка таба иеләтөшеп, елмаеп торды, бик ымсынып, нидер көтте. Ләкин тегенең тарафыннан бернинди игътибар булмагач, халатын эләктерде дә эчке бүлмәгә таба юнәлде...

Нинди иблис бу Эрхард, дип, уйга калды Отто. Ул арада хезмәтче хатын аның җиңеннән тартты. Алар шыпырт кына баскычтан аска төшеп китте. Керогазында су кайнап торган икән, хатын тиз генә кофе кайнатты һәм чынаякларга бүлде.

– Күрдеңме? – дип пышылдады ул, күз агын ялт-йолт китергәләп. – Эрхард Эрнаның ятагына бармый, янына ятмый. Белдеңме? Эрна шуңа күрә нишләргә белми үрсәләнә. Әллә Эрхардның рәте юкмы икән, ә?

– Белмим, нишләп миннән сорыйсың?

– Ир-ат ир-атны яхшырак beләдер инде...

– Әйтә алмыйм.

– Син аның серен ачарга теләмисеңме?

– Нинди сер? Мин берни дә белмим, – диде Отто.

– Ник ул Эрнага битараф икән соң? Сәбәп нәрсәдә?

Отто ни әйтергә белмәде, тынып калды. Авыз белән өстәл арасында чынаяклар гына хәрәкәтләнде.

– Эрна аның кеме соң? – дип кызыксынды Отто.

– Эрхард ишеләргә кәнизәк тиеш икән. Начальниклары боерган, Ригадан ияреп кайткан иде.

– Эрхард бит үгез кебек таза.

– Әйе, ләкин Эрна ятагына ятмый. Нәрсә кирәктер инде? Эрна шуңа бик борчыла...

– Нәрсәдер бар монда, – дигән булды Отто, ул палач турында кешечә фикер йөртүдән тыйлыгып һәм шуны сиздермәскә тырышып.

– Ярый, бар, – дип, хатын кабалана-кабалана, урыныннан кузгалды. – Хәзер кыңгырау шылтырар... – Оттога бу серне белгерткән өчен, ул үзе дә шөлләгән шикелле иде. Шуңа күрә Отто тиз-тиз итекләрен киде дә чыгып китте.

Эрхардның шундый сәер ягы ачылуын ул тыныч кабул итте, чөнки аның бер гаепсез кешеләрне атып, үтереп йөрүеннән үзенә берни дә булмавына гаять дәрәҗәдә гаҗәпләнә иде. Ничек инде, ул кешеләр канын коя, әмма бер җәза да алмый. Бу бит коточкыч гаделсезлек, моңа табигатьме, башка көчләрме җәза бирергә тиеш дип ышана иде Отто. Кан коюжирдә җәзасыз калырга тиеш түгел... Кан бит үзе генә дә кешегә бик нык тәэсир итә. Кешегә генә түгел, хайваннарга да. Мал чалган җирдә, кан исен сизеп, сыерларның хәтәр үкерешкәннәрен дә күзәтергә туры килгәне булды аның. Кан исе хайваннарны да котыру халәтенә китерә. Эрхард кеше канына битараф кала ала микәнни? Ничек итеп? Әллә аңарда адәм затына хас тойгылар бөтенләй юкмы? Әллә үз-үзен мәҗбүр итеп тыямы ул тойгыларын? Ничек кенә булмасын, кешенең җанын кыю аның психологиясендә эз калдырырга тиеш. Эрхард автомат дәрәҗәсендә боерык үтәргә күнектерелгән булса да, җаны бар ич әле аның. Ми тартмасы да бөтенләй үк үлмәгәндер. Ничек аның башында бер сорау да тумый икән? Адәм баласы бит сораулар белән туа. Эрхард кебекләр үзләрен тулысынча хаклы итеп саный, күрәсең. Газетларга да язалар: без тарихның канлы, пычрак эшен башкарабыз, кан коюдан курыкмагыз, диләр. Эрхард, шул котырган фюрер сүзләрен чынга алып, шуңа тугрылыклы булырга тырышамы? Билгеле, шулай. Ул бик кирәкле, җаваплы эш башкарам дип уйлый инде. Аңа

аз гына вакытка булса да аек акыл килми микәнни? Бер гаепсез балаларны юк итүне ничек башка сыйдырырга һәм акларга мөмкин? Моның өчен бөтенләй башсыз булырга кирәк. Фашистлар үз кадрларын шултиклем җансыз автоматка ничек әйләндергән? Хуш, аларны үлем куркынычы астында тоталар, шуңа адәмнең боерык үтәүдән башка чарасы калмасын да ди. Ләкин үлем куркынычы алай нык тәэсир итмәгән очраклар да була ич. Ул чагында нәрсә? Фюрерга сукырларча табынумы? Фюрер әйтте – бетте, закон, ул тикшерелми, бары үтәлә генә. Бер гаепсез җирле халыкны гаммәви төстә кырганда, «нигә», «ни өчен» дигән сорау туарга тиеш. Тумыйча кала алмый. Әллә бу эшнең зарурилыгы бармы соң дип уйларга куркамы немец солдатлары? Ләкин аларны куркак? дип әйтеп буламы? Күпме кешеләрне нахакка үтерәләр, барысы да тоташ ерткычлар түгелдер бит инде?

Хезмәтче хатынның «әллә Эрхардның ирлегенә хилафлык килгәнме» дип шикләнүе бер дә нигезсез түгелдер. Хикмәт нәрсәдә булырга мөмкин? Әллә табигать эшеме бу? Табигатьтә дә үз-үзен саклау, үз-үзен яңарту галәмәте бар. Мәсәлән, агач үзенең төп кәүсәсен саклап калыр өчен кайбер ботакларына кирәкле матдәләр бирүне туктата һәм ул ботак корый. Биредә дә шуңа охшашрак бер хикмәт түгелме? Кеше канын кою Эрхард психологиясенә начар тәэсир итәдер, моны ул үзе дә аңлап җиткермәскә мөмкин. Шул кире тәэсир аның берәр әгъзасын зәгыйфьләндерүгә китерсә, нәрсәсе гаҗәп? Кайбер кешеләр кан күргән чакта һушларын да җуя ич. Табигатькә каршы барсаң, ул сиңа җәза бирә дигән фикерне дә кайдандыр укыганы бар. Менә, шул рәвешле, Эрхардка да табигать үзе җәза бирмәдеме икән? Бик ихтимал бит бу!

Тагын бер гаҗәп хәл: Эрнаның шәрә тәне Оттога никтер бер дә тәэсир итмәде. Бу оккупантларга тәмам каны каткан икән. Ул нәфрәтнең чәнечкеле чыбыгын бернинди матурлык та үтеп чыга алырлык түгел. Оккупантларда кешечә сыйфатлар юктыр да анысы. Ә бит кешечә кыланырга маташалар. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәттә булса да! Инстинктлары сүнмәгән, шуны канәгатьләндермәкче булалар. Ә соң кеше үтерү инстинкты каян килгән? Чыннан да, немецларда культура дигән нәрсә тышкы юка кабык эчендә генә булган. Котырган фюрер үзенең канечкеч идеяләре белән ул «кабык»ны бик тиз салып ташлаттырган булырга тиеш. Кешедәге борынгыдан килгән һәм томаланып торган ерткычлык инстинкты бәреп чыккан һәм үзенең ерткычлыкларын кыла башлаган. Адәмнең эчендә ерткыч утыра бит. Менә шул ерткычның кулларын котырган фюрер чишеп җибәргән. Гыйфрит шешә эченнән чыгарылган, хәзер аны тиз генә элеккеге урынына кертә алмыйсың. Аңардан физик юк итеп кенә котылырга мөмкин. Мөгаен, бүтән чара юктыр...

Калнинь яңа хәбәрләр китерде: Курск дугасында моңарчы күрелмәгән бәрелеш булган, ике яктан да бишәр йөз танк кара-каршы килеп сугышкан. Күп кан коелган. Немецларны чигенергә мәҗбүр иткәннәр. Сталинградтан соң бу аларның иң зур җиңелүе булган. Һаман да артка тәгәриләр, ди. Димәк, көчләре сүрелә бара. Шулай булырга тиеш тә иде ул.

Икенче хәбәр Оттоны уйга калдырды. Эш шунда: Калнинь белән Оттоны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләү турында СССР Югары Советының Указы «Известия» газетасында басылып чыккан. Латвия Компартиясе Үзәк комитеты тәкъдим иткән булган, дип аңлатты Калнинь. Башта Отто моңа һич тә ышана алмады. Икенче көнне, очраша торган квартирада газетаны үз күзләре белән күргәч тә ышанмады әле. Бу «Умант» операциясе өчен булырга тиеш, дип шәрехләде Калнинь.

Отто моңа сөенергә тиеш иде, әлбәттә, әмма ул тирән уйга чумды. Нәрсә булып чыга соң әле бу? Җирле партизаннарны, властька каршы килгәннәрне атып йөргән өчен, немецлар Эрхардны әллә ничә тапкыр «Тимер тәре» белән бүләкләде. Аны бүтәннәргә үрнәк итеп, мактап, үз газеталарында язып чыкты. Ә аларны немецларга бик теләп булышучы җирле кешеләрне юлдан алып ташлаган өчен бүләклиләр. Әмма ике очракта да җирле латыш халкы кырыла, кан коя. Ә халыкның бернинди гаебе юк. Җирле крестьян, әйтик, политик исәптән түгел, ә кешелеклелек җәһәтеннән ач партизаннарга икмәк бирә. Моны үзе кебек үк күрше крестьян күреп ала да немецларга барып әйтә. Ул да, бәлки, политик исәптән түгелдер, күршесенә ачу итеп кенәдер? Адәм балаларында бер-берсеннән күпсенү, бер-берсен күралмау гаҗәпкә калдыра. «Кеше – кешегә бүре» дигән сүз дөрес әйтелгән, ахрысы. Властьлар шуңардан файдалана. Башта кешеләрне бер-берсенә астыртын гына котырталар. Бу яшерен эшне һәртөрле куштаннары, агентлары ярдәмендә башкаралар. Аннары һәркемне персональ рәвештә СД органнарында хезмәттәшлек итү өчен яллыйлар...

## XIX

Җәй үзенең соңгы чәчкәләрен коеп утырган моңсу вакыт иде. Агачларда сары яфраклар күренгәли башлады. Әмма йомшак җылы бар әле. Иртән мул булып салкын чык төшә, үлән тәлгәшләренә бәллүр алкалар булып эленә. Яфракларны тир тамчылары кебек итеп каплый. Җәй буе бик еш яуган яңгырлар туктады, кояшлы көннәр китте. Җәй көзгә таба авыша башлаганда, шулай якты һавада, җирдә пәрәвез җепселләре елык-елык килеп уйнаган чаклар булып ала...

Асфальттан гади юлга борылдылар. Көпчәк эзендәге туфрак нәкъ көл төсле, шактый калын, шуңа күрә ком иңеп, батып керә дә барырга комачаулый иде. Эрхард, машинаны кызулатырга кушып, акаеп-акаеп, Оттога карап ала. Күзләре аңа пистолет көпшәсе кебек куркыныч булып төбәлә. Күз алмалары бер урында гына тора һәм Оттоның йөрәгенә ук шикелле кадала сыман.

Хуторда икешәр катлы өч-дүрт йорт бар иде. Барысы да икешәр катлы. Икенче каты кыек астына эшләнгән. Тәрәзәсе дә икәү генә.

Хутор кечерәк бер елга буена, үзәнлеккә утырган. Елгага озын гына бер күл дә килеп тоташа. Биредә балык тотып һәм иген игеп көн итәләр булса кирәк. Тыштан ук күренеп тора: хутор шактый җитеш тормыш белән яши кебек.

Калын урман массивына терәлеп диярлек торган тагын бер йорт бар иде. Аның асты таштан, өсте бүрәнәдән салынган. Кәрнизләре матур итеп сырлап эшләнгән, ак буяуга буялган. Шулай ук шактый җитеш тормышлы кешенеке булырга охшап тора.

Полицайлар йортны чолгап алган, әмма якын килә алмыйлар, чөнки йорт эченнән аталар иде.

Өйләр артына килеп туктауга, полицайлар машинаны сырып алды. Начальниклары Эрхардка хәлне аңлатырга тотынды:

– Төнлә партизаннар килгән дә икмәк таләп иткән, – диде ул. – Хуҗа бирергә теләмәгән, тизрәк ат менеп, полиция идарәсенә чабып килгән. Без, берничә полицай килеп, урман буена засадага яттык. Алар шуннан килгән, шунда китәргә дә тиеш дип уйлаган идек. Шулай булып чыкты да. Таң атып килә иде, өч партизан, аркаларына зур-зур капчыклар асып, урманга таба чаба башлады. Без мылтыкларны хутка җибәрдек. Икесе йортка таба үрмәләде, ә берсе, җиргә яткан көе, мылтыктан ата-ата, аларны ышыкламакчы булды. Бик

төз атучы иде, ахры, өч кешене яралады. Ахырда без аны дөмектердек. Йортны чолгап алдык. Тегеләргә юлны кистек. Качарга өлгерә алмадылар. Хәзер, әнә, өйдән атып яталар...

– Ничә партизан?

– Икәү булырга тиеш. Әмма кайчак өчәү кебек тә тоела, шундый каты аталар.

– Өйдә хуҗалар бармы?

– Хуҗаны хатыны, ике баласы белән чыгардылар, ишекне бикләп алдылар. Без үзебез чыгаруларын сорадык, диләр.

– Хуҗа алар белән элемтәдә булганмы?

– Бернинди таныш-белешлегем юк иде, ди.

– Алдаша ул. Патроннары бик күпмени?

– Күп булмаска тиеш.

– Патроннары беткәнче прицелда тотарга, аннары үзләрен кулга алырга!

– Өйгә якын бармасаң, алар атмый, билгеле. Ә якын килсәң – бетәсең.

– Бер куркынычсыз урын табып, шуннан атып, аларның патроннарын тизрәк бетерергә кирәк.

– Без шулай итеп караган идек тә, ләкин тиз сизенделәр. Патроннарын бик саклап тоталар...

Полиция начальнигы, ялагайланып, Эрхардка ничек тә ярарга тырышып сөйләнә, эт кебек, аның һәрбер ым-боерыгын тотып ала һәм аны тизрәк үтәргә ашыга иде.

– Ә хуҗа кайда?

Эрхард барын да хәл итә торган зур командир кыяфәтенә керде. Сорауларына озаклап аңлатма бирә башласалар, бер сүз белән өзә, туктата, конкретлык таләп итә иде.

Полиция начальнигы Судмалис кырыйдагы бина подвалына ымлап күрсәтте. Хуҗаны хатыны һәм балалары белән шунда кертеп япканнар иде.

Подвал балык тозлый торган мичкәләр, балык тоту җайланмалары, тагын шундый вак-төяк әйберләр белән тулган иде. Болар кергәндә, тегеләр сүс өеменә чүмәшкән, хатын, балалар елый-елый ярсып беткән, тыела алмыйча, укшып, нечкә авазлар чыгарып куйгалый иде.

– Хатынны, балаларны башка җиргә алып китегез, – диде Эрхард, бик коры гына.

Куштан полицайлар шул арада әллә каян өстәл һәм урындык алып кереп куйдылар. Эрхард шунда килеп утырды. Хатынны, балаларны елата-елата алып чыгып киттеләр. Күршедәге подвалга илтеп яптылар, ахрысы.

Эрхард тәрҗемәче аша хуҗадан сорау алырга кереште. Хуҗаның тышкы кыяфәте үк эшчән икәнен күрсәтеп тора иде. Кызгылт төк белән капланган тулы битле, кыска какча борынлы, җитен чәчле, сажин җилкәле, урта буйлы кеше иде ул. Киң маңгай астыннан караган елтыр күзләре бер хәйләсез, яхшылык кына теләгән шикелле карый иде.

Полицай аңа сорауларны латышчага тәрҗемәләп биреп торды, теге сөйләде.

– Минем алар белән бернинди элемтәм юк, – диде. – Алар кичә кичен керде дә икмәк сорады. Безнең ике буханка гына пешкән ипи бар иде. Хатын шуны чыгарып бирде, аннары бәрәңге теләнделәр. Хатын анысын да җавапсыз калдырмады, бер чиләк бәрәңге дә бирде. Менә шул. Капчыкларын асып чыкканда, өйләрдә кемнәр яши, полицайлар юкмы, дип сорадылар. Хатын, юк, дигәч, рәхмәт әйтеп саубуллаштылар. Бүген таң алдыннан өйдән ерак түгел, урман буенда атышлар башланды. Без астагы катта яткан идек. Тәрәзәләр

тыштан капкач белән томаланган, берни күренми. Мин өскә менеп киттем, анда да тәрәзәләр ябулы, шулай да форточка аша бер як капкачны ачып күзәттем. Ләкин берни дә шәйли алмадым. Шулчак бик каты итеп ишек дөбертәтергә тотындылар. Мин ачарга курыктым, алар каерып ачып керде дә эчтән бикләп куйды. Безгә караңгы бүлмәдә торып торырга боердылар.

– Руслармы, латышлармы? – дип бүлдерде аны Эрхард.

– Анысын аера алмадым, латышча сөйләштеләр.

–Ниндирәкләр?

– Юк, таза гәүдәле түгел. Икесендә дә кызылармияче чалбары, өсләрендә – сырган фуфайка.

– Кораллары?

– Икесендә дә немец автоматы. Башка коралларын шәйләмәдем.

– Син аларга ник икмәк, бәрәңге бирдең, ә? – дип, Эрхард кычкырына башлады. Бите кабарынды, бүртенде. – Германия командованиесенең «кем бандитларга ярдәм итә, шул җәзага тартыла» дигән боерыгын белмисезмени, ә?

– Мин аларның партизан икәнен белмәдем, автоматлары юк иде, тик ишекне ватып кергәч кенә коралларын шәйләдем.

– Юк, син белгәнсең, белеп ярдәм иткәнсең. Син алар белән элемтәдә торгансың. Кайчаннан бирле элемтәдә торасың, аларның урнашкан җире кайда? Әйт! Кайда?

– Әйтәм бит, бернинди элемтәм юк, мин аларны белмим, беренче мәртәбә күрәм, господин начальник.

– Ә дәүләткә тиешлесен түләдеңме? – Эрхард полиция начальнигы Судмалиска таба борылды.

Теге, сумкасыннан амбар кенәгәсен чыгарып, исемлекне карый башлады. Тапты да әйтте:

– Барысын да түләгән, – диде.

– Әйдә, элемтәләреңне әйт! – дип кычкырды Эрхард һәм, пистолетын кулына алып, хуҗа янына килде. Аның борын төбендә коралын селки-селки, тагын шул сорауны кабатлады.

Хуҗа шаккатып куркып калды, муены агарып китте.

– Бернинди элемтәм юк! – диде ул, тавышын күтәрә төшеп.

Шулчак Эрхард аның чигәсенә пистолет тотәсе белән сугып җибәрде. Хуҗаның куллары як-якка җәелеп китте, әмма егылмады, тотынып калды, авызыннан кан саркып чыкты.

– Әйдә, элемтәләрең турында сөйлә! – дип кычкырды Эрхард.

Хуҗа кан төкерде, йөзе исә башка бер сүз дә эндәшмим дигән ачулы-үчле рәвешкә керде. Ике бите, иякләре каралып китте.

– Партизаннар кайда урнашкан, әйт! Әйт! – Эрхардның тавышы хәтәр чыга, сүзләрен әйткәндә, муены шултиклем бүртеп юаная, мундир якасына сыймыйча, читкә бүселә һәм тынын буа иде. Икенче җөмләсен әйткәндә, тәмам гыжылдап, сүзләрен көчкә генә этеп чыгара иде.

Хуҗа бик каты ачулы-үчле кыяфәттә башын як-якка чайкады да тынып калды. Эрхард күпме акырса да, ул аның сүзләрен ишетми, кабул итми кебек иде.

Эрхард полиция начальнигына таба борылды:

– Бер баласын алып керегез, – диде.

Судмалис, ашыга-ашыга, боерыкны үтәргә чапты. Хәзер бик яман хәл булачак иде. Отто әлегә кадәр көчкә чыдап торган иде, хәзер тизрәк машинасы янына чыкты.

Хуҗаның ун яшьлек малаен алып керделәр. Судмалис аны бер такта өстенә йөзтүбән сузып яткырды да аркасына сыек чыбык белән сыдыргалап алды, малай хәтәр чырыйлады. Әтисе йөзен ике учы белән каплады, аннары малаена таба ыргылды, ике полицай, тотып алып, аны урынына бастырды.

– Партизаннар кайда урнашкан, әйт? – дип кычкырды Эрхард.

Хуҗага бу берничек тә тәэсир итмәде, ул, малаеның канлы аркасын күрмәс өчен, ике учы белән күзләрен каплап, тере мәет кебек басып тора һәм, эчтән елаганын сиздермәс өчен, алга таба бөгелеп-бөгелеп ала иде. Эрхард кабат полицайга ым какты, тегесе тагын үрсәләнеп яткан малайның аркасына чыж-чыж чыбык сыза башлады. Малайның башы бер якка янтайды, тавышы кинәт тынды. Ул һушын җуйган иде.

– Әйт бандитларның кайда икәнен! – дип җикеренде Эрхард.

Хуҗа элеккечә бернинди реакция белдермәде, күзләрен учы белән каплаган килеш, эчке сызланудан, сыкранудан алга таба бөгелеп-бөгелеп төшә, аннан турая иде.

Ул арада аткан тавышлар ишетелде.

– Партизаннарның кайда икәнлеген уйлый тор! – диде Эрхард һәм, хәле китеп, ыңгырашып яткан малайны алып чыгарга боерды.

Аны бер таза полицай муеныннан һәм аягыннан эләктереп алды да әнисе янына, икенче йорт подвалына китереп куйды. Ана улы өстенә капланды.

Эрхард белән полиция начальнигы, подвалдан чыгып, күрше йорт почмагына ышыкланып, партизаннар урнашкан йортны күзәтә башлады. Күршедәге жандармериядән бер машина полицайлар килгән икән. Шулар өстәге кат тәрәзәләренә атканнар. Партизаннар шуңа җавап биргән.

– Тәрәзәләргә сак куярга, өйгә бәреп керергә. Ләкин тереләй кулга төшерергә! Аңлыйсызмы, алар безгә тереләй кирәк! – дип боерды Эрхард. Үзе ышыктан чыкмады.

Полиция начальнигы шул боерыкны үтәр өчен полицайларны оештырырга ашыкты. Эрхард үзенең сакчысын да аның белән җибәрде:

– Терелэй кулга төшерергә, үлеләр кирәк түгел! – дип кычкырып калды ул.

Эрхард почмактан күзәтеп тора иде. Менә полицайлар һәр тәрәзә янына стенага ышкыла-ышкыла килеп басты.

Полиция начальнигы веранда ишеген лом белән каерып ташлады. Полицайлар эчкә ыргылды. Өй ишеген каерырга тотындылар, шулвакыт каты шартлау өйне дер селкетте. Партизаннар граната ыргытты. Кемдер яраланган, ярдәм сорап ухылдый иде. Ә Эрхардның сакчысы идәнгә йөзтүбән авып төшкән. Аны әйләндереп карадылар да, маңгаенда кара кан табы күргәч, барысы да аңлашылды. Аның эше беткән иде.

– Бирелегез, гомерегезне гарантиялибез! – дип кычкырды полиция начальнигы, русчалатып.

Әмма аңа җавап итеп өйдән бер кыска «очередь» бирделәр. Автоматлы ике полицай бар иде, аларга өй эчен утка тотарга боерылды. Алар өй эченә тоташ «очередь» биреп алды. Анда нәрсәләрдер ватылган тавышлар ишетелде. Болар аста атышкан арада, полицайлар баскыч белән өстәге кат тәрәзәсенә менде, аны ватып эчкә керде.

Партизаннар өйнең базына төшәргә мәҗбүр булды. Полицайлар аста да, өстә дә шау-гөр килде. Үзләре, идәнне мылтык түтәсе белән төя-төя: «Бирелегез, гомерегез гарантияләнә!» – дип кычкырыналар иде.

Базның бер башы болдыр баскычы астындагы тар гына ишеккә чыга икән.

Моны полицайлар күреп алып, ишекне каерып ачып, эчкә башларын тыккан иде, тегеннән атып җибәрделәр дә, ике полицай шунда ук башларын җиргә төртте. Берара шау-шу, буталыш, акырыш-бакырыш булып алды.

Эрхард эшнең кая таба барганын тиз чамалап алды. Өй янына үзе килеп, кабат боерыкларын бирергә тотынды:

– Тереләй кулга төшерергә, тереләй!

Тагын баягы тактиканы кабатладылар: ике полицай, автоматтан ата-ата, эчкә кереп китте. Берни аңларлык түгел иде. Берзаман автомат тавышлары тынды. Граната шартлау тагын өйне дер селкетте. Шунда кинәт тынлык урнашты. Полицайлар базга кереп китте. Берсе фонарь яндырып тоткан иде. Бераздан автоматчыларны култыклап алып чыктылар. Икесе дә яраланган иде. Ә партизаннарны, күтәреп чыгып, чирәмгә салдылар. Алар исән иде әле. Ләкин икесен янәшә куйгач, шул аңлашылды: алар үз-үзләрен шартлаткан иде. Икесенә шул бердәнбер гранаталары калган булгандыр. Корсак турысында икесенең дә киемнәре умырылган һәм тәннәре дары төтене белән каралган иде.

Отто партизаннарны килеп карады да чак кына егылып китмәде. Партизаннарның берсе Андрей Милаш иде. Әйе-әйе, аны күзләре алдамый. Әнә чигәсендә зур гына миңе дә бар. Ләкин Андрей бик нык үзгәргән, танымаслык булып картайган иде. Теге чагында Клара нигә Андрейның кайда булуын аңардан яшереп маташты икән? Оттога ышанып җитмичә, саклануы булгандыр инде. Хәер, аны гаепләп тә булмый иде, хәзерге шартларда беркемгә дә ышану мөмкин түгел. Иң ышанычлы дип санаган таныш-белешләр, туганнар да хыянәт итте. Билгеле, үзләре теләп түгел, шартлар мәҗбүр иткәнгә күрә. Үзләрен саклау өчен. Ләкин шуны сәбәп итеп, кешеләрне гаепләп буламы? Һәркемгә дә үз башы кадерле, газиз бит...

Икенче партизанны Отто танымады. Ул – Андрейның дусты Зорис иде.

Полиция начальнигы җан биреп ятучыларның куеннарын, кесәләрен актарып чыкты, тәмәке янчыгы, зажигалка, ниндидер кәгазьләр табып алды. Ләкин исем-фамилияләрен белгертә торган берни дә тапмады.

Эрхард, һәрвакыттагыча, партизаннарның гәүдәләрен фотога төшереп алды. Бу аңа хисап бирү өчен кирәк иде.

Отто һаман Андрей Милаш турында уйлады. Бу кешенең ихласлылыгы аның күңеленә аерата сеңеп калган иде. Партизаннарга киткән булган икән. Шартлар мәҗбүр иткәндер инде. Югыйсә врач кешегә тынычрак урын да табылган булыр иде. СД агентлары аны үзләренә хезмәткә ялламакчы булган, билгеле. Әмма Андрей андый адымга бара торган зат түгел. СДга кермәдең, язмышың билгеле, сине кайда да читкә тибәрәләр. Немецларда ул мәсьәлә каты куелган.

Нинди зыялы, итагатьле, намусны беренче урынга куя торган кеше үз гомерен менә ничек очлады...

Эшләр тәмамлангач, моннан ун чакрымдагы жандармерия участогына кайттылар. Анда, гадәттәгечә, мәҗлес табыны әзерләгәннәр иде. Ашарга-эчәргә дә бик мулдан иде. Эрхард нигәдер ачулы күренде, ул һәр чәркәне авызына аударып кына барды. Үз-үзен тотышында да әүвәл булмаган хәрәкәтләр сизелде. Элек ул бер дә болай уйсыз, дуамал кыланмый торган иде. Һәр хәрәкәте, сүзе исәпләнгән булыр, һәр эше киләчәкне күздә тотып башкарылыр иде. Бүген ул бөтенләй сәер хәрәкәтләр ясый, сүзләр сөйли. Әллә биредән китәргә уйладымы икән? Немецларның кораблары батачагы хәзер инде ачык күренеп тора бит. Күсе ише җәнлекләр моны бик алдан сизә һәм корабны ташлап кача башлый. Бер газеталарында хәтта «Көнчыгыш кампаниясендә без оттырдык» дип тә яздылар. Моны хәзер һәр җирдә күрергә була иде. Җир

биләргә, үзләренең элеккеге байлыкларын кайтарырга дип, Германия үзәгеннән килгән колонистлар инде кире китә башлады. Эрхард та, бәлки, берәр нәрсә чамалыйдыр? Ничектер ул монда утырган кебек түгел, уйлары кайдадыр читтә йөри. Эндәшсәләр ишетми, кабат кайтарып сорый. Нәрсә булган моңа? Әллә берәр нәрсә сизенәме? Үзе Оттоны берөзлексез эчәргә кыстый. Шулай да Отто авызына бер тамчы да капмады. Аңа бик нык аек булырга кирәк иде. Әллә ул Оттоның йөзеннән берәр нәрсә «укыдымы»? Аның да уйлары биредә түгел бит. Бүген сакчы юк, аларның икесенә генә кайтырга туры киләчәк. Башка мондый форсатның чыкмавы да мөмкин. Ничек кенә булмасын, Эрхардны бүген хәл кылырга, иртәгәгә калдырмаска кирәк. Иртәгә аңа тагын сакчы куячаклар. Аннары эш катлаулана. Кулдан ычкынуы да бар. Бәлки, ул, берәр сәбәп табып, Германиягә таярга да исәп тотадыр. Ригага, врачлар янына еш баруы да юкка гына түгелдер. Үзенә җылы урын әзерли булыр.

Юк, бу форсатны һич кенә дә кулдан ычкындырырга ярамый иде.

Караңгы төшә башлаган иде инде. Табын янында Эрхард тәмам мәлҗерәде. Полиция начальнигы «кунып кына китегез» дия башлады. Эрхард аның сүзләренә колак салырлык дәрәҗәдә түгел иде. Шуңа күрә Оттога мөрәҗәгать иттеләр. Ул, башын чайкап, «иртәгә бик мөһим эшләр бар», диде. «Өлкә комиссары фон Медемда киңәшмә булачак, анда Эрхард информациясе тыңланачак», дип, Отто тегеләрнең тәкъдимен кире какты. Фон Медем фамилиясен ишеткәч, барысы да тынып калды, кыстаудан туктады.

Ике полицай Эрхардны машинаның арткы утыргычына кертеп салды. Ул шунда ук, кырын авып төшеп, гырлап йоклый да башлады. Әмма Эрхардка ышанып та булмый, аның исереккә сабышып ятуы да мөмкин. Оттоны сынар өчен. Берничә мәртәбә шулай эшләде дә инде ул. Ләкин бу юлы чынлап исергәнгә охшаган иде. Хәер, аек булса да, Отто аңа бирешмәячәк иде. Ул аның пистолетын алып, утыргыч астына куйды. Обоймадагы пуляларын да чәчеп ташлады. Хәзер Эрхардның язмышы тулысынча Отто кулында иде.

Ул, жандармериядән ерагайгач, кайту юлына борылмады, ә үзе белгән калын урман эченә таба кереп китте. Машинаны хәтәр кызу алып барды. Сикәлтәле юлда Эрхардның башы утыргыч кырыена каты гына бәрелгәләп тә ала иде. Әллә шуңардан ул капылт кына уянды да, мыгыр-мыгыр килеп, мундирын салып ташлады. Отто, нишли икән бу, дип борылып караган иде, Эрхард, яңа гына исенә килгән кебек, аны күреп алды, ике кулы белән арттан кочаклап үбәргә дә тотынды. Чү, тукта, нәрсә соң бу? Оттоның битен тәмам чылатып бетерде, әмма үзенең бер сүзен дә аңлап булмый иде. Шулчак Оттоның башына әллә бу бәндә гомосексуалистмы икән дигән уй килде. Чыннан да, нинди чибәр Эрнага да карамагач, Эрхардның хәзерге кыланышын ничек аңлатмак кирәк? Бераздан Эрхард тәмам котырынды, Оттоның киемнәрен йолкырга тотынды. Машинаны алып барырга һич мөмкинлек калмады. Алар инде урман юлыннан шактый эчкә кергән иде. Отто машинаны туктатты. Аяк астыннан үрелеп ачкыч алды, Эрхардның башын утыргычка бөкте дә муен тамырына бик каты итеп сукты. Караңгыда тегенең күз аклары артка тәгәрәгәне күренде. Ул шунда ук тутырган авыр капчык шикелле бөгелеп төште. Отто аны машинадан өстерәп төшерде дә якындагы бер куш каенга сөямәкче булды. Тик ул аягында басып тора алмый, үзе һаман нидер мыгырдана, күзләре ябык иде. Отто утыргыч астыннан дилбегә кебек озын бау тартып чыгарды. Немецларда бауны иллә дә шәп итеп ишәләр. Кешеләрне бәйләргә, асарга ифрат җайлы нәрсә инде. Ул Эрхардны шул бау белән агачка бәйләргә кереште. Башта аякларын,

аннары гәүдәсен, турайтып, кәүсәгә чорнады. Кулларын артка бәйләп куйды. Кычкырмасын өчен, ак майкасын кайтарып, авызын да ныклап томалады...

Шуннан соң ул машинаны тиз генә кирегә борды да алга элдерде. Бераз үткәч, урман авызына җитәрәк, кечкенә кул пычкысы алып, кабинадан чыкты, нечкәрәк агачларны кисеп, тиз генә үтеп керешле булмасын дип, юлга аркылы аудара башлады. Шуннан соң ул машинасын тагын да ярсыбрак куарга тотынды. Кайту ягына түгел, бөтенләй кире якка. Отто юл уңаенда бер бик тирән сулы чокыр барлыгын белә, анда ничек тә караңгыда барып җитәргә кирәк иде...

Менә ул упкын кебек зур, тирән чокыр кырыена килеп туктады, тиешле әйберләрен алып, машинадан төште. Бераз тирә-юньне күзәтеп торды. Ул-бу юкмы, тавыш-мазар ишетелмиме? Юк, үлем тынлыгы, бу тирәдән үтеп-сүтеп йөрүче юк иде. Отто җан-фәрманга машинасын этә башлады, һәм ул, кызулап килгән көйгә, текә ярдан аска мәтәлеп төшеп китте. Бер минуттан аста су күбекләренең аксыллыгы гына күренеп калды. Су машинаны гына түгел, зуррак нәрсәләрне дә йотарлык тирән иде.

Отто бераз гына басып торды, аннары адымнарын тизләтеп китеп барды. Артка юл юк иде, ул «күперләрне яндыра-яндыра» чигенә барды. Менә ничек була икән ул күперләрне яндыру дигәннәре.

Ул моннан унике чакрым тирәсе ераклыкта урнашкан хуторга, очрашу урынына таба юнәлде. Аңа ялан кырларга чыкмаска-күренмәскә, ничек тә урман эчләтеп, сазлыклы урыннардан барырга кирәк иде. Әмма соңга калды, урманны чыгып җиткәндә, яктыра башлады. Алга таба кыр буйлап барырга кирәк иде, шуңа күрә ул туктарга мәҗбүр булды. Төнне көтмичә мөмкин түгел иде. Хәзер немецлар Латвиядә һәр төштә күбәйде, чөнки чигенгән частьлары бирегә килеп тулды. Кызыллар Воронежны, Харьковны алган, Белоруссияне азат итеп бара... Кыскасы, сугыш тәмамланып килә...

Отто, урман ешлыгына кереп, чыбык-чабык сындыргалап, җиргә түшәде дә шуның өстенә ятты. Ләкин тиз генә йоклап китә алмады, чөнки йөрәге еш-еш тибә, күңеленнән курку хисе дә чыгып бетмәгән иде. Ул үзен-үзе тынычландырырга тырышса да, ярсыган, урыныннан купкан тойгылары һаман бимазалап торды. Чынлап та, адәм баласы үз хисләренә хуҗа була белми, ахры. Хисләр безнең иректә түгел микәнни? Әллә Отто гына шулай гайре булып яралганмы? Хисләрнең күплеге кешене бәхетсез итә дигәннәрен ишеткәне бар иде аның, әмма ул хакта уйлап караганы булмады. Хәзер инде белде, хисләр кешегә бәла, җәфа гына китерә икән. Менә бит, үзе кайчаннан бирле бер файдасызга бәргәләнеп, дулкынланып ята, тик шуны акылы белән аңласа да, тыя-тыела алмый.

Хәзер барысын да онытып торырга, уйларны, хисләрне тынычландырырга, баш миен ял иттерергә кирәк. Ял итәргә, ял итәргә! Аннары бу яңа ситуацияне саф баш белән тикшереп, алдын-артын исәпләп карарга...

Отто ниндидер кош пырылдап очканга уянып китте. Сәгатенә караган иде, шаккатты, өйлә узып бара икән. Шактый йокланылган. Сизелә, йөрәк тибеше дә бераз салмакланып, үз ритмына кайткандай булган...

Шул мәлдә тагын Андрей исенә төште. Менә сиңа метаморфоза! Андрей үзе, партизан булып, оккупантларга каршы көрәшкән, ә малае, Радик, шул оккупантларга хезмәт итә. Нинди язмыш! Немецлар Андрейның улын тартып алган, гомер иткән хатыны белән дә низаг чыккан. Кларанын сиздермәскә тырышып сөйләүләреннән шул аңлашылды. Үзең табып үстергән балаңны,

яшьлек юләрлегеннән файдаланып, явызларча синнән аерсыннар әле! Моңа ничек җан сыкрамасын?! Радикның соңыннан исенә төшәр, аңына да килер, әмма инде бик соң булыр. Ул чагында берни дә эшли алмас. Кирегә юл юк. Кызыллар килгәч, оккупантларга булышканнарны, һичшиксез, бетерәчәк. Андрей, күрәсең, үз хәленең бик өметсез икәнен аңлаган да партизаннарга барып кушылган. Анда да яра бәйләп, дәвалап кына ятарга риза булмаган, хәрби операцияләрдә катнашкан. Берничә мәртәбә эшләре уңышлы гына килеп чыккан да булгандыр. Уңыш һәрчак шулай дикъкатьне, сизгерлекне киметә. Уңышлардан баш әйләнү – кеше психологиясенә хас нәрсә. Аны җиңә белергә кирәк.

Радик... Җаннарыннан артык күреп, иркәләп кенә үстергәннәр иде. Иң кыен вакытта ул әти-әнисенә хыянәт итте. Моны егет үз акылы белән эшләмәгән, фәкать аның яшьлек юләрлегеннән явызларча файдаланганнар гына. Бу кешелексез ысул Советларда да кулланыла икән. Анда да баланы ата-анасыннан аералар, диләр. Хәтта үз кагыйдәләре дә бар: «Сын за отца не отвечает». Әмма барыбер кешенең чыгышына нык әһәмият бирәләр, чөнки тыныч тормышта ниндидер бер дәрәҗәдә улы этисенең язмышын кабатлый. Психологиясе, холык-фигыле туганнарыныкы кебек була. Ә бит гомуми закончалык бар: кешенең характеры, рухы аның шәхси язмышын билгели, диләр. Әлбәттә, Радик очрагындагыча, читтән басым һәм адаштыру булмаган чагында...

Барча җәмгыять системасы өчен уртак бернәрсә бар шикелле. Ир бала, иртәме-соңмы, барыбер этисенә хыянәт итә. Моны ниндидер тәрәккый итү закончалыгы дияргә дә мөмкиндер. Отто үзе якыннан белгән ничәмә-ничә гаиләне күздән, хәтердән кичерде, барысы да шул закончалыкны раслый...

Тора-бара Оттоны тагын йокы басты. Күпмедер черем иткәч, ул ниндидер тавышка сискәнеп уянды. Өстәвенә куркыныч төш тә күрде ул: артыннан ике оккупант аны эзәрлекләп килә, Оттоның пистолетында патрон беткән, үзе кая керергә белми иде... Менә-менә эләктерәләр дигәндә, төше өзелде. Йөрәге, күкрәк читлегеннән чыгардай булып, бәргәләнә-бәргәләнә тибә иде. Ул торып басты, як-ягына каранды. Көн кичкә авышкан, кузгалырга вакыт иде. Шулчак агачлар арасыннан ниндидер шәүлә хәрәкәтләнгән һәм, агач артына посып, аны күзәтә шикелле тоелды. Юк, берни дә түгел, просто нервылар какшаган дип, үзен үзе юатты ул. Чәбәләнеп үскән кәрәшкә, корыган кауданнарны ерa-ера ары китте. Кинәт артына борылып караган иде, тагын теге шәүлә, бер агач артыннан чыгып, икенче агачка таба хәрәкәт итте дә юк булды. Әллә Эрхард өрәге аны шулай эзәрлеклиме, шайтан алгыры! Отто бит аны теге дөньяга атып үтереп тә озата ала иде, ләкин кан күрүдән курыкты. Канга карый алмый шул ул, шунда ук буыннары йомшара, күз алдында мамык кисәкләре очып йөрергә тотына. Әйе, һәр кеше дә палач була алмый, юк. Эрхард, туктаусыз кешеләр үтереп йөреп, ничек яши алды икән? Әллә шул эш буенча аерым мәктәп узды микән? Юк, яшәү дигән нәрсә тәтемәгәндер аңа! Әллә бик рәхәтләнеп яшәгәнме? Адәм баласы теләсә нинди шартларга күнегә бит. Мәсәлән, моргта эшләүчеләр канга күнегеп бетәдер. Әйе, анда да теләсә кем эшли алмый, диләр. Сайланып калганнар гына эшен дәвам итә икән.

Эрхард та шулай бер гаепсез адәмнәрнең канын коярга күнеккән инде, чөнки ул үзеннән өстәгеләр боерыгын карусыз үтәргә үзен үзе өйрәткән. Уйлап тормый, бары әмер-боерык үтәвен белә. Боерыктан башка аңа беркем берни тормый. Шулай да аның тамырларында да кызыл кан ага, йөрәге дә үз урынындадыр ич. Дөрес, ул йөрәген бәләкәй читлек эченә ябып куеп, аны

үзеннән изоляцияләгән булгандыр. Ул аның тавышын ишетми, тибешен сизми...

Чү, теге шәүлә тагын күченде кебек. Чынлап та, Эрхард шәүләсенә дә охшаган сыман үзе. Әллә күзенә генә шулай күренәме?

Юк, Оттога хәзер ялгызы гына булырга ярамый. Әллә Рута янына кайтыргамы? Умантны аскач та бер мәлгә шундый тойгы кичергән иде ул. Чаттан борылганда, анда гел Умант яшеренеп торган сыман була иде... Шул галәмәт Рута янында беткән иде...

## XX

Хутор янына килеп җитәрәк, Отто җиргә ятты да тирә-якны күзәтә башлады. Хуторга сукыр килеш барып керүдән нык сагайды ул. Һәр төштә полицайлар, фронттан талкынып чыккан солдатлар уралуы ешайган чак иде. Кинәт шул тарафтан мотоцикл тавышы ишетелде. Алар өчәү булып чыкты. Фараларының яктысы, ак мөгезләр кебек, караңгыны сөзеп бара. Өч мотоцикл, бер-берсеннән шактый ара калдырып, хутордан чыгып китте. Анасын корт чаккыры, нәрсә инде бу? Очрашу урыны немецларга фаш булып, эсэсчылар әллә төнлә килеп засада оештырганмы? Әллә тикшереп, тентеп китеп баруларымы? Бу бит бик яшерен очрашу урыны, моны Калнинь белән Отто гына белә иде. Әллә Калниньга бер-бер хәл булганмы? Моннан бер-ике көн элгәре ул мастерскойдан китәргә, эшкә бармаска тиеш иде. Шулай сүз куештылар, чөнки Эрхардның югалуы гестапоны аякка тиз бастырачак. Иң элек Оттоны эзләячәкләр, аның Калнинь белән таныш булганын яхшы беләләр. Калнинь ычкынырга өлгерә алмады микәнни? Юк, өлгергәндер, бик үткен егет ич. Алайса, нинди хәл соң бу? Ничек дип белергә моны? Димәк, хуторга керергә ярамый. Алайса, кая барырга, нишләргә? Әллә урманга партизаннарны эзләп китәргәме?

Ерак түгел урман полосасы каралып тора иде. Аның бер кишәрлек кенә булуы икенче ягының яктырып күренүеннән беленә. Күзәтеп ятарга ярап торыр, ачык кыр түгел дип карар итте Отто һәм шул якка таба атлады.

Урманга кергәч, ул, колагын шомрайтып, бераз тыңлап торды, аннары чыбык-чабыклар җыеп, шуның өстенә сузылып ятты.

Күпмедер ятканнан соң, күзен ачса, офык буйлап ак тасмалар сузылганын шәйләде. Ак тасма бераз алсулана башлады, төнге караңгылык эреп югала бара иде.

Отто хуторны күзәтергә кереште. Алар очрашасы хутормы соң бу? Әллә бүтәнме? Ләкин бу төштән хутор йортының морҗасы гына күренә, алгы якта лапаслар иде. Лапаслар артында – бәрәңге бакчасы. Юк, арырак китеп, ишегалды күренә торган җирдән күзәтергә кирәк.

Урман әчләп ул шактый барды, әмма хәзер өй күренә, ә ишегалды икенче якта икән. Ә аңа ишегалды кирәк. Нишләргә? Биредән ачыклык башлана, шуңа күрә ерактарак урнашкан тагын ике хутор корылмалары күренә иде. Әллә шуларга барып карыйсымы? Ул буталды, ахрысы. Өстәвенә бу тирәләрдә булганы да юк иде. Шулай да әйтеп җибәрүләренә караганда, билгеләр туры килә: менә урман полосасы, төньяк тарафка арты белән корылган лапаслар, чүлмәк түбәле, алтыпочмаклы йорт. Ишегалдында чыгырлы кое булырга тиеш.

Отто кыр буйлап лапаска таба барырга ниятләде. Межага төште, шуннан атлады. Бер якта – бәрәңге басуы, икенче якта – чөгендер плантациясе. Эре-эре чөгендерләр җир өстенә үк чыгып үскән. Тегендәрәк камыллы басу китә, игенен күптән җыеп алганнар.

Межа коймасы балчык белән бик яхшылап сыланган үрмә читәннән

гыйбарәт иде. Кырга чыга торган тар гына такта капкасы да бар. Отто шул капкага турылап килде, шуннан ишегалдына күз салмакчы булды. Әле бик иртә, халык уянганчы, нәрсәдер эшләргә кирәк. Лапаска кереп, печәнлеккә менеп яшеренергә дә мөмкин. Аннан күзәтеп ятарга уңайлы, куркынычы да әзрәк, үзеңне һәрчак ышыклый аласың... Отто капканы ачыйм дигәндә генә, эчтә ниндидер аяк тавышы, калайга чиләк бәрелгән аваз ишетелеп китте. Ул җәнлек тизлеге белән ишек артына посты. Менә ишек ачылды, аннан чиләк белән көрәк тоткан таза гына бер ир-ат чыкты. Өстенә свитер кигән, башында күксел козырёклы тимерюлчылар кепкасы иде. Отто бу кешене шундук танып алды, ул – Стубе иде. Һәм аның исе-акылы киткәндәй булды. Ничек ул бирегә килеп эләккән? Отто әллә чынлап та очрашу урынын бутады микән? Бу адәм аның язмыш тактасына язылган, ахры, совет чорында заводта эшләгәндә дә ул аңа күпме этлекләр эшләде, йөрәгенә кан саудырды. Инде менә тагын юлында очрады. Нишләргә? Үч алыргамы? Болай да аның турында «немецлар белән хезмәттәшлек итә» дигән сүзләр йөри иде. Ә бирегә ул каян килеп чыккан? Бәлки, туганнарының хуторыдыр? Болгавыр чакларны шушында посып уздырмакчыдыр? Немецларга эшләсә, аны нишләтергә? Тотып атаргамы? Юк, Отто андый нәрсәне булдыра алмавын шушы ике тәүлек эчендә тәгаен аңлады һәм карар итте: кеше канын коюдан сакланырга, качарга кирәк аңа. Күзенә кан күренсә, ул һушын җуяр дәрәҗәгә җитә һәм үзен көчкә тыеп кала. Ә бит тыела алмавың да ихтимал...

Бер мизгел эчендә Оттоның башыннан әнә шундый уйлар йөгерешеп узды. Ул капканы япты, шыгырдау тавышы тегене борылып карарга мәҗбүр итте. Әйе, бу, чыннан да, Стубе иде. Юк, аның кулындагы көрәк, чиләк җиргә төшеп китмәде, ул аларны ипләп кенә иелеп куйды да Оттога караган килеш катып калды. Аннары каушаудан чиләгенә иелгәндәй итте, кинәт турайды. Күзләрен тасрайтып төбәгән дә сын кебек тик басып тора. Башта кешене киеменә карап бәялисең. Оттоның өстендә – кара күн тужурка, билендә – немец каешы, күн итеге дә немецныкы, дагалы, фуражкасы шулай ук аларныкы иде. Әйбәт кенә кырынган (Отто механик бритваны һәрчак сумкасында йөртә. Кичә урманда кырынып алырга да иренмәгән иде). Чиста гына күренә. Димәк, партизан булмаска тиеш.

– Стубе, әллә танымыйсыңмы? – диде Отто, тегене шок хәленнән чыгарырга теләп.

– Ә-ә, Зингер, Зингер! – дия-дия, елмайгандай итенде Стубе. – Син каян килеп чыктың бирегә?

– Ә син үзең монда нишләп йөрисең?

– Сине дә немецларга хезмәт итә дигәннәр иде... – Стубеның калын битендә, орчык төбедәй очлы иягендә һәм алга чыгып торган буразна кебек сызыклы маңгаенда ис китү кыяфәте бетте, өскә менгән кашлары кире үз урынына төшеп утырды. Ул Оттога якынрак килде, аңарда бернинди куркыныч чалымнар тапмагач, хәрәкәтләре иркенәеп китте, чалбар кесәсеннән сигарет чыгарып, авызына капты, икенчесен Оттога сузды. Отто зажигалка кабызды. Эчке дулкынланудан тизрәк бушанырга теләп, алар борыннарыннан төтен чыгарды. «Син дә немецларга хезмәт итәсең, мин дә, димәк, без бер дәрәҗәдәге, бер мичәүгә җигелгән кешеләр, иптәшләр...» – Стубеның йөзенә шул фикер язылган иде. Оттоның немецларга эшләвен хуплавы әллә каян күренеп тора. «Син дә...» дип әйтүендә үзенең немецларга сатылуына аклану тапкан шикелле мәгънә төсмере дә ишетелде. Отто монысына әһәмият итмәде, үзенең чын йөзен

белгертергә ярамаганын гына бик тиз абайлады. Аның Оттоны немецларга эшли дип белүе әйбәтрәк тә әле, чөнки ул үзен иркен тотып сөйләшәчәк.

– Әллә бу синең берәр кардәшең хуторымы? – дип сорады Отто йомшак тавыш белән. Элек Советларда үтә кызыл активист булып йөргән кешенең хәзер немецларга хезмәт итүе Отто өчен кызыклы да, гыйбрәтле дә нәрсә иде. Стубе бит идеология, политика кешесе, Отто ише, тимер-томыр арасында эшләүче түгел. Алардан идеология соралмый. Маховик кем хаҗәтенә әйләнсә дә – барыбер. Кыскасы, аларның башлары эшләми, куллары гына хәрәкәт итә. Ә бит Стубе алай була алмый. Ул, – башы-аягы белән дигәндәй, политика кешесе, фәкать бер якка гына хезмәт итә ала. Әллә ул, гомумән, иманлы кеше булмаганмы? Имансыз кешеләргә нинди идеологиягә хезмәт итсә дә барыбер инде. Стубеның тирән инануы булмагандыр, күрәсең. Хәер, Оттоның да андый ук инанганлыгы юк шул. Ул Шачин йогынтысына бирелде. Баштарак бераз икеләнгән чаклары да булды. Ләкин хәзер ул моңа бер дә үкенми. Бу орышта немецларның оттыруы бернинди шик тудырмый.

– Бу хуторда подпольедагы обкомның очрашу урыны булган, – дип аңлатырга ашыккан кебек булды Стубе. – Засада куйдылар. Тагын җиде хуторга шулай куеп чыктылар. Монда ике радист утыра. Мине исә эләккән кешене тану өчен алып килделәр. Мин бит элеккеге обком, горком, райком кешеләрен яхшы беләм...

– Алай икән... – диде Отто, исе китмәгәндәй. – Ә син үзең ничек немецлар кулына эләктең соң?

– Танышлар саткан, – дип, кулын селтәде Стубе, әмма йөзенә үкенү, ачу төсмере чыкмады. – Мине дә бит күпләр белә иде.

– Ничек үзләренә эшләргә күндерделәр?

– Башта гестапо бик нык җәзалады, мин чыдый алмадым һәм үземә мәгълүм кайбер яшерен нәрсәләрне аларга чиштем, аннары хезмәт итәргә ризалаштым. Моны үзе татып карамаган кеше аңламый, билгеле. Сатылган, саткан, дип авыз чайкый. Менә син үзең гестапога эләгеп кара, махсус станокка куеп, аягыңны шартлатып сындырып карасыннар. Мине дә станокка куйдылар. Шуннан соң ризалык бирдем...

– Әйе, үз башына төшмәгәннәр синең хәлне белмәс шул, – дип мыгырданды Отто, ә башында умарта күчедәй уйлар тузынды. Өстәвенә өйдә ике немец та утыра бит әле. Алар килеп чыкса тикшерә башлаячак. Ә Стубе һаман сөйли дә сөйли, Оттога исә, берәр сәбәп табып, тиз генә ычкынырга кирәк. Аны юри сөйләндереп тормыймы икән бу халуй? Эченә тәмам ут төште. Итәк-чабуы яна кебек.

– Кызыллар өчен гомерне бирерлек түгел, бәяләмиләр, – дип, сүзен дәвам итте Стубе, резина төсле күгәргән иреннәрен кыймылдатып. – Әнә минем абый латыш укчысы иде. Революцияне саклап калуда күп көч куйган, Ленин охранкасында эшләгән, ә 37 нче елда үзен бер гаепсезгә аттылар. Чит ил шпионы дигән гаеп тakканнар. Юк, кызыллар да өметсез. Мин шундый фикергә килдем: иң яхшы заман да, иң яхшы җәмгыять тә, иң яхшы халык та булмый... Кызыллар килгәч, кан коячаклар әле...

– Аларның Себере әллә нихәтле халыкны йота, бер эзе дә калмый, – дип куйды Отто, Стубеның сүзен куәтләгәндәй. Әйе, ике ут арасында калган кеше болар турында уйлый алмый, ул бары үз башын саклап калуны кайгырта. Һәр тере җанның табигате шундый инде, берни эшләр хәл юк...

Отто урман эченнән чапты да чапты. Тамагы ач, хәле беткән булуы да

онытылды. Стубеның зиһене эшләп, бераздан Оттоның кем ягында булуын чамалавы мөмкин иде. Стубе, шайтан, әллә белмәмешкә генә салыштымы? Ул хәзер немецларның варварлар икәнен белде бит. Артык тырышлык куюның файдасыз булуын үз җилкәсендә татыды. Хәзер ул теге якка да, бу якка да битараф хәлгә килгәндер. Үзенең башын саклауны бөтенесеннән дә артыграк күрәдер. Ничек тә кулын кеше канына буямаска тырышадыр. Оттоның күңелендә дә шундый ук ният түгелме соң? Коточкыч гаделсезлек хөкем сөргәндә, һәркем үзен генә коткарып калу турында уйлый. Бу – табигый канун. Стубе гел дә чүпрәк баш булмаска тиеш. Бик күп уйлангандыр.

Ниндидер кисентектә Отто хәле бетеп тuктады һәм өелеп торган чыбык өстенә ауды. Анасын корт чаккыры, немецлар шулай да барча очрашу урыннарын ачыклады микәнни? Кая барырга? Ригага китәргә куркыныч, төнлә шәһәрне бомбага тоткалыйлар, анда берничә квартира бар барын. Әллә Рута янына элдерергәме? Ләкин андагы хәлне дә белеп булмый, Рута үзе ничек, исәнме-юкмы? Добэлегә дә төнлә бомбалар төшкәли. Рута янына барырга күңеле тарта да тартуын, Оттоның бит көтеп тора торган бер кешесе дә юк. Ә Рута көтәдер... Үзләренең хуторында хәлләр ничек икән? Ничек белергә? Белсәң дә, анда кайту мөмкин түгел инде. Юк. Очрашу өчен тагын ике хутор бар барлыкка. Бәлки, аларына да засада куелгандыр. Бернинди ышаныч юк.

Хәл алгач, Отто торды да ачыклыктагы чаукалык эченә кереп китте. Очраша торган хуторга таба юнәлергә кирәк иде. Ул берничә чакрым араны якты вакытта үтәргә һәм хуторны озак кына күзәтеп торырга тиеш булачак.

Отто урман кырыйларыннан, ачык кырлар аша да барды. Бер адәм заты да очрамады. Бар тере зат үз өненә кереп поскан. Бу вакытта җир сөрүчеләр, чөгендер алучылар басу тулы була торган иде. Оккупантлар крестьянның икмәген, малын ала да китә. Марка түләгән булалар булуын. Ул маркага беркаян берни ала алмыйсың... Ә бит латышлар үзләре оккупантларга бик теләп булыша. Власть көчле, ә адәм баласы көчсез, нишләсен инде? Әмма үзе теләп тәлинкә ялаучылар да шактый бит. Нәрсәгә исәп тоталар диген? Немецларның кояшы баеганын барысы да белә югыйсә.

Кичкә таба ул хутор янына килеп җитте. Урман буеннан бераз күзәтеп торды. Бирерән башта – камышлы басу, аннан – озынчарак күл, ә күлнең теге ягында чирәп түбәле шактый бөтен йорт һәм каралтылар күренә.

Нык арылган икән, күзе йомыла башлады. Өченче тәүлек авызына бер тәгам ризык кергәне юк, ул да үзен нык сиздерә иде. Отто чыбык-чабык җыйды да, куе агач төбенә түшәп, шунда ятты. Ничектер бик тын, урман кошлары гына кайчак, пырылдап, тынлыкны боза иде. Отто шундук йоклап китте. Күпмедер вакыттан соң уянды, буыннарына хәл кергәнен тойды. Төн караңгы иде. Шулай да, урман кырыена чыгып, теге йортны озак кына күзәтеп торды. Анда да шулай ук караңгы иде. Хәзер төнлә ут алу юк, булса да, тәрәзәләр эчтән томалана. Бәлки, бирердә дә томалап куелгандыр? Ә нигә әле аңа шултиклем сагаерга, куркырга? Бер-ике оккупантка гына бирешми әле ул. Аннары бит аның «мастерской механигы» дигән документы да бар. Ни өчен монда йөрисең, дип төпченсәләр, туганнар янына килдем, дисең. Иң мөһиме, сине күреп танучы очрамасын... Ул, кире урманга кереп, чыбыклар өстенә ауды да кабат йокыга китте.

Бераз яктыргач, уянып, Отто тагын элеккеге күзәтү постына басты. Әмма такта койма биек булганлыктан, ишегалды күренми иде. Ә капка ачылмый да ачылмый. Әллә йортта бер тере җан иясе дә юк микән? Морҗадан төтен-мазар

чыкканы да күренмәде. Көн аяз булырга вәгъдә итә иде. Бу вакытта кай елны ай-ай ярым буе бер тамчы яңгыр төшми. Җирнең дымы тәмам бетә, туфрак, көл шикелле уалып, тузанга әйләнеп кала. Быел да шундыйрак ел, ахрысы.

Әгәр засада куелган икән, анда ике солдат һәм аларның башлыгы булуы ихтимал. Ул бик мөмкин хәл, бит аларның өчесенең дә эшен бетерә ала. Чүтеки тиз ату буенча көн саен диярлек күнекмәләр ясаган кеше. Нәрсәгә шултиклем куркып торырга? Ләкин ул аткач, алар да атар шул, ә үләсе килми, шайтан алгыры. Инде яшәүнең мәгънәсен дә күрмисең, әмма теге дөньяга китәргә теләмисең. Адәм баласының җанына мәңге яшәргә омтылу хисе салынган, күрәсең.

Хәзер Оттоның бар теләге – ничек тә Шачинны күрү. Башкарылган эшләр турында аңа хәбәр итәргә кирәк. Оттоны онытып җибәрмәсен тагын. Анысы да бик мөмкин хәл, үзенең дә эше бик тыгыздыр, гомере дә кыл өстендә генә торадыр. Шуңа күрә очрашырга да базмыйдыр...

Өйләгә хәтле диярлек күзәтеп ятты ул. Өйдән чыккан-кергән җан әсәре күренмәде. Ишегалдын күзәтеп булмый. Шулай да, ахыр чиктә тәвәккәлләп, кузгаласы итте. Хәрәкәтсез нидер көтеп яту берни бирми, тәвәккәлләргә кирәк иде.

Иң элек Отто күлнең аргы башыннан әйләнеп узды, аннары туры капкага килде. Ярыктан ишегалды уч төбендәге кебек күренә. Сулда – таш келәт, шуңа лапас тоташкан. Лапас авызында арба тәртәләре күтәртеп куелган булырга тиеш, ә алар җирдә ята. Димәк, монда да засадамы, әллә башка нәрсәме? Шайтан алгыры, нишләргә? Бик йөрәксенеп килгән иде, кинәт эчтәге гаярьлеге сүрелә башлагандай булды. Әгәр засадага эләксәң, үзеңне, башкаларны куркыныч астына куясың. Яки кан коймыйча гына да булмас. Әйе, булмас. Ләкин каннан аның җаны ытыргый, андый ихтималлыктан тизрәк качарга тели иде. Шулай да ул итекләрен үлән белән яхшылап чистартты, пистолетын барлады һәм шул мәлдә җирдә мотоцикл тәгәрмәче эзләре күреп алды. Әйдә, ярар. Берәр рольгә керергә аның документлары бар ич.

Ул капканы тиз генә ачты да бераз хәл алды, ишегалдын, болдырны күзәтте. Шунда верандадан лапаска сузылган, кер элә торган баулар селкенгән кебек тоелды. Отто, аска карап, бик хәстәрле кыяфәт белән, болдырга таба якынайды. Ишеккә җитәрәк, артта «Һальт!» дигән ике карлыккан тавыш ишетеп, артына борылды. Лапастан ике полицай чыгып, мылтыкларын төбәп, Оттога таба килә башлады. Алар аны ниндидер начальник дип кабул иткән кебек тоелды, чөнки бик сүрән кыймылдыйлар иде. Полицайлар якынаюга, Отто кулын өскә күтәрде дә «Һайль!» дип кычкырып җибәрде, тегеләрнең йөзенә аптырау галәмәте чыкты, «һайль» дип әйтергә дә оныттылар. «Сезнең начальнигыгыз кайда?» – дип сорады Отто, бик коры гына. «Өйдә», – дип, ияк какты тегеләр. Отто шунда аларның икесенең дә шактый исерек икәнен чамалап алды. Начальниклары немец булырга тиеш, аның белән каты гына сөйләшергә кирәк. Ахыр чиктә үзен аларны тикшерергә килгән инспектор итеп тә күрсәтә ала бит ул.

Өйалдын, алгы өй бүлмәсен узып, эчке бүлмәгә керделәр. Өстәл янында немец офицеры тәмәке көйрәтеп утыра, алдында чирекле көмешкә шешәсе, савытлар, ашамлык-кабымлыклар тора иде. Отто, ишектән керүгә, кулын өскә күтәреп, тагын «Һайль!» дип кычкырып җибәрде, немец начальникларының шуны яратканын белә иде ул. Офицер, күзләрен әлҗе-мөлҗе китереп, муенын турайта алмый маташа иде, өстәлдә яткан кулын көчкә кубарып әз генә күтәрде дә, авыз эчендә ботка пешергәндәй, «Һайль!» дип кабатлады. Отто аңа карап

шаккатып калды. Бу – Андрей Милаш белән Клараның улы Радик иде. Ул бик нык эчкән, тәмам мәлҗерәгән, нидер әйтмәкче була, тик теле бәйләнә.

– Мине өлкә комиссариатыннан сезне тикшерергә җибәрделәр, – диде Отто, тавышын күтәрә төшеп.

Ике полицай ишекнең теге ягында шым булып басып тора, ә Радикның башы аска иелгән, үзе авыз эченнән нидер мыгыр-мыгыр килә иде. Оттога күтәрелеп карарга кыймый, начальниктан курка иде шикелле. Отто тиз генә исен җыеп кычкырды: «Лейтенантның башын салкын су белән юыгыз!» – диде. Ике полицай, мылтыкларын куеп, Радикны култыклап алып чыкты. Өй артында гына, туры лапас астында чыгырлы кое бар иде, шунда салкын су белән тегенең башын кат-кат ышкып юдылар. Алар маташкан арада, Отто өстәлдәге ветчина, казы кисәкләрен сыптырды, кыюлык өчен бер стакан көмешкәдән дә авыз итте... Хуҗаны алып киткәннәр, ахрысы, дигән фикергә килде ул. Ярар, белгертмәскә кирәк.

Менә мундирын төймәли-төймәли Радик килеп керде һәм өстәл түренә барып утырды. Ул инде бераз айныган кебек иде.

– Биредә бернинди вакыйга булганы юк... – диде ул, Оттога текәлебрәк карап. Радикта икеләнү, эчке көрәш барганлыгы йөзендә шәүләләр биегәннән күренде.

Отто полицайларга:

– Постларыгызга барыгыз! – дип кычкырды.

Тегеләр шыпан-шыпан чыгып китте. Ишек ябылгач, Отто мич артыннан урап чыкты, беркем дә юк икәненә ышангач, сүз башлады:

– Радик, син монда нишләп йөрисең? – диде ул, якын кешесенә эндәшкән кебек.

Теге һаман күзен акайтып карап каткан килеш утыра иде.

– Отто абый, бу әллә синме? – Радик тәмам айнып киткәндәй булды һәм ни өчендер як-ягына каранып алды.

– Мин булсам нишләтерсең?

Отто аңа авыр карашы белән кадалды. Радик бер мәлгә өнемме-төшемме дигән кебек әсәренеп торды. Юк, бу һич тә провокация түгел иде.

– Йа Хода, йа Хода! – дип, ул ике учы белән битен каплады. – Юк, мине күп сынадылар инде. – Андрейның улы башын тезләренә таба иеп бөгелеп төште.

– Нишләдең син, сволочь малай, ә? – диде Отто, фаҗигале, кайгыртучан кеше тавышы белән. Әлеге сүзләр тегене бу хәлләрдән суырып алгандай итте.

Радикта аек акыл һәм бераз гына оят дигән нәрсә сакланып калган икән әле. Бу, бәлки, үзен саклаудан килә торган инстинкт кынадыр...

– Адаштырдылар, Отто абый! – диде ул, битеннән учларын алып һәм, тураеп, тизрәк сигарет капты да көйрәтеп җибәрде. Үзе һаман, Оттога туры карарга кыймаган кебек, карашын читкә борды. Күңелендә уйлары һәм шикләре тартышканлыгы йөзенең әле агарып, әле күгәреп китүеннән сизелә иде.

Отто шунда ук һөҗүмгә күчәргә, бу адашканның миен айкап ташларга кирәклеген аңлады:

– Тиздән кызыллар килеп җитәчәк, аңлыйсыңмы син шуны, ә? – дип кычкырды Отто. – Иллюзияләр бетте!

– Да, иллюзияләр... – дип мыгырданды Радик. Ул әле шок халәтеннән һаман чыгып җитмәгән иде шикелле.

– Күзеңне ачып карар вакыт җитте түгелме, ә?

– Бәлки, йомар чак якынлашадыр?

– Әйе, котылгысыз җәза кылә. Качып калу мөмкин түгел...

– Әллә немецлар белән ычкыныргамы?

– Синдәйләрне алмаячак алар. Үзләре дә канга буялып беткән, тагын канга буялганны ник сыендырсын алар?!

– Юк, алырга тиешләр! Мин аларга хезмәт иттем... – Радикның куллары калтырый иде. Ул, калтырана-калтырана, тагын сигарет кабызды. Нервыланып, үзен белештермичә, тиз-тиз суыргаларга тотынды.

Отто да сигарет алып капты.

– Тагын иллюзия! – диде Отто, фаҗигале, сискәнүле төстә.

Радик җавап кайтармады, ул уйга чумган иде. Шулай тын калып, озак кына сигарет төтәттеләр. Радикның элеккеге әтәчлеге берсәк шиңгән кебек иде. Шулай да нәрсәгәдер өмет баглый сыман. Яшьлек томаннары таралып бетмәгән, ахрысы.

– Яшерен корал дигәннәре дә гадәти шапырыну булды микәнни? – дип, Радик башын күтәрде.

– Норвегиядә шул яшерен корал ясый торган заводны англичаннар бомбага тоткан. Разведкалары шәп эшли икән... – Отто бу адашкан җанны чынбарлыкка кайтарырга тырыша иде. – Дойчландны бар яктан кысып киләләр...

– Изәрләр микәнни? Да...

– Шултиклем кан коюга, син нәрсә, гадел җәза булмый калмаячак.

– Мине немецлар югары бәяли...

– Аларда хәзер һәркем үз башы өчен кайгыра. Немец өчен син хәзер чүп! Әнә руслар Польша – Румыния чигенә килеп җиткән. Тиздән Киевны алачаклар, ди.

– Бу зилзиләдән котылып булмас микәнни, шайтан алгыры! – дип, үтә дә ачыну белән әйтеп куйды Радик.

Отто, хәлне тагын да кискенләштерергә теләп, каяндыр колагына кереп калган хәбәрне әйтте:

– Беләсеңме, – диде, – немец башлыкларына яшерен боерык килгән, анда, барча шаһитларны тизрәк юк итү ягын карарга, диелгән. Аңлыйсыңмы, син немецларның бик күп канлы эшләрендә катнашкан, үзең дә канга буялган. Нишләп алар синдәй шаһитны үзләренә ияртсен? Мин дә ияртмәс идем. Немецлар ахмак түгел...

– Юк, киресенчә, шаһитларны биредә калдыру алар өчен куркынычрак бит.

– Менә шуңа күрә шаһитларны бетереп китәчәкләр...

– Фюрерның кыланмышлары авантюра гына булган, алайса? Ничек шулай бер төркем авантюрист бар халыкны алдый ала? Аптыраш...

– Коточкыч катастрофа булачак.

Тагын тынып калдылар. Бу хәлләрне ничектер акылга сеңдерергә һәм үзеңне шуңа көйләргә кирәк иде.

– Ә партизаннарга качсам? – Радик кабат Оттога текәлде.

Тегесе башын як-якка чайкап торды да:

– Койган каннарны казып чыгарачаклар. Барыбер үлем, ике тиен – бер акча! – диде.

– Әгәр хәзер үк китсәм, мин аларга файда китерә алам әле. Нүжәли шуны исәпкә алмаслар икән? Ялгышу бар, ялгышны төзәтү бар, ә?

– Белмим, русларның бәгырьләре бик каткан. Аяу көтеп булмый... – Отто бу мәлдә үзе дә немецлар белән хезмәттәшлек итүче сыйфатында сөйләште. Аңа вакытны сузу кирәк иде. Радикка һич тә серне чишәргә ярамый, дип уйлады ул.

– Мин үзем, шәхсән, бер кешене дә атмадым, – дип, саламга ябышырга форсат тапкан сыман әйтеп куйды Радик. – Облаваларда катнаштым, билгеле. Ә төп вазифам почтада эшләү булды.

– Чынлап та атмадыңмы? Булмадымы андый хәл? Никтер ышандырмый, чөнки немецлар канлы эшләрне җирле халык кулы белән эшли. Сине дә мәҗбүр итми калмаганнардыр.

– Бер-ике тапкыр булды бугай, бик нык исерек идем, берни хәтерләмим... Юк.

– Ә корбаныңның якыннары сине бик яхшы хәтерли булыр. Шаһитлар барыбер кала ул...

– Нишләргә соң, нишләргә? – Радик йодрыклары белән тез башларын үзенә үч һәм ачу белән төйде дә төйде. Муен тамырлары калынаеп, күгәреп китте, тамак төере терсәк башы сыман әле болай, әле тегеләй хәрәкәтләнде. Чигәсеннән тир бөртекләре агып төште. Ул яшь шул әле, дип уйлады Отто, аңа карап. Әле иманы утырмаган, уйлары эзгә салынмаган. Нәрсәгәдер һаман өмет итә. Кылган гамәлләренең никадәр яман булуын тирәнтен аңлап бетерми. Мөгаен, ул бүгенге көн белән генә яшәүчедер. Андыйлар да байтак бит... Тукта, әллә моңа этисенең нинди батырлыклар эшләп һәлак булганын сөйләргәме? Башындагы алсу томаннар таралып китмәсме? Бәлки, үзенең дә кызыллар ягында эшләвен тишәргәдер? Юк, ярамый. Әтисе хакында әйтсәң дә, бәяли алмастыр. Иллюзияләрен ничек чыгарып бетерергә соң бу адәм актыгының? Туганлык, әти-әнисен жәлләү хисләре аңа ничек тә ярдәм итүне сорый иде. Әмма ничек итеп? Ул үзе дә капкында ич. Өстәвенә бу малай бик тирән батканга охшаган, аны беркем дә тартып чыгара алмас. Әнә Рита апасы, энекәше, Виктор турында сорашып та карамады. Үз хәле хәл икән шул.

– Ничек син шулай түбән төшә алдың? – дип, аны авыр уйларыннан бүлдерде Отто.

Радик аңа карап куйды һәм, абыйсының йөзендә хәерхаһлык чаткысы күргәч, ачылырга теләп, иң элек бер стакан көмешкә салып эчте. Аннары сигаретын кабызды да чәчелергә кереште:

– Мине Баурих дигән СД агенты яллады, – дип башлады сүзен Радик. – Ул, партизаннардан сорау алганда, аерым тест куллана, кыйнамый-сукмый. Үзе бик мөлаем иде. Ахры, тест ярдәмендә мине дә капшап белгән ул, чат ябышты. Мин сине кеше итәм, диде. Үзеннән ычкындырмады. Бер чибәр кыз белән таныштырды. Түбән тәгәрәү шуннан башланды. Өйләнгәч тә, мине почта башлыгы иттеләр. Немецча әйбәт белә идем. Эшкә тиз өйрәндем. Кыз да немецча сөйләшә иде. Кайчандыр «Иске Васыять»тән «малай әти-әнисенә хыянәт итәр, хатыны итәгенә берегер» дигән сүзләрне укыганым бар иде. Әмма моның ни рәвешле эшләнүен күз алдына китерми идем. Әти-әнигә хыянәт итүемне сизми дә калганмын. Әни мине каргады, елый-елый, шул кыз белән араңны өз, дип ялварды. Ләкин мин инде хатын итәгеннән куба алмадым. Баурих мине еш кына кунак итә, сөйләндерә, күңелгә нидер сала иде. Кайчак, ничек белә ул минем баштагы уйларны дип, аптырап та калам. Уйлый торгач таптым: хатыным мин сөйләгән сүзләрне Баурихка түкми-чәчми җиткереп бара икән. Шуннан Зута белән аңлаштым. Башта танымады, каршы торды, соңыннан чишелде. Баурих аны ышандырган, иреңнең карьерасы өчен шулай кирәк, дигән. Әгәр син иреңнең бар уй-фикерен безгә ирештереп барсаң, без аны югары постка күтәрәбез, дигән. Чынлап та, гади хат ташучыдан башта бүлекчә мөдире, аннары бүлек башлыгы иттеләр. Яхшы квартира бирделәр. Ригада курсларда укып кайттым. Чинымны күтәрделәр.

– Хатының синең өстән шымчылык иткәч нинди гаилә була инде ул? – дип сүз кыстырды Отто.

– Була икән шул, – диде Радик, исе китмәгәндәй. – Бик әйбәт гаилә. Немецларда шундый тәртип икән. Бу дәүләт мәнфәгатьләреннән чыгып эшләнә һәм моңа беркем дә каршы килә алмый, ди. Әгәр карышучылар булса, аны җәзалыйлар. Җавапка тартып түгел, ә тормышта төрле киртәләр куялар икән. Берни эшли алмыйсың... Зута белән бозылышканнан соң, минем эш түбән тәгәри башлады. Юктан низаг чыгаралар, җанга диверсия ясап торалар. Чыдый алмыйча, авыздан нидер ычкына. Аларга шул гына кирәк тә. Мине шулай итеп эштән төшерделәр дә жандармериягә куйдылар. «Менә, – диде Зута, минем түбән тәгәрәүгә кайгырып, – миннән баш тартмаган, дуламаган булсаң, барысы да нормаль бара иде». Ул өйдәге низагны да Баурихка барып әйткән. Белмим, әллә тыңлап торганнармы... Немецларда ике йөз метрдан торып тыңлау аппаратлары бар. Үзем күрдем... Юк, мине немецлар калдырырга тиеш түгелләр...

– Ә монда әниеңә, туганнарыңа ни буласын аңлыйсыңмы?

– Аңлыйм. Нишләргә соң миңа?

Радикның соравына Отто ни дип җавап бирергә дә белмәде. Тирәнгә керергә теләми иде.

Ни уйлаптыр, Отто теге полицайларны чакырып кертте. Алар шактый сүлпән-үшәннәр иде. Шуңа Отто, үзен хуҗа шикелле тотып, тегеләргә берәр стакан көмешкә салып бирде. Бик теләп, ятатып эчтеләр. Күптән шуны көткән булганнар, күрәсең. Икесе дә латыш, хутор кешеләре икән. Ни өчен полицай булып киттегез?», дип сораганга «Җир бирделәр, ат, марка...» дип аңлатты өлкәне. Фамилиясе Лазан икән. Яшьрәге Янис исемле бик чибәр егет иде.

– Ә син?» – дип төпченде Отто.

– Миңа да җир, ат бирделәр. Үзебезнең атларны кырыгынчы елда артельгә җыеп алганнар иде, – дип җаваплады ул.

– Немецлар монда озак торачакмы? – диде Отто.

Полицайлар бер-берсенә карашып куйды, куркынган күзләре Оттоны кистереп алды. Оттода бернинди шантаж сизелми иде. Ул гади, ачык, мөлаем чырай белән карап торды. Тегеләр ни әйтергә белмичә сагая калды.

– Безнең анда ни эшебез бар? – диде Лазан, шешәдәге көмешкәне күзе белән үлчәп.

– Ничек булмасын, тиздән кызыллар киләчәк һәм сезне кылган эшләрегез өчен стенага терәячәк... – Отто бик ышанычлы тон белән, кире кагып булмаслык итеп әйтте. Шунда ук тегеләргә тагын берәр стакан көмешкә салып бирде.

Бераздан аларның күзләрендә вак тәңкәләр уйный башлаганны чамаларга була иде. Алар тагын, җавап эзләп, командирларына төбәлде. Радик карашын читкә алды, үз уйларына чумган төстә туктаусыз сигарет пыскытты. Янис кыбырсыграк икән, урындыгында боргаланды, арты гүя кадакка туры килгән диярсең. Лазанның яңак калкымнары шәмәхә төскә керде, борын кырыйлары кызарып чыкты. Үзе һаман, мәрхәмәт көтеп, Радикка төбәлеп утыра бирде. Ахырда Радик түзмәде, кычкырып:

– Үзегез койган кан өчен үзегез җавап бирегез, мин берни дә эшли алмыйм, сволочьлар! – дип әйтеп салды. Ул, кулын өметсез селтәп, бөтенләй алардан баш тарткан кыяфәткә керде.

– Күпме туганнарыгызның канын койдыгыз, халуйлар? – диде Отто

кырыс тавыш белән. – Һәр тамчы кан өчен башыгыз белән җавап тотарсыз, үч алу сәгате килеп җитәр! Ә сез, кабахәтләр, кан коюю болай гына үтәр дип уйладыгызмы? Юк, башка баш булыр!

– Безне мәҗбүр иттеләр, – диде Янис, кыюланган булып.

– «Мәҗбүр иттеләр» исәпкә алынмый, күпме кан коюың, җан кыюың гына чутланачак, башың белән түләргә туры киләчәк. Көнегез бетте, бәдбәхетләр! – Отто тагын да кырысланды, чөнки боларга сүзе үткәнен сизеп алды. – Сезне бернинди аяу булмаячак!

– Без – бәләкәй кешеләр, ни кушсалар, шуны үтәдек, – диде Лазан, аның тавышы калтыранды, бит җыерчыклары буйлап күз яшьләре агып төште.

– Әйе, Германиядән җир биләргә килгән колонистлар да тая башлады, димәк, тиккә түгел! – диде Янис үзен дә, башкаларны да ышандырырга теләгәндәй тавыш белән. – Ә без нишләргә тиеш, господин командир? – Янисның да бугазына төер утырды, сүзен әйтеп бетерә алмады. Башы күкрәгенә бөгелеп төште. Бәлки, көмешкә тәэсире генә булгандыр?

– Балавыз сыгып утырмагыз, сволочьлар! – дип кычкырды Радик, үз өстенлеген күрсәтәсе килеп.

Полицайлар аңа бик сәерсенеп текәлеп карап тора башлады, йөзләренә ачу төсмере чыкты. Немецларның моннан озакламый китәчәгенә тәмам ышанып җиттеләр шикелле. Икеләнүләре коелып төшкәндәй булды.

– Туктагыз, без гаепле түгел, без нишли алабыз соң? – Лазан еламсыраган тавыш белән чыелдап куйды.

– Әнә партизаннарга китегез, үләсегез килмәсә! – диде Отто, бер дә уенмуенга урын калдырмаслык итеп.

– Партизаннарга?! – дип, хәтәр гаҗәпләнде полицайлар. Тагын командирларына текәлделәр. Аннан Оттога шикләнеп карап алдылар.

Радик мин берни дә белмим, үз башыгызны үзегез кайгыртыгыз дигән кыяфәттә, читләшкән төстә утыра бирде. Оттога да бер сүз әйтмәде, бернинди реакция белгертмәде, чөнки аның үзенең дә башы тәмам каткан иде. Яшьлек исереклеге белән күп ялгышлар эшләнгән, хәзер шулар өчен башың белән түләргә кирәк. Уйланырсың, кодагый.

– Господин командир, безгә нишләргә соң? – диде Янис, ялварулы чырай белән Радикка төбәлеп.

Радик бераз дәшми торды да күтәрелеп бәрелде:

– Олагыгыз, сволочьлар, үз туганнарыгызны сатучылар! – дип, өстәл сугып акырып җибәрде.

Стакан, чынаяклар бәрелешеп, чылтырап, зыңлап куйды. Отто, хуҗалар кайда икән соң, нигә бер дә күренмиләр, кайда посып яталар, дип пошынып уйлады. Хуҗага күз төшереп кенә алырга иде, ичмасам. Кыяфәтеннән барысын да аңлар иде... Ул чирекле шешәне алды да дүрт стаканга да тутырып көмешкә салды. Шуның белән башка эчәр нәрсә дә калмады.

– Әйдә, эчегез! – диде ул, стаканын кулына тотып.

Полицайлар тагын командирларына күз сирпеп алды, стаканга үрелде. Отто күтәргән чакта, аңардан калышмаска тырышкандай, эчеп тә куйдылар. Кабымлыкка үрелмәделәр, бары тыннарын тышка өрделәр.

Отто сәгатенә карап алды да:

– Хәзер штурмфюрер Тоффен үзе тикшерергә киләчәк, барыгыз, постларыгызга басыгыз! – дип боерык бирде.

Полицайлар бу юлы Радикка карап тормады, тизрәк мылтыкларын алып

ишеккә юнәлде. Шулай да, Янисның хәрәкәтләрендә нидер сизенү һәм Отто сүзләрен бик үк санга сукмау галәмәте чагылып куйды. Отто моны күреп өлгерде, ашыгырга кирәклеген аңлады. Полицайлар постка басмаячак, ә Отто турында хәбәр итү өчен жандармериягә чабачак. Идарә биредән ерак түгел, алты чакрымда гына. Мотоцикллары булуы да мөмкин...

Отто урынынннан кузгалды, берара мәрткә киткәндәй, һаман айный алмыйча утырган Радикка карап торды, аннары, кысталган кешедәй, мин хәзер керәм, диде дә, ашыга-ашыга, ишеккә атылды. Тегеләр лапаста юк иде. Кое янында да күренмәделәр. Оттоның гөманы дөрескә чыкты. Шайтаннар! Астан гына бер-берсенә карашып алганнар иде шул. Отто нәкъ шул караштан бик шикләнгән дә иде.

Ул кое янындагы читәннән бакчага сикереп төште. Бәрәңге кишәрлегенең аргы башы кечкенә урманга барып тоташа иде. Ызан буйлап шул тарафка йөгерде. Урманга җитәрәк, мотоцикл тавышы башына китереп суккан кебек итте, аңа әллә нинди көч бирде. Урман эченә кергәч кенә артына борылып карады ул. Бер урман полосасыннан икенчесенә күчте, поши шикелле, вак-төяк куакларны ера-ера йөгерде...

### XXI

Отто икенче көнне яктырганда гына очрашу өчен билгеләнгән хуторга барып җитте. Калын урман буена урнашкан шактый җитеш, кызыл чирәп түбәле, берничә бүлемтекле йорт иде ул. Кырыйдан гына арба юлы үтә, юл буенда чыгырлы кое бар.

Хуҗаның бер аягы юк иде, тезенә каеш тасмалар белән агач аяк җайлаган. Йөзе ничектер төлкене хәтерләтә, алга таба очлаебрак тора. Күзләре калын сары каш астыннан бик тыныч, күп сер туплаган сыман ялтырый. Һәр хәрәкәтендә салмаклык, үзенә ышанганлык сизелә иде. Аны күргәч, Отто да бераз тынычланган кебек булды. Яныңдагы кешенең кәефе сиңа да күчми калмый шул. Отто беренче күрешкәндә әйтеләсе сүзләрне тегеңә ирештергәч, хәл-әхвәл белешүгә күчте. Шикләнмичә, ачылып сөйләшергә була, ахрысы, дигән уйга килеп, оккупантлар нишли, бик басымчак итмиләрме, дип белешәсе итте.

«Алар бирегә баш тыгарга шүрли, – диде хуҗа, эчке канәгатьләнү белән һәм калын урманга ымлады. – Даугавпилска кадәр тоташ бара ул. Анда Россия белән чиктәш урманнар, сазлыклар китә. Бик күп борынгы крепостьлар да партизаннар өчен уңай...

– Шунда яшеренеп яталармы? – дип сорап куйды Отто.

Хуҗа сагайды, артыграк сүз ычкындырып ташлаганын искәрде.

– Анысын төгәл генә әйтә алмыйм, – диде ул, сүзне бүтән дәвам итәсе килмәгән төстә.

Гомумән, бу аяксыз кеше белән уртак тел табып булмады. Бик аз сөйләшә. Тыштан керми, лапасында нидер кага-суга, бакчасында казына. Өстәлгә Отто белән бергә утырмый, гел телен йоткан кебек йөри. Шулай да әз-мәз генә сүз алышкан чакта да ул кызылларга тел тигереп алды. Шуннан Отто шикләнә калды, моның тотып бирүе дә бар бит, дип уйлады. Крестьянга ышанып буламы? Гариплеге бераз ышаныч тудыра иде, билгеле. СД агентлары аны хезмәткә ялламаган. Гарип булганга калдырганнар. Аяксыз сүз арасында шул хакта әйтеп куйды. Юкса немец агентлары һәркемне СД белән хезмәттәшлек итәр өчен имза куйдырып чыккан.

Хуҗа суны урамдагы коедан алып керә иде. Оттога уңайсыз булып китте.

Бу гарип эшләп тапкан ипи белән бәрәңгене ашап ята ич ул. Ичмаса, кайбер эшләрендә булышкаларга иде. Тик хуҗа Оттоны күрерләр дип курыкты, чөнки койма буеннан гына юл уза иде. Әллә Оттоның ашап ятуын өнәмичә, кызылларны сүгәме ул? Бәлки, шулайдыр. Крестьянга һәр сынык ипи кадерле, ул аны кара тир түгеп, газапланып таба. Бигрәк тә бу начар җирләрдә... Шулай да кызылларны өнәмәгәч, нигә үзе аларга ярдәм итә соң ул? Чынлап та, уйландыра иде бу нәрсә. Аның белән бәхәсләшүнең мәгънәсе дә юк кебек. Крестьянны берәр фикергә күндерү үтә дә кыен. Ул җир белән генә эш итә, җирне тыңларга, җир белән генә сөйләшергә күнеккән. Читтән аңа сүз керми. Отто моны җир кортлары булган абыйсы белән апасыннан чыгып белә. Тәмәке көйрәткәндә, Отто хуҗадан иплэп кенә сорап куйды:

– Ә син, агай, кемнәр яклы соң? – диде.

Тегенең бер дә исе китмәде. Гүя шул сорауны гына көтеп торган. Үзенең хуҗа булу өстенлеген белгертәсе килеп, ул тамак кырды, бераз уйланып торды.

– Кем яклы дип... Крестьянга ни аңа... Нинди власть килсә, шуңа бил бөгә ул. Җирдә тир, яшь түгәр өчен барыбер... Кайсы власть крестьянны кысмый, шул әйбәт. Кем яклы дигәндә, крестьян җир яклы, чөнки җиргә законлы хуҗа кирәк. Әйе, законлы – «никахлы» дисәң дә ярый. Ир затыннан башка бер хатын-кыз да бала таба алмаган кебек, хуҗасыз җир дә уңыш бирә алмый. Яки бик аз бирә. Ирсез хатын җилдән бала тапкан шикелле генә...

Җир мәсьәләсендә бу агай, кем әйтмешли, эт ашаган кемсә булырга охшый, аңа каршы килеп булмый иде. Отто кырыгынчы елны берләштерелгән эре терлекләрнең кыш буе кырылуын үз күзләре белән күрде. Аларны заводтан колхоз конюшнясына улаклар ясарга җибәргәннәр иде.

Торган саен биредә уңайсыз була барды. Отто хуҗага су ташырга булышкалый башлады. Күңел өчен бусы да ярап тора иде. Хуҗа ике чиләк белән суны коедан капкага чаклы китерә, аннары Отто эләктереп алып кереп китә. Лапастагы тимер мичкәләргә, өйдәге кисмәкләргә тутыра.

Шулай берничә көн үтте, әмма элемтәче күренмәде. Шачиннан кем дә булса килергә яки берәр боерык китерергә тиешләр иде. Хәзер бик катлаулы вакыт. Подпольеда калдырылганнарның кайберләре һәлак булды, кайберләре тотылудан куркып ята. Ник дисәң, немецларның җиңеләсе сер түгел хәзер, исән каласылары килә.

Алар су ташыган арада, кое янына бричка җиккән олау килеп туктады. Отто капка артына посып күзәтә башлады. Олаудан икәү сикереп төште. Берсе су чыгарырга тотынды, икенчесе чиләк алып килде. Атның авызлыгын салдырды. Чиләк белән суны ат алдына куйды. Су чыгарганы, кое бурасына чиләкне кыегайтып куеп, үзе озак кына эчте, аннары иптәшенә бирде. Тукта, болар иске танышлар түгелме соң? Шайтаннар! Алар теге полицайлар Лазан белән Янис иде. Анасын корт чаккыры! Әллә яннарына атылып чыгаргамы? Юк, булмый. Әһә, арбадагы йөк өстендә тагын ниндидер кеше ята икән. Менә аны башыннан тотып торгыздылар да, чиләкне кыегайтып, су эчерделәр. Әллә офицер мундиры кигән инде? Ә куллары алга чыгарып бәйләнгән. Нәрсә бу? Монысы да таныш лабаса, елбыр саргылт чәчле, ике якка шәрәләнеп эчкә кергән киң маңгайлы. Радик ич бу! Ник аны шулай иттеләр икән? Араларында нәрсә булган? Әллә аларны Оттоның сүзләре дошманлаштырганмы? Радикны кулга алып, каядыр алып баралар. Немецларга ярар өчен, үз аталарын сатарлар, валлаһи!

Юлчылар китте. Хуҗа, чиләкләрен тутырып, су алып килде. Отто үтә дә нык кызыксыну белән аңа карады, тегеләр турында сораштырды.

– Кая барганнарын әйтмиләр, – диде хуҗа, мыегын кул кырые белән сыпырып. – Тик моннан партизаннарга гына юл барса, башка җиргә – юк. Әнә немец оберын бәйләп алып баралар, партизаннарда ышаныч казану өчен. Әйе, әйе, бу беренче очрак кына түгел...

– Нүҗәли шулай икән? – дип, Отто хәтта ышанмыйча торды.

– Соң, немецлар корабына су керә башлады бит! Сизәләр күселәр, полицайларны әйтәм.

– Теләсә нинди хәлгә бик тиз җайлашалар, ай-һай!

– Анда, Россиядә, кайбер яшьләр карьера өчен эти-әниләреннән дә баш тарта, ди. Ә бу – гади бер эш...

Аның сүзләренә каршы Отто берни дә әйтә алмады, чөнки үзенең дә хәлләре туган абый-апасыннан баш тарткан сыманрак килеп чыкты. Шачин җитәкчелегендә эшли башлагач, туганнарына бер мәртәбә дә кайтып күренмәде. Хәлләрен чит кешеләр аша гына белешеп торды. Әгәр аралашса, туганнарының да, үзенең дә язмышы куркыныч астына куелачак иде. Менә хәзер ачык күренә, Отто сайлаган юл дөрес булган.

Тагын берничә көн узды. Аның белән күрешергә берәү дә килмәде. Чылбырның берәр боҗрасында тагын өзеклек килеп чыкты микәнни? Гестапо һәм аның арт ялаучылары тик ятмый шул. Шачин исән микән соң? Калнинь нишләде икән? Рутаның хәлләре ничек? Кичекмәстән аны күрергә кирәк. Ләкин ничек итеп? Оттоны бар төштә эзлиләр һәм эзләтәләр булыр. Рута бирегә килсен иде дә бит. Тиздән сугыш хәрәкәтләре тимер юл узелларына, зуррак шәһәрләргә күчәчәк. Ул тирәләрдән читкәрәк китеп баруың хәерле. Моны Рута үзе дә чамаларга тиеш...

Оттоның, көтеп ята-ята, сабырлыгы төкәнә башлады. Инде хуҗаның икмәге дә тамагыннан үтмәс булды. Ул аңа, шактый юмартланып, немец маркалары бирде. Шулай итмәсә, хуҗаның кызылларга карашы тагын да начараер дип уйлады. Марка гарипнең күңелен күтәрде, йөзе яктырып китте. «Болай икәнен белсәм, әйбәтрәк тәрбия иткән булыр идем», – диде ул. Отто аңа рәхмәт әйтте һәм, кич булып килгәндә, өйдән чыгып китте.

Элемтә юклыгы аны тәмам чыгырдан чыгарды. Аннары агачка бәйләп калдырылган канечкеч Эрхард та гел исенә төшеп, бимазалап тора иде. Кеше үтерүче үзенең җинаять кылган урынына тартыла, диләр. Чынлап та шулаймы бу, әллә бер канатлы сүз генәме? Отто ни өчен бу хакта уйлый соң? Ул бит җинаять кылмады, бары палачны канлы эшен дәвам итүдән генә туктатты. Ичмаса, берничә йөз кеше исән калыр. Ятимнәр, тол хатыннар әзрәк булыр. Полицайлар, никадәр кансыз кыланса да, Эрхардка ук җитә алмас. Җавап бирәсе булыр дип, бәлки, алар хәзер кан коюдан тыелыр да. Ә Эрхардка җавап бирү турында уй да килми, чөнки ул күбрәк үтергән өчен бүләк ала. Берсеннән-берсе кыйммәтле бүләкләр. Өстәвенә, булдыклы, тугры хезмәт итә, дип, үзен газетада да мактап язалар.

Оттоны тагын шунысы кызыксындыра: Эрхард эше бик тә уңа торган, судан коры чыгучан кеше иде, бу юлы да аны килеп коткармадылар микән? Оттоны гел бер сорау борчый иде: ничек итеп бу палачны кеше үтерергә өйрәткәннәр? Шуның сере ачылмыйча калды. Хикмәт үзендә генә булмагандыр... Бервакыт Эрхард әз генә ачылып куйды. Партизаннарга азык белән ярдәм итүдә гаепләнгән өч латыштан сорау алды ул. Тегеләрнең берсе дә гаепләрен танымады. Эрхард аларны бик нык җәзалады, әмма тоткыннар барыбер гаепләрен танудан баш тартты. Эрхард аларны үзе атмады, полицайларга

кушты, чөнки үз гаепләрен танымаучы латышларга бик каты рәнҗегән иде. Ул бу юлы алардан өстен чыга алмады. Процесс тәмамлангач, жандармерия идарәсендә Эрхардны шәп кенә сыйладылар. Ул Оттоны да эчертмәкче булды, кыстады, әмма Отто бирешмәде. Эрхард шунда аңа, яратам шул гадәтеңне, дип әйтеп ташлады. Отто аңардан кешечә сүз чыгуга бик нык гаҗәпләнгән иде. Бераз кызып алгач, Эрхард:

– Минем аларга бернинди ачуым юк. Әйе, ачуым да, үчем дә юк, – дип тә әйтеп куйган иде.

– Алайса, ничек соң... – Оттоның теле тотлыкты, сүзен әйтеп бетерә алмады, чөнки «үчем, ачуым юк» дигән сүзләргә тәмам аптыраган иде.

Эрхард барысын да бик гади аңлатып бирде:

– Мин аларны принциптан чыгып юк итәм, – диде ул. – Әйе, әйе! Барын да принципка сылтыйм. Күңелгә берни алмыйм. Мин принцип кушканны башкаручы автомат кебек кенә. Минем өскә бер җаваплылык та төшми. Принципны җитәкчеләр эшләгән, тормышка ашырырга безгә боерган. Без үзебезгә йөкләнгән бурычны үтәүчеләр генә. Кызылларда да шулай ул. Париж коммунасы тарихын хәтерлә. Бөек химик Лавуазье булган, кислород белән водородны ачучы. Коммунарлар аны, тәмәке белән сату иткәне өчен, гильотинада башын кискәннәр. Беркемнең аңа һичбер үче, ачуы булмаган. Спекуляциягә каршы законга нигезләнеп, шул принципны тормышка гына ашырганнар...

Моңа каршы Отто берни дә әйтә алмады, чөнки коммунарларның андый явызлыклары турында белми иде. Бәхәскә дә кереп булмый. Гитлерчылар үзләрен бар яктан хаклы саный, хаклыкларын җиңүләре раслый иде. Менә хәзер җиңелә башладылар, бик нык каушаулары һәм нервланулары сизелә. Шулай да принципларында каты торалар әле. Эрхардның үз корбаннары турында «минем аларга карата бернинди нәфрәтем юк», дип әйтүе Оттоның һаман хәтерендә әле. Ничек аңларга моны? Нәфрәт булмаса, тере кешегә ничек мылтык төбәмәк кирәк? Аларда «ни өчен?» дигән сорау тумый микәнни? Адәм баласы яралганда ук шундый сораулар белән туа ич. Күңел конфликты була нормаль кешедә. Гитлерчылар адәм баласында күңел конфликтын һәм «ни өчен?» дигән сорауны ничек томалаган? Нәрсә белән, ни бәрабәренә? Киләчәктә яхшы тормыш вәгъдә итепме? Бары фюрер әмеренә буйсындыру аркылымы? Тоташ куркыту атмосферасы тудырыпмы? Әйе, алар, тоталь куркытып, кешеләрдә туа торган «ни өчен?» дигән сорауның тамырына балта чапкан. Үз башын, җанын саклар өчен, һәркем эндәшмәскә тиеш була. Ялганны чын итеп күрә һәм шул ялганга хезмәт итә. Бу бит шул ук коллык түгелме соң? Бәлки, культуралы коллык дияргә дә буладыр. Син боерыкны үтәүдән, эш башкарудан башка берни белмәскә, кызыксынмаска тиеш. Эшләрең өчен син җавап бирмисең, фюрер аны үз өстенә ала, имеш. Менә солдатларның кулларын ни рәвешле чишкәннәр. Үтер, бетер, ләкин син җаваплы түгел... Бу кан коюлар барысы да Ватаныңның киләчәге, бәхете өчен эшләнә. Башка ырудагы халыкларны кырып бетерү хисабына бәхет була ала микәнни? Юк, башыңда шундый сорау туса да, син аны әйтмәскә тиеш. Бернинди шик булуы мөмкин түгел. Бу идеологиягә әз генә шик белдерү дә аяусыз хөкем ителә. Шуңа күрә адәм балалары телләрен тешләргә мәҗбүр була. Гаять көчле яшерен террор барча тере җаннарны дер калтыратып тота. Әлеге хәлләргә әз генә кырын караганнар төнлә нәсел-ыруы белән юкка чыга. Серле юкка чыгу бар нәрсәләрдән көчлерәк тәэсир итә. Һәркем үз башын кайгырта. Кеше

үзенең бер гаепсез туганын яклый алмый. Бер гөнаһсыз хатынын аралаудан да мәхрүм. Якласа, үзен гаеплиләр һәм ул бер төнне юкка да чыга... Димәк, табигате белән яхшы кеше, әйбәт тәрбия алган булса да, барыбер гамәлдәге тәртипләргә буйсынырга мәҗбүр. Кешелекле булуына карамастан, боерыкка буйсынып, тере җаннарны бетерергә, кырырга тиеш. Юкса үзе һәлак ителә. Менә сайла: йә үлем, йә үзең ишеләрнең канын кою. Һәр тере кешенең ничек тә гомер итәсе килә һәм ул, гадәттә, соңгысын сайлый...

Отто теге урманга икенче көнне кич кенә барып җитте. Төнне бер хуторның ындырындагы салам кибәнендә яшеренеп уздырырга туры килде. Суык иде, шактый туңды. Таңнан торып, юлга ашыкты. Шунда гына аякларына, эченә җылы керде. Ярый әле аяк асты коры иде. Һәр иртәдә мул булып кырау төшә.

Ул Эрхардны калдырып киткән җиргә керергә бүген батырчылык итмәде. Кыр аша узгач, урман кишәрлеге бар иде. Отто шуннан ерак түгел тукталды да күзәтә башлады. Чыбык-чабыклар өстенә утырып, кичке шәфәкъның сихри матурлыгы белән юанып, урманны, аңа алып керә торган арба юлын күздән кичерде. Тирә-юньгә дикъкатен юнәлтте. Анда-санда күренгәләгән саескан, каргаларга игътибар итте. Алар кайда ни барын, тавыш биреп, бик тиз белгертеп тора. Җәнлек үтеп китсә дә, сизгерлек күрсәтәләр. Иптәшләренә сигнал биреп, кычкырып-кычкырып куялар. Әмма бүген урман тын иде. Каргалар, чәүкәләр кырда чүпләнеп йөри-йөри дә, очып килеп, кырыйдагы агачларга куна.

Моннан унбиш-егерме көн элек урман яшел иде әле. Ә хәзер сары, сары-кызгылт төскә кереп бара. Көн саен төшеп торган салкын кыраулар шулай иткән инде. Урманда каен һәм өрәңге агачлары күбрәк икән. Кайбер агачларның яфраклары коелып бетә язган, кайберләренеке әле коела гына башлаган. Бар төштә яфраклар кыштырдавы ишетелә. Имештер, яфрак кыштырдавы куяннарны шөбһәгә сала, шуңа күрә алар, бу кыштырдаудан качып, япан кырларга китә икән.

Шул мизгелдә Отто кинәт Рутаны исенә төшерде. Әйе, аңа Рута белән кушылырга кирәк булыр. Ул үзе дә шуны бик тели, Оттоның да башка сыеныр кешесе юк. Кыз аның авыр кайгысын җиңеләйтте, дөньяда яшисе килү хисен кабат уятты. Хәзер ул үзе дә аны бик еш искә төшерә. Акылы искә төшермәсә, тәне һәрдаим искә төшереп тора. Тән әллә акылдан көчлерәкме? Әйе, тәннең дә таләбе көчле. Үз-үзеңнән беркая да китә алмыйсың. Элек ул тәненең аваз салуын ишетми, сизми иде. Ул авазны Ритасыз яшәү томалап торган икән. Менә Рита югалганга да ике елдан артык вакыт үтеп киткән инде. Җанындагы киеренкелек бераз кими төште шикелле, тәне дә үзенең барлыгын, исәнлеген сиздереп куйгалый башлады. Ә Ританы Рута алыштыра алырмы соң? Рита бик назлы да, нәзакәтле дә хатын иде. Ничектер аның белән үзеңне тагын да баеган, яңарган кебек хис итә идең. Ул сине әледән-әле яңартып тора. Ничек шулай итә алды икән? Нинди рухи көч салып? Рита рухы белән юмарт, тәне белән бер дә туйдырмый, акылы ягыннан тормозы да тота белә торган хатын иде. Ирләр өчен әнә шул тормозы да бик мөһим бит!..

Рутаны тизрәк күрәсе иде. Ул бик куркыныч эштә йөри, һәр көне кыл өстендә үтә. Мөмкинлек булса, аны бу эшеннән азат итәргә, шул хакта Шачиннан сорарга кирәк. Хәзер күп нәрсәләр ачыкланды, немецларның вакытлы гына икәне тәгаен аңлашылды. Латыш крестьяннарына бу инде сер түгел. Ә аларга саклану чаралары күрергә кирәк. Исән каласы килә бит, шайтан алгыры!

Төне буе Оттоның миен ачы уйлар ермачлап бетерде. Төн суык иде, һич тә йоклап булмады.

Иртән ул тагын күзәтү белән мәшгуль булды. Тынлык аңа бик шомлы тоелды. Әллә засада куелганга, тирә-якта шундый тынлык урнашты микән, дип тә уйлап куйды ул. Тик күпме генә күзәтеп торса да, шикләнерлек, шөбһәләнерлек берни сизмәде. Куенына җайлаган пистолетының предохранителен ычкындырды да ары таба кузгалды. Урман авызында адымнарын акрынайта төште.

Теге юлны тиз тапты ул. Бар җиргә сары яфрак түшәлгән. Шулчаклы да мул яфрак булыр икән. Салам җәйгән ындыр табагыннан көчкә атлаган кебек барасың. Менә юлга аркылы аударылган каен күренде. Беренче шлагбаум. Бераз киткәч, икенче каен юлга киртә булып ята, аннан илле метрлар ары өченче каен да җирдән җәнлек үтәрлек ара калдырып ауган иде. Шуны узгач, юлның сул ягында куш каен булырга тиеш. Кара, ничек барысы да танымаслык булып үзгәргән. Кайбер агачлар бөтенләй шәрәләнеп калган, урман яктырып киткән.

Өченче киртәне узгач, Отто як-ягына дикъкать белән карап бара башлады, әмма теге куш каен юк иде. Ул бер чокырга килеп төртелде. Каян килгән бу? Чокыр аның хәтерендә калмаган иде. Димәк, ул чокыр аша чыкмаган. Отто кире борылды. Бигрәк тә уң тарафны җентекләп күзәтеп, таягы белән яфракларны актарып-актарып барды. Тукта, менә бит ул куш каен. Аны зелпе куагы каплап тора икән. Нишләптер бу Оттоның исендә калмаган. Ул Эрхардны куш агачның икенче ягына бәйләп куйган иде бит. Ә хәзер бу урында берни дә юк. Нүжәли килеп коткардылар икән? Әллә полицайлар эзләп таптымы? Алар инде үз урманнарының һәр түмгәген яхшы белә.

Отто таяк очы белән куш агач төбен актара башлады. Иң элек буялып беткән ак материя күзенә чалынды. Икенче кырыйдагы яфрак катламын кузгаткач, ап-ак баш сөяге килеп чыкты. Шунда ук аксыл умыртка баганасы, кабыргалар аунап ята иде. Ничек болай соң бу? Әллә берәр җәнлек итен кимереп бетерде микән? Бик гаҗәп бит бу. Ул Эрхардның үле гәүдәсен күмеп куярга дип килгән иде. Менә нинди гайре табигый хәлгә очрады...

Ул, бераз читкәрәк тайпылып, яфракларны актарды. Шунда чүмәлә чаклы, кыймыл-кыймыл килеп торган кырмыска түмгәген күреп алды. Күзләре күргән нәрсәгә ышанмый торды. Да, менә ничек булып чыккан икән... Кырмыскаларның үлгән атны да сөяккә калдырганчы чистартып бетергәннәрен ишеткәне бар иде аның.

Оттоның тәне буйлап өшеткеч калтырау узды. Югыйсә ул бу мәлдә үч кайтарудан канәгатьлек тоярга тиеш иде. Әмма күкрәгенә әллә нинди авыр таш кебек борчу тулды, йөрәген шул сызлатып, ачыттырып узды. Ул тизрәк бу төштән китү ягын карады.

Кайту юлын Отто бик авырлык белән үтте. Эчендә нәрсәдер өзелгән кебек булды. Шул халәт буыннарының хәлен дә алгандыр, мөгаен. Нәрсә булды соң аңа? Кеше үтергән кеше үзе дә шул мәлдә яртылаш үлә, дигән әллә кайчангы сүзләр исенә төште.

Аяксыз, кыйналып ташланган эттәй, гәүдәсен көчкә-көчкә сөйрәп, теге хуторга килеп керде ул. Хуҗа да, аны күргәч, куркып киткәндәй итте, хәлен сорашырга тотынды.

Отто күпме генә ачыккан булмасын, тамагыннан бер тәгам үтмәде. Әзрәк сөт эчкәләде. Хуҗаның сөтле кәҗәләре бар иде.

Ул югалып торган арада бирегә килүче булмаган. Отто үз хәленең шәп түгеллеген аңлады, ничек тә Рутаны табарга кирәк дигән ныклы карарга килде. Ләкин үзе булдыра алмаячак ул бу эшне. Әллә хуҗаны Добэлегә җибәрергәме? Маркалар бирсәң, барыр шикелле...

## XXII

Бу тетрәндергеч хәлләрне, вакыйгаларны Таня әнисе һәм Рута сөйләве буенча белде. Немецларның ерткычлыклары хакында укып, ул болай да күп нәрсәләрдән хәбәрдар иде инде. Оккупациянең тере корбаннарын күргәч һәм аларны тыңлагач, немецларның элекке ерткычлыкларына тагын да җан өшеткечрәк явызлыклар өстәлде.

Таня әнисен сугыш беткәч тә эзли һәм эзләтә башлады. Бу эштә аңа Альфред та булышты. Ул артиллерия училищесының җиденче бүлегендә эшли башлаган иде. Төрле адресларга язулар берни дә бирмәде. Ә үзең барырга мөмкин түгел иде. Хәрби булмаганнарны Латвия җиренә кертмиләр.

Кырык алтынчы елның җәендә генә Елгавага килә алдылар (шәһәрнең Митава дигән әүвәлге исемен шулай үзгәрткәннәр иде). Альфред частьтан командировка юнәтте. Шуның литеры белән килделәр. Елгаваның элеккедән калган хәрби шәһәрчеге бар иде. Ул ничектер бөтен көе сакланган, аңа бер бомба да төшмәгән. Таня, үзләре яшәгән кызыл кирпеч йортны күргәч, сөенеченнән кычкырып җибәрде. Станциядән хәрби шәһәрчеккә килгәндә, җимерек йортлар күп очрады. Әллә нинди ымсындыргыч өмет белән, Таня йөгерә-йөгерә баскычтан менеп китте. Альфред аста көтеп калды. Әмма Таня бераздан бөтенләй сүрелеп, кара коелып килеп чыкты. Хәзер бу йортта хәрбиләр генә яши икән. Альфред барып урнашыр урын өчен кайгыра иде. Ул, Таняны юатырга тырышып: «Күз яшеңне сакла әле, кирәк булыр», – диде, ни әйтергә белмәгәч. Таняның керфекләре юешләнеп, укмашып-укмашып тора иде.

Алар штабка килде. Альфред юл кәгазьләренә тамга куйдырды. Әмма урнашыр урын мәсьәләсе бик кыен икән. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга дигәндәй, аларны бик авырлык белән ике катлы бинада урнашкан санчастьтагы кысан каптёркага керттеләр.

Таня иртүк шәһәргә чыгып китте, госпиталь, больницалар буенча йөрде. Бер госпитальдә аңа Кларааны белгән санитар хатын очрады. Ләкин ул яхшы хәбәр әйтмәде: «Мин Кларааны советлар килгәч алып киткәннәр дип ишеттем, – диде. – Чөнки ул немецлар больницасында эшләгән иде. Шуның өчен гаепләгәннәрдер дип уйладым». Кларааны белә торган икенче бер хатын: «Аны партизаннарга дару, дәвалау әйберләре биргән өчен немецлар аткан икән дип ишеттем, – диде. – Немецлар партизаннарга аз гына мөнәсәбәте булганнарны рәхимсез кыра иде. Шуңа Клараның холкын бераз белгәнгә күрә, мин ул хәбәргә ышандым...»

Таня әтисе турында да сорашты. Тик аны белүчеләр бөтенләй очрамады. Кыскасы, элеккегеләрнең кайсысы немецлар килгәч каза күргән, кайсысы, руслар килгәч, гаепләнеп, Себергә озатылган. Себердә латыш бистәләре дә бар, имеш.

Сугыш алдыннан Милашлар хезмәт иткән хәрби частьның да эзе калмаган. Шәһәр җимерелеп бетә язган, кеше язмышлары да асты өскә килгән. Хәлләр хәзер дә бик киеренке, кешеләр бер-берсеннән курка. Бер кешедән бер сүз ала алмыйсың. Белгәнен дә әйтергә шикләнәләр. Бу тоташ курку кешеләрнең канына сеңгән, йөзләренә чыккан. Кемгә генә барып төртелсәң дә, ул сине бик сагаеп кабул итә, күбрәк «белмим», «күрмәдем» дию белән чикләнә. Үзенең яхшылык эшлисе дә килә, синең хәлеңә керергә тели, ләкин эчендә оялаган курку телен йозаклый да куя.

Таня елады да елады. Чишенеп караватка яткач кына, бераз тынычлана төшкәндәй булды.

– Биредә кешеләр хәзер бер-берсеннән курка, элек бер дә андый нәрсә сизелми иде, – диде ул, авыр көрсенеп.

Альфред исә бу хакыйкатьне тормышта күреп, эчтән генә сизеп яшәсә дә, «шулай кирәк» дигән ышанычы нык иде.

– Фашистлар йөрәкләрен алып бетергән, әле ирекккә күнегеп житә алмыйлардыр, – диде ул, Танянын үртәлүен тизрәк төкәндерергә теләп.

– Куркытылган кеше үзен генә кайгыртырга мәҗбүр, – дип, Таня сүзен дәвам итте. – Нигә, әллә Казанда шулай түгелме?

– Ул курку түгел, Таня, җаваплылык. Ә син көлмә, кешеләр ил мәнфәгате өчен үзләрен чикли дә ала... Бу – кирәкле нәрсә...

– Яхшылык кылудан тыелуны да кирәкле дисеңме? Шулай дөрес дип уйлыйсыңмы? – диде Таня, үртәлеп. Ул бүген үзенә ярдәм итәсе килмәгәннәрне күп күрде, шуңа эчендә кемнәргәдер ачуы, үче кузгалган иде, шул ачуын Альфредка чыгарасы килде. – Димәк, һәр кешегә яхшылыкны дәүләт үлчәп кенә бирә. Начарлыкны да шулаймы? Анысын да үлчәп кенә бирәме?

– Нигә, начарлыкны сиңа күп итеп бирүләрен телисеңмени? – диде Альфред, шаяртулы тонга күчеп.

– Кешедәге яхшылык та, начарлык та дәүләт милке булуына гаҗәпләнәм. Бу турыда, үз башыма төшмәгәч, ничектер уйламый идем, менә хәзер күңелдә шул гына... Бездә Рәүфәт Газизович атлы врач бар иде. Юаш, күндәм кеше иде. Шуны, әй, кыерсыттылар да инде. Бер лавеласы хатынын тартып алды. Начар күңелле, тискәре холыклы бәндәләр шул яхшы кешене политик яктан ышанычсыз дип тә кимсетте. Җыен әтрәк-әләм, шуны рәнҗетеп, үзенә политик капитал эшләде. Ә ул кинәт инфаркттан вафат булды, бичара. Җирләгәндә, веноклар бик күп иде. Үлгәч инде аңа нәрсәгә...

– Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың?

– Димәк, кешене чынлап хөрмәт итүгә караганда, веноклар очсызрак...

– Дөрес тотып алгансың...

– Шәхестәге яхшылык һәм начарлык дәүләт карамагында, әйе бит?

– Ярар, синең хакка гына килешәм.

– Шаяртма, мин чынлап әйтәм. Ягъни, кеше үзендәге яхшылык һәм яманлыкны теге яки бу адәмгә дәүләт рөхсәте белән генә күрсәтә ала. Үз ихтыяры белән түгел, шулай бит? Әллә мин ычкынып бараммы соң? Мине чеметеп кара әле...

– Әйе, чынлап та, акыл иясе булып киткәнең сизелә шул, – диде Альфред һәм Таняның көрәнсу төстәге мул күкрәген чеметеп алды. – Авырттырдыммы?

– Башкасы булмаса да, чеметергә оста икәнсең, – дип кеткелдәде Таня һәм шунда ук аның йөзендәге җылылык бетте. – Әллә минем сүзләремдә дөреслек юкмы, ә?

– Бардыр, ахрысы, Таня, тик синең өчен генә...

– Боргалама, – дип бүлдерде аны Таня, җитдиләнеп. – Ничә процент дөреслек бар ул сүзләрдә?

– Ничә процент дөреслек өчен утырталар, диген. – Альфред буыла-буыла көләргә тотынды.

– Димәк, син дә мине хуплыйсың?

– Юк-юк, Таня, мин шаярттым гына! – диде Альфред, көлүеннән туктап. – Без кирәкмәс нәрсә турында сөйләшәбез. Бу безнең компетенциядә түгел бит.

Нигә баш ватып маташабыз? Без үзебезгә генә начар эшлибез, чөнки башка килгән һәр фикерне әйтү куркыныч, үзең дә беләсең. Шаярып сөйләшкән сүзнең кайчак, баш миенең берәр почмагында кысылып калып, кискен мәлләрдә авызыңнан ычкынуы мөмкин. Шулай бит?

– Син – булган кеше, Альфред, дөрес сукалыйсың. Мин дә нәкъ шулай уйлыйм. Ләкин минем синнән яшерен бер уем да булырга тиеш түгел. Менә шуңа күрә генә мин сиңа аларны әйттем...

– Әйтмәскә кирәк иде, – диде Альфред, үкенечле тавыш белән. – Безнең болай да ипсез араны ул тагын да катлауландыра гына бит...

– Мине – артта калган, үзеңне алдынгы фикерле, дип әйтмәкче буласың инде?..

– Таня, тормыш таләпләренә буйсынмыйча ярамый, юкса арбадан төшеп каласың. Бервакытта да җиңел заман булмаган... Заман кешене үзенең кануннарына буйсындыра, шунсыз тормыш бармый. Синнән бүген кешеләр куркып йөз чөергән икән, бу да заман галәмәте. Шуны аңла да шым бул. Заманга карышсаң, ул да сиңа карыша. Төшенәсеңме?

– Юк, Альфред, юк, – диде Таня, кинаяле уфтанып.

– Мине тыңламыйсың син, Таня, шуңа төшенмисең. Теләмисең...

– Теләп кенә булмый ул...

– Әйе, минем сине үземнеке итә алганым юк, шунлыктан сиңа бер сүзем дә үтми, стенага борчак сипкән кебек кенә...

– Үзеңнеке ит соң, ит!

– Кара, син нинди сүзләр сөйли башладың. Монда килгәч, бөтенләй үзгәрдең! Сиздем, башка ир-атларга күзең елтырый, – дип, Альфред, нindидер кызышу белән, Таняны чишендерә башлады. Бар нәрсәләрен салдырып бетерде.

Тәрәзәдән төшкән ак төн яктысында ымсындыргыч матур сын, сыек кына нурланып, тагын да гүзәлләнебрәк күренә иде. Ул, вак-төяк кимчелекләреннән дә арынып, сихрилеге артып, үзенә бөтереп ала торган тылсымлы көчкә әверелде. Шул тарту көченә чыдый алмыйча, Альфред чырае белән Таняның күкрәгенә капланды, ләкин башка берни дә эшли алмады. Нәрсәдер эшләргә кабат-кабат омтылыш ясап карады, әмма, берни кыла алмыйча, кире чигенде. Күңел ярсуына тән берничек тә җавап бирерлек хәлдә түгел иде... Бермәлне Таня үзенең күкрәгенә Альфредның күз яшьләре тамганын тойды. Ул яшьләр тәнне пешерә, учактан чәчрәгән утлы күмер кебек иде. Таня аны тагын да ныграк үзенә кысты, һәм ихтыярсыздан күз яшьләре агып китте. Ул, Альфредны йомшак куллары белән сыйпый-сыйпый, яшь баланы юаткан шикелле тынычландырмакчы булды. Әмма Альфред тиз генә тыела алырлык хәлдә түгел иде. Алар шулай кочаклашкан көе озак үкседе.

Һәм мондый хәл еш кабатлана, ләкин аның һәрберсе бүтәнчә, бер-берсенә охшамаган иде. Биредә хәтта Таняның гүзәллеге ярдәм итә алмады. Ә бәлки, шул гүзәллекнең гаебе дә бардыр әле. Гүзәл хатын-кызны һәр ир-ат үзенеке итәргә омтыла. Билгеле, хикмәт анда гына түгел, бар бәла Альфредның коточкыч ярасында. Сугыш ярчыклары аның яшәү тамырларын өзгәләп бетергән. Нервыларның кискәләнүе бик хәтәр икән. Бар нәрсә нервыга бәйләнгән, ди. Нервысы беттеме – кеше дә бетте дигән сүз.

Әллә хикмәт башка нәрсәдәме икән? Бәлки, Альфредның тәне Таняның тәнен кабул итмидер? Мондый хәлнең дә булуы мөмкиндер ич. Врачларның үтенүе һәм үз ихтыяры белән Таня зур фидакярлеккә барды. Дәвалаучы врач

аны бик озак үгетләп көндерде: «Менә, – диде, – фашист ярчыгыннан яраланган лейтенантка бик мөһим дару кирәк. Ул дару – син, синең тәнең. Менә шуны лейтенантка кызганмый бир...» «Ә моның соңы ни булыр?» – дип кызыксынды Таня. «Әгәр ошасаң, ул сиңа өйләнер, ошамасаң ташлар, анысына да әзер бул, – диде Дания Әхмәтовна. – Хәзер һәркемнән корбан сорала. Җиңү өчен...»

Таня Альфредны яхшы ук өйрәнде, дүрт ай буе диярлек аңа укол кадады, дарулар эчерде. Врачларның сүзенә каршы килмәде. Аларның мөнәсәбәте ныгый барды, үзара шаяртып та, җитди темаларга ачылып сөйләшүләр дә үзенекен итте. Ниндидер бәйрәм уңаеннан Таня Альфредны бүлмәсенә алып кайтты. Үзе тулысы белән аның ихтыярына бирелде. Дөрес, очсызланмас өчен, ул бераз карышып та маташты, егетне кыздыру өчен, бусы да кирәк иде. Аннары Таняның үзе теләп бирелгән кызлардан егетләр тиз бизә дигәнне дә ишеткәне бар иде. Кадереңне җибәрәсең килмәсә, әзрәк каршы тору да файдалы. Таня да шулай итте, Альфредның хәрәкәтләренә ялындырыбрак риза булып торды. Егет аның җанына да якын, күңеленә дә хуш иде.

Таня Альфредны акылы, уйлары белән яратты. Дөрес, ул үзе гашыйк була торган зат түгел икән, бергә сөйләшкән, дуслашып йөргән чакта кыз шуны аңлады. Хәзер ул аны җаны, тәне белән дә ярата башларга тиеш иде. Ләкин бу юлы да андый нәрсә булмады. Альфред, үзенең кыз алдында кабат уңайсыз хәлдә калганына үртәлеп, кинәт ятактан торды да, өстәл янына барып, тәмәке кабызды. Таня, өстенә җәймә генә тартып, аны сабыр гына көтте. Альфред бер папиросын тартып бетергәнче икенчесен кабыза иде. Таня зиһенен эшләтте, болай барча тырышлыклар җилгә очачак иде. Альфред аның янына башка бервакытта да килмәячәк, бу бүлмәгә аяк атламаячак иде. Ул халатын иңенә салды да Альфред янына килде, йомшак, кайнар куллары белән аның муеныннан кочып алды, иреннәннән, битеннән үбәргә кереште, колагына пышылдап кына: «Болай сиңа рәхәтме, әллә җирәнгечме?» – дип сорады. «Рәхәт», – диде Альфред, шулай ук кызны кочаклап...

Ул вакыттан соң Альфредка өч тапкыр операция ясадылар. Соңгысын Мәскәүдән шул өлкәдәге зур белгеч килеп эшләде. Бик өмет кузгата торган итеп алдан сөйләгәннәр иде. Операциядән соң Альфред, үзен сынар өчен, кабат Таня янына барды. «Юк, сине болай түбәнсетүемә түзә алмыйм, әйдә язылышыйк», – диде. Таня берсүзсез риза булды. Егетнең әйбәт кеше икәненә ул ышанган иде инде. Аның баш бәласен Танядан башка аңлаучы да табылмас иде. Ул, егетне сафка кайтару өчен, берни дә кызганмаячак, терелгәч ташлап китсә дә, аңа үпкәләмәячәк иде.

Ләкин операция өметләрне акламады. Тагын уңышсызлык килеп чыкты. Инде Альфред үзе дә нишләргә белми. Таняны җәлли. «Минем өчен үзеңнең яшьлегеңне корбан итәсең, – дип кайгыра. – Мин – корыган агач, ахры, үзәгем корыган, яшел яфрак ярмам...»

...Альфредның биредә эшләре күп булып чыкты. Таняның әти-әнисен эзләшүдә артык катнаша алмады. Таня шәһәр буйлап күбрәк үзе чапты. Алтакта куелган оешмаларга кереп, сорашкаларга да туры килде. Ни булса, шул булыр дип, «ЗАГС» дигән учреждениене дә читләтеп узмады. Монда архив туплый башлаганнар. Фотолабораториясе дә бар икән. Зур гына бүлмәдә җепләргә озын-озын фотоплёнкалар эленгән. Киптерер өчендер, мөгаен. Ә бер стена буйлап өстәлләр тезелеп киткән, анда пыяла астына фоторәсемнәр куйганнар. Пөхтә генә киенгән хатын-кызлар шул карточкаларны карап йөри иде. Таня да алар янына барды, сүз катты. Аңа, фашистлардан калган

плёнкаларны биредә ачыгайталар икән, дип аңлаттылар. Немецлар үзләре үтергән партизаннарны һәм властьларга каршы эшләре өчен җәзаланган кешеләрне фотога төшереп барган. Үз идарәләренә хисап өчендер дип уйларга кирәк. Әмма, качып киткәндә, негативлар белән тулган әрҗәләрне алырга вакытлары булмаган. Хәзер безнекеләр шуларны ачыклау белән мәшгуль икән. Бик җитди документлар бит. Әти-әнисен югалтканнарга, туганнарын эзләүчеләргә күп нәрсәләр сөйли торган фотолар. Союздан да эзләп килүчеләр бар, ди. Кайберәүләр фотодагы кешеләрне танып, копиясен ясатып алып китәләр икән. Билгеле, күпмедер түләп инде. Бик кирәкле эш оештырганнар. Көн саен яңа фотоларга өстәлләр куялар. Анда сыймаганнарын стеналарга стенд итеп беркетергә дә иренмәгәннәр. Нинди генә фоторәсемнәр юк монда! Немецларның ерткычлыгын сүзсез фаш итәләр. Кайбер фотоларга эсэсчылар, латыш полицайлары да эләккән. Анда өлкә комиссары, эсэсчы фон Медемның тар даирәдә бер тантана уңаеннан төшкән рәсеме дә бар. Пенсне күзлеге артыннан боздай салкын бәбәкләр карап тора. Янәшәсендә куштан елмаю белән яраннары тезелешеп баскан. Чит җирләрне басып алып, ниләр генә кылып бетермәгәннәр, Латвияне канга батырганнар.

Таня бу күргәзмәгә көн дә бер кереп чыга башлады. Бервакыт ул әтисе чыраен хәтерләткән сурәткә тап булды. Үтерелгән ике гәүдә янәшә ята. Берсенең йөзе, борыны, ияге гел әтисенеке кебек тоелды. Маңгаенда да охшашлык күренде. Таня кат-кат карады, икеләнде, йөдәде, үртәлде. Ул, бар хәтерен җигеп, әтисен күзалларга тырышты. Көлгән-шаярган, уйчанланып утырган чаклары хәтеренең бер почмагында яктырып киткәндәй тоелды.

Таня әлеге фотоның, шуңа охшаганрак тагын бер сурәтнең копиясен төшертеп алды. Бер җирдә дә туганнарының эзе табылмагач, милициягә мөрәҗәгать итте. Биредә «паспорт өстәле» бар икән, туганнарын шундагы исемлектән эзләргә туры килде. Ләкин анда Милаш фамилиясе очрамады. Таня үзе дә исемлекне барлап, күздән кичереп чыкты. Бәлки, фамилияләре үзгәргәндер дигән гөманнар да күңеленә керде. Ләкин анысына һич тә ышанып булмый иде. Ичмаса, берәр танышы да очрамый. Дөрес, алар хәрби шәһәрчектә яшәде. Аның үз клубы, кибетләре бар иде. Җирле халык анда бөтенләй яшәмәде. Елганың уң ягындагы шәһәр үзәгенә әти-әнисе кемнәргәдер кунакка гына баргалый иде. Тик алар бервакытта да биредә күренмәде. Бәлки, хәрби шәһәрчеккә килергә рөхсәт ителмәгәндер.

Таня һаман шәһәрнең шул ягында йөрде. Әүвәлгечә хәрби шәһәрчектә гаскәри булмаганнар очрамый иде. Шәһәр зур түгел. Өч-дүрт көн эчендә аркылысын-буен йөреп чыгарга мөмкин. Һәр җирдә хезмәт кайный, каланы җимереклекләрдән чистарту эшләре бара иде. Хатын-кызлар хәрби машиналарга кирпеч ватыклары, зур-зур кантарлар төйи. Иртәдән алып кичкә кадәр шундый манзарага тап буласың. Таня шунда бер җимерек йорт янында бөтен кирпечләрне сайлап, штабельгә өеп маташкан хатыннарны күзәтергә кереште. Кызыл яулык бәйләгән, ирләр пиджагы кигән бер хатынның килеш-килбәте ничектер аны үзенә җәлеп итте. Бу юлы Таняны эчке сиземләве алдамады. Элекке көрәнсурак йөзе чуен китегә кебек кояшта каралып беткән, матур иреннәре купшакланыбрак, ә күзләре нәкъ яшь вакыттагыча очкынланып торган хатын аның әнисе Клара иде. Таня аңа шактый ерактан «әни» дип кычкырганын сизми дә калды. Ләкин әнисе, эш белән мавыгып, аны ишетмәде. Алдына килеп баскач, Таня тагын эндәште. Тавышка Клара башын борды, шулчак аның кулындагы кирпечләре төшеп китте, ул күзләрен Таняга төбәгән

көе тынсыз калды. «Таня, кызым!» – дип, әнисе, алга таба атлый алмыйча, кирпеч өеменә ике куллап таянды. Аның хәле киткәнлеге күренеп тора иде. Иптәш хатыннары Клараны култыклап торгызды. Таня, килеп, әнисенең ике кулыннан тотып алды. Алар хәтсез генә бер-берсенә эндәшә алмыйча торды, икесенең дә күзеннән яшь ага иде.

Иптәшләре бүген Клараны эштән азат иттеләр.

Әнисе ничектер исән калган өч катлы таш йортның икенче катында, кечкенә бер бүлмәдә торып ята икән. Кайту белән, ул эш киемнәрен алыштырды, керосинкага чәй куйды. Таня бердәнбер тәрәзә буендагы кечкенә өстәл янына килеп утырды. Бугазына бик ачы төер тыгылды, ни эчкә үтми, ни тышка чыкмыйча, сүзләрен томалады да куйды. Әнисенең таушалган, изелгән кыяфәте аның бәгырен өзеп-өзеп алды. Ә ул үзе тыныч шикелле күренде, әллә барын да эченә яшерергә күнеккәнме? Авыр тормыш шартлары сабырлыкка, буйга сеңдерергә өйрәткәнме? Әйе, Таняның әнисе танымаслык булып үзгәргән. Йөзендәге гаҗизлек сызыклары аны моңсу, өметсезлеккә бирелгән кебек итеп күрсәтә иде. Ул үз эченә йомылган, күңелендә җыелганны бик үк ачасы да килми, нидәндер курка, шикләнә төсле тоелды. Сугыш чорында араларына әллә нинди хикмәтләр кереп тулган икән шул. Аралар ерагайган, салкынайган. Клараның үз язмышы, Таняныкы – үзенеке. Әнисенең язмыш кырына кызы керә алмый. Һәм, киресенчә, әнисенә кызыныкына кушылып китәргә нидер комачау итә...

Бүлмә эче бик ярлы иде. Әнисенең өс-башы да әйбәт түгел. Хәер, шәһәрне җимерекләрдән чистартучы башка хатын-кызлар да шулайрак киенгән иде. Барысында да яртылаш ир-ат киеме, кирза итек, гимнастёрка... Ничек мондый хәлгә калган бу әни дип, Таня ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ул болай түбән төшәргә тиеш түгел иде шикелле.

– Әни, нишләп син врачлык эшендә түгел, ә? – дип сорап куйды Таня мич тирәсендә кайнашкан әнисеннән.

– Хәзер, кызым, хәзер, – дип, Клара пәрдә белән бүленгән кухня сыман җиргә кереп китте.

Менә буялып беткән клеёнка ябылган өстәлгә чәй килде, тәлинкәгә, турап, кара ипи һәм патока конфетлары куелды. Таня һаман гаҗәпләнүеннән айный алмый утыра иде. Ул әнисен үзләре белән алып китәргә дигән ныклы карарга килде. Анда, һәрхәлдә, болай ук булмас дип уйлады.

– Әни, әти кайда, Радик ни хәлләрдә? – дип, ашыга-ашыга, сорау яудыра башлады Таня.

– Хәзер, кызым, концентрат боткам бар иде, шул көяр дип куркам, – дип, әнисе, кашык тоткан кулы белән пәрдәне этеп, кухня ягына атлады. Таняның түземлеге тәмам төкәнер чиккә җитте.

Ниһаять, ботка пешеп чыкты. Клара аны кәстрүлдән тәлинкәләргә бүлә башлады. Таня үзенә бүлдермәде, бер кабар җирем юк, чәй генә эчәм, диде. Әнисе, үз тәлинкәсенә ботка салып, кызы каршына килеп утырды. «Кара, ничек салкынайган, – дип уйлап куйды Таня. – Минем өс-башым әйбәт булгангамы, берни кайгыртып сорашмый, кызыксынмый. Үз хәле хәл инде, монда әнисенең гаебе юк...»

Клара боткасын капкалап, чәен эчеп куйды да кызына сугыш башланганда ниләр булганын сөйләргә кереште:

– Квартираны немецлар үзенә алды, барча йорт әйберләре шунда харап булды. Үзебезне көч-хәл белән елганың уң ягындагы танышлар сыйдырды, – диде ул.

– Фашистларның СД дигән органнары бар икән, һәр кешене, жандармериягә чакыртып йә өенә килеп, шул оешма белән хезмәттәшлек итәргә куштылар. Андрей да, мин дә кул куймадык. Шуннан безне эзәрлекли башладылар. Ни генә эшләтеп бетермәделәр. Бер җиргә эшкә алмыйлар. Эшләмәсәң, ачка үләргә кирәк. Андрей бер танышы аша немец армиясендәге симулянтларны дәвалый торган госпитальгә эшкә кергән иде. Көн дә канга батып кайта иде, симулянтлар бик каты кыйный икән үзен. Берничә тапкыр аңын җуйганчы тукмаганнар. Аңына килмәс борын, өйгә китереп ташладылар. Мин немец врачы җитәкчелегендә җирле халыкка медицина ярдәме күрсәтүдә эшләгән булдым.

Ә Радикны Баурих дигән тәҗрибәле бер эсэсчы үзенә хезмәткә яллады. Бер чибәр генә латыш кызы аша. Ул кыз Радикны уч төбендә биетә башлады. Шуның котыртуы белән малай безне кыерсытты. Башта әтиеңә бәйләнде, нигә немецларны яратмыйсың, дип, аннары – миңа... Ниләр генә күрсәтмәде, исереп килә дә погром ясый иде. Ә теге кыз шунда аңа көч биргән шикелле үчекләп басып тора иде. Андрей нинди кадерле улының немецларга ялчы кебек эшләвен белде, күрде. Ачынып үгетләде, ачуланды, оккупантларның вакытлы гына булуын тәкрарлады. Радик безне тыңлаудан узган иде, теге кыз сүзен генә сөйләп торуын белде. Ул элекке фабрика хуҗасы кызы булган икән, шул фабриканы кире кайтарып алам да Радикка яздырам, дип, гел тегенең колак төбендә жуылдады. Андрей бу хурлыкка чыдап торды-торды да, ахырда партизаннарга китәргә карар итте бугай. Миңа әйтмәде, ачылмады, мине Радик яклы дип уйлады, ахры. Без үзара сөйләшми башладык. Андрей, миңа бер сүз әйтмичә, көннәрдән бер көнне юкка чыкты. Бер көн, ике көн, атна буе юк. Шуннан бөтенләй суга төшкән кебек булды. Мин немецча сөйләшә белгәнгә, Андрей миңа шикләнеп карады. Әйбәт кенә эштә дә эшли башлагач, немецлар белән хезмәттәшлек итәсең дигәнрәк уйга килде. Дөрес, ул моны сүз белән әйтмәде, бар кыяфәте, дәшмәве белән белгертте. Без Радик белән аңа хыянәт иттек дип уйлады. «Клара, – диде ул соңгы тапкырында, мин сиңа нинди начарлык эшләдем, нигә сез мине Радик белән икәүләп адәм хуры иттегез?..» Мин үземнекен исбат иттем, акландым, Радикны да яклап сөйләдем. Әле акылы да утырып бетмәс борын аны немец агенты адаштырды, юлдан яздырды. Бер-ике тапкыр канлы эш тә эшләткән бугай. Менә шулай бер гаепсез кешеләрнең канын койгач, Радик безнеке булудан туктады. Ай, ул малай үзенең ахмаклыклары белән бар йөрәгемне өстәлгә куеп, пычак белән телгәләп-телгәләп бетергән кебек итте. Менә ак чәчләремне күрәсеңме, барысы да аның эше. Уф, юк, башка сөйли алмыйм, булмый...

Ул кабат чәен уртлап алды, боткасын капкалады...

– Әтиеңнең партизаннарда һәлак булганын ишеттем. Отто абыең күргән. Рита апаңны хәтерлисеңдер бит? Ул бичараны кемдер, үзе укыткан бер малайның анасы, диделәр, «яһүдә» дип барып әйткән. Немецлар килгәнгә ике ай да үтмәгән иде әле. Ританы улы Виктор белән бергә комендатурага алып киткәннәр. Яһүдләр белән эсэсчылар үзләре шөгыльләнә, полицайларга ышанмыйлар иде. Отто Ритага үз исеменә милләте «немец» дип язылган паспорт юнәтеп биргән булган. Мин дә шундый паспорт ясатып исән калдым. Ә Рита комендатурада элекке паспортын күрсәткән. Әллә онытып калдырган, әллә укытучыны җәзаламаслар дип ышанган. Кеше бит ышана. Немецларны шултиклем вәхшиләр дип кем уйлаган? Менә шулай харап булды бичара Рита белән Виктор. Ә Отто подпольеда калдырылган икән. Рита исә өлгерә алмаганмы, ул да яшеренергә тиеш булган. Үтерерләр дип

башына китермәгәндер, мөгаен. Ул да бит бик ышана торган зат иде. Немецлар еврейларны кан дошманы санады. Урамда очрасалар, шунда ук атып китәләр иде. Ә Андрейның партизаннарда һәлак булганын 1943 елның көзендә ишеттем. Отто үзе шаһит булган. Мине дә, аны да белә торган бер кеше аша кыска гына язу җибәргән иде.

– Әни, тукта, – дип, Таня кара лаклы редикюленнән теге фотоларны чыгарып, аңа сузды. – Менә бу безнең әти түгелме? Мин ничектер аңа охшаттым...

– Ничек, каян алдың? – дип гаҗәпләнде әнисе, кызына ышанып бетмичә, күз сирпеп алды. Таня аңлатып биргәч, Клара фотоны, күзенә якынрак китереп, бик дикъкать белән озаклап карап торды. Аннары, кызыксынуы сүрелеп, фотоны кире бирде. – Мин бер дә охшый торган нәрсәләр күрмим, – диде. Фотоны тагын алып, җентекләп тикшергәндәй итте. – Юк-юк, мин берни дә тапмыйм, – дип куйды.

– Борыны, ияге, кашлары гел әтинеке бит инде, – диде Таня.

– Бераз охшашлык бар кебек, ләкин бу Андрей түгел! Түгел!

– Ярар, алайса, – дип, Таня килешәсе килмичә генә әйтте. Тик фотоларны ташламады, кире салып куйды. – Йә, шуннан соң, шуннан соң ничек булды?

– Аннары бездә дәваланган бер ир-ат, тимер юлчы, миңа сагыз кебек ябышты. Һич кубарып алышлы түгел. Үзе миннән яшьрәк тә. Нишли аласың, без хатын-кызларның язмышы ир-ат кулында инде. Алар үз дигәннәрен итә. Шундый ягымлы, мөлаем кеше, эчке культурасы бар, һәр хәрәкәтендә ниндидер затлылык сизелә иде. Мин һаман сине исемә төшердем, бу кеше белән кавышырга син барыбер каршы килер, әти истәлеген аяк астына салып таптыйсың, дияр кебек идең. Ул үзе бик тә ихтыярлы, нәзакәтле кеше иде. Юк, миңа ирләр кирәкми, мин ансыз да яши ала идем. Ләкин Миша белән тора башлагач, минем дә фикерләрем үзгәрде. Хәер, анысы мөһим түгел. Сугыш бирегә килеп җиткәнче, без ерак бер хуторга киттек. Поездлар йөрүдән туктагач та элдердек, чөнки тимер юлны, шәһәрне бик нык бомбага тотачаклар иде. Һәм, чыннан да, шулай булган да... Мин, әйтергә кирәк, Миша аркасында гына исән калдым. Шәһәрдә котылып калырга уйлаганнар барысы да харап булды.

– И-и әни, нигә син фамилияңне алыштырдың соң? – дип бүлдерде Таня, әнисенең кияүгә чыгуын бер дә өнәмичә.

– Миша шуны таләп итте, кызым, өзмәде дә, куймады да. Паспортны алыштырганда, шулай яздырды.

– Син аны әтидән дә ныграк яратасыңмы әллә?

– Ышансаң ышан, ышанмасаң – юк.

– Ничек инде ул алай?

– Хатын-кыз эт кебек ул, кызым, үзен кем ошатса, ул шуныкы була да бетә...

– Ничек инде, әтигә хыянәт итеп... – Таняның йөзе караңгыланып китте.

– Синең, кызым, оккупациядә булганың юк, бередәге хәлләрне белмисең. Исән калу өчен адәм баласы әллә нәрсәләргә бара. Әти-әнисен, якын кешесен сата. Мин Андрейны сатмадым. Ул һәлак булды. Үлгән артыннан үлеп булмый. Миша бик ялынды, матди ягым бик авыр иде. Немецлар эшләгән өчен берни бирмәде. Ачлык бик изде. Ә Миша – таба белә торган кеше. Мин аңа, дөресен әйткәндә, тамак өчен генә чыккан идем, аннары ул үзен яраттырды...

– Фамилияңне булса да калдырырга иде, әни?

– Мишаның теләгенә каршы килә алмадым. Аның ни әһәмияте бар соң, дип уйладым. Шунда ялгышканмын, кызым, хәзер үзем дә аңладым. Ул чагында акыл белән ачлык идарә итә иде шул.

– Теләсә нинди шартларда да кешелекне саклап калып булмыймы?

– Булмый, кызым, булмый. Менә күз алдыңда ич. Ачы тәҗрибә дә шуны раслый. Барысы да әйбәт кенә бара иде, кызым, ләкин миңа бәхет бер дә килешми. Гамәлдә шулай булды да. Без – мин дә, Рита да – бәхетсезлек өчен яратылган булып чыктык. Бәхетлеләр янында бәхетсезләр дә булырга тиеш. Менә без шул бәхетсезләр графасында, балансны саклау өчен. Юкса баланс бозыла...

– Бүтәннәр бәхетле булсын өчен сез бәхетсезме? Нәрсә сөйлисең син, әни?

– Булганны сөйлим, кызым. Берәүләр бәхетле, берәүләр бәхетсез, әллә шулай түгелме? Берәүләр өстен, икенчеләр түбән.

– Түбән булсалар, бөтенесе үзләреннән генә, әни! Син дөрес уйламыйсың!

– Юк, үзләреннән генә түгел, кызым. Тормыштан чыгып әйтәм, үзләре генә гаепле булса, бер хәл. Түгел шул! Менә моннан нәкъ биш ай элек төнлә безнең икебезне дә кулга алдылар. Квартирабызны конфискацияләделәр. И, ул чактагы ут йотулар, тетрәнүләр! Ике төн эчендә чигәмдәге ак чәчләр күзгә күренеп күбәйде. Әле берни дә белмим, Мишаны миңа күрсәтмиләр, мине – аңа. Төнлә сорау алалар. Шултиклем аяусыз кыланалар. Бер тамчы йоклатмыйлар. Җитмәсә, надзирательләре дә хатын-кызлар. Имине умырып тоталар да йолкалар. Авыртудан кычкыра башласаң, авызга китереп сугалар. Ике ай буе миннән сорау алдылар. Нәрсә беләселәре килә, максатлары ни – һич төшенер хәл юк. Болгаталар, болгаталар, болганчык суда балык тотмакчы булалар. Мин бар белгәнемне сөйләдем дә шуңарда нык тордым. Әйткәннәремне кабатладым. Беркөнне камерага Рута килеп керде. Оттоның яңа хатыны. НКВДда эшли.

– Отто абый Рита апаны ничек оныта алды икән, ә? – дип, Таня тагын әнисенең сүзенә аркылы төште. Күңелендә әнисенә каршы ачуга охшаш ниндидер хис кабат уяна башлагандай булды. Нилектән булыр бу?

– Тормыш ата-анаңны да оныттыра, кызым. Синең әле начар хәлләрдә калганың булмаган, шуңа әхлакый яктан дөрес фикер йөртәсең. Безне гаеплисең. Безнең башка төшкән бәлаләр бернинди әхлакка урын калдырмады, кызым... Рута әйтте: «Мишаны немецлар биредә шпионлык итәргә әзерләп калдырып киткән, ә синең гаебең юк, син аның шундый кеше икәнен белмәгәнсең, – диде. – Мин сине үз җаваплылыгыма алам, Отто күземне ачырмый, ярдәм итәргә куша. Сине порукага бирергә риза булдылар...»

Ике көннән чыгардылар, ләкин врач булып эшләргә ярамый, синең өчен ул профессия тыела, диделәр. Шулай итеп, миңа җир казучы булырга туры килде. Ә Мишадан бер хәбәр юк, сорап караган идем, бик каты кисәттеләр. Әгәр кабат эләгәсең килмәсә, бу тирәдә йөрмә, дип киңәш бирделәр. Миша нинди әйбәт, хөрмәт итүчән кеше иде. Шәһәр Советының тимер юл бүлегендә эшләде. Миңа бик яхшы киемнәр юнәтеп бирде. Каракүл пальто, габардин макинтош, лаклы туфлиләр. Барысы да конфискациягә эләкте, берсенең дә игелеген күрә алмадым...

– Ничек инде син чүпрәк өчен кайгырасың, ә профессияң җәл түгелме? – диде Таня, тавышын күтәрә төшеп. Аның күңелендә әнисен җәлләп әрнү хисе бөтенләй беткән сыман булды.

– Болай гына әйтәм, кызым, иң мөһиме – профессия, белгеле. Ләкин эшләргә рөхсәт итмәгәч, мин нишли алам? Бәлки, Альфред кияү минем язмышны җиңеләйтү әмәлен табар, ә? Әгәр карьерасы өчен курыкмаса? Ә?

– Юк, әни, син аңа исәп тотма... Аның үз эшләре четерекле... – Таня бу сүзләре өчен бераз уңайсызланды, карашын читкәрәк алды.

– Их, бер елар идем, – диде Клара, ачы үртәлеп, йодрыгын күкрәгенә кыса-

кыса. – Рәхәтләнеп үкереп елар идем, елый да алмыйм бит, бер тамчы күз яшем калмаган... Уф! – Ул, тәмам өметен өзгәндәй, кызына берсәк текәлеп карап торды да боткасын капкаларга тотынды. Ә башында рәнҗүле уйлар кайнашты: аңа үз кызы да сәяси ышанычсызлык күрсәтә түгелме соң? Ник дигәндә, тормышта кешеләрнең бәясен, тоткан урынын, кирәкме-түгелме икәнен сәясәт кенә билгели. Язмыш дигән нәрсә юк хәзер, сәясәт кенә бар. Дошман элемент белән мөнәсәбәттә булган кеше дә пычранган санала, һәм ул пычрак беркайчан да бетми, юылмый. Моны Таня яхшы аңлый, Клара да изаланып төшенә бара. Туганлык хисләре дә берни тормый, очсызлана да кала. Таня хәзер үз әнисен дә чын тойгылар белән ярата алмый, ул яраткан булып кылана, уйный гына. Бу икейөзлелекне сизеп, аңлап торган әнисе исә кызының мөнәсәбәте белән килешергә, аны хөкем итмәскә тиеш була. Сәясәтнең нәрсә икәнен бераз аңлый ул. Ананың эчкерсез, табигатьтән килгән тойгылары мәҗбүри монафикълык белән чәкешә һәм җиңелә. Әгәр Таня әнисенә бернинди конъюнктурасыз, ихластан караса, бу аның үзенә минус булып языллачак, чөнки моны исәпкә алып торучылар бар. Шул нәрсәнең Альфред карьерасына да тәэсире булмый калмаячак. Менә Таня ни өчен сагая һәм әнисенә карата сүрелә бара иде.

Клара мөнәсәбәтләр арифметикасын бераз гына чамалый иде. Ярар дип килеште ул Таняның кырыслыгы белән, үз тормышын корган икән, яшәсен. Үзеннән күләгә төшеп, кызының гомерен бозмасын, караңгыламасын. Ана йөрәге барысын да сыйдыра: балаларының рәнҗетүен дә, фәкать үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртуларын да, хыянәтләрен дә... Барысын да гафу итә. Күз яшьләрен эчкә йота, җанына җыя. Шунда мәңгегә кибеп бетәчәк алар...

Таня, үзләренә кайткач, әнисен эзләп тапканын, аның белән сөйләшкәнен Альфредка әйтмәде. Мендәренә капланып елады да елады. Альфред, аның хәлен җиңеләйтә алмавына үртәлеп, ишекле-түрле йөренде. Таня исә әнисенә дорфа сүзләр әйткәненә, аны әтисенә хыянәт итүдә гаепләвенә үкенеп, җәлләп елый иде. Тәмуг газаплары кичергән әнисен нигә шулай рәнҗетергә иде?! Бу мәхшәрдә хатын-кыз нишли ала инде? Ташкынга эләккән йомычка кебек, аны рәхимсез дулкыннар теләсә нишләтә бит! Әнә ул нинди бәхетсезлеккә дучар булган. Аның шаукымы бөтен нәселгә китәчәк, буыннан-буынга күчәчәк. Аңа әнисенең күләгәсе төшәр дә төшәр инде, алай гына түгел, Альфредка да җитешер. Таня да шуңа күрә кырыслангандыр инде. Мәҗбүри рәвештә. Бар төштә дә мәҗбүрилек, мәҗбүрилек. Нишлисең, шулай кирәктер, мөгаен. Без бернәрсәне дә үзгәртә алмыйбыз ич, шунлыктан тормышның барча мәҗбүриятен шулай тиешле дип кабул итәбез. Адәм баласының башка чарасы юк. Юк, Таня әнисе каршында гаепле түгел. Ә ул үзе гаеплеме соң? Аның да гаебе юк шикелле. Таня әнисен ниндидер Мишага кияүгә чыкканы өчен генә шелтәләде. Һәм дөрес эшләде. Алай эшләмәсә, ни булган? Яисә башка берәү беткәнмени? Илнең кан дошманын үз кочагында асраган бит. Моңа һәркемнең ачуы килер. Ә менә Альфредка ни дип әйтергә? Әллә әйтмәскә генәме? Ялганлавы бик авыр, кайчан да бер тотыласың. Икейөзле булуың ачыла.

Төнлә уянып, Таня тагын әнисе турында уйларга чумды. Аның күңеле әнисенә карата әрнүле, ачы хис белән тулган иде. Ничек бераз алдын-артын уйламаган ул? Теге адәмнең кем икәнен әз генә дә сизә белмәгән. Юк, монда ачлык кына гаеплеме икән? Ул әнине үзенең игътибарлы, илтифатлы булуы белән дә кулга төшергәндер. Бәс, өйрәтелгән кеше икән, аның кулында ялгыз хатынны кулга төшерү кораллары да күп булгандыр, билгеле. Башкаларны үзләренә карату һөнәренә аларны махсус өйрәтәләр, диләр ич. Менә нинди

бүре туры килгән бит әнисенең юлына. Котылып кара син аннан. Клараны ул озак күзәткән булырга тиеш. Больницада әнисе эшли торган палатада айлар буе ятсын да күзәтмәсен... Корбанын сайлый белгән, имансыз. Ә әни тома сукыр булган, чыдамы җитмәгән, бирешкән. Яңа тормыш корырга хыяллангандыр инде. Һәр ялгыз хатын-кыз шуңа омтыла, бер җай көтеп яши. Аның әнисе төшеп калганнардан түгел, үзен акыллы кеше дип исәпли иде. Менә шулай хатын-кызлар еш кына үз-үзләрен алдый...

Икенче көнне иртүк Таня әнисе янына чапты. Альфредка әлегә берни белгертмәде, өстәвенә аның кәефе дә юк иде. Аңарда әллә нинди үзгәреш сизелгән кебек булды. Сөйләшүе дә элеккечә назлы түгел сыман. Нәрсә бу? Әллә үзенең теләгенә ирешә алмауны Танядан күрәме? Чынлап та, яңа фикер бу. Моңарчы аның башына мондый уйның килгәне юк иде, менә хәзер әллә кайдан төртеп чыкты, хәерсез! Әллә Таняның үз шикләре шундый фикергә этәрдеме? Булуы бик мөмкин. Ул бит, Альфредны югалта күрмим дип, дер калтырап тора. Әнә кайда ул хәтәр фикернең орлыгы. Таняның куркуында, шикләнүендә. Ә Альфредның башына шундый уй килмәс дип ничек әйтә аласың. Бик өметләндергән, гарантия куелган операция ясалганга биш ай тулып китте, яхшы якка бернинди үзгәреш юк... Ә бит кешенең үзен-үзе белмәгән, аңламаган чаклары күпме? Альфредның мөнәсәбәтләрендә дә Таняга карата итагатьлелек бурычын үтәгәнлеге чагылып киткәндәй булды. Таняның ишеткәне бар иде: ир-ат бер хатын-кыз янына бара – берни дә майтара алмый. Ә икенче хатын-кыз янына барса, барысы да тәртип була, ди. Хатын-кызда хикмәтләр күп була, дип, ир-атлар шундый мисал китерә. Нигә, бик мөмкин, бу хәлгә ышана ул. Нигезсез нәрсә түгел. Кеше психологиясе – тоташ табышмак. Ни өчен һәр адәм баласында кимлек кәсафәте бар дип әйтәләр?.. Ә Альфредның психологиясе нигә үзгәрмәсен, комплекслары нигә артмасын? Уңышсызлыклар кешегә бик нык тәэсир итә. Бигрәк тә Альфред кебек мин-минлекле затка. Бик иркәләп кенә үстергәннәр шул аны. Әти-әнисе бердәнбер уллары өчен кан калтырап тора. Һәр кешегә үзен урап алган тирәлек, мохит хәлиткеч тәэсир итә. Кешенең уйлары шулар йогынтысында барлыкка килә, формалаша.

Таня әнисен эшкә барырга чыгып килгәндә очратты. «Әйдә, эшеңнән сорап китик», – диде ул аңа. Әнисе белән кара-каршы утырып, бик тә сөйләшәсе килә иде аның. Әнисе җавап бирмәде. Хәл-әхвәлләр турында сөйләшә-сөйләшә, эш урынына килделәр. Әнисе кирпеч ватыклары арасына яшергән көрәген алды. Тиз арада бергә эшләүче хатыннар җыелды. Кайсында – лом, кайсында кәйлә иде. Машина килде, кабинадан бригадир хатын да төште. Ул галифе чалбар, кирза итекләр кигән, иске, агарып беткән гимнастёркасын киң комсостав каешы белән буып куйган, башында пилотка иде. Таня аның каршына килде, елмайды, әнисен бераз вакытка эштән җибәреп торуын сорады. Бригадирның йөзе кинәт каралды, иреннәре кысылды, ул көрәкләренә таянып торган хатыннар арасына керде. Таняның бик яхшы киемнән булуын ошатмавы йөзенә үк чыккан иде.

– Бүген дәме? Син безне кемгә саныйсың? Без кичә аның өчен дә эшләдек! Әзрәк кенә намус кирәк! Юк, без аның ялчылары түгел! Син нәрсә, фырт киендем дигәч тә! – Хатын чырылдады да чырылдады. Шушы форсатны гына көтеп торган диярсең. Аны башкалар күтәреп алды.

– Әллә безгә артыгы кирәкме? Әллә безгә өстәп түлиләрме? Кичә дә аның өчен өч машина төядек. Кара син аларны!

– Әниеңне җәлләсәң, әйдә, үзең кил көрәк тотып! Бер хәчтерүш лейтенантны каптырган да үзенең кем икәнен оныткан!..

– Болар – аналы-кызлы арт уйнатып, кәнтәйләнеп, йолдызлыларга сыланып, ябышкак булып яшәүчеләр!..

– Әнә кызы күзләрен ничек буяган, ә анасы битен акшарлап кына тора... Күбәләкләр, кунар урын күзлиләр булыр...

– Җитәр сезгә! – дип кычкырды Таня һәм үкси-үкси машина артына китте.

Шофёр, яшь кенә егет, җиргә утырып, тәмәке тарта иде. Клара кызы янына килде, аны юата-юата сөйләнде. Егет алар ягына карарга уңайсызлана иде.

– Нишләп алар шултиклем миһербансыз, ә?

– Миңа, кызым, һәр төштә дә шундый мөнәсәбәт. Күптән инде. Аларны миңа каршы котыртып куялар шикелле. Ничек уйларга да белмим. «Халык дошманы» итеп карыйлар. Немецлар күпме рәнҗетте, инде килеп, хәзер – үзебезнекеләр. Бу хакта Альфредка әйтми тор. Ул, бәлки, ышанып та бетмәс...

Шул мәлдә Кларага кычкырдылар. Хатыннар, җыйнаулашып, оешып каткан зур бер кирпеч кантарын лом белән кузгатырга азаплана иде.

Таня үкси-үкси кайтып китте. Кичсез аңа әнисе белән сөйләшү мөмкин булмаячак иде...

Бер кичне алар Оттоларга барды. Танinformationың аны бик тә күрәсе килә иде. Ул Оттоны бер дә исеннән чыгармады. Таня юл буйлап алсу хыяллар эчендә йөзеп барган бер мәлдә кабат Оттоны күргәндәй һәм шундук өнсез калгандай булды. Отто шундый мөлаем, гаҗәеп матур иде, Таня хыялында баш-аягы белән аның кочагына чумды. Оттодан башка берни күренмәс булды, күзләрен томан сарган иде. Нәрсә бу? Ник ул шундый халәткә килде? Оятын тәмам җуйды. Отто бит Рита апасының ире, ничек җөрьәт итмәк кирәк?! Адәм мәсхәрәсе ич, валлаһи!.. Эчтән аңа аек уйлар килә, ә тыштан зур шатлыкка тарыган кеше кебек көлә дә көлә. Гәүдәсе шундый җиңел, шул җиңеллек, рәхәтлек эчендә ул йөзә дә йөзә... Үз-үзен бераз кулга алгач, чәбәләнгән уй-хисләрен киләпкә саргач та, Отто янына якын барырга куркып йөрде. Кинәт, үзен белештермәстән, муенына асылынырмын, исемә килгәч, бик оят булыр, дип, аңардан кача иде... Барысы да үкенечкә генә булган. Әмма Отто сурәте аны озак вакытлар ээзәрлекләде. Рәхәт эзәрлекләү иде бу. Аны күрәсе килү теләге Таняны эчтән гел бимазалап торды. Бәлки, бу хис түгел, гади бер кызыксыну гына булгандыр. Кем белә...

Ләкин күпме генә шакысалар да, аларга ишек ачучы булмады. Әнисе моны үзенчә юрады: «Рута миннән хәзер нигәдер качыбрак йөри, – диде. – Отто белән дә очраштырмаска тырыша. Нәрсәгә шулайдыр инде, белмим. Әмма Рутага рәнҗергә минем бернинди хакым юк. Көн саен аңа рәхмәтләр укыйм. Ул мине порукага алды бит. Оттоның бик нык соравы, үтенүе, таләп итүе буенча. Отто миңа бик яхшы характеристика язган. Партизаннарга медикаментлар юнәтеп бирүемне дә онытмаган. Моны раслаучылар тагын да табылган... Ә Оттоның хәле бик мөшкел, кызым. Бәлки, ул соңгы көннәрен яшидер. Бик бетерешкән, диделәр. Беләсеңме, ни булган? Отто башта Рита белән малаен кем үтергәнне ачыклаган, төрле хәйләләр корып, теге палачның шофёры булып ук киткән. Ышанычка кергән, җаен туры китереп, аны аулак бер җирдә агачка бәйләп калдырган. Менә шулай күпме кешеләрне үлемнән коткарып кала ул...

Бераздан, яфраклар коелган чорда, Отто шул урынга бара һәм, теге палачның мәете юклыгын күреп, бик нык тетрәнү кичерә. Яфрак-ботакларны актарыбрак караса, анда баш сөяге белән скелет аунап ята икән. Отто шунда зур чүмәлә чаклы кырмыска түмгәген күреп ала һәм барысын да аңлый. Шул чакта авырый да башлый... Башта, нервы авыруы, дигәннәр иде, соңга таба ашавы үтмәскә әйләнгән. Юк, сөйли алмыйм, Таня! Йөрәгемә ярамый, Оттоны шундый ярата

идем, үз ирем кебек якын күрә идем. Тик менә сугыш барыбызны физик яктан да, рухи яктан да гарип итеп калдырды... Кызым, синең бәхетеңә, сез вакытында хәвеф-хәтәрсез ычкынып өлгергәнсез...

Танякның Оттоны бер күз кырые белән генә булса да күрәсе килгән иде – барып чыкмады. Яшь чакта йөрәкне кузгаткан, талпындырган хисләр кешегә гомер буе кадерле була, ахрысы. Хәзер ул җилкендергән, ымсындырган тойгылар чәлпәрәмә килеп җимерелеп бетсә дә, шуның кыйпылчыклары да ничектер якын тоела...

Инде яшереп тору мөмкин түгел иде, Таня Альфредка барысын да ачып салды. Үзенең күзеннән бертуктаусыз яшь акты.

Кичен, табын әзерләп, Кларага алып килделәр. Сөйләшү-аңлашу бик сүрән барды. Ниндидер күзгә күренми торган явыз көч аларның рухын басып, газаплап тора иде. Һәркемнең үз хәле хәл, Таня әнисенә ышанып җитмичә карый, ә Клара Альфред белән Танядан сагая иде. Менә бит ничек: кайчак үз балаңнан да курка башлыйсың. Син аны иркәләп, бөтен җаныңны биреп үстерәсең, ә аны синнән тормыш тартып ала һәм үзенеке итә. Синең иң кадерле йөрәк парәң хәзер сиңа түгел, тормышка буйсына. Ул синеке түгел, синең сүзне тыңламый, аның үз кыйбласы, үз тәҗрибәсе бар. Бер канлылык хисе шунда бетә.

Туганлык җепләре белән бәйләнгән өч җан шулай ризык капкалап, аны-моны сөйләшеп, бер-берсен сынашып утыра бирде. Альфред та ачылып китә алмады. Таня да, Клара да үткәннәрне искә алудан тыелды. Өстәвенә Клара, минем аркада Таня белән Альфредка авырлык килә күрмәсен, дип, гел борчылып утырды. Шулай да кияү кеше, итагатьлек саклап, нинди дә булса игелек эшләргә тиеш иде. Моны үзе дә яхшы аңлаган Альфред сүз арасында «Таняның әнисе хакында сөйләшеп карармын», дип әйтеп куйды. Ләкин Клара моңа катгый каршы төште. Ул инде үзенә беркем дә ярдәм итә алмаячагын тәгаен аңлый иде. «Юк-юк, – диде ул, – син инде миңа җиңеллек китерә алмассың, бары үзең генә тапланып калырсың...» Хәлләр нәкъ шулай булып чыкты да. Бер инстанциядә Альфредка шыпырт кына әйттеләр: «Егет, син бу өметсез эш белән йөрмә, башың ике түгелдер», – диделәр.

Альфредның командировкасы тәмам булды. Таняга беразга биредә калырга да була иде әле, ләкин ул моңа бармады, чөнки әнисенә берничек тә ярдәм итә алмаячагы көн кебек ачык иде.

Казанга кайткач, Альфредның авыруы тагын да көчәйде. Ләкин аның Мәскәүгә операциягә барасы килми иде. Ул инде врачларның үзенә ярдәм итә алуына өметен өзгән иде...

Шулай да Таня яраткан кешесе хакына бик тә тәвәккәл адым ясарга карар кылды. Ул Альфредны чибәр йөзле, тыгыз йомры гәүдәле, терекөмеш кебек җитез, уңган бер кыз белән таныштырды. Фреда хирургия бүлегендә шәфкать туташы иде, булганлыгы, ул һәр эшне җиренә җиткереп башкаруы белән хөрмәт казанды. Таняның тәкъдименә Альфред башта бик сәерсенеп, ышанмыйча карады, чөнки ул аның алдында үзен чиксез бурычлы итеп сизә иде. Бик нык үгетли торгач кына ризалашты.

Менә шулай кирәк бит, бу юлы Таня көткәннең гел киресе килеп чыкты: аның белән булдыра алмаганны Альфред Фреда белән булдырган да куйган бит! Кыз моңа ничек, ни рәвешле ирешә алган? Кичен Таня, Альфред белән Фреданы үзләрен генә калдырып, төнге дежурга киткән иде. Иртән кайтып

керсә, танышканнан бирле, беренче мәртәбә Альфредның йөзе кояш кебек балкый иде.

– Таня, хет үтер мине, валлаһи! – диде ул, аны кочаклап, колагына кайнар тынын өрә-өрә. Таня шунда барысын да аңлады.

– Нүжәли, кит әле! Булмас ла! – диде ул, Альфредның күкрәгенә төрткәли-төрткәли.

– Үтерсәң дә, син хаклы, Таня! – Альфред, ни әйтергә белмичә, Таняның зур итеп ачылган күзенә текәлде.

Таняның йөзенә ниндидер эчке каушау һәм шуны сиздермәскә тырышу галәмәте чыккан иде. Ул карашын читкә алды да Альфред яныннан бер-ике адым читкә тайпылды. Буыннары тәмам йомшап калган шикелле иде.

– Нишләп мин шултиклем бәхетсез соң, Таня, ә? – дип, Альфред ике йодрыгы белән маңгай кырыйларын ачынып төяргә тотынды.

– Киресенчә, Альфред, син хәзер бик бәхетле, – диде Таня, тамагына утырган төерне көчкә йотып.

– Юк, Таня, яраткан кешемнән ничек аерыла алыйм соң мин? Син шуны аңлыйсыңмы?

Алар озак сөйләште. Альфред Таня каршында үзен бик гаепле сизде.


– Бу – акыл эше, мәкер эше түгел, Таня, – дип инәлде. – Бу – табигать эше. Син моны үзең дә беләсең. Ник син мине Фреда белән таныштырдың дип икейөзлеләнә алмыйм. Акыл ярдәмендә туган теләктә генә түгел икән хикмәт, табигатьнең үзендә дә без белмәгән табышмаклар бар икән. Яшермим, шатландым да, кайгырдым да. Шатлыгыма эчке әрнү өстәлде. Менә мин Фреданыкы булдым да калдым. Нәрсә бу, Таня? Нүжәли шушы нәрсә хәлиткеч була ала? Аны җиңәр көч юкмы? Юкмы?..

Таня борчылуын да, Альфред өчен канәгать булуын да белдермәде. Дөрес хәлме икән бу дип кенә баш ватты. Ничек Фреда ул белә алмаганны белгән, тапкан? Альфред «табигать сере» ди дә бит, кеше мәкере дә түгелме икән бу?..

Икенче елны Таня әнисе янына ялгызы гына барды. Ләкин аның өмете бер дә сүнмәгән, сүрелмәгән, ул дөньяга дәртле елмаеп карый иде...

**Редакциядән:**

*Татарстанның халык язучысы Хисам Камалның әлеге романы Икенче Бөтендөнья сугышы чорында оккупация михнәтен кичергән халыкның фаҗигале тормышын тасвирлауга багышланган. Сугыш мәхшәрен үз башыннан да кичергән әдип аерым кешеләр, гаиләләрнең аянычлы язмышын кырыс реалистик буяулар белән, тирән психологик кичерешләр аша сурәтли. Бу әсәр язучының «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым» кебек киң танылу алган романнарының дәвамы кебек тә укыла. Әсәр укучыларыбызга, әдәби мирас буларак, Газинур Морат эшкәртүендә тәкъдим ителә.*



Рәшит
Бәшәр

# АЛДА – БИЕК ТАУ ТҮБӘСЕ...

## Әни

Әни судан кайтты. Песие
Каршысына килде йөгереп.
Һәм уйнаклап исте йомшак җил,
Ачык тәрәзәдә гөл күреп.
Шомырт чәчәгенең таҗлары
Сулы чиләкләрдә йөзә ич.
Әни белән кайткан гүзәллек
Бездә генә бары, бездә ич!
Чиләкләрне әни бик ипләп
Утыртты да сары баскычка,
Үрелде дә мүкле ярыкка
Кыстырылган баулы ачкычка,
Ачып кереп китте ишекне.
Шыгыр-шыгыр сайгак сайравын
Үрмәкүчләр хәтта ишетте.
Чормадагы ап-ак пәрәвез
Тирбәлгәләп алды, чайкалды.
Әни чыкты самавыр тотып,
Чишмә суы белән чайкады...
Ак парларын бөркер самавыр,
Һәм сандыктан чыгар чәй кабы.
Көянтәсен элде кадакка,
Ак песие килде... Иркә бик.
Әни аны җылы кулында
Сыйпый-сыйпый гына йөртә бит.
Ак чиләктә кояш күтәреп,
Кереп китте алар икәүләп.
Ишегалды, кояш, ак песи,
Ак яулыклы әни – бер дәүләт...
Әни дә юк инде... Песи дә...

---

Рәшит БӘШӘР (1949) – *шагыйрь һәм прозаик; «Сандугачлы бишек», «Ачык капка», «Былбыл оясы» һ.б. китаплар авторы. А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чаллыда яши.*

Айлы төндә кереп төшләргә
Сынап карый әни кайвакыт:
«Насыйп булсын озак яшәргә,
Хатирәләр белән яшәргә!»
Мин чишмәгә киләм... Баш иям
Сукмагында үскән гөленә.
Чәчрәп-чәчрәп оча тамчылар,
Керфегемә тамчы эленә.

## Кайту

Күзе яшьле моңсу балачакның
Йөрәгемдә калды юшкыны.
Карт зиратта ящь-яшь үлән үсә,
Чардуганга синең ышкылып.
Гомер буе сиңа кайтам, әни,
Сөйләр сүзләрем күп. Әйталмыйм.
Басып торам соңгы тукталышта,
Һаман сиңа кайтып җиталмыйм.

## Печәнче

Транзисторы тын болында
Нидер сөйли мыгыр-мыгыр.
Корымланган чәйнегендә
Су кайнады быгыр-быгыр.
Камыт, дуга ята читтә,
Болын тулып бии нурлар.
Яшелләнә бик якында
Төлке уйнар текә урлар.
Тиргә баткан ат сыртына
Килеп куна төклетура.
Печән чапкан ирне күзләп
Кымшанмый да тик утыра.
Талчыкканын таза бу ир
Сизде бугай хәзер генә.
Баш очында ап-ак болыт
Кульяулыгы кадәр генә.
Ак кульяулык чыгара ул
Чалбарының кесәсеннән.
Эре-эре ак тамчылар
Тәгәрәшә иңсәсеннән.
Ир тирләгән битен сөртә,
Су тамыза учагына.
Юешләнгән учак чыжлый,
Яктылыктан күз чагыла.
Җәй эссесе – кочагында,
Ат пошкыра. Черки безли.
Сүнәр-сүнмәс вак күмерләр
Пышылдаша учагында...

## Челтери кичке сулар

Челтери кичке сулар...
Таллыкка качып кына.
Аякларын юа кыз,
Ак ташка басып кына.
Ак күлмәге итәген
Селкеткәли шаян җил.
Суга иелгән саен,
Сыгылыплар китә бил.
Челтери кичке сулар...

Кыз башын игән саен,
Толымнарының очы
Суларга тигән саен,
Чәчрәп куна тамчылар
Кызның ап-ак тезенә.
Сүнә кояш. Таллардан
Соңгы нурлар өзелә.

Челтери кичке сулар...
Ап-ачык ишетелә
Шул челтерәү тавышы.
Очып арган кошларның
Салмак канат кагышы.
Кызны күзли бер егет,
Таллыкка качып кына.

Яшел мүккә төренгән
Түмгәккә басып кына.
Селкеткәли чәчләрен
Кошның канат җилләре.
Ымсындыра кызыйның
Сыгылмалы билләре.

Сихерләде егетне
Ап-ак ташка баскан кыз.
...Кич җитүгә, күкләрдә
Кабыначак пар йолдыз.
Челтери кечке сулар...

## Күкләрдән килгән аваз

Моң үкси сулык-сулык:
– Гөл идек! Сулдык... Сулдык...
Килде бу нинди заман?
Җан өши. Суык... Суык...
Әллә ниткән халәт бу,
Бер дә бетмәс моңсулык.
Үле җырлар ил тулы,
Җаннарга да сил тулды.
Юа җан гәүһәрләрен,
Милләтнең җәүһәрләрен.
Кабатлана шул аваз:
– Гөл идек! Сулдык... Сулдык...
Милләтнең бакчасында
Җилгә очар көл булдык.
Чүп-чар тулы бакчада
Әкренләп күкси-күкси,
Иртәсен дә, кичен дә
Халык җырлары үкси.
...Күзем ачтым, сискәнеп,
Кояш чыккан. Өй якты.
Төшләнеп ятам ласа,
«Әдрән диңгез» уятты...

## Ташландык авыл

Кунаклар да кайтмый инде,
Чит-ятлар да күренми.
Ишегалды буш. Сабыйлар
Шомыртларга үрелми.
Атлар беткән. Ара-тирә
Атлы арба үр менми.
Арба тәгәрмәче төшкәч,
Йөкчеләр дә сүгенми.
Каршыга тик чабып килә
Хуҗасыз этләр генә.
Яшь туйралар чыгып килә
Карт агач төпләренә.
Сүнгән өметләр генә.
Тишек-тошыктан сикереп
Менгән дә кыю гына,
Тырнак чарлый кара песи
Буш абзар кыегында.
Кыштыр-мыштыр килә картлар,
Күзен кысып кояшка.

Кулны тыгып билләрдәге
Кыршылган тар каешка:
– Ике адым атлаганчы,
Аяклар арый, – диләр.
– Айлык пинсәне алганчы,
Яшәсәк ярый, – диләр.
Үткәннәрдән, гамьле чактан
Кайтаваз килә кебек.
...Утыра ул тау астында
Тавышсыз кино кебек.

## «Мин үзем дә ил сыман...»

Мин үзем дә ил сыман –
Хәлсезләндем, таушалдым.
Таш атканга аш аттым,
Шактый кыен ашадым.
Аязыр, диеп, көннәр,
Хыялланып яшәдем.
Ирексез ил җилендә
Кибеп бетте яшьләрем.

Сүтмәдем күперләрне,
Янып кала учагым.
Ишетәм: яшьләр килә,
Һәрберсенең ут чагы.
Фидакарьләр булсыннар,
Ил-көн диеп янсыннар.
Без нигез салдык инде,
Алар ирек алсыннар!

## Тауга таба

Әйтәсең гел: «Янәшәңдә
Мин барында туңмассың!»
Кай арада бу гомерләр
Искән җилдәй узган соң?
Менә тагын юлдан кайттым,
Синнән башка авыр ла.
Сөрт яшеңне, елмай әле,
Күмер сал самавырга.
Бер тын чәйләп алырбыз,
Үткән көннәрне уйлап.
Ипи сал син, китап сал син,
Биштәремне куй җайлап.
Алда әле безне көткән
Биек тау түбәсе бар.
Төнгә кадәр, җитәкләшеп,
Шул тауга менәсе бар.
Йолдыз нурына сөттәй ак
Яулыгың эләсе бар.
Җанымда сиңа укыйсы
Мәхәббәт сүрәсе бар.
...Ак күлмәгең ки, аппагым!
Юллар кыска, тау якын.
Кузгалыйкчы,
Йөрәкләрдә
Сүнмәгән әле ялкын.



# Нәбирә Гыйматдинова

## ХИКӘЯЛӘР

### Түрә

«Хуш, яшелчәләрне берәм-берәм юып, тастымал белән корыттыңмы? Башта кайсысын турарга икән? Әйдә, суганнан башла! Аны чыжлатып майда кыздыргач, эре тешле кыргычтан уылган кишер белән «бизәклә»! Өченче катламга помидор кисәкләре җәй! Иң өскә тоз-борыч сибелгән ит телемнәрен тез! Шуннан соң яшелчә катламын, капкач белән томалап, кызу мичкә тык!»

Ул, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, тәгам әзерләде. Тәгәрәсә дә тәгәрәр икән текә таудан адәм баласы! Әле кайчан гына Илмәт Гаязович бик зур, бик бай компаниянең җитәкчесе иде! Генеральный! Ничек шәп яңгырый! Бүген гаярь түрә гап-гади пешекче сыйфатында аш бүлмәсендә кайнаша. Дилбегә буе озын-озын көннәрне ничек уздырасың ди! Сәгать теле, үртәгән сыман, әкрен генә кыймылдый, әйтерсең, аны артка йөрешле итеп көйләгәннәр иде. Беренче мәлләрдә ул китап укыды, хатыны Гөлфизә киосктан ташыган «свежий» газет-журнал актарды, шулай вакытны тизләтергә тырышты. Ләкин бу шөгыль тиз туйдырды, кәгазь битендәге һәр җөмлә, һәр сүз башын гына аңгырайта кебек иде. Гөлфизә: «Хәзер акча күктән яумый, әллә җыештыручыны кыскартыйкмы?» – дигәч, каршы килмәде. Биш ат арбасы сыярлык ишегалдын үзе себерә! Физкультура. Биек-биек койма артында аның себерке белән җилләнгәнен кем күрсен ди! Ләкин физик эш тә эч пошуын бастырмады. Киресенчә, җил куып уйнаган сары яфрак, кыш буе ишкән кар кәефен генә боза иде. Утыз бер ел югары урыннар биләгән генераль директор урам себерүче дәрәҗәсенә төшәргә тиеш идемени?!

Пешекче Әлфияне дә җибәрделәр. Аш-су зыялырак өлкә, һәр «блюдо» иҗат җимеше санала иде, яңа вазифасына Илмәт Гаязович аерым дәрт белән җиң сызганып keреште. Ир-ат итен-фәләнен жәлләми, мулдан тондыра: ярты түшкә үрдәккә сарык кабыргасы кушып кайнаткан шулпа тәмле иде, хатыны мактый-мактый ашады. Эштән ачыгып кайтсаң, майсыз ботка да тамак ертмый анысы. Гомер «эш» димәгән, дипломын шкаф тартмасына яшереп, матурлык салонында чәч бөдрәләткән, бит тиресен шомарткан иркә бикәч көннәрдән

---

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА (1956) – *Татарстанның халык язучысы; «Мәхәббәттә гөнаһ бар», «Икебезгә дә авыр», «Үзем генә беләм» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

бер көнне: «Синең белән өйдә күңелсез, кеше арасында рәхәт», – диде һәм, курслар тәмамлап, төзелеш фирмасына сәркатип булып урнашты. «Ярый әле фамилияләребез төрле-төрле, фәлән түрәнең хатыны дип, күземне ачырмаслар иде», янәсе!

«Яшелчә катламасы» пеште. Табаны өстәлгә куйгач, түрә озак кына аңа карап утырды. Бүлмәгә, ашказанын котыртып, хуш ис таралды. Ләкин аппетит уянмады. Монысы да куандырмый... Үз-үзен юата гына. Кул-аяк хәрәкәтләнә, йөрәк тибә, ә ул гарип хәлендә, бер тиенемә дә ярамый. Иң куркынычы – нәрсәдер үзгәртер-яңартыр өчен теләк юк! Хәзер генә ничек, тәхетеңнән кубарылып, салкын идәнгә төшеп басасың ди! Аның бөтен тормышы анда иде. Иркен кабинетта! Йомшак кәнәфидә! Түшенә орден-медальләр таккан тантаналарда! Затлы банкетларда! Оешма белән идарә итүе ансат, ник дигәндә – чимал табигать бүләге, җир – юмарт, астагы байлык торбалар буйлап сызгырып кына өскә күтәрелә иде. Планны арттырып үтәр өчен нинди генә ысуллар эзләмәде ул. Өченче урынбасары:

– Илмәт Гаязович, без бит инде җирнең җелегенә хәтле суырабыз, бәлки, норма белән чикләнергәдер, – дигәч, өстәл төеп кычкырды:

– Өйрәтмә, маңка! Монда мин хуҗа! – диде.

Оешманың гынамы, дөньяның хуҗасы кебек иде ул. Җир шарының күчәрен нәкъ менә аның җитез куллары әйләндерә, әгәр теләсә туктата, теләсә тагын да кызулата иде. Һәр эреле-ваклы түрәгә хас чир икән бу: син – баш, син – түш! Гаҗәпмени! Әнә, тараканнарның да әйдаманы бар: ярыкта иң беренче аның мыегы селкенә.

Ә өстән кемдер күчәрне «ватты»: Илмәт Гаязовичны лаеклы ялга озаттырды. Күкрәгенә чираттагы калайны чәпәделәр дә, выжт! Имеш, яшьләргә юл бирәбез. Имеш, син ял ит! Алтмыш биш яшь картлыкка пародия генә! Кызык, читтән алмаш китермәделәр, һәр җитәкчегә ләббәйкә дип торган ялагай беренче урынбасарын башкаручы директор итеп билгеләделәр. Өстәгеләргә яраса, төп хуҗа итеп калдырырлар, билгеле. Сәркатип Гөлсара, телефоннан гына зарланып:

– Әтәч инде, әтәч! Кикриген кабартты. Юктан да миңа бәйләнә, куарга ахры исәбе, – дигәч, ул, төрттереп:

– Син дә усал, кушаматыгыз – Шөпшә, – диде.

– Сез дә атлы-чатлы Илмәт Гаязович! – Шөпшәнең мыскыллап көлүе колак яфрагын куырды. – Сезне «тимер йөрәк», диләр. Беркайчан да кеше жәлләмәдегез бит! Кырык өченче үлчәмле бәтинкәгез белән адәм башыннан йөрдегез!

– Ну, ну, минем хакта тагын ниләр сөйлиләр? – «Тимер» икән, ул хагы-нахагын ишетергә тиеш иде.

– У-у, шытыр-шытыр чәйниләр! Түбәсе болытларны тишәрлек коттедж салды, герман хастаханәсендә генә дәваланды, чит илләрдә типтерде, диләр. Швейцария банкында миллионнары чери, диләр. И-и, аптырама, кемнең кулында – шуның авызында, абзыкаем!

Түрә гарьләнеп телефонын сүндерде. Һи, хәсрәт тәнкыйтьчеләр! Аның байлыгы – чеметем тоз. Бүген ил тулы угры! Әйе, йорт салды, гаражына ике машина кертеп бикләде. Хәзер диңгезне абзар артыннан да якынрак күрә халык. Ике-өч сәгать оч та кайнар комда ауна! «Бүтән сораштырып вакланмыйм», дисә дә, Илмәт Гаязович «вакланды»: көн саен төшке аш вакытында гына (кабул итү бүлмәсендә кемдер телефонны тыңларга мөмкин) сәркатипкә шалтыратты.

«Теге нишли? Теге кемнәр белән аралаша? Өстәгеләр аңардан канәгатьме?» кебек игезәк сораулардан соң ул: «Илмәт Гаязович, компаниянең хәле мөшкел, әтәч булдыксыз, сезне сагыналар», – дигән җавап көтте. Тик андый җавап булмады. Ике айдан соң Гөлсараны да эшеннән «шудырдылар».

Барсы да төштә сыман иде. Кинәт уяныр да... шул ук кабинет, шул ук кәнәфи... Ә чынбарлык, ай-һай, рәхимсез кыланды, хәтта саташтырып интектерде: иртән уянып, кырынып-юынгач, түрә үтүкләгән күлмәк кия һәм, шуның төсенә сайлап, элгечтәге йөзәрләгән муенчакны күздән кичерә. Киенгәч тә, күн портфелен кыстырып, турга* чыга. Машина юк! «Кайда сөйрәләсең син, сабакы!» – дип, черетеп шофёр егетне сүгә. Шөкер, хатыны кире тотып өйгә кертә дә, миеңә сеңдер дигәндәй, ун тапкыр:

– Илмәт, син директор түгел, – дип кабатлый. Бу баш китүләр белән ул ай буе интекте. Үз хәлен аңлады, әлбәттә. Ә аңлап та аңламастай хикмәтләр күп, мәсәлән, моңарчы Фәлән Фәләнович дип алдында көянтә төсле бөгелгән урынбасарлар белән ярдәмчеләре саңгырауга әйләнде: кичәге хуҗаларының шалтыратуын «ишетмәде». Серен уртаклашырдай якын дусларга тиенмәсә дә, табында ризык бүлешкән, җыелышларда җилкәдән кагып исәнләшкән танышлар шактый иде. Рәхмәт яугыры, ташланган иске чабата димәделәр, телефоннан булса да хәл-әхвәл белештеләр. Әмма, көннәр-атналар үткән саен, алар да сирәгәйде. Бүген исә тынлык... Телефон дәшми... Ул тирән йокыга чумган...

Иренең чытык чыраеннан туйган Гөлфирә:

– Илмәт, өч атнадан туган көнең җитә, әйдә, дус-ишләреңне җыеп, ресторанда матур гына бәйрәм ясыйбыз, – дигәч, ул берсүзсез ризалашты.

Хатыны, кәгазь-каләм белән коралланып, исемлек төзергә кереште.

– Син әйтеп тор, Илмәт!

– Беренче тегене яз! «Кемне, кемне!» Вакытлыча минем урынга төртелгән ялагай Әмин Маликовичны, атаң башы!

Гөлфирә, шикләнеп:

– Килер микән соң? Син пенсионер картка, – диде.

– Килер! Дәльше киттек! Унлап кунакның исем-фамилиясен алтын буяу белән каймаларбыз. Дәрәҗәләре буенча. Калганнарыныкын көмештән. Типографиядә бастыру – кыйбат. Дәльше киттек! Өстәлләргә урнаштыру тәртибе болай: түргә ялагай Әмин, аннары мин, аннары Фәлән Фәләновлар... Дәльше киттек! Өченче-дүртенче өстәмә... Тәк-тәк... Кемнәр? Монда завод директорлары.

– Ә туганнарны кая утыртабыз? Әтиең ягыннан Шамил абыйларны, минем яктан әнинең сеңлесе Фәйрүзә апаның улы белән киленен чакырырга иде, Илмәт! Гомергә бер тапкыр!

– Исемлек тулды! Нокта!

– Уян әле, уян, син бит инде түрә түгел, Илмәт! – Гөлфирә хәтәр ярсыды. – Абау, ни үзеңнекеләрне, ни минекеләрне санламадың! Урының белән масая идең. Син бит бүген гап-гади өй кошы гына!

– Миндәмени сәбәп? – диде Илмәт Гаязович, күзен акайтып. – Затлы кунакларны өтек әтрәк-әләм туган-тумача белән ничек буташтырыйм ди, ә? Уйла әле син!

Бүре көчсезләнсә, куяннар әрсезләнә икән, элек аяк очына гына басып йөргән юаш хатын, ире кәнәфиеннән колак каккач, тәмам шәбәрде: тавышын бөереннән алып сөйләшә, каһәр! Хәзер дә аның һәр сүзен кылычтан үткәрде:

* Тур – капка төбе *(диал.)*

– Аларның кайсысы затлы соң? Бөтенегез дә авыл бәрәңгесе ашап үскән ләбаса!

– Син дә, – дип кыстырды түрә.

– Әйе, мин дә! Тик мин сезнең сыман чыгышымнан оялмыйм. Рәхмәт, синең акчаңа дөнья иңләдем, матур киендем, тәмле ашадым һәм шунысын да онытмадым: моның бер чиге булачак, дидем. Сәркатип дип алдадым, йөрәгеңә ярамас, дидем. Урындыгыңнан егылма, яме? Бичәң – чәчтараштa чәч кисүче! Син тап-таза ир, сиңа да эш табарга мөмкин. Әнә, баганага азык-төлек базасына төнге сакчы кирәк дип белдерү элгәннәр.

Бу тәкъдим, гәрчә үртәү рәвешендә әйтелсә дә, Илмәт Гаязовичның бәгыренә кадалды. Хатын-кыз – елан, чакса – агуы кан тамырларыңны тишә икән, ул, кисәк хәлсезләнеп, бүлмәсенә атлады. Ләкин аңарда да усаллык хәттин ашкан иде. «Түрә», тамак төбен гырылдатып:

– Ресторанга бер генә этрәк-әләм дә аяк басмасын! – диде.

Ир белән хатын бер-берсенә үпкәләсә дә, җаваплы мәҗлескә ныклап әзерләнде. Үзәктә ресторан сайладылар, меню төзеделәр. Чакыру кәгазьләрен тарату мәшәкате Гөлфирәгә йөкләнде. Ике көннән соң телсез элемтә чарасы «җанланды».

– Гафу үтенәбез, Әмин Маликович сезнең мәҗлестә катнаша алмый, ул командировкада, – диде үзен ярдәмче дип атаган ир-егет. Шуннан бирле телефон гел «тәтелдәп» торды:

– Гафу, Фәләныч авырый... Гафу, Фәләныч бушамый... Гафу, Фәләнычның оныгы туды...

Гүя барысы да чиратка тезелгән дә телефонны бер колактан икенче колакка күчерә иде.

– Шикләнгән идем аны, – диде хатыны. – Шигем расланды. Хәтерлисеңме, ит комбинаты директоры белән сез әшнәләр идегез. Без ике гаилә Карловы Варыда ял иттек.

– Хәтерләдем ди! Шуннан ни?

– Шуннан шул, аны бер гаепсезгә төрмәгә япкач, син, шалт, арагызны өзгән идең, Илмәт. Фикердәшем дип мактанган нефть тармагы башлыгы Әнәс Кутуевны вазифасыннан төшергәч, йөрәк өянәге белән хастаханәгә эләкте. Хәлен белдеңме, Илмәт? Белмәдең!

– Мин аларның берсенә дә начарлык теләмәдем! – дип мыгырданды «түрә».

– Сиңа да теләмиләр, сиңа да, абзыкаем! Бары тик исемеңне генә сызып ташлыйлар! Нәкъ синең төсле. Әгәр кемгәдер тары бөртеге хәтле генә изгелегең тисә, үзеңә кире әйләнеп кайтмас идемени, Илмәт?!

Ул озак сызланды. Бу сызлану хәтта ки аякларын чатнатты. «Кемгәдер тары бөртеге хәтле генә изгелегең тисә», имеш! «План, план», – дип, туктаусыз муен тамырыңа тондырсалар, кем изгелек турында уйлар икән?!

...Тимер капканың кыңгыравы чыңлады. «Чың-чың»... «Чың-чың»... Илмәт Гаязович ишек кырыендагы экранга карады. Олы гына яшьтәге хатын, күрәсезме мине дигәндәй, тешен җемелдәтеп елмая иде. Гөлфирәнең эт каешы – туганнары микәнни? Ресторанда алар күңел ачты һәм менә әрсезләнеп коттедж сукмагын да таптыйлар. Әрсез кунакны урамнан ук озату нияте белән, «түрә» үзе каршы чыкты.

– Танымыйсыңдыр, иеме, энем-җаным? – «Җемелдек теш», сумкасын кочаклап, тимер эскәмиягә җәелгән иде.

– Танымыйм! – диде хуҗа, кырыс кына. – Гөлфирә эштә.

– Мин атап сиңа килдем, энем-җаным. Әдрисеңне оешманың кадрлар бүлегеннән белештем. Ялда икән син. Ял кирәк, исән килеш картаю зур бәхет.

– Гозерең ни, гражданка? – «Түрә» кеше тыңлап өйрәнмәгән иде.

– Гыраждан димә әле, Сафия түтиегез мин. Танымассың шул, энем-җаным. Аннан бирле байтак сулар акты.

– Кыскарак тот, Сафия түти!

– Кыскасы – озыны шул: син ябь-яшь директор идең. Мин синең кабинетыңны җыештыра идем. И-и, орыша идең инде, пычрак юасың, дип. Идән чүпрәге белән йөземә дә ордың инде.

Беренче уй – тизрәк капканы ябу иде. Болай да авыр, тагын китереп өстиләр!

Ә хатын елмая-елмая дәвам итте:

– Гаеп миндә иде, энем-җаным. Җиде яшьлек авыру улым йоклаганда өлгерим дип ашыга идем. Берсендә син Мәскәүдә командировкада дигәч, Илдарымны да ияртем. Синең кәнәфиеңә яткырдым. Әй, Ходаем, шунда син бүлмәгә кермәссеңме! Самолёт очмаган икән. Таш кебек мең өлешкә уалдым, билләһи.

«Түрә» моның ише вак-төякне хәтерлимени! Бәреп үтермәгәндер, шәт! «Во-он» дип акыргандыр, анысы хак.

– Син түлке тыныч идең, энем-җаным. «Улыңмы? – дидең. – Ник аның чырае ап-ак?» – дидең. «Чирле», – дидем. И Алланың мәрхәмәтле бәндәсе, шофёрыңны чакырттың да: «Бар, әнкәсе белән икесен фәлән бүлнискә илт, баш табибка минем исемнән җиткер, малайга сручны диагноз куйсыннар, бездә дәваламасалар, чит илгә барырга документ хәстәрләсеннәр, расхудларын үзем түлим», – дидең. Табиб: «Әзрәк соңарсагыз, улыгыз үлә иде», – диде. Син генә минем газиземне коткардың, утыз ел мин сиңа рәхмәт укыйм, энем-җаным!

– Хәтер савытының төбе саеккан, – диде хуҗа. Кайчандыр орден-медальләр белән чуарланган күкрәк салкынайган иде, ул җылынып йомшарды. Күзгә яшь пәрдәсе эленде. Йөрәк алай ук тимер түгел икән... Сафия түти «түрә»нең капылт үзгәрүен сизмәде.

– Әй, оешмада меңәрләгән кеше, каян хәтерлисең ди! Мин сездә бүтән эшләмәдем бит, табиблар балагызга тазарыр өчен кымыз эчерегез дигәч, туган якларга – Башкортстанга киттек. Илдарым, шөкер, мәктәп тәмамлады, Мәскәүдә укыды, Уфада калхуз фермасыннан әз генә кайтыш кантурда нәчәлник иде. Аннан тагын да югарырак урынга менде. Ике атна элек Казанга күчендек, Алла кушып.

– Без шат, – диде Илмәт Гаязович. «Без» кемнәр? – анысы мөһим түгел иде. Өч дистә елдан соң рәхмәт китергән кунакны ул, әлбәттә, чәйгә дә чакыра алыр, алар хәзер тигез, алар бер үк статуска ия иде.

Сафия түти сумкасыннан пыяла савытлар бушатты.

– Сиңа әз генә күчтәнәч, энем-җаным. Кыргый бал кортлары агач куышлыгына җыйган ширбәт.

– Рәхмәт, Сафия түти. Мәшәкатьләнмәскә иде.

– Нинди мәшәкать ди! Бер очтан шатлыгымны да бүлешим, дидем. Оешмагыздан хәбәр иткәннәрдер, яңалыклар турында?

– Юк, компания белән хушлаштык без, хәзер безнең дөнья йорт белән генә чикләнә шул, Сафия түти.

Аның тавышы шундый мескен иде ки, ул үзен кызганып куйды.

– И-и, Алла бәндәсе! Кичә генә оешмагызга билгеләнгән яңа хуҗа Илдар Сафаев синең ярдәмең белән терелгән бәгырь җимешем бит, Илмәт энем!

## Котылу

**1**

Күз алмасы кебек кадерләп үстергән бердәнбер оныгы, җәһәннәм читендә хезмәт иткән җиреннән, исәпләмәгәндә генә кайтып төшкәч, Мәрфуганың дөньясы түгәрәкләнде. Солтан ерак-еракларда адашып калыр дип ул иртә-кич кайгыра иде. Оныкка чандыр гына гәүдәле, сары чәчле кыз да тагылган иде.

– Әбекәй, таныш, бу – минем хатын, – диде Солтан.

– Сөбханалла, бигрәк чибәр! – Карчык токмач камыры баса иде, кулын алъяпкыч итәгенә җәлт кенә сөртеп, киленен кочакларга сузылды, әмма сары чәч кисәк артка чигенде:

– Ой, кагылмагыз! Күлмәгемне онга буйыйсыз!

– Безнеңчә сөйләшми ахрысы. – Мәрфуга, дөрес, тылмачсыз да киленне аңлады, яшь чагында күрше авыл марҗалары белән бергә имән чикләвеге җыйды, шунда ул «аларча» шактый сукаларга өйрәнгән иде.

– Әбекәй, Изольда Петровна белән дуслашырга тырыш, яме? – Солтан чемоданнарын идән уртасына өйде. – Мине үзәктәге хәрби комиссариатка эшкә чакырдылар. Әлегә фатир юк, диләр. Без ничәдер ай синдә яшәсәк, кысан димәссең микән? Район белән авыл арасы биш чакрым, йөреп эшләр идем.

– Яшәгез, балам, яшәгез! Мәрхүм бабаң нигезе, мәрхүм атаң йорты, – диде карчык, сөенеп. Ә йөрәккә шом үрләде. Изулдә... Ярабби, Питыр кызы Изулдә... Гел генә дә әллә ничек... Тел әйләнми...

Яшьләр, ашап-эчкәч, култыклашып, бакча артында гына җәелеп аккан Көмеш елга буена китте. Тынычлыгын җуйган Мәрфуга анда тотынды, монда тотынды, ләкин баягы шом таралмады. Дөньяда бик зур хата кылынган, һәм аны шушы мәлдә үк төзәтмәсәң – җир убылыр, күк гөмбәзе урталай ярылыр сыман иде. Әй, онык, онык! Уйларда гына яндырасың ла! Үз тиңең беткәнмени соң, йә?! Изулдә... Әйе, ул да адәм баласы, төптән уйласаң. Кемнеңдер газизе. Туктале син, кортка, бәргәләнмә! Бу хатаның ичмасам яртысын, һич югы чиреген булса да төзәтергә мөмкиндер бит. Киленнең исемен үзгәртергә кирәк. Әйтик, Нәркизә, диик. Озын, дисәләр, Нажия, инде дә ошамаса – Наилә. Өчесе дә күңелгә ятышлы. Гәрчә, Изольда әби кеше белән көрешергә чирканса да, карчык үпкәсен «йоткан» иде.

Әлеге уеннан канатланган Мәрфуганың кунакларны көтеп торырга сабырлыгы җитмәде, ул йөгерә-атлый бакчага чыкты, утын бүкәнгә басып, яр буендагы карт өянке төбендә чүкердәшкән яшьләргә кул изәде:

– Балакайлар, килегез әле, кил!

Килде «балалар».

– Әйдәгез, өйгә керик, аяк өсте сөйләшер сүз түгел, – дигәч, икесе дә артыннан иярде. Сары чәчкә «кырмавык» дигән кушамат бик килешер иде, иренә чат ябыша, йә күкрәгенә баш төртә, йә беләгенә асылына, әнә, Солтан диванга утыргач та, куначадагы тавыкмыни, тезенә менеп кунды. Урамда аунаган исереккә кызыкмаган шул, телеграмм баганасы кебек озын буйлы, төскә-биткә чибәр, эшкә батыр асыл егетне каптырган.

Карчык, башта оныгына төбәп:

– Улым, безгә чит кавемнәр белән туганлашырга язгандыр, нишләтәсең, – диде. – Мин сезгә бәхет телим, – диде. Аннан, каты-коты урысчасын телендә җебетеп, килененә эндәште:

– Кызым, рас син безнекен сайлагансың икән, гореф-гадәтләребездән дә

йөз чөермә. Исемеңне үзгәртеп, никах укытыйк. Кыз-катын – инәгә тагылган җеп, димәк ки, ул иренең хак динендә булырга тиеш!

Солтан, хатынын тезендә биетә-биетә, шаркылдап көлде:

– Ну синдәге фантазия, әбекәй!

Изольда учы белән аның авызын каплады:

– Көлмә! Шулай тиеш икән, мин риза!

Мәрфуга, аягын өскә чөйгән киленнең үкчәсеннән сыйпап:

– Рәхмәт яугыры, балакаем. Мулладан колагыңа нindирәк исем кычкыртырбыз икән?

Оныгының йөзе үзгәрде:

– Әбекәй, әллә акылың кителдеме? Киленеңнең исеме бар! Изольда ул!

– Безнеңчә кирәк, улым, безнеңчә. Нәркизә, Наҗия, Наилә ишерәк ат сезгә ошармы икән?

– О, романтика! – Сары чәч тагын иренең авызына чәпәде. – Стоп, дәшмә! Абейка минем дустым!

Солтан тиз көйләнде. Көйләнми ни! Карчык беренче минутта ук аның хәлен чамалады: хатыныннан бихуш ир гаилә тәхетендәге солтан түгел, итек олтаны гына иде. Боларны уйлап уелса да, Мәрфуга канатын салындырмады: никах мәҗлесенә әзерләнде. «Мичтә мәмрәп пешә», дип, сарык бәрәне суйдырды, йомыркага каймак туглап тутырсаң, тиресе дә суелмый иде, карт тавык та пычакка «алынды». Аргы очтагы аш-суга уңган Фирданиядән ат көпчәге хәтле табада гөбәдия ясаттырды. Бавырсак, чәкчәк ише нәрсәләргә үзе дә оста иде. Кунаклар күп иде, алгы бүлмәгә, бер-берсенә ялгап, ике өстәл бастырдылар. Бер эшкә дә кушылмыйча, озын сөлге җәеп, елга буенда тән каралткан киленгә ачуланып ни файда, син кулың белән этеп кенә кәкре каен турайса икән! Аллаһ каршысында никах белән тату гына яшәсеннәр берүк! Иң азактан кием хәстәренә керешге Мәрфуга. Килен нәрсә генә кисә дә, үзе кыска, үзе җиңсез иде, үзәктәге мөселман тауарлары кибетеннән аңа күлмәк белән яулык юнәтте. Арса да, «уф» димәде, тез капкачын уа-уа чаптыйөгерде. Никах көненә өлгерде ул. Оныкэшеннән ял сораган иде, мәрхүм әтисенең кәләпүшен киеп, капкадан ук кунакларны каршы алып торды. Тик менә соңгы минутта гына килен тәртәгә типте.

– Атакайга шалтыратып киңәштем, динегезгә дә күчмим, никах та укыттырмыйм! – диде.

Карлыган куагы төбендә телефонда казынган хатынын Солтан озак үгетләде:

– Үзең ризалык бирдең бит, Изочка! Әйдә, киреләнмә.

Сары чәч ирен тупас кына этеп җибәрде:

– Бәйләнмә!

**2**

– Син аңа ачуланма инде, әбекәй. – Башын аска игән Солтан, күзен мөлдерәтеп, Мәрфугага карады. Оныкның кыяфәте кызганыч иде. Бөркетнең йонсыз чыпчыкка әверелүе иде бу. Һич курку белмәс малай иде лә балакай. Кем, Гыйләҗләрнең сарае янганда, ут эченә ыргылып, терлекләрен тышка куалады? – Ул! Тыны кысылып, суга баткан дусты Әхсәнне кем елга төбеннән сөйрәп чыгарды? – Ул! Ә бүген шушы батырдан бер кемсәсе бау ишә...

Кунаклар таралышкан, өстәл тулы сый-нигъмәт шул килеш калган иде, Мәрфуга, кайнар сулыштан ярылган иренен көчкә кыймылдатып:

– Ачуланып ни, – диде. – Кешедән оят менә.

Өйалдында кемдер дак-дак идән төйде.

– Хуҗалар өйдәме? Бичура керә, бичура, ха-ха!

Карчыкның бала йоны кабарды. Никахка дигән озын күлмәк кигән, битенә кара карлыган сытып сылаган, чәчен пумала итеп тузгыткан, ә кулына Мәрфуганың таягын тоткан «Бичура», тавышын ясалма калынайтып, тагын үкерде. – Ник дәшмисез, ахмаклар! Ха-ха!

– Изочка, театр уйнама, – диде Солтан. – Әйдә, тамагың ачкандыр, аша!

– Ой, сколько тәмле әйбер! – Изольда кыстатмады, табынга утырды.

Мәрфуга «ә» дә димәде, «мә» дә димәде. Йөрәк кенә, өзеләм-өзеләм дип, куагында талпынган яфрак төсле калтырый иде.

Хәерсез килен никах күлмәген, йомарлап, чолан идәненә бәргән икән, карчык аны юып киптерде. Авыр таш белән бастырылса да, күңелдә өмет бөреләнә, күлмәк иясен табар, һәм оның үз тиңе белән кавышыр кебек иде. Солтан көнозын эштә, йортта ни хәлләр – бихәбәр, ә кич, карчык аһ-зар белән аның җанын талкымады. Өйдә исә элеккеге тынычлыктан җилләр исте: сары чәч үз тәртибен урнаштырды. Мәрфуга намаз укыганда, дивар селкетерлек итеп музыка акырту, телевизор кабызу, лар-лар телефоннан сөйләшү – никадәр генә кисәтсәң дә, колакка эленмәде. Бервакыт Изольда аның намазлыгы өстендә аяк тырнагын кисә иде, картайдым, дисә дә, көч-гайрәт бөтенләй үк суырылмаган икән, карчык киленне тибеп очырды. Туп төсле тәгәрәде килен. Тәбегә кысылган тычкан төсле чинады килен.

Аның:

– У-у, карт җен! Мин сиңа күрсәтәм әле, – дип янавына игътибар итмәгән иде Мәрфуга. «Күрсәтте» имансыз. Карчык агач сандыкта үлемтекләрен саклый, ә андагы «хәзинә»нең эчтәлеге яшьләргә мәгълүм, газраил ишек шакыса, ул аларны ничек кулланырга икәнен өйрәткән иде. Беркөнне борынны ярган әшәке ис тойды карчык һәм нуешне капшады, фонарь яктыртып, идән астын тикшерде, һәркайда чисталык иде. Аптырап сандык капкачын ачты һәм әз генә аркан аумады: таслап-таслап төрелгән сөлге-тастымаллар, ак ситсылар нәҗескә буялган иде. Әй, күңелнең иң нечкә кылларын сындырды килен! «Мондый әрнүне дошманыңа да язма, Раббым!» – дип елады ул. Оныкка белгертмәде, үлемтекләрне яндырды. Ә Изольда читтән генә елмаеп йөрде...

Ун көнгә командировкага китмәсә, әбисенең күзеннән ташыган хәсрәтен Солтан бәлки күрер иде. Мондый тормыш җүнлегә илтмәс, миңа килен белән мөнәсәбәтләрне җайларга кирәк, ул да бит адәм баласы, гел кара балчыктан гына әвәләнмәгәндер, аңа ак төс тә кушканнардыр дигәндә генә, Изольда, мәче төсле, үзе каенанасына сырпаланды.

– Абейка, давай дуслашабыз. Мин бүген Самарадан Сашка абыемны көтәм. Аның янында әрләшмик, ладно?

Беркатлы Мәрфуга ереде инде, ереде. Хәтта ки: «Ирең өйдә юк чакта кунак китермиләр», – дип тә чәпчемәде. Юл сумкасын аркасына аскан табак битле ир-ат үгезгә охшаган, карашы белән сөзеп ызбаңны ишәр кебек иде. Абыйлы-сеңелле, төнлә каядыр югалып, таң атканда гына пәйда булды. Төшкә хәтле, алгы бүлмә ишеген ябып, икесе дә йокы симертте. Уянгач, битен дә юмаган килеш килен кыяр-помидор турады, ипи кисте.

– Без туганым белән пикник оештырабыз. Кызынырбыз, су коенырбыз.

«Пикник»ның мәгънәсен аңламаса да, карчык урынын белде: карт өянке төбендә икән. Аулак, кеше йөрми...

Табигать кочагыннан туганнар айкалып-чайкалып кайтты. «Болар кояш эссесеннән миңгерәгән ахрысы», – диде Мәрфуга. Ә кичкырын, азгын кәҗәсен

эзләгәндә, өянке төбендә аунаган аракы шешәләренә абынып чүт егылмады. Менә сиңа «эссе кояш!»

«Пикник» өченче көнне дә дәвам итте. Иртән үк көн бозылырга маташа, күк читендә куерган болытлар әкрен генә авылга таба шуыша иде. Яшен ялт-йолт күз «уйнатты», таш тутырган кисмәк дөбер-дөбер тәгәрәде. Давыл килә иде, карчык баудан керләрен җыйды, тавык-чебешләрен абзарга куалады. Мондый вакытта яр буенда кызынып яту куркыныч иде, бу ике җәфаны чакырыйм булмаса дигәндә генә, капкада Солтан күренде.

– Бәй, сәфәрем ун көнлек дигән идең лә, улым?

– Бурыч үтәлде, әбекәй. Поезд тәрәзәсеннән җил бәргән бугай, башым шаулый.

– Хәзер, улым, үлән чәе эчсәң – тереләсең, иншә Аллаһ, – дип, Мәрфуга ашыгып өйгә әйдәде. Чынлап та, Солтанның маңгае уттай кызу иде.

– Давыл купты, Изольда кайда соң?

Кемгә нәрсә, кәҗәгә кәбестә шул, моңарда хатын хәсрәте!

– Юрганга төренеп ят әле, улым. Үлән чәе тирләтә-җиңеләйтә ул.

Өянке төбендәге шешәләр турында сөйләргә теле бик кычытса да, карчык тыелды. Ир белән хатын арасын шайтан гына бозар.

– Изулденең абыйсы килгән ие, улым.

Онык мендәрдән башын калкытты:

– Нинди абыйсы?! Аның бер туганы да юк, Изольда ятимнәр йортында үскән!

– Чү, улым, чү! Хәзер хатыныңны чакырам, алар су буенда гына.

Мамык та мамык, Мәрфуганың да аягы мамык иде. Ул көчкә-көчкә генә атлады. Болытлардан ут чәчелә, таш төягән кисмәк яман дыңгырдый иде. Табигать никадәр генә тузынса да, бер басыла, ә менә карчыкның күңелендә бөтерелгән өерменең һич тынасы юк иде. Хәйләкәр килен күзгә карап алдады микәнни? Әйтәм аны төнлә югалалар иде. Сарайдагы печән өемен, шәт, кәҗә таптамагандыр? Шикләнү дә шайтан котырыгы, диләр.

Чиләкләп-чиләкләп яңгыр яварга тотынды. Сукмак лачма чыланды. Таеп егылмас өчен, яртылаш бөкрәйгән Мәрфуга гәүдәсен турайткан иде, аягы җиргә кадакланды. Өянке төбендә ике туган бер-берсенә береккән иде...

– Изулдә, ирең кайтты!

Күк күкрәвенә күмелсә дә, хатын аның тавышын ишетте, «абыйсы»ның кочагыннан суырылып:

– Ой, ник бик тиз? – диде. – Сашенька, татар кайткан! Тай тизрәк!

– Айн момент! Хушлашыйк башта, иркәм. – Сашенька бугазына голт-голт аракы койгач, шешәсен карчыкка табан ыргытты. – Әй син, карга! Татарга серне тишсәң, сагалап торып үтерәм мин аны! Молчи, карга!

«Үгез», исерек хатынны кочагына кысып, янә өянкегә сөялде.

Мыскыл! Хурлык! Гарьлек! Әйтеп кенә ышанса иде икән Солтан! «Нахак», дияр. «Изольданы яманлама, әбекәй, мин аны бөтен хата-кимчелекләре белән яратам», – дигән иде, яратучылар бер син генә түгел әнә! Тегесе дә, елый-елый: «Ялган! Абейка сине миңа каршы котырта, бездә берниндидә кунак булмады», – дияр.

Яшен, кая барып бәрелергә белмәгәндәй, камчысын әле уңга, әле сулга селтәде дә, алагаем кизәнеп, нәрсәгәдер китереп сукты. Колак тонды, арка пеште. Ләхәүлә, ләхәүлә, ләхәүлә... Мәрфуга артына борылды: карт өянке чытыр-чытыр яна иде.

# Әти-и!

## 1

…Ул зур гына бәлешне төбенә хәтле капйот төсле ялтыратып куйды. Үзе туйса да, күзе туймадымы, «тагын нинди тәмле әйберләрең бар?» дигәндәй, карашы белән табынны айкап алды. Әллә артык ачка киселгән иде – хатын аңламады. Таза ир-ат батырып ашый, моңа гаҗәпләнәсе дә юк, ләкин сакалбай көнозын бер тамагы белән мәшгуль иде. Иртән генә ике тәлинкә борай боткасы «состы», йомырка тәбәсеннән баш тартмады, сөтле чәй белән «озатылган» чәпәк-чәбәк кыстыбый да матур гына үз урынына кереп «урнашты». Күпсенмәде Илһамия, киресенчә, сөенде генә! Аның кул җылысы тигән ризыкларны сагынгандыр. Бу сөенечкә икенче сөенеч тә өстәлде: димәк, читләр белән яшәгәндә, кадере булмаган. Хатын-кыз тәрбиясе күрсә, телгән чыра кебек болай ябыкмас иде.

– Шулпаң кайныйдыр анда, тутый кошым, – диде ир, корсагын сыпырып. – Исе таралды.

– Ите катырак, әзрәк пешсен әле. Ял ит бераз, Минсабир.

– Төнлә яхшы йокладым мин.

– Ризыктан ял ит дим. Берьюлы күп ашап чирләрсең тагы.

Илһамия табак-савытларны җыештырганда, Минсабир өстәл кырыендагы тар диванга җәелде. Баш астына кечкенә мендәрчек кыстыргач, яңгыратып кикерде дә:

– Шулай итеп, безнең малай өйләнә инде, ә? – диде.

– Өйләнә, Аллага шөкер.

– Туйда әти түрдә – янәшәмдә утырачак, ди инде, ә?

– Утырачак, ди, әйе.

– Әтиең кайтты, дип, син хәбәр юлладыңмы, тутый кошым?

– Ничек мин, ничек? – Хатын гаҗәпләнеп иренә карады. – Әле аңа синең хакта ләм-мим. Син Булат белән үзең күрешкәнсеңдер ич! Әти туйда була дип шылтыратмас иде лә!

– Каян килеп күрешик! Аның әдрисен кем әйткән ди!

– Авылдан берәрсе сызгыргандыр, өч көнлек иске кунак лабаса син!

Илһамия тынычланды, ир дә бүтән бәхәсләшмәде. Булат этисе турында белә, шул җиткән!

– Тырыш икән безнең малай! Безгә нинди шәп йорт тергезгән. Бүлмәләре зур, хет шар сугып уйна, – диде Минсабир, канәгать елмаеп.

Хатын:

– Әни, ялгыз интекмә, безгә – Казанга күч, ди. Аякта чагымда өемнән китәмме соң! – дигәч тә, – ир, сүзеңне раслыйм дип, теле белән шапылдатып мөһерен сукты:

– Китмисең, тутый кош! Син хәзер ялгыз түгел, без икәү! Өр-яңадан тормыш башлыйбыз!

«Тутый кош» биемәде, аллы-гөлле каурыйлары суга чылангандай куырылып бөреште. Егерме биш елдан соң күктән төшкән «сәяхәтче бака»ны, бусагадан уздырмаган очракта, әлбәттә, аны беркем дә «миһербансыз» дип гаепләмәс иде. Ә ул уздырды, хәтта кунак итеп кадер-хөрмәт күрсәтте. Әнә, ничә көн аш бүлмәсендә төрледән-төрле тәгам әзерли. Уздырды, чөнки үзе дә ялгышты… Ишетмәгәндер, мәгәр ишетсә – коймак-кабартмалар бугазына тыгылмагае әле. Хәер, Илһамия

җебемәс, беренче син ташладың, имансыз, дияр. Ни гаҗәп, хәсрәт утына салып яндырса-көйдерсә дә, шушы «телгән чыра» кай төше беләндер җанга якын иде. Әйтерсең, былтыр яккан мичнең кызуы сүрелмәгән, әйтерсең, ул һаман йөрәкнең бер читен җылытып тора!

Авыл чибәрләре белән чагыштырганда, Илһамия төскә-биткә шактый кайтыш иде. Ә Минсабир аңа өйләнде. И-и, көнләште дә соң кызлар! Юк кына буй-сының, юк кына кыяфәтең белән менә дигән егетне эләктер әле! Яратмаслык түгел иде Минсабир. Шук-шаян, телгә оста... Их, ул яшьлек! Их, шул чакта кайнап ташыган хисләр! Әнә, әле дә эчтән ургый, ә хатын битараф кылана, тыштан гына, билгеле! Янәсе, сине күрдем дип өзелмәдем... Хәер, йөрәге мүкләнмәсә, ир табынга ризык белән наз да ташылганын сизәргә тиеш иде.

– Килен кайсы яктан? – диде ир.

– Казан кызы. Бик акыллы.

– Хи, чалыш-полыш димәгән икән.

– Кем чалыш-пылыш?! Кем?!

– Аңгыра мәллә син? – Минсабир йодрыгы белән мендәрен төйде. – Безнең малай! Уң аягы зәгыйфь бит аның. Кечкенә вакытта ат арбасының тәгәрмәченә кыстырган иде.

Илһамия кулындагы чәйнеген шап иттереп өстәлгә утырткан иде, капкачы ачылып, ирнең битенә су тамчылары чәчрәде. Тамчы белән бергә ул ачуын да бөркеде. (Сабыен яклаган ана кеше ерткычтан да хәтәррәк иде.)

– Безнең Булат туп-туры атлап йөри! Аягы төзәлде. Син кыстырдың аны исерек килеш, син! Врачларга илтик, дидем, күпме ялындым, кул гына селтәдең! Бала дип хәсрәтләнмәдең, кәгазьдә генә ата идең шул!

– Йә, әнкә тутый кош, зерәгә тавыш куптарма инде. Аягы турайган икән, мин бик шат! – Минсабир яткан җиреннән үрелеп кенә Илһамиянең күлмәк итәгеннән тартты. – Лутчы әйт, туйга мин нәрсә киям? Күрәсең, өстә сәләмә кием.

– Ул икебезне дә кайгырта. Әтигә үзем тектертәм, диде. Нечкәлекләренә хәтле сөйләшмәдек, телефоннан гына хәбәрләштек дим бит. Иртәгә Казанга барам, шуннан соң барсы да ачыкланыр. Син дә әйт менә, егерме биш ел син – сәяхәтче баканы кайсы илләр-җирләр өстеннән очырттылар?

Ир мәче кебек киерелде-сузылды да:

– Дөнья гиздем, әйдәле, үткәннәрдә казынмыйк, – диде.

– Булат «әти» дип көн-төн елады. Син аны үстерешергә ярдәм дә итмәдең, миһербансыз! Җир тишегеннән ун тәңкә акча җибәрер идең хет!

– Чәпчемә инде, Илһамия! Тучны, ялгыз яшәп, тавыш тансыклагансың икән. Мужыт сиңа җен ияләшкәндер, шул котыртадыр. Малай, бак, кинә тотмый бит, «әти» дип, зурлап туена дәшә! Әй, ит пешмәде микән анда?

**2**

Бүген ул үз-үзен ике атнага эштән «азат итте». Кичтән үк урынбасарына күрсәтмәләр биреп калдырды. «Уң кулы» ышанычлы, тормыш дулкынын кораб кебек ярып йөзгән оешманы бу арада гына төпкә батырмас. Төштән соң авылдан әнисе килде. Чәй дә эчмичә, башта өч катлы коттеджның һәр почмагын җентекләп тикшерде.

– Улым, залга ничә кеше сыяр икән? Туй мәҗлесе шунда узадыр бит?

– Юк, әни, туй ресторанда үтә.

– Абау, улым! Өең нинди зур! Бүлмә өстенә бүлмә! Мин бай дигәч тә алай ук кыланмаска иде инде. Расхут бит ул.

– Акча эшлибез, әни, бер дә борчылма.

Аналы-уллы менә шулай ипләп-җайлап кына туй хәстәре турында сүз башлады һәм моның ахыры бик күңелсез тәмамланыр дип уена да китермәде. Тиктормас әнисе ни эзләгәндер, өске каттан кәчтүм-чалбар тотып төште.

– Уртадагы бүлмәдә ят ир-ат әрбире күп. Сиңа әллә ниткән дуслар сырыша. Кем инде ул тагы? Килен ошатмас, тиз арада чыгар! – дип, ул кулындагы табылдыгын үз буена үлчәгәндәй итте. – Монысы кемнеке? Бигрәк затлы.

– Әтигә туй бүләге, әни. Син дә кибеттән күңелеңә ятышлы күлмәк сайларсың.

– Мин качмам анысы, менә әтиеңне зурлагансың, рәхмәт яугыры! Карале, улым, – әнисе элгечтән чалбарны салдырды. – Моның балагы озынрак. Бер сүәм кистертәсе иде моны. Синең әтиең, хәтерләсәң, кыска буйлы. Әй Аллам, сабый гына идең, ни хәтерлисең икән!

– Әни, әтигә тап-таман ул! Аның үлчәме бу!

– Кечкенәдән үк үз туксаның туксан иде! Озын тек, озын! Жирафка теккәннәр диярсең. Әтиең ябык та әле, кәчтүме дә киң.

Булат, шикләнеп:

– Тукта әни, әллә без икебез ике кеше турында сөйләшәбезме? – диде.

– Ниткән ике кеше? Атаң берәү генә синең ул. Минсабир атлы, тискәре малай! Уф, башым чатный. Әзрәк җилләнәм, Вьетнам базары тирәләрен урыйм. Озатма, адашмам. Уф, башым!

**3**

Димәк, югалган «кем» табылган. Ләкин ул табылды дип кенә берни дә үзгәрмәс һәм чалбар балагы да кыскартылмас... Үчме? Һич юк! Мәҗлес үтәсе залда һәркемгә урын җитә, ә түрдә... түрдә фәкать аның әтисе утырачак! Нокта! Әйе, үч юк, ә хәтер исән.

...Беркөнне әти кеше иске чәйнектәге акчаның эресен-вагын кесәсенә койды да:

– Барасы җирем бар әле, – диде.

Алты яшьлек малай әнисенең кызарган күзеннән «укыды»: «барасы җир» ерак, бик ерак ахырысы. «Әти, китмә!» – дип, ул елый-елый олы юлга кадәр аның артыннан чапты. Әти кеше автобус тукталышына яхшы ат кебек юыртты, Булат, бәлки, аны куып та тотар иде, зәгыйфь аягының хәле бетте. Аннары әтисе борылып яман акырды:

– Икенче аягыңны да сугып имгәтәм, борыл!

Җир өстенә сары буявын сибә-сибә көз иңде, аны зәмһәрир суыгы белән колакны чеметкән кыш алыштырды, көлә-көлә гөрләвекләр аккан җылы яз да озакламады, җәе дә үз чиратын уздырды, ләкин йортта олы хуҗа күренмәде. Эш дигәндә әллә ни калкынмаган әтисе мунча бурасын яртылаш бурап ташлаган иде, әнисе күрше авылдан балта остасы яллады. Иске генә машинасына кирәк-яракларын төяп килгән абзыйның буе әкәмәт озын, ул үрелсә, күктәге торнаның тәпиеннән эләктерер сыман иде. Кушаматы да Колга Камил икән. Булат дусларыннан көнләшеп үлә, әтиләре аларны йә велосипедта, йә мотоциклга атландыра, әнә, Саматны әтисе тәмам очындыра, йөк машинасында йөртә иде.

Озын Камилнең «тимер аты» ачык иде, күзен елтыратып, малай шуның янында таптанды.

– Улым, кер, рулен борып уйна! – диде оста. «Улым!» – дип йомшак кына әйтте. Ә кичкырын Озын Камил аны, тезенә утыртып, ике кат урам әйләндерде. Уч төбе кытыршыланган дәү кулның җылысын тоеп руль боргалаган малай әледән-әле ачык тәрәзәчеккә карады: янәсе, күрегез, Булат та тимер ат «иярләде!» Мондый «сәяхәтләр» көн саен кабатлангач, әнисе, өнәмичә:

– Бу Озын нәрсә дип кеше баласына багына икән, – диде.

Ә «озын» белән «кыска» отыры бер-берсенә беректе. «Тимер ат» көйсезләнсә, малай да төзәтеште: очлы таяк белән анда төртте, монда төртте. Ник шунда Озын Камил «Ярамый, бозасың!» – дип кычкырсын. Әтисе исә: «Аяк астында буталма!» – дияр иде дә маңгайга чиертер иде. Мунчаның бигенә хәтле ясап эшен төгәлләгәч, Оста машинага балта-пычкысын төяде. Аның белән бергә Булатның шатлык-куанычы да китәчәк иде. Ул, күңеле тулып, алгы бүлмәдә борынын мышкылдатмакчы иде, олыларның сүзе колагына чалынды:

– Мунча өчен акча алмыйм, Илһамия.

– Юк, юк, Камил, күпме көч салдың, аласың! Иртәгә, бозауны сатып, хагын түлим.

– Илһамия, егет бит буй тарта. Быел мәктәпкә җыенасыз. Саткан акчаңны аңа кием-салымга тот!

– Син инде тагы, рәхмәт яугыры. Гомергә рәхәт күр, Камил. Яшермим дә инде, акчага кысылган чагыбыз шул.

– Булат аксый, нәрсәдер эшләргә иде, Илһамия.

Бушка мунча бастырганга сөенгән әнисе монысын борын төбендә безелдәгән чебенне кугандай сүзсез генә уздырып җибәрде. Аяк мәсьәләсендә аның җавабы күптән әзер иде: «Ходай шулай язгандыр...»

– Камил... Әллә дим... – Әнисенең тавышы калтырады. – Бездә генә каласыңмы? Син дә ялгыз, мин дә ялгыз.

Менә тамам, менә тамам дип торган күз яшен җәлт кенә кулы белән сыпырган малай арткы бүлмәгә атылды:

– Кал, китмә, кал!

Оста аны кочаклап күкрәгенә кысты.

– Әниең белән уйлашырбыз, яме, улым?

Ике ялгыз озак уйламады, Озын Камил бөтенләйгә аларга күченде.

Урамда яшьтиләр: «Яңа әти алдыгызмы?» – дип үртәсә дә, Булат гарьләнмәде, киресенчә, эчтән генә горурланды: ул да әтиле хәзер, ул да... Берсендә малай:

– Бүген без әти белән көпчәк ямыйбыз, – дигән иде, әнисе авырттырып колагын борды:

– Чит абыйларга әти димиләр, ахмак! Синең газиз атаң исән!

Ә «газиз ата» кайда иде соң, кайда? Малайның өзелеп-өзелеп әти диясе килә, андый кеше янәшәдә генә: ул йомшак күңелле Озын Камил иде. Оста бит, әнә, «минеке түгел» дими, нинди генә эшкә керешсәң дә: «Улым, әйдә, булыш», – ди. Малайның булышуы болай гына инде анысы... Ярдәме шул хәтле генә. Үсендерә бит әле җитмәсә: «Вәт, булдырасың, улым», – ди. Иске машина белән рәхәтләнде Булат. Шунда казына-казына детальләрне аерырга өйрәнде. Берсендә, кызыксынып, моторны сүтте хәтта. Оста читтә – шабашкада иде, орышмады. «Улым, хәзер ашыкмыйча гына, уйлап кына киредән җый», – диде. Җыйды малай. Озын Камил:

– Башлы син, улым. Алла кушса, киләчәктә зу-ур гына автосервис төзерсең, – дип мактаган иде, әнисе дөрләп кабынды:

– Ник баладан көләсең?! Юрама аңа әкият тормышы! Күрәсең бит, ул җанвалит!

Аз сүзле иде Оста, эшләгәндә дә аның өчен «чык» та «чык» балта гына «сөйләшә» иде. Уңган иде үзе, хуҗалыкта ауган-егылган торгызылгач, ул ягада йортлар салышты, кыскасы, акчага тилмертмәде. Балачакта аксак аягына әлләни игътибар итмәгән малай үсә-үсә үзенең гариплегеннән кимсенә башлады. Бишенче сыйныфта укытучы табышмак уйларга кушкан иде, партадашы Рәхилә: «Чалыш-полыш, ә укуда үзе тырыш», – дигәч, барысы да Булатка борылып көлде. Абзар артында яшеренеп сызланган малайны Озын Камил юатмады, нибарысы: «Битеңне салкын су белән ю!» – дип кенә әйтте. Иртәгәсен ул каядыр китеп кич кенә кайтты.

– Илһамия, егеткә чиста күлмәк-ыштан хутла, без Казанга – бүлнискә барабыз, – диде.

– Анда ни нужагыз калган? – Хатын ире нәрсәгә генә ният итсә дә, хәрәмләшкән «батыр» кебек, аңа аяк чалырга маташа иде.

– Булатны табибка күрсәтәм.

– Һи, акчасыз сине бүлниснең бусагасыннан да уздырмыйлар ич!

– Ансы минем хәсрәт, Илһамия.

«Йортка кергән ир» исеме күтәрсә дә, Оста, хатын кубызына биемичә, дилбегәне җай гына үз ягына каера иде. Беренче көнне алар Камил абыйның ботак очы туганы Әлтәфләрдә кундылар. Әлтәф баш табибның шофёры икән, әмма ул «тән сакчысы» булса да, артыгын сорарга базмый икән. «Ботак очы»:

– Чиратка язылырсың инде, энем, – дигәч, Оста, кайгылы гына:

– Юк, безгә тиз арада операция ясасыннар! – диде. – Түлим мин, акча белән килдем!

...Наркоздан айныган малайга ике күз текәлгән иде. Ярату белән мөлдерәмә тулы ике күз... Карават кырыена тезләнгән Озын Камил аның чәченнән сыйпады:

– Хәлең ничек, улым? Операция яхшы үтте, ди хирург. Яшибез, яме, улым!

Шушы кешегә, үз атасы кебек кайгырткан кешегә малай: «Рәхмәт, эти», – димәкче иде, бер-берсенә ябышкан ирене кыймылдамады. Авызын мамыклы су белән чылатып сөрттеләр, хәер, әмма әнисенең: «Синең газиз атаң исән», – дип колакны боруы телен ачкыч белән бикләткән шикелле иде. Аркасына мендәр терәп утыртканда да, күтәреп бәдрәфкә илткәндә дә, Булат тагын «талпынды»: «Әти, эти...» Биленнән тотып, беренче адымын атлатканда да, әлеге сүзне күңеленнән генә ун тапкыр кабатлады: «Әти, эти...»

Баласының туп-туры басып кайтуына әнисе чиксез-чамасыз шатланырга тиеш иде. Тик алай булмады шул. Ул шик-шөбһәләре белән Останың җанын ашады:

– Табиблар ярты елдан тыпыр-тыпыр биер дигән, имеш! Син – беркатлы, ышандыңмы? Ялгаган сөяк кире сынса, ә? Бөтен аксак-туксак операция ясатыр иде. Әле начармы, яхшымы, үз көенә йөрештерә иде бала!

Булат ак белән караны аерырлык яшьтә, ул хаксызга битәрләнгән Останы яклап, бер генә түгел, ун сүз кыстыра ала иде. Ник кыстырмады икән, ник?! Берсендә Озын Камил: «Без әнкәң белән әзрәк җиләннең тузанын каксак – тыгылма, улым», – дигән иде. Тыгылма, имеш. Нишләп алайса ул хатынының әче теленә түзеп тора, нишләп Булатның этисе кебек «Җитте!» дип кычкырмый?!

Аяк тиз төзәлде. Балачак та әкрен генә артка чигенде. Останың иске генә

машинасын сүтә-җыя, шактый шомарган үсмер механик һөнәренә кызыга, әнисе, аның бу теләген хупламыйча:

– Сәүдә тирәсенә елыш, әнә, сатучылар балда-майда йөзә, – дип тукылдаса, Оста беркая да кыстамады:

– Башың җилкәңдә, улым, үзең сайла, – диде. Ул йортлар сала-сала җыйган акчага яңа «Жигули» юнәткән иде, икәү Казанны урадылар. Аннан әйләнеп кайткач, егет беренче тапкыр әнисенә бик каты бәрелде:

– Котыртасың дип Камил абыйны талкыма! Оятсыз син, әни, без ничә ел аның акчасына яшибез! Балда-майда йөзәргә хыяллансаң, үзең сат кибеттә, мин документларымны механика факультетына тапшырдым!

Студент Булатны тулай торакка да Оста китерде. Әйберләрне бүлмәгә урнаштыргач, Озын Камил аның кулына машина ачкычын сонды:

– Мә, улым. Миңа хәзер бу арбаның хаҗәте шул хәтле генә. Күз начарайды. Иренмәсәң, бу арба сине туендырыр, укудан бушаган вакытларда вокзал-фәләннән кеше ташы!

– Рәхмәт, әти! – дияргә тиеш иде егет, күңел дә шулай тели иде, ләкин авыздагы «йозак» ачылмады...

Көндез уку, кич эш (ул, Останың киңәшен тотып, вокзалда клиентлар сагалады) белән дәртләнгән Булат, күчтәнәчләр төяп, ярты елдан соң гына авылга ашыкты. Озын Камил өйдә юк иде.

– Сине Казанга озатканнан соң, гүпчим күренмәде абзаң, – диде әнисе, битараф кына. – Аңардан башка да рәхәт әле.

– Кайда ул, кайда?! – Егет Остага дигән йон свитерны сумкасына бөгәрләп тыкты. – Үзләренең авылындамы?

– Җенләнмәсәнә, шунда ятадыр.

– Син аны кудың мәллә, әни?

– Кусам ни! Болай да аның белән күпме гомерем заяга узды. Яратмадым мин ул бәндәне. Әтиең дә аңа була кайтмагандыр әле. Йортка чит ирләр ияләштергәнне ишеткәндер.

– Их, син, әни! – Булатның йөрәге, күкрәгенә сыймыйча, ярсый-ярсый типте. Камил абый бит... Камил абый, миңа... Ләкин бу җөмләгә «әти кебек» дигән ике сүз өстәлмәде.

...Останың йорты беренче урамда иде. Таныш капканы озак шакыды ул, тышта инде караңгылаткан иде, кесә фонарен тәрәзәгә табан яктырткач кына, өйдәгеләр уянды. Болдырга чыккан хатын-кыз:

– Кем анда? – диде.

– Мин – Булат. Камил абый өйдәме?

– Бәрәч, ул монда биш былтыр яшәми бит инде, син кем, Булат! Сручны гына безгә ызбасын сатты әллә кайчан инде. Малайга операциягә акча кирәк дип. Оланы җиде яшьтә үк суга батып үлгән иде. Саташты микән? Син кем, Булат, аны Гаделшадан юлла инде. Камил Илһамия атлы катынга өйләнде дигәннәр иде.

Кәкре аякны төзәтү бер йорт бәясе... Бер йорт...

Егет эчтән кызу бәреп кызышкан яңагын кар белән уды. Эрегән кар суына күз яше дә кушылды. Юк, Булат түгел, теге аксак малай сыктый иде...

Ул аны ничә еллар буе эзләде. Институтны тәмамлагач, дипломын күрсәтергә дип эзләде, үзенең эшен оештыргач эзләде, балачактагы уенчык-машиналар чынбарлыкка күчеп, автосервис төзелгәч тагын эзләде. Күк-җирләр актарырга әзер иде Булат. Ахыр чиктә берьюлы дүрт шымчы яллады, өч айдан соң аңа

күңелле хәбәр ирештерделәр: баксаң, Оста борын төбендә генә тереклек итә икән!

Картлар йортында аны директор каршылады.

– Сез Баязитов агайга кем буласыз? – диде.

– Мин аның улы, – диде егет.

– Хәл-әхвәлен сораштырырга килдегезме? Менә шулай килеп күренәсез дә, аннан картларыбыз йөрәк чиренә сабыша. – Ханым әллә кисәтә, әллә үпкәсен белдерә иде.

– Мин аны үземә алып китәм. Бөтенләйгә! – Иң кадерле әйберемне тартып алмасыннар дигәндәй, Булат тиз-тиз сөйләде.

– Камил Баязитов, Камил агай... – Директор амбар кенәгәсен актарды. – Әһә, менә ул. Үзбәкстанда торган икән. Ун ай бездә. Йорт-җирсез, кыскасы, бомж. Нинди чирләре бар, саныйк. Бәлки, шуннан соң «җәфа икән» дип кире уйларсың. Беренчедән, күзе начар күрә.

– Операция ясатырбыз!

– Буыннары сызлый.

– Дәваларбыз.

– Гаиләдә ничә кеше? Фатирыгыз зурмы?

Ханымның сораулары мәгънәсез тоелды.

– Йортым өч катлы! Әлегә мин буйдак!

– Хуп, хуп. Әйдәгез, безнең аксакаллар телевизор карый. Камил агай да шунда, – дип, директор аны ял бүлмәсенә кадәр озатты. Түрдәге диванда өч карт гәпләшә, ә читтә – кәнәфидә берәү башын янтайтып йокымсырый, аның телевизорда һич гаме юк иде. Ничәмә-ничә еллар күңел төпкелендә кузгалмыйча яткан сүздән дивар яңгырады:

– Әти-и!

Барсы да Булатка табан борылды:

– Әти ди? Кемгә әйтә икән? – диеште өч карт та, бертавыштан. – Камил туган, бак, алай-болай сиңа түгелме?

Озын буй гәүдәсен кәнәфидән куптармакчы иде, хәле бетеп, кире урынына ауды. Булат, очып килеп, аны күтәреп торгызды.

– Әти-и!

...Егет киемнәрне кире урынына кертеп элде. Урта бүлмәдә аның өчен иң кадерле кешесе – әтисе яши иде... «Туй алдыннан көч җый», – дип, ул аны шифаханәгә урнаштырды. Озак түзмәс, кайтыр. «Улым, мине ярты ел төзәтә-төзәтә, баштанаяк яңарттың, артыгы кирәкмәс», – дияр дә бер рәхәтлек белән гараждагы иске машиналарда казыныр...



Рәмзия
Габделхакова

# ҖЫЙДЫМ БӘХЕТ ТАМЧЫСЫН...

## Бик ышанган идем...

Мунчаладай чуалганнар еллар,
Минем язмыш шулар арасында.
Бик ышанган идем лабиринтта
Дөрес юлны таба аласыма.

Көчләр мулдан, өмет зурдан иде,
Йөз урадым дивар араларын.
Йөз сугылдым ачык ишекләргә,
Ирек юлын әмма табалмадым...

Алга, дидем... Үзем кабат-кабат
Кайтып төштем канлы эзләремә...
Кемнәр көлеп, гаҗәпләнде икән
Таш эченнән гөлләр эзләвемә?

Кемнәр көлеп күзәтеләр икән
Таш эченнән гөлләр тапканымны?
Шул гөлләрне кысып күкрәгемә,
Соңгы сулыш алып ятканымны...

## Иртәгә

Иртәгә... Әйе, иртәгә!
Яхшырак булыр күпкә.
Җил-давыллар тынып калыр,
Гел кояш балкыр күктә!
Иртәгә... Әйе, иртәгә!
Ямьле булыр тормыш та.
Шатлык көләр, бәхет килер,
Юл ачылыр уңышка!

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА (1959) – *язучы; «Көмеш тун», «Тау артында кояш бар», «Нишләттегез Гөлкәйне» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Әлмәттә яши.*

Иртәгә... Әйе, иртәгә!!!
Алга ашкына күңел.
Кадеремне белмисез, дип,
Үртәлеп кала Бүген...
Ә иртәнгә ул Иртәгә
Койрык болгап узачак.
Төн үтүгә, чөнки ул да
Шул ук Бүген булачак...

## Туган җирдә

Монда тормыш авыр, диеп,
Илне үги иттеләр.
Җир өстендә оҗмах эзләп,
Читкә чыгып киттеләр.

Җил чатында басып калды
Үз илләрен сөйгәннәр.
Таш яуса да, боз яуса да,
«Ватан-Ана!» – дигәннәр...

Җәйләре салкын әлегә,
Җилләре җанны телә...
Тик барыбер туган җирдә
Гомер итәсе килә!

Соңгы сулышыма чаклы
Шунда каласым килә!
Әткәм-әнкәм яткан җиргә
Башым саласым килә...

## Үртәмә

– Син бигрәк сәерсең, – дисең,
Нинди булырга тиеш?
Мин инде яшәп арыган
Яшәмәгән дә килеш...

– Яраттыңмы?..– дип сорыйсың, –
Язылган ич күземә...
Мәхәббәт килде дә китте,
Бушлык төяп күңелгә.

– Бушлык, – дисең, – сызламый ул, –
Хәзер инде җиңелдер.
Тере килеш утта ян да...
Шуннан минем хәлем бел.

Вакыт дәвалый...
Юк, тукта!
Син үртәмә йөрәкне.
Вакыт мине кешеләргә
Ышанмаска өйрәтте!

## Сиңа килдем

Якты эзләп юлга чыкканнарга
Үз ишләре тора табылып,
Эзләреннән гөлләр өзә-өзә,
Сиңа килдем, аны сагынып.

Йортың таптым, ишегеңне кактым...
Юлдашым да бары җилләрдер...
Җиде ятка килеп сер бушаттым,
Мин, чынлап та, ахры, җүләрдер...

Әманәтен аның тапшыргач та,
Саубуллашу иде теләгем.
Әмма калдым, һаман тоткарландым...
Мин ышандым сиңа нигәдер...

Чакырмыйча килгән кунакны да
Яхшы хуҗа кыймас куарга.
Өең җылы. Күңелең дә җылы...
Тик китәргә кирәк шулай да.

Мине дә бит үз офыгым көтә,
Югалтулар булыр соңласам.
Төнге юллар адаштырмас кебек,
Учагыңнан ялкын урласам...

Җилләр сиңа миннән сәлам әйтер,
Хәбәр итәр: «Ул бар. Ул исән!»
Ишек ачарсың бит, бусагаңа,
Җылы эзләп, кабат мин килсәм?

***

Күпме юллар үтелгән дә,
Күпме еллар кичелгән.
Синдә – акыл, миндә – йөрәк
Төрле уйлар кичергән...
Кем җиңгән дә,
Кем җиңелгән?
Икебез дә бер чама.
Үткән булып, мөлдер-мөлдер
Татлы мизгелме тама?..

Ничә тапкыр очрашкан без,
Ничә тапкыр хушлашкан...
Утны бозга кушмак булып
Өзгәләнгән, саташкан...
Ни отты икән бу язмыш
Безне бергә бәйләүдән?
Миндә – акыл, синдә – йөрәк...
Ялкын бозга әйләнгән...

## Яңа биттән...

Бик тырышсаң, хәтта ялганны да
Була аңлап, була кичереп.
Үпкә-рәнҗүләргә ишек ябып,
Саф хисләрне искә төшереп...

Шулай дисең... Оныт яраларны,
Саксыз әйткән тупас сүзләрне.
Хыянәтне кичер, күңелләрдән
Юып ташлыйк керле эзләрне...

Ап-ак кардай яңа биттән башлыйк,
Әйтерсең лә берни булмаган.
Арын, дисең, авыр биштәреңнән –
Җаның телеп торган уйлардан...

Шатлык, бәхетләрнең өр-яңасын
Безгә, имеш, бергә табасы...
Матур сүзләр...
...Тик син башта ышанычны кайтар!
Ышанычның булмый яңасы...

***

Үз өстемә алдым һаман
Дөньяның бар ачысын.
«Киләчәк» дигән касәгә
Җыйдым Бәхет тамчысын.
Балаларга булсын, дидем,
Язмышларның татлысы.
Юк икән шул... Аларга да
Әрем тәмен татыйсы...

***

Ничә кат яшимдер җирдә,
Кем генә булганмындыр...
Бу килүемдә, ахры,
Мең гасырлык гөнаһымны
Юарга туганмындыр...

## Хәтерлимсез?..

Хәтерлимсез, бар иде бит
Безнең якта бер авыл.
Хәзер аны табып булмый,
Кычкырсаң да каравыл...
Урамнары иркен иде,
Тыйнак иде йортлары.
Юлчыларга сәлам биреп
Балкый иде утлары.
Балачакта йөгереп йөрдек
Чирәмле урамыннан.
Чиләкләп җиләкләр җыйдык
Әрәмә-урманыннан.
Хәзер юк ул... Сан-исәптән
Сызып ташланган авыл.
Җилләр генә ыңгырашып
Эзли һаман: «Кайда ул?»
Хәтерлимсез... Иншар дигән
Авылны безнең якта?
Гел шул авыл аша үтәм,
Кайтканда балачакка...



Резеда
Вәлиева

# ХИКӘЯЛӘР

## Марфа түти

Бөек Ватан сугышы башланганда, миңа унбер яшь тулган гына иде әле. Без дүрт кеше: әтием, әнием, мин һәм өченче яше белән баручы энем Хәйдәр бик тә дус, бик тә тату бер гаилә булып яшәп ята идек. Әтием белән әнием укытучылар, мин шул елны дүртенче классны тәмамлап, бишенчегә күчкән бер малай идем. Өстәвенә, ул елны әниебез кечкенә бәби алып кайтырга тиеш иде.

Без яңа төзелеп килгән район үзәгендә яши идек. Өебез өч бүлмәле, бүлмәләребез зур булмаса да, биек, якты. Ә ишегалдыбызда ямь-яшел бөдрә куш каен үсеп утыра. Аннары тагын бакчабыз бар. Анда без бәрәңге һәм төрле яшелчәләр үстерәбез. Бакча белән ишегалды арасында озын-озын бүрәнәләрдән салынган сыер абзары, ачык лапас һәм кечкенә генә келәт кебек бернәрсә бар. Сыер абзарында Домна исемле сыерыбыз, ә ачык лапаста, үзенең тактадан ясалган оясында, салпы колаклы, елтыр күзле, бик тә шаян, бик тә күңелле Муйнак исемле этебез яши иде.

Сугыш башланган көнне мин гомеремдә дә оныта алмам. Ул көнне без бик иртә тордык, чөнки барыбыз бергә Тын Елга буена сәхрәгә чыгарга сөйләшкән идек. Әни: «Бакчада да эш күп, өйдә дә, әллә мин бармыйм гына микән?» – дип, әкрен генә әти янына килеп утыруга, энем Хәйдәр, киеп маташкан оекбашларын ташлап, авызын кыеш-мыеш китереп елап җибәрде:

– Ю-у-к! Син дә бал! Әнием белән балабыз, әнием белән!

Күзләрен йодрыклап уа-уа, яшьләрен мулдан түгеп, шундый кызганыч итеп елады ул, әни, авыр гына кузгалып, аның янына килде дә, яшьләрен сөртә-сөртә, аркасыннан сөя-сөя, безнең белән барырга вәгъдә итеп, аны тынычландырырга ашыкты.

Гел шулай елап җиңә иде энем безне. Әти моның өчен аны еш кына ачуланса да, ничектер һаман шул гадәтен ташлата алмый килдек. Артык яратканбыздыр инде, күрәсең. Күзләре бигрәк кара иде шул аның, чем-кара чәчләре бөдрәләнеп тузгып тора, ә үзе сакау теле белән берөзлексез такылдый иде.

Барыр юлыбыз ерак түгел, кояш көянтә шәе күтәрелгәндә, инде без Тын елга буендагы Түгәрәк аланда идек.

---

Резеда ВӘЛИЕВА (1930) – *шагыйрә, прозаик, тәрҗемәче; «Китмә, сөю», «Кояшлы яңгыр», «Сүрелмәс җырым син» һ.б. дистәләрчә китап авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Түгәрәк алан... Сез аның матурлыгын күрсәгез икән! Баруын да бит анда теләсә кем, теләсә кайчан бара алмый. Көймә белән елгага каршы менәсең. Уң якта түбәсе күккә тигән текә кыялар. Алар бераз гына елгага кереп тора, шуңа күрәдер, ул урында Тын елга бик тирән. Таш кыяларны әйләнеп, менә шушы борылышны узуга инде, уң якта гаҗәеп гүзәл күренеш ачыла – табигать юри түгәрәкләп бүлеп куйгандай, түм-түгәрәк зур яшел алан. Ул хәтфәдәй яшел йомшак үлән, аллы-гөлле чәчәкләр белән капланган. Аланның бер ягы – әрәмәлек. Анда шомырт, миләш агачлары, кура җиләге куаклары, анда көмеш сулы Салкын чишмә, анда җырчы кошлар...

Ул көнне без менә шунда килдек, һәм ул көн минем гомеремдә онытылмаслык иң якты, иң бәхетле, шул ук вакытта иң куркыныч, иң шомлы авыр бер көн булып исемдә калды. Бу көндә якты дөньяга коточкыч афәт килде – кешелек тарихында кара хәрефләр белән язылып калачак дәһшәтле сугыш башланды...

Икенче көнне инде без әтине сугышка озаттык. Ә бер айдан сеңлем Зәйтүнә туды.

Сугышның беренче ике елында без ашау-эчү ягыннан әллә ни зур кыенлык кичермәдек. Кара көздән базга бераз бәрәңгесе кереп кала, аның янына кишере-шалканы дигәндәй... Әмма, барыннан да бигрәк, безне ачлыктан сыерыбыз Домна коткарды. Болай гәүдәгә артык зур булмаса да, сөте бик куе иде аның. Әни гел мактап бетерә алмый иде инде үзен.

Шулай да соңгы елларны язга таба ашау яклары такырая башлады. Ярый әле, якын-тирәдә, халык телендә хуторлар дип йөртелә торган вак-вак кына, кайберләре берничә генә өйдән торган рус авыллары бар иде. Менә шул хуторларда кешеләр бик хәлле яшәде. Азык-төлеккә аптырый башласак, безнең әни өйдән нәрсәне булса да ала да, шунда барып, онга, ярмага, бәрәңгегә, кайвакыт ит-майга кадәр алыштырып кайта иде. Ләкин тора-бара өйдәге әйберләр дә сирәгәйде. Иң соңыннан ул хәтта стена көзгесен дә шунда илтеп, дүрт кадак онга биреп кайткан иде.

Сугыш бетәсе елны, язга таба, ничектер, безнең тормыш тагын да авыраеп китте. Көннәр менә-менә язга авышырга торган бервакытны, өебездә тәгам ризык калмады. Әкрен-әкрен, әзләп-әзләп кенә хәтта орлыкка дигән бәрәңгене дә ашап бетердек. Домнага ашаткаладык шул без аны. Чөнки кыш буе утынны да, чанага җигеп, шул Домна белән ташыдык, өстәвенә ул буаз да иде. Шуңа күрә, бик хәлсезләнеп китмәсен дип, үзебезнең авыздан өзеп булса да, аңа бәрәңгесеннән дә, көрпәсеннән дә өлеш чыгарып килдек. Безнең хәлләрнең авыраеп китүенә дә шул Домнаның ташлатып торуы сәбәп булгандыр әле, мөгаен.

Беркөнне эштән кайтып керсәм (мәктәптән соң колхоз эшләренә йөри идем), энем Хәйдәр белән сеңлем Зәйтүнә, әтинең иске тунын ябынып ятканнар да әллә ничек тып-тын булып калганнар.

– Нишләп ятасыз? – дип сорыйм.

Күзләрен бер генә ачып карадылар да тагын йомдылар. Бер сүз эндәшмиләр. Миңа кинәт бик куркыныч булып китте. Өй салкын, караңгы, балалар сүзсез... Йөрәгем кысылып куйды.

– Хәйдәр, Зәйтүнә, нәнием! – дим. Эндәшмиләр.

Мин өстемнән сала башлаган сырмамны кире кидем дә ишектән чыгып йөгердем. Колхоз фермасына, әни янына чабарга иде исәбем. Әмма, урамга чыгуга, ашыга-ашыга кайтып килүче әнине күреп, туктап калдым. Мине күргәч, әни каршыма йөгерә үк башлады:

– Ни бар? Балаларга бер-бер хәл булганмы әллә? – дип сорады ул, калтыранган тавыш белән, мине узып, капкага таба ыргылып.

– Ашыйсыгыз килдеме, бәбкәйләрем?! – диде әни, ашыгып өйгә килеп керүгә үк балалар янына ташланып. – Хәзер, хәзер, газизләрем минем, менә Сания әбиегез бер уч он белән бер чынаяк сөт биргән иде. Хәзер үзегезгә аш пешереп ашатам, – дип сөйләнә-сөйләнә, өс-башын салып элде дә мичкә яга да башлады.

Мин Домнаны карап, тыштагы эшләрне бетереп кергәндә, бер чынаяк сөткә су кушып, бер уч он туглап пешергән аш өстәлдә иде инде. Әни шул ашны чәй кебек итеп чынаякларга гына бүлеп салды да кечкенәләр янына килде.

– Йәле, улым, Хәйдәр, эчеп җибәр әле, менә нинди тәмле аш пешердем үзегезгә, күр әле, – диде ул, Хәйдәрнең аркасыннан әкрен генә кагып.

Хәйдәр, зур кара күзләрен ачып, аптыраган кыяфәт белән карап торды да яткан урыныннан гына әнигә кулын сузды.

– Юк, юк, тор син, торып утыр, түгеп-нитеп куя күрмә, кил әле менә монда, өстәл янына утыр әле. Менә шулай, менә әйбәт булды, – дип сөйләнә-сөйләнә, әни калтыранган куллары белән аны, күтәреп алып, өстәл янына китереп утыртты. Энем әкрен генә чынаякка кулын сузуга, әни:

– Үзең генә карап ашата күр, түгеп харап итмәсен, – диде. Үзе тизрәк сеңлем өстенә иелде:

– Йәле, кызым, тор әле. Менә нинди мәмәй алып кайттым үзеңә, – диде ул, аның битләреннән үбеп, чәчләреннән сыйпый-сыйпый.

Тик Зәйтүнә торырга теләмәде. «Мәмәй» дигән сүзгә дә исе китмәде аның. Әни коелып төште, ул калтыранган тавыш белән миңа эндәште:

– Бу ни бу? Күр инде, улым? Ни булган аңа? – диде ул, дерелдәп торган кулы белән баланың әле битен, әле маңгаен тотып карап. Аннан түзмәде, Зәйтүнәне күтәреп алып күкрәгенә кысты да үксеп елап җибәрде.

– Ниләр генә булды, балакаем?.. Зәйтүн гөлем минем, сусыз сулган гөл кебек сүнмәкче буласыңмы әллә, бәбкәм? – дип такмаклый-такмаклый, аның бишмәтен чишеп, битләреннән, күзләреннән, күкрәгеннән үбәргә тотынды.

Шулчак Зәйтүнә күзләрен ачты. Аның күзләре хәлсез, йөзе агарынып калган иде.

– Менә шулай, балам, – диде әни, күз яшьләренә буылып, – менә шулай, әйдә әле, ашап карыйк...

Зәйтүнә, әниемнең күзләренә текәлеп, башын чайкады:

– Юк. Киләкми...

– Ник кирәкмәсен, балам?! Син башта кабып кара әле, кабып кына кара, – диде әни, нишләргә дә белмичә, өзгәләнеп, һәм, кечкенә кашык белән алып, ашны Зәйтүнәнең ирелнәренә тидерде. Зәйтүнә башта, әни өзгәләнгәнгә генә капкандай, теләмичә генә йоткалап торган иде, озакламый, авызын зур ачып, һәр кашыкны көтеп ала башлады...

Шулай көч-хәл белән балаларны, туендыргандай итеп, чишендереп, урыннарына салгач, әни минем янга килеп утырды. Үтә нык борчылудан булса кирәк, ул үзе дә бөтенләй агарынып, хәлсезләнеп калган иде.

– Зәйтүнәкәебез харап була бит, балакаем, нихәлләр итик?! – диде дә, башын иңемә салып, бөтен гәүдәсе белән тетрәнеп, үксеп елап җибәрде. Үземнең дә тамагыма төер килеп тыгылды, сүз әйтә алмас булдым.

– Менә тиздән сугыш та бетәр, әтиең дә кайтыр, шулай ук үзенең зәйтүн гөлен күрә алмый калыр микәнни инде? Йа Ходаем, кайлардан ярдәм табыйк? Күп тә калмады бит инде, күп тә калмады! Берәр атна-ун көннән сыер да бозаулар, сөт тә булыр, күп тә үтмәс, көннәр җылыныр, дөньялар яшәрер, язлар килер... Ничек кенә бәбкәйләремне шул көннәргә исән-имин китереп

җиткерим? – диде ул, ачыргаланып, һәм авыр сулап куйды да, башын түбән иеп, сүзсез калды.

Әниемнең бөкрәеп калган аркасы, иелгән башы, хәлсезләнеп, салынып төшкән куллары – һәммәсе, һәммәсе аның соң дәрәҗәдә өметсезлеккә төшүен күрсәтеп тора иде. Мин, аны кызганудан нишләргә белми, аркасыннан кочып алдым.

– Ичмаса, өйдә әйбере дә калмады бит, берәр хуторга барып кайтыр идек, – дидем, бик борчылып, нигәдер пышылдап кына.

Кинәт әниемнең иелгән башы күтәрелде, мин, аның йөзен күрүгә, әллә нишләп киттем: шулкадәр дә үзгәргән иде ул. Әнием шатлыктан зур ачылган, ялтырап киткән күзләре белән миңа текәлде:

– Бар бит, балам, бар андый әйбер! – диде ул кинәт, минем иңнәремә кулын куеп. Баштарак мин аны, ачка үлсәм дә, бернәрсәгә дә алыштырмам, дип, ераккарак җыеп куйган идем. Шуңа да истән чыккандыр әле, рәхмәт төшкере! – дип, әле генә үлеп утырган урыныннан җиңел генә кузгалып китте дә, чыңгырдатып, зур ак сандыкның капкачын ачып җибәрде. Күп тә үтмәде, иске оек кунычына тыгылып, шырпы кабы кебегрәк бернәрсә тартып чыгарды.

– Менә алар – безнең коткаручыларыбыз! Минем алтын алкаларым! Әнием ягыннан әллә ничә буыннан килгән зиннәтле алкалар болар, балам. Күрәсеңме, ташлары ничек яна?! Әниемнән миңа калган, миннән Зәйтүнәгә, Зәйтүнәдән аның кызына каласы алкалар иде... Юк, юк, кызганмыйм, кызганаммы соң! Балаларым гына исән булсын, – диде ул аннары, үзен-үзе юаткандай сөйләнеп.

– Тик мин фермадан китә алмыйм, маллар күтәртә анда, эшләр бик начар, китә алмыйм. Син генә барырсың, балам, бригадирың белән үзем сөйләшермен, мәктәптә дә... Кечкә калып йөрергә ярамый, куркыныч, бүреләр дә күбәйде, салкыны да, адашып-нитеп куюың бар, – диде ул. – Иртәгә иртән генә кузгалырсың. Әндриевләр хуторына барырсың. Ул якынрак та, кешеләре дә йомшак күңелле, юмартрак, – дип өстәде ул аннары, ничектер тынычланыбрак калып һәм янә эшлекле кыяфәт алып.

– Куркыныч бит, әни, шундый дөнья бәясе әйберне үземә генә алып китү. Әйдә инде, ничек тә бергә барырга тырышыйк, – дидем мин, алтын кадәр алтын алкалар белән япа-ялгыз юлга чыгуны күз алдыма да китерә алмыйча.

– Нихәлләр итим соң, балам?! Анда барып кайтырга бер көн яктысы кирәк. Әле барасы, әле өйдән өйгә йөреп, теләгән кешесен табасы. Юк, юк, сорап торасы да юк, җибәрмәячәкләр мине. Хәзер без бер көнгә түгел, бер сәгатькә дә фермадан китеп тора алмыйбыз – маллар үлә башлады, дип әйтеп торам бит, иске саламны кайнар суда пешекләп, турап ашатабыз... – диде әни.

Мин, аны кызганудан, телемне тешләргә мәҗбүр булдым.

– Ярый, ул кадәр үк алдамаслар әле, үзең дә кечкенә түгелсең инде, уйлап эшли күр берүк, әзрәк он, әзрәк бәрәңге, әзрәк туң май да булмасмы, сорап карарсың инде. Бик сатулашып китеп, буш кул белән әйләнеп кайта күрмә тагы. Әнә үзеңнең дә чыкмаган җаның гына калды бит инде, – диде ул, яшьле күзләре белән миңа текәлеп. – Тик менә юлга гына ни белән тамак ялгатып чыгарыйм? – дип өстәде аннары, нәүмизләнеп.

Иртәгесен көн чалт аяз, әмма салкын иде. Мин мәтрүшкә чәе эчеп алдым, аягыма әтинең киез итекләрен, өстемә сырма киеп, билемне киң солдат каешы белән кысыбрак будым да үзебезнең тыкрык аша гына Әндриевләр хуторына таба юл тоттым.

Башта кызу-кызу атларга тырышсам да, бара торгач, арыта башлады, арка тирләп чыкты, маңгай юешләнде, аяклар авырайды. Мин адымнарымны

әкренәйтә төштем. Шулай, бер кызулап, бер әкренәеп бара-бара, байтак юл үтелде. Менә әни әйткән ике юл чатына да килеп җиттем. Бу урында моңа кадәр бер генә булып килгән юл, икегә аерылып, икесе ике якка кереп китә иде. Берсе уң якка авыша, икенчесе, сулга каерылып, вак куаклыклар арасына кереп югала.

«Моннан инде Әндриевләр хуторына күп калмаска тиеш», дип уйладым мин, куанып, һәм шунда ук, кайсы юлдан китәргә дә белмичә, аптырап калдым. Әни бит, куаклык булыр, дип әйтмәде, ялан кыр белән барыла, дигән иде. Димәк, уң якка китәсе... Тиздән барып җитәргә тиешмен дигән өмет хәлсезләнә барган аякларыма көч бирде.

Шулай бертигез нык адымнар белән янә байтак юл үттем. Ничек кенә күз текәп карасам да, беркайда да йорт-җир әсәре һаман күренми иде. Арыта башлады. Хәзер инде, аякларны өстерәп диярлек, көч-хәл белән генә атлый башладым. Туктап, тирә-якны күзәтәм, бернинди җан иясе күренми, шылт иткән аваз да ишетелми. Шундый шомлы бер тынлык... Кинәт миңа куркыныч булып китте. Колакларым зыңлый башлады. Шулай да юлның нык тапталган булуына карап, аның барыбер кеше яши торган бер урынга китереп чыгарачагына ышанып, ары атладым. Ләкин хәл бетә башлаган иде инде. «Оят түгелме, җебегән нәрсә? – дип, үз-үземне ачуланып-ачуланып алам. Ничек кенә булса да барып җитәргә кирәк, барып җитәргә, югыйсә Зәйтүнә... әни...»

Мин инде юлның шомарган җиреннән – уртасыннан бармыйм (бер-ике мәртәбә, аягым таеп, чүт егылмыйча калдым), юл читләтеп кенә атлыйм. Колактагы чыңлау бетми дә бетми, һаман көчәя генә бара, күзләрем дә әлҗе-мөлҗе килә башлады... Әнинең, бик нык борчылып, юлда ял итәм дип утырасы булма берүк, дигән сүзләре күңелемә нык сеңеп калган, һаман түзәргә тырышып барам. Менә бервакыт, үз күзләремә үзем ышанмый, туктап калдым: уң якта, кашлаграк бер урында, өйләр каралып күренде. Морҗаларыннан төтен чыгып тора! Тагын аз гына, тагын аз гына, чүт-чүт кенә... Күңелемдә бары шул гына уй, шул гына теләк. Кинәт, үзем дә сизми калдым, аягым тайдымы, абындыммы, барган уңайга егылып киттем. Егылып кына да калмадым, сөзәклектән түбәнгә таба бер-ике тәгәрәп, чокыргамы, канаугамы әйләнеп төштем. Ярый әле алкаларны әни кесәмә булавка белән эләктереп куйган иде, дип уйлап өлгердем һәм шунда ук бөтен тәнемә таралган рәхәтлектән изрәп-эреп киттем. Хәз-зер, хәз-зер, әз генә, печтик кенә ятам да, дип уйлаганым исемдә. Шуннан ары берни дә хәтерләмим...

Күзне ачып җибәргәндә, ниндидер чит өйдә дөрләп янган мич каршындагы тәбәнәк кенә агач караватта ята идем.

– О, уяндыңмы, балакай?! Менә әйбәт, менә шулай кирәк, улым, – дигән тавыш ишетелде. Мин торып утырдым, як-ягыма каранып алдым. Каршы яктагы почмакта, зур мич алдында кайнашкан олы яшьтәге бер рус хатыны, шат елмаеп, яныма ук килеп утырды.

– Йә, хәлләрең ничек? Ул, кулы белән йомшак кына итеп аркамнан кагып алды. – Бер җирең дә авыртмыймы?

– Юк, авыртмый. Кайда соң мин? – дип сорадым аннан, мичкә терәп куелган киез итекләремне, сырмамны күреп, һәм шулвакыт, башымнан үткән хәлләр искә төшеп, куркып киттем. Сикереп торып, сырмамны барып алдым, кесәмә тыгылдым. Чүпрәккә төрелгән шырпы кабы урынында иде.

– Йә, ничек соң? Бар да тәртиптәме? – дип сорады теге апа, миңа текәлеп карап, һәм: – Томилиннарда син, бар да әйбәт булыр, курыкма, – дип тә өстәде.

– Рәхмәт, – дидем мин, уңайсызланып.

– Мин сине канаудан таптым, көрткә чумып йоклап ята идең. Ярый әле юлга

төшеп калган бүрегеңне күреп алдым, шул бүрек коткарды сине, юкса эшләрең харап иде, балакай, – диде ул, кинәт җитдиләнеп. – Көч- хәл белән алып кайттым, аннары менә бөтен тәнеңне үлән сулары белән удым. Ничек кенә чыктым да, ничек кенә таптым үзеңне, әй бала, бала, гомерең бетмәгәнгә бер сәбәптер инде, – диде ул, бер кулы белән ияген тоткан килеш башын чайкап. – Ходайга шөкер ит инде...

Аннары ул кинәт, урыныннан кузгалып, яктырып киткән йөзен миңа таба борды:

– Әйдә, юын да ашап-эчеп алыйк, бәрәңге дә пеште, – диде.

Минем инде тәмле бәрәңге исеннән башым әйләнеп-әйләнеп китә иде, шуңа күрә уңайсызланып, тамак кына кырып куйдым да, тәрәзә янына килеп, урамга карадым. Тышта таң атып килә. Таң атып килә! Димәк, мин биредә кунганмын! Ә әнием нишләде икән? Ул бит, әллә ниләр уйлап, акылыннан язар дәрәҗәгә җиткәндер!

– Юк, юк, рәхмәт. Миңа ярамый, миңа тизрәк өйгә кайтырга кирәк. Әнием борчылып үлә торгандыр анда! – дидем мин, барыннан да бигрәк өстәл янына килеп утырудан уңайсызланып. Ә өстәлгә, бәрәңге янына, ике телем ипи, дуңгыз мае һәм хәтта суган да куелган иде.

– Ярый, ярый! Аллага шөкер ит, югыйсә әниеңә бер генә төнне йокысыз уздырырга туры килмәс иде әле. Ә хәзер инде ул, кичә борчылып үлгән булса да, син исән-сау кайтып кергәч, бүген терелер, Алла боерса, – диде апа, тыныч кына.

Мин, өстәл янына килеп утыруга, кулым калтырый башлаганын тоеп, бәрәңгегә үрелә алмыйча, башымны түбән идем.

– Марфа түти булам мин. Марфа Томилина, – диде бу апа, ярмаланып пешкән эре-эре бәрәңгеләрне минем алдыма ук китереп тезә-тезә. – Аша инде, кичәдән бирле тәгам капмаган бит син, нишләп утырасың?! – диде ул аннары, бу юлы инде чыннан да ачуланып.

Мондый да тәмле бәрәңгене минем моңарчы әле ашаганым юк иде, аннан соң да булмады...

Бик ачыгуымны аңлапмы, Марфа түти, ашаганда, миннән берни дә сорашып маташмады. Ашап туеп, хуш исле үләннәр салынган чәй дә эчеп алгач, табынны җыештыра-җыештыра, миңа сораулар бирә башлады. Мин, бернәрсәне дә яшермичә, үзебезнең өйдәге хәлләрнең һәммәсен бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Алкаларның тарихына кадәр сөйләп ташлаганмын хәтта.

Сырмамның кесәсенә булавка белән беркетеп куйган алкаларны алып, аңа суздым. Ул аларны бик кадерләп кенә, саклык белән генә кулына алды. Әле бер якка, әле икенче якка яктыга якынрак китереп, сокланып карады-карады да, иплэп кенә тартмасына салып, кире үземә сузды.

– Ә әтиең исәнме соң? Хаты киләме? – дип сорады ул әкрен генә.

– Килә, килә! – дидем мин. – Ул инде фашистларның үз өнендә сугыша. «Берлинга якынлашып киләбез!» – дигән.

– Күр инде! Минем ирем Фёдор да шулай дип язган! Менә бит ничек! – диде ул, кинәт җанланып китеп, һәм, урыныннан торып, кызу-кызу гына мичне болгатып алды. – Күр инде син аны, бергә сугышып йөриләр икән бит! Якташлар шул, якташлар, берни дә әйтә алмыйсың! – дип өстәде ул аннары, бик тә куанып һәм дулкынланып.

– Йә, кемгә бирәбез инде, Марфа түти? Алкаларны әйтәм... – дидем мин. – Сез ярдәм итә алмассызмы икән? Миңа бит ризыксыз кайтырга ярамый.

– Беркемгә дә бирмибез! Бирергә ярамый аларны! – диде Марфа түти, кинәт катгый рәвештә: – Син курыкма, бөтенләй буш кул белән кайтармам, әз-мәз ни булса да әтмәлләрбез. – Ике улым да сугышта иде минем, олан, бер улымның

кара хәбәре килде, икенчесенең – төпчегемнең дә байтактан хәбәре юк иде. Менә кичә генә хаты килеп куандырды әле. Шуның белән юанып яшим хәзер, Аллага мең шөкер! – дип сүзен очлады да вак бөрчекле кара алъяпкычы белән күзләрен сөртеп алды. – Азык-төлек байтак иде минем, үзем генә калгач, бик тараттым шул. Ничек итеп таратмыйсың, кешеләр ачтан үлә бит, балалар, сабыйлар ачыга, – диде ул. Аннары, минем күңелсезләнеп калуымны күреп булса кирәк, урыныннан кузгалып, өс-башына киенде дә өйдән чыгып китте. Мин нәрсә дип уйларга да белми калдым, әллә нинди кәрзиннәр, капчыклар күтәреп кереп тә җитте.

– Берәр капчык кебек нәрсәң бармы соң синең? – дип сорады ул, мич ягына үтеп китешли. Мин аптырап аңа карап торганны күргәч, тагын борылып яныма килде. – Аптырама син, бер телем икмәкне бишкә бүлешеп кабар вакыт безнең хәзер. Әйе, әйе, менә тиздән җиңү килер, тагын элеккечә, юк, элеккедән дә матуррак итеп яши башларбыз. Күп калмады инде, түзәргә кирәк, олан, түзәргә, бер-беребезгә ярдәмләшеп, ничек тә бу явызларны дөмектергәнче түзәргә кирәк! Ә алкаларга тимә син, менә берәр атна тамак ялгап яшәрлек ризык әмәлләдем үзегезгә, ә анда инде сыерыгыз да бозаулар, яшел үлән чыгар, кычытканы, юасы дигәндәй... Күп калмады инде, – дип сөйләнде ул һаман да. – Ә бу алкаларга тимәгез сез, әниеңә дә шулай дип әйтерсең...

– Туктагыз әле, ничек була инде бу? Әни бит миңа Әндриевләр хуторында бик кече күңелле кешеләр яши, шунда бар, дигән иде, ә мин бөтенләй икенче якка, Томилиннар хуторына килеп чыкканмынмы? – дидем мин, аптырап.

– Нишләп бөтенләй икенче якка булсын? Син алардан узып киткәнсең, әрәмәле калкулык артында калган алар, без өч чакрымга арырак, – диде ул, елмаеп, һәм, менә күрдеңме инде үзеңнең кем икәнеңне дигәндәй, минем борыныма бармак очын тидереп алды.

Бер ярты сәгатьтән инде без Марфа түти белән, гомер буе бергә яшәгән якын туганнар шикелле, чүкердәшә-чүкердәшә, олы юлга чыгып бара идек. Үзенең авырлыгы белән күңелемә нindидер татлы рәхәтлек биреп, минем аркамда ярыйсы гына зур биштәр дә юлга чыкты...

Олы юлга җиткәч, Марфа түти туктады. Биштәр-капчыгымның бауларын рәтләп куйды да, көчле, нык куллары белән иңнәремнән кысып:

– Йә, ярый, улым, хәерле юл, исән-имин генә кайтып җитә күр берүк, – диде.

Шунда кинәт әллә нишләп күңелем тулып китте. Менә шушы авыр хәсрәтләр кичергән олы җанлы, мәрхәмәтле рус хатынын кочып, җыерчыклы битләреннән үбеп аласым, күп-күп рәхмәт сүзләре әйтәсем килде. Тик, күзләремә тулган яшьләрне күрсәтмәс өчен, башымны идем.

– Рәхмәт Сезгә, рәхмәт, һәммәсе, һәммәсе өчен дә... – дигән сүзләрдән башка берни дә әйтә алмадым.

Ул да минем хәлне аңлады, ахры.

– Ну, ну, ничего, ничего. Дай Бог, чтоб вы сберегли своих малышей, – дип, кат-кат иңнәремнән кысып куйды. Аның үзенең дә күңеле тулган иде, күрәсең.

Мин, артыма борылып, аңа кат-кат кул болгадым. Ул, юл уртасына баскан килеш, бер кулы белән авызын каплап, һаман миңа карап тора иде әле.

## Кара тавык

Сугыш башланганчы, безнең ишегалды тулы мал-туар, кош-корт иде. Зур мөгезле бик күркәм сыер, кыш чыккан башмак тана, өч-дүрт сарык, ел саен ике-өч бәти китерүче бик сөтле бер кәҗә, утызлап бәбкә үстерүче ике ана каз.

Аннары безнең ялан сыйракларыбызны чукыйм дип куркытып, берөзлексез артыбыздан куучы бик усал бер ата каз, унбишләп тавык. Өстәвенә салпы колаклы, минем үземә гел көлеп торгандай күренгән мөлаем күзле, кыска аяклы шаян этебез, минем җан сөйгәнем – Дүрткүз.

Сугыш башлануга, безнең өй эче дә, ишегалды да коточкыч тизлек белән бушап калды.

Сугыш башланган атнада ук олы абыем белән әткәй фронтка киттеләр. Алар китеп, бер ай да үтмәде, кече абыйны хәрби курсларга алдылар. Шулай итеп, күз ачып йомган арада, өч бүлмәле зур өйдә без әнкәй белән икәү генә торып калдык.

Малларга килгәндә, иң элек әти дә, абыйлар да җәй уртасында өйдән чыгып киткәнгә, сыерга печән алыр өчен, башмак тананы саттык. Әткәй белән олы абыйны озатканда – бер сарыкны, кече абый киткәндә, икенче сарыкны суйдык. Бер бәтие белән кәҗәне сөте өчен күптән сорап йөдәткән күршебез Мәфрузә әбиләргә саттык. Бер бәтине әлегә үзебездә калдырып торырга булдык. Казларның да кышка әнкәй берсен генә калдырды. Тавыклар гына әле һаман ишегалды тулып йөриләр иде.

Сугыш башланганның икенче җәендә, чалт иткән кояшлы бер иртәдә, янәшәбездәге тыкрык буена урман кебек булып үскән кычыткан арасыннан ябыгып, кеп-кечкенә булып калган чуар тавыгыбыз килеп чыкты. Байтактан бирле югалткан идек инде без аны, табылуыннан да өмет өзгән идек. Биек булып үскән куе кычыткалык арасыннан ничектер бик оста гына килеп чыкты да, тамак төбе белән «корт-корт» итеп, артына борылып, туктап калды. Мин, гаҗәпләнеп, ни буласын көтеп торган арада, кычыткан арасыннан берәм-берәм чебиләр йөгерешеп чыга башлады. Берәү, икәү, өчәү... җидәү... Мин, бетте бугай дип, өйгә, әнкәй янына йөгерергә генә торганда, чуар тавык ничектер борчулы тавыш белән корткылдап куйды да, артына борылып, кычыткан арасына үрелеп карады һәм тагы да борчулырак тавыш белән нидер көтә башлады. Шулвакыт аннан башка чебиләргә караганда бер башка калкурак, озын аяклы, озын муенлы, әллә ничек, аяк атлауларына кадәр үзгә, горур бер чеби килеп чыкты. Ул чыгуга, чуар тавык тынычланып калгандай булды һәм башка чебиләре янына килде. Бераздан ул аларны гадәттә әнкәй тавык-казлар ашата торган урынга, ябык лапас астына ияртеп керде.

Ә инде әлеге озын торыклы чеби, аларга әйләнеп тә карамыйча, каршыма килеп туктады да, хәзердән үк кикрикләре беленеп торган зур, матур башын кыек салып, мәрҗән кебек җемелдәп торган түм-түгәрәк күзләре белән бик кызыксынып, миңа карап тора башлады. Мин дә, соң дәрәҗәдә сокланып һәм гаҗәпләнеп, аңа карап каттым. Шулай бер-беребезгә карашып торганда, ул кинәт кенә сикерде дә кулымны чукып алды.

– Әнкәй! – дип кычкырып җибәрдем мин. – Әнкәй, чык әле тизрәк!

Мин кычкырганга чебинең исе дә китмәде. Ул һаман шулай, башын кыек салып, минем кулыма карый һәм, сикереп, аны чукып-чукып ала иде. Шунда гына мин, аның ашарга соравын аңлап, өйгә йөгердем.

Әнкәй белән без чыкканда, ул, алпан-тилпән атлап, башын бик горур тотып, ашыкмыйча гына башка чебиләр ягына таба китеп бара иде.

Әнкәй, чуар тавыкны кызганып, әллә ниләр сөйләнә-сөйләнә, аларга пешкән йомырка турап бирде, эремчек ваклап сипте, иске табага чиста су чыгарып салды.

Ә әлеге чеби, бер тамчы да ятсынмыйча, минем кулдан гына ашады, зур тавыклар шикелле итеп, озын муенын артка каерып су эчте дә, әнкәй белән

икебезне шаккатырып, ачык лапас астындагы кояшка, кызган туфракка кырын ятты һәм озын тәпиләрен сузып җибәрде.

– Менә Ходайның рәхмәте, нинди чеби соң бу? Тавык йомыркасыннан мондый чеби чыкканны гомеремдә дә күргәнем юк иде. Күркә чебие дисәң, күркәгә бик охшамаган бугай, кыланышлары да бик сәер, үзе дә. Нәрсә булыр бу? – диде әнкәй, кызыксынып, яратып, якты йөз белән аны караштыра-караштыра. – Ни дип әйтим икән, этәчтер, эре токым этәч булырга тиеш бу, кызым. Тик шунысы гаҗәп: каян килгән ул шушы бармак башы кадәр генә йомырка салучы кечкенти чуаркайның яшерен оясына? Кайсы тавык салып китте икән соң андый зур йомырканы? Күрше-тирәдә дә андыйны салырдай эре тавыклар юк бугай ич! Әллә бармы икән соң? Белеп тә бетермәссең инде, булса бардыр да, – дип, сүзен тәмамлады әнкәй, чын-чынлап гаҗәпләнгән бер хәлдә.

Шулай итеп, бер дә уйламаганда-көтмәгәндә, безнең ишегалдында минем өчен бик тә кызыклы тагын бер җан иясе артты, һәм ул тормышының шундый сәер башлануы белән үк күңелемдә үзенә аерым урын яулады. Шул көннән мин аны, Дүрткүздән дә якын күреп, бик тә яратып, зур игътибар белән ашата-эчертә, карый башладым.

Чебиләр тиз үстеләр. Көзгә инде безнең ишегалдында чуп-чуар дүрт яшь этәч белән шундый ук аклы-каралы, чуар өч яшь тавык тибенеп йөри иде. Ә сигезенчеләре, әлеге озын торыклы зур чеби, этәч дип көткәнебез, янып торган кып-кызыл зур кикрикле, озын муенлы һәм ботлы, чем-кара каурыйлы, гаҗәеп матур бер тавыкка әверелгән иде. Мин аңа Каракай дип исем куштым. Ул беркемнән дә курыкмый, аркасыннан сыйпап сөйгәнне ярата, үзе белән сөйләшкәндә, бик кызык кына, башын янтайтып тыңлап тора, ни бирсәң дә, кулдан алып ашый, гомумән, ишегалдында үзен хаклы бер хуҗа итеп сизә иде. Аннан соң ул, калын тавыш белән, матур итеп, сузып-сузып җырлый белә иде. Озын ботлары белән эре-эре атлап, зур кикрикле матур башын кыңгыр салып, миңа карый-карый, шундый тырышып-тырышып, сузып-сузып җырлап җибәрә, аңа соклануыма түзә алмыйча, янына йөгереп килеп, аркасыннан сөя- сөя, тары ярмасы, ипи валчыклары белән сыйлый идем. Ахры, шуңа да ул мине, чыгып киткәндә, аягыма бәрелә-сугыла янәшәмнән атлый-атлый, озатып кала, капкадан кайтып кергәндә, йөгереп килеп, каршы ала иде. Аны кулыма күтәреп сөям, ә ул, бик канәгать булып: «Ко- ко-ко!» – дигән авазлар чыгарып, мәрҗән кебек елтыр күзләре белән миңа үз итеп, яратып карый иде.

1945 елның башында әткәй, авыр яраланып, сугыштан кайтты. Олы абыем бу вакытта өлкән лейтенант дәрәҗәсендә дошманны үз өнендә тукмый иде. Тик кече абыем гына сугышның беренче елында ук Ленинград фронтында хәбәрсез югалды.

Әткәй кайтканда, ишегалдыбызда сыер белән Каракайдан гайре бер мал да, кош-корт та калмаган иде инде. Сыерыбыз безне иң авыр вакытларда да ачлыктан саклады. Ә Каракайны шушы көнгә кадәр авызыбыздан өзеп ашатып килдек. Ул да, көнаралаш эре-эре йомыркалар салып, безне тукландырып тора, өстәвенә үзенең сөйкемле кыланышлары, моңы булмаса да, тырышып-тырышып җырлаулары, «Исән-имин кайттыгызмы?» дигәндәй, үз шөгыльләрен ташлап, капкадан кайтып керүгә йөгереп каршыбызга килүләре белән күңелләребезне күтәреп, куандырып яши иде.

Әткәй мал-туар беткәнгә һич тә кайгырмады. Ул безнең тормышыбыздан бик канәгать булып, сыерны саклап калганга куанып бетә алмыйча, әнкәйгә моның

өчен кат-кат рәхмәтләр әйтте. Үзе дә госпитальдән бик бетеренеп кайткан иде, әмма күп тә үтмәде, шушы сыерыбызның шифалы сөте аркасында булса кирәк, ярыйсы ук тернәкләнеп, хәлләнеп, үзе кебек үк танымаслык булып үзгәргән, актык чиккә җитеп өшәнгән колхоз атлары янында кайнаша башлады.

Беркөнне мин иртән йокымнан кәефсезләнеп, авырсынып уяндым. Чалт аяз, тып-тын матур бер иртә иде югыйсә...

Ул вакытта без, бик тырышып, рус әдәбиятыннан инша язарга өйрәнә идек. Өйдә әзерләнеп, язып киләбез дә мәктәптә бергәләп тикшерәбез. Бүген дә шунда барырга тиеш идем. Иптәшләрем көткәнне белгәнгә, анда бармыйча калуны күз алдыма да китерә алмый идем. Шуңа күрә әткәй белән әнкәйгә хәлемне сиздермәскә булдым. Иртәнге чәй янына табынга берәр ярым бәрәңге һәм хәтта яртышар көлчә дә куелган иде. Ләкин ризыкка күңелем тартмады. Мәтрүшкә салынган кайнар чәй генә эчтем дә табын яныннан кузгалдым. Әткәй белән әнкәй, бик борчылып, миңа карап-карап алалар иде.

– Мин кайткач ашармын, яме, әнкәй?! – дидем мин, шат булып күренергә тырышып, һәм тизрәк өйдән чыгып китәргә ашыктым.

Ләкин болдыр баскычыннан йөгереп төшеп, безнең якларда урыс капка дип йөртелә торган зур, авыр капканы тартып ача башлауга, кинәт башым әйләнеп китеп, чак егылмыйча калдым. Колакларым зыңлап, күз алларым караңгыланып китте. Башымны капкага терәп хәл җыеп торганда, артымда әнкәйнең аяк тавышларын тоеп, аңа таба борылдым.

Ике күзен миңа текәп, бик борчулы кыяфәттә әткәй дә баскыч төбендә басып тора иде инде.

– Кара инде йөзеңне генә, бөтенләй агарынып калгансың ич! Бу ни хәл бу? Ачлыктан гына, ачлыктан! – диде әнкәй, минем ике иңемнән кысып алып. – Әйдә, хәзер үк кереп урынга ят, хәлең начар бит! Әтисе, күр инде моны! Ачлык галәмәте, – дип кабатлады ул аннары, аптыраган бер кыяфәттә тирә-якка күз йөртеп. – Шулпа әсәре капмагач, май-каймак күрмәгәч, көн-төн укыган балага ничек түзмәк кирәк!

Ул арада әткәй дә килеп җиткән иде.

– Әйдә, өйгә кер, кызым, бераз ятып тор, аннары барырсың, булмаса, үзем әйтеп кайтыйм иптәшләреңә, көтеп тормасыннар... Мин хәзер, – дип, капкага ук үрелә башлады ул.

Хәлем ярыйсы кебек иде инде. Мин:

– Хәзер кайтам, куркакларым минем! Йәле, әткәй, егетләрчә, капканы ачып җибәр әле, – дип, әткәйгә карадым.

– Урамда-нидә генә егылып калмасаң ярый ла!.. Хәлең шәптән түгел бит, кызым. Рәтле ризыгы да юк шул, чыннан да, үсмер кешегә әз-мәз бәрәңге дә җәймә... Ризыкмы инде ул? – диде әткәй дә.

– Ни сөйлисез сез?! Әнә Фәния көнгә бер-ике бәрәңге белән генә дә укый әле! Ә башкалар? Мин ашаган ризык әләгә дисезме аларга? Юкка борчылмагыз, мин классыбызда иң тук укучылардандыр әле, беләсегез килсә! – дидем мин һәм авыр капканы каерып ачып торган әткәй яныннан елмаеп-көлеп кенә узып киттем.

Кичке якта, мин мәктәптән кайтып кергәндә, өй эче итле шулпа исе белән тулган иде, кинәт башларым әйләнеп китте хәтта.

– Бу ни бу? Кайдан алдыгыз? – дип сорадым мин, шатланасы урында, аптырап калып.

– Таптык инде менә! – диде әнкәй, кече яктан үрелеп кенә карап, ул ничектер бик куанган да, дулкынланган да төсле күренә иде.

– Әйдә, юынып ал да утыр, шулпа кап тизрәк. Ни шулпа булмасын, ни сөте-каймагы... – дип сөйләнә башлаган иде дә, әткәй аның сүзен бүлдерде.

– Хәлең ничек соң, кызым?

Хәлем шәптән түгел иде, шулай да, аларны борчымас өчен:

– Ярый, ярый... Менә хәзер шулпа да ашап җибәрсәк, – дигән булдым мин, кулларымны угалап.

Әнкәй өчебезгә дә шулпа бүлде. Мин агач кашыкка шулпа алып, иреннәремә китерүгә, ул ит табагы өстеннән ашъяулыкны тартып алды:

– Йәле, бүлеп җибәр әле, әтисе!

Шулвакыт мин, ит табагыннан тырпаеп чыгып торган озын ботларны күреп, әллә нишләп киттем. Кинәт йөрәгем убылып төшкәндәй булды, кулымдагы шулпалы кашыгым төшеп китте, аркаларым чәнчешеп, бөтен тәнемә ут йөгерде. Мин әткәйгә күтәрелеп карадым. Ул шунда ук күзләрен яшерде...

– Сез нәрсә?! Әллә!!!

Мин өстәл артыннан атылып чыктым да ишегалдына ташландым.

– Каракай! Каракай! Каракаем!!!

Юк... Ул юк иде... Гадәтенчә, озын ботларын кызык итеп, алпан-тилпән китереп атлый-атлый, канатларын кага-кага, ул каршыма йөгереп килмәде...

Мин кетәклеккә ташландым: ул да буш иде. Кетәклек идәнендә аның ашый торган савыты да сулы табасы гына калган...

Кинәт бөтен ишегалдыннан минем өстемә шундый бушлык, шундый өметсезлек, шундый бер салкын кабер тынлыгы килеп ябырылды, сулыш та ала алмас булып, ике кулым белән амбар киртәсенә барып сарылдым. Ничә еллар күрмәгән, хәзер инде күрү мәңге дә мөмкин булмаган кече абыем, әллә кайда, чит җирләрдә ут эчендә йөргән олы абыем сүзсез генә күз алдыма килеп бастылар... Бугазыма тыгылган төер тын алырга да, еларга да бирмәс булды. Мин, буыла башлавымны сизеп, тизрәк әнкәйләр янына керергә омтылдым. Ләкин аякларым мине тыңламады. Шулвакыт әткәй, килеп җитеп, аркамнан кочаклап алды.

«Ничек куллары күтәрелде икән?.. Ничек?..» дигән уй миемне телеп үтте...

Әнкәйнең, елый-елый:

– Акылыңа кил, бала! Акылыңа кил! – дигән сүзләре әллә кайда, бик еракта яңгыраган кебек кенә ишетелде.

Ничек итеп үземне өйгә алып кереп урынга салганнарын хәтерләмим.

Шул көннән мин ике айга якын урын өстендә яттым.

...Үпкә ялкынсынуы һәм нервлар тетрәнүе. Врачлар минем авыруымны шулай билгеләгәннәр иде...

## Өзелгән моң

Галия әби белән Шаһидулла бабай арысландай өч малай һәм тыйнак кына, сылу гына бер кыз үстерделәр. Инде балалары башлы-күзле булып, төрлесе төрле якка таралып бетсәләр дә, кайсын кышка, кайсын көзгә, кайсыларын Сабантуйга каршы алып, аннары тагын кайтуларын көтеп, күңелле генә яши бирделәр.

Шаһидулла бабай яздан башлап кара көзгә кадәр өй артындагы алма бакчасын карый, бердәнбер маллары булган сыерларын асрый. Галия әби исә, бакча җимешләреннән балаларына кагын, кайнатмасын әзерли, чолан белән кар базы арасында мәш килә. Кыш көннәрендә, әле тегесен, әле монысын карап, өй эчендә кайнаштылар. Балалары аларны акчасыннан да, күчтәнәчләреннән дә өзмәде.

Бигрәк тә зур гына урында эшләүче олы уллары Закирҗан ярдәмләште. Шулай итеп, Шаһидулла бабай картлыгыннан да, балаларының аерым яшәүләреннән дә артык зарланмыйча, булганына шөкер итеп, карчыгы белән чүкердәшеп кенә яшәп ятты. Балалары кайткан чакларда, алты почмаклы матур өйләре гөр килеп тора иде. Җәй көне булса, бакчаларында, ишегалларында җыр, гармун тавышы тынмый, кыш көннәрендә исә ябык тәрәзәләр аша да моң саркып, тын авыл урамнары буйлап ерак-еракларга ишетелә иде.

Яшь чакларында Шаһидулла бабай бик шәп гармунчы, Галия әби авылның беренче җырчысы булган, дип сөйлиләр. Күрәсең, шуңадыр, Шаһидулла бабай әле хәзер дә гармунны еш кына тоткалый. Андый минутларда Галия әби дә ничектер балкып, яктырып киткәндәй була.

Шулай гомер буе бик матур, бик тату яшәделәр алар. Галия әби, сабыр холыклы булгангамы, сәламәтлегеннән үзе бер дә зарланмый иде. Ә инде карты кәефсезләнебрәк китсә, угалап-сыйпап, ниндидер үләннәр эчертеп, янында бөтерелеп йөрер иде. Шундый чакта, карчыгына карап: «Үземнән калгач, нишләр инде бичаракаем, бигрәк бер җан булып яшәдек шул», – дип, үзәкләре өзелеп куя иде Шаһидулла бабайның.

Ләкин язмыш боларын үзенчә хәл итте. Җәйге бер иртәдә, сыерларын көтүгә куып, ишегалдына кайтып керүгә, башындагы ак яулыгы белән йөзен каплап баскычка кырын яткан карчыгын күреп, Шаһидулла бабай эсселе-суыклы булып китте. Тез буыннарының калтыравын җиңә алмыйча, карчыгы янына килеп утырды да дерелдәгән кулы белән әкрен генә аның иңенә кагылды:

– Сиңа әйтәм, башың әйләнде мәллә?

Карчыгы җавап бирмәде...

Шуннан соңниләр булганы ачык кына исендә калмаган Шаһидулла бабайның. Врач килүен дә, үзенә укол кадауларын да, балалары кайтып төшүен дә авыр төш кебек кенә хәтерли ул. Ә менә кып-кызыл балчык белән ачылып яткан җир куенына Галиясен иңдерүләре бер генә минутка да онытылып торганы юк. Ничек итеп онытмак кирәк, өйдәге бөтен нәрсә: тәрәзә төбендәге гөлләр дә, мөгрәп йөргән коба сыер да, алмагачлар да, хәтта гомер буе икесенә чәй эчергән җиз самавыр да аны юксыналар кебек бит.

Әтиләренең авыр хәлен күреп, уллары аны үзләре белән алып китәргә тырышып карады.

– Әнкәгезнең эзе дә суынып бетмәгән бит әле, ничек телегез бара? – дип кенә җавап бирде ул, әрнеп.

Әниләренең өчесен уздыруга, уллары, әтиләре янында яшь баласы белән сеңелләрен калдырып, китеп бардылар.

Авыр хәсрәт эчендә елдан артык гомер узды. Көз көне, ниһаять, Закирҗан Шаһидулла бабайны үзләренә барырга күндерә алды. Сыерны саттылар, йортның тәрәзәләрен кадакладылар.

...Өч атна инде менә Шаһидулла бабай Казан каласындагы зур бер йортның дүрт бүлмәле фатирында яши. Улы һәм килене эштән соң гына кайта. Бердәнбер уллары Альберт көне буе үз эшләре белән мәшгуль, әле дәрес әзерли, әле телевизор карый, алай да булмаса, иптәш малайлары белән бергәләп магнитофон акырта. Озын буйлы, җитү чәчле, сөлектәй оныгына карый да хәйран кала Шаһидулла бабай: ни арада үсеп җитте әле ул? Кайчан гына бот буе бала иде. Авылга кайтты исә, алма бакчасына куыш корып, бу минем штаб, дип, шунда үзенчә туплар куеп, алардан аткан булып уйный торган иде. Бик тә тере, бик тә зиһенле бала иде. Тик киленнәре Даниянең аңа «Алька», «Алечка»,

дип, ир балага һич тә ябышмый торган исемнәр белән дәшүе, оныкларының үз телебездә сөйләшмәве генә олыларның күңелен рәнҗетә иде. Дәү әниләре, мәрхүмә, бакчада кайнашкан оныгын ашарга керергә чакырып-чакырып та, тегесе һаман кермәгәч, тәмам гаҗиз булып: «Әй Ходаем, үз балаң белән икең ике телдә сөйләшкәч, ул сине ничек якын итсен!» – дип, бөтен йөрәге белән сыкранып ала торган иде.

Әйе, якын итеп бетерми шул оныклары. Менә хәзер, көннәр буе ялгызы утырган чагында: «Нихәл, дәү әтием?!» – дип, бер генә эндәшсә дә, яралы күңеленә җиңелрәк булып китәр иде дә бит, юк шул, эндәшми. Алай гына да түгел, оныгы аның барлыгын да сизмәгәндәй итенә, ә килгән дуслары күпвакыт исәнләшергә дә оныталар. Яшьләрнең мондый кыланышлары Шаһидулла бабайны бик тә рәнҗетә, шуңа күрә ул алар күзеннән кая да булса читкәрәк качарга тырыша иде.

Беркөнне улы Закирҗан эштән иртәрәк кайтты. Кайтып керүгә үк, тантаналы төстә куанычлы хәбәр әйтте: аны, илле яшь тулу уңаеннан, озак еллар намуслы хезмәт итүе өчен, орден белән бүләкләгәннәр, кичен кунаклар да киләсе икән.

Кичке сәгать җиде тулганда, балкып торган зал уртасындагы зур өстәл кунаклар каршыларга әзер иде инде.

Мәҗлес күңелле генә барды. Уен-көлке, тантана вакытында сәгатьнең узганы сизелми дә калды. Шаһидулла бабай күп көннәрдән соң беренче тапкыр авыр кайгысыннан айнып киткәндәй булды, кешеләр белән бергә ашады-эчте, балаларының куанычына куанып, күңелле генә елмаеп утырды. Бераз кызып алгач, кунаклар җырлаша, биешә башладылар. Шаһидулла бабай да әкрен генә урыныннан күтәрелде дә, күрше бүлмәгә кереп, гармунын кулына алды...

Шулкадәр бирелеп уйнады ул, бөтен күңеле, йөрәге белән сызланып: «Галиябану, сылуым иркәм, шулкадәрле сагындым...» – дип сузган чакларында күзләренә тулган яшьләрен башкалар күрмәсен өчен, гармунына сыена төшеп, башын түбән иде. Ләкин кечкенә бүлмәгә җыелып өлгергән кунаклар үзләре дә аннан ким дулкынланмаганнар иде, күрәсең, барысы да моң иркенә бирелеп, башларын иеп тынып калганнар.

Шулчак, кинәт кенә:

– Әй, ниткән меланхолия бу?! Ну-ка, дед, хәзер үк туктат! – дигән тавыш яңгырады.

Әллә кечкенә бу бүлмәдә агылган көй артык нечкә, моңлы булганга, әлеге яшь тавыш шулкадәр дорфа ишетелде ки, тыңлаучылар, тетрәнеп китеп, башларын күтәрде.

Алар алдында Закирҗанның Альберт басып тора иде. Ишектән, ваемсыз гына елмаешып, тагын ике-өч егет кереп киләләр...

Шаһидулла бабай башын күтәрде, оныгының тәкәббер карашы белән очрашып, сүзләренең мәгънәсе зиһененә барып җиткәч, үзе сузган гармун күреген дә җыя алмаслык бер хәлдә, урыныннан кузгалды. Тик гармун гына, өзелгән моңны кызганып уфтангандай, авыр сыкранып куйды...

Стеналарны дер селкетерлек куәт белән үкереп-чинап җибәргән магнитофон тавышыннан кунаклар, исләренә килеп, уянып киткәндәй булды.

Бераз гына вакытка онытылып торган авыр кайгыларын янә иңнәренә өеп куйгандай, бөрешебрәк калган Шаһидулла бабай, иелгән башын күтәрмәде. Аңа елышыбрак баскан кунаклар да сүзсез калганнар... Бүлмәдә колак тондыргыч музыка тавышы гына ярсыганнан-ярсый бара иде...



Рифат
Сәлах

# ҖИЛЛӘР ИСӘ КЫЙБЛА ЯГЫННАН...

## Татарстан

Чүккән идең, янә торып бастың,
Сүнгән сыман идең – ут булдың!
Яраларың ямап, зур галәмнең
Тәхетенә менеп утырдың.

Бал кортлары сиңа ширбәт ташый,
Сөлекләрең чирең суыра.
Яралангач, тору – табигый хәл,
Үлгәч кенә бары соң була.

Фәрештәләр болытларны куган,
Җен-пәриләр комнан бау ишкән.
Бар дөньясы торараштай калыр,
Бездә өмет әле бар, дисәң.

Бөтен дөнья торараштай калыр,
Бөтен дөнья синсез адашкан.
Күтәрел дә җиргә иман өләш,
Бар җиһанга ямь өр, Татарстан!

Яра эзе сине бизи генә,
Беләм, ныклы синең иманың!
Татарстан, әгәр син булмасаң,
Бер яме дә калмас дөньяның!

***

Бер адашкач, чыгып кара, әйдә,
Табарсыңмы юлын галәмнең?
Мин битараф, җаным, әллә нигә
Таш йөрәккә янә әйләндем.

Рифат СӘЛАХ (1987) – *шагыйрь; «Күңел бөртекләре», «Яшел ай», «Ташта үскән гөлләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Мәхәббәтем кышкы бураннарда
Өшегәнме, белмим, туңганмы...
Әллә инде сөю хисен җуеп,
Йөрәгем дә кинәт тынганмы?

Әллә ниләр булды... Ниләр булды?
Кем сихере, әйтче, кем эше?
Яши алмам мондый язмыш белән,
Битарафлык белән килешеп...

Мәхәббәтем әллә эрегәнме,
Язгы ташуларда акканмы?
...Еллар буйлап эзләп барам кебек
Керфегеңә кунган ак карны...

## Җомга үтте...

Җомга үтте... Менә кояш байый...
Җилләр исә кыйбла ягыннан.
Шәфәкъ нуры иңгән җир йөзенә
Фирүзәдәй юрган ябылган.

Җомга үтте... Күккә моң эленгән,
Болытлар да эри тын гына.
Кар астыннан гөлләр эзләп йөрим,
Бар тапканым ләкин туң гына.

Җомга үтте...
Тагын бәйрәм көтеп,
Җанда өмет белән йөрербез.
Тик иманны туңдырмаска иде, –
Кыштай салкын булыр илебез.

## Сәерлектер

Кышкы урам. Ишеп карлар ява,
Мин тунымны салып йөгердем.
Ап-ак дөнья буйлап бер үтмәсәм,
Гүзәллекне ничек күрермен?

Тәрәзәдән тоеп буламыни
Бу сафлыкка чумган җир йөзен?!
Килә минем ак көртләргә батып,
Урман эчләрендә йөрисем.

Кар көртләре киртә буламыни,
Күңелләргә иңгән сафлыкка?!
Тәлгәш-тәлгәш ак йолдызлар ява,
Аксыл карга каеп ак ука.

Аклык белән иләсләнеп йөрим,
Мәхәббәтен тапкан яр сыман.

...Шагыйрь кеше сәеррәк була
Сәер кешеләрнең барсыннан.

Мондый ямьне күрми йөргән затмы?.. –
Ул – таш йөрәк, димәк, ул – агач!
Кеше ничек шагыйрь була алсын,
Минем кебек сәер булмагач?!

## Тимер арба

Тимер арба кыңгыравы
Чыңлый да чыңлый гына.
Күңелдәге тиле уйлар
Тынмый да тынмый гына.

Уянып китәм салкыннан,
Чыгам да китәм юлга.
Бернәрсә дә сөендерми,
Сәбәп юк елмаерга.

Уянып китәм яшәүдән,
Тирәмдә – чынлык кына.
Котылырмын күк гамемнән
Юлларга чыгып кына.

Тимер арба кыңгыравы
Чыңлар да чыңлар һаман.
...Кешеләрнең күңелләре
Тимердәй каты заман.

## Хыял булып яшәр ярыма

Итәкләрең җилдә җилфердидер,
Болыннарда шәүләң чагыла.
Тугайлардан йөгереп киләсеңдер
Яшьлекнең иң ямьле чагына.

Көлүең – чулпы чыңы, йөрешләрең
Аккош көнләшерлек иде лә.
Кояш сыман сары күлмәгеңнең
Кагыласы иде җиңеңә.

Сылу идең, зифа буйлы идең,
Һәр авазың челтер чишмәдәй.
Офыкларга гына кереп киттең,
Су алырга гына төшкәндәй.

Тузганаклар арасында калдым,
Шул сурәтне салып җаныма.
Бу җырымны сиңа бүләк итәм –
Хыял булып яшәр ярыма.

# РИФАТ СӘЛАХ ШИГЫРЬЛӘРЕ

Рифат Сәлах – иҗатта үз юлын, шигъри фикерне формалаштырып, сүзләргә төреп укучыга тәкъдим итү калыбын әлегә табып җиткерә алмаган, әмма эзләнүчән, талантлы каләм иясе булып тоела миңа. Әгәр кеше шигырь язудан туктамый икән – димәк, талант орлыгы бар, әмма аңа үсеп чыгарга, чәчәк атарга кирәк. Шул ук вакытта еш кына моның өчен читтән ярдәм (остазлык, димме) кирәк була.

Тәкъдим ителгән шигырьләр бәйләме шундый фикерләргә этәрә. Чөнки аларны югары шигърият үрнәкләре дип бәяләп булмас. Әмма авторның шигъри тоемлы, дөньяга чыгарга «ашкынып торган» шигъри фикерле булуын да инкарь итәргә ярамый.

Беренче шигырь гражданлык лирикасына карый – «Татарстан» дип исемләнгән. Татарстанга мәдхия укыган лирик герой аның булуын, яшәвен тели һәм соңгы юлларда *«син булмасаң, дөньяның яме калмас»,* дип белдерә. Мондый фикер әйтелгән шигырь һәр татар шагыйренең иҗат хәзинәсендә бар. Һәр шагыйрь кадерле республикабызга үзенчә мәхәббәт аңлата...

Рифат Сәлах текстында да шигъриятле, яңалыгы булган ике юл игътибарны җәлеп итә:

*Күтәрел дә җиргә иман өләш,*
*Бар җиһанга ямь өр, Татарстан!*

Бу юлларда республиканың иманлы-кыйблалы яшәү үрнәге булырга тиешлеге дә, лирик геройның һәм укучының аңа үсү-күтәрелү теләве дә бергә килеп тоташа. Сүзләр сайланышы да матур (дөрес, *«өр»* сүзен *«бир»* белән алыштыру образны нәзакәтлерәк итәр иде, чөнки укучының, гомумән, кеше затының бер өлеше укыган текстны күрмә образларда күзаллый, ди фән).

Әмма калган юллар бу югарылыкны саклый алмый. Алар, күңелдә шатлык, горурлык яки борчылу хисләре уятудан бигрәк, каршылыклы сораулар барлыкка китерә. Беренче тезмәдә *«чүккән»*нән соң торып баскан, *«сүнгән»*нән соң – утка әйләнгән вакыт, күрәсең, совет чорындагы сынауларга ишарә ясый. Әмма *«зур галәмнең тәхетенә»* менеп утыру нәрсә икән ул? Дөньядагы мөстәкыйль илләр белән бер түгәрәктә түгелбез бит. Бәлки тәхеттә булу – үзе хакында хәбәр итүе, үсештә булуы турында сөйлидер. Әмма алай икән, тәхеттәге илнең *«чирле»* булуы (икенче строфадагы югары шигъриятта кулланылырга тиеш булмаган *«сөлекләрең чирең суыра»* фразасы), өмет бар дип әйтү мөмкинлеге (өченче строфа) һәм дөньяның Татарстансыз «адашкан» булуы, лирик геройның соңгы строфада аны «күтәрелергә» чакыруы кабат сурәтне бозып ташлый. Ничек инде галәм тәхетенә менгәнне күтәрелергә чакырырга мөмкин?! Кая кадәр күтәрелү турында сүз бара? Инде шигъри текстларда иң әһәмиятле фикерне аерып күрсәтә торган кабатлау (*«Бөтен дөнья тараташтай калыр»* тезмәсе) мәгънәне бөтенләй чуалта. Нишләп Татарстан күтәрелү хәбәреннән бөтен дөнья тораташка әйләнергә тиеш? Күрәсең, автор әйтергә теләгән фикер укучыга аңлашылырлык итеп формалашмаган.

Әлбәттә, һәр текстта талантлы, шигъриятле юллар булу аларның ни өчен бөтенлекле шигырь булып чыкмавы сәбәбен эзләргә мәҗбүр итә. Икенче текстта *«...Еллар буйлап эзләп барам кебек / Керфегеңә кунган ак карны... »* – шундыйлардан. Бу текстта беренче строфа артык, аннан башка укыганда, текст мәхәббәтен югалтып сагышланучы лирик герой хисләре турындагы матур гына шигырь булып чыга (дөрес, өшегәнме, туңганмы синонимнарын янәшә куллануның отышсыз икәненә игътибар юнәлтик). Әмма беренче строфа бөтенләй үзгә – бергәләп галәм серен эзләргә чакырган сөйгәненә тискәре җавап биргән – битараф (бәлки, бөтенләй яратып карамаган!) лирик герой сурәте ясый. Бер текстта – ике төрле герой хасил була. Һәм текст шигырь булудан туктый.

Өченче шигырь – *«Җомга үтте...»* белән дә шулай. Уңышлы табылган шигъри

исем. Ике строфа белән туктаганда, гади генә, әмма килешле генә шигырь килеп чыга. Өченче строфадагы:

*Тик иманны туңдырмаска иде, –*
*Кыштай салкын булыр илебез, –*

юллары шигърияттән – публицистикага алып китә.

*«Сәерлектер»* – бәйләмдәге иң уңышлы шигырь. Анда тергезелгән дөнья сурәте дә, гыйсъянчы лирик геройның хисләре дә, хәтта үзирониясе дә тәэсирле һәм матур гына килеп чыккан.

*«Тимер арба»* шигырендә фикернең ачыклыгы җитмәү хакында әйтергә кирәк. «Тимер арба» җәмгыять символы булып укыла ала, моңа ачкыч күрсәтелмәсә дә. Кыңгырауның арбага түгел, бәлки ат җиккәндә дугага тагылуы яшерен мәгънә эзләргә этәрә һәм, юл символы белән (икенче строфа, *«Чыгам да китәм юлга»*) янәшәдә, шушы укылышны ныгыта. Икенче һәм өченче строфаларда үзгәреп кабатланган тезмәләр бар: *«Уяныр китәм салкыннан»* һәм *«Уянып китәм яшәүдән»* (?!). Соңгысы, *«Котылырмын күк гамемнән / Юлларга чыгып кына»* тезмәләре белән янәшәдә, әлеге образны җимереп ташлый. Тимер арбаның без тапкан мәгънәсе югала, аны башкача укуга да мөмкинлек күрсәтелми. Һәм соңгы строфада тимер арба кыңгыравының башка мәгънәсе күренеп китә: ул – лирик геройның тәнкыйди фикере, гаме, ваемы!

*Тимер арба кыңгыравы*
*Чыңлар да чыңлар һаман.*
*...Кешеләрнең күңелләре*
*Тимердәй каты заман, –*

юлларында кеше күңелләренең катылануы турында лирик герой-шагыйрьнең, гомумән, шигърият-әдәбиятның гел кисәтеп торачагы хакындагы фикер тоемлана. Әмма бөтенлекле яки үсештәге-үзгәрештәге образ булмау текстны тарката, аңа шигырь булып оешырга мөмкинлек бирми. Чөнки бу табылган мәгънә белән кабат текстның беренче строфасына әйләнеп кайтуга, каршылык уяна:

*Тимер арба кыңгыравы*
*Чыңлый да чыңлый гына.*
*Күңелдәге тиле уйлар*
*Тынмый да тынмый гына.*

Күрәбез, әле генә пафос белән шагыйрьнең яшәештәге тискәре үзгәрешләр турында кисәтүе бу очракта «тиле уйлар» дип бәяләнә алмый бит инде!

*«Хыял булып яшәр ярыма»* шигырендә яңалык булмау хакында әйтергә кирәк. Халык иҗатыннан, җырыннан килгән образларның кабатлануы бу тәэсирне тагын да көчәйтә.

Шулай итеп, журналның бу санында тәкъдим ителә торган шигырьләр бәйләме миндә канәгатьсезлек хисе дә уятты. Икенче яктан, гади укучы бу текстларда күңеленә файдалы фикер, матур сурәтләр дә таба аладыр, бәлки. Бер үк вакытта, мин, басылып чыккан шигырь җыентыкларына, проза китапларына да югары әдәбият күзлегеннән тәнкыйтьнең булмавын, дөресрәге, иҗатчыларыбызның үзләренең үк мондый тәнкыйтьне әдәбият мәйданыннан чыгарып бетерүен уйлап куйдым...

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



Лилия
Вәлишина

# ҖИҢҮ ЯЗЫ КИЛГӘНДӘ...

ХИКӘЯ

## Урман

– У-у-ууу!..

Җилекләргә үтеп керердәй ачы җил томырыла. Чатнаган салкын, борынга ябыша да, өзәрдәй итеп, чеметә-чеметә тәмам кызартып бетерә, зәһәрлегеннән куллар, аяклар үзләренең сиземләвен югалткандай була.

Нәрхәятнең күз алдына әнисе килеп басты, аның назлы карашы, йомшак куллары кызны җылыта кебек. Хәзер ул берни дә күрми, ишетми, тоймый төсле. Уйлары белән еракта, туган өйдә: мичтә гөрелдәп янган салам тавышына кадәр ишетә; түгәрәк табын янында, ә анда – әнкәсе әле генә мичтән алган татлы ипи, хәтта ул аның хуш исен сизгәндәй, борынын тартып куйды.

– Агач! Саклан!

Яңгыравык тавыш кызның колак төбеннән чыңлап үтте. Нәрхәят кинәт сискәнеп китте. Бу матур төш, күз ачып йомганчы, чүлләрдәге чалым шикелле югалды.

Кыз бөтен җитезлеге белән кырыйга тайпылды. Бер мизгел эчендә озын, таза нарат, гәүдәсен тоталмыйча, шаңгырдап карга ауды.

Кыш. 1941 елның соңгы тәүлеге. Бусагада 1942 елның гыйнвар ае ишек кага.

Кышкы урман моңсу, боек. Кая карама – һәркайда ап-ак кәфенлек – кәбек кар...

Тирә-юньне биләгән. Кәүсәләрнең аскы өлешен көрт ураган, әйтерсең, шуңадыр да күңелсез һәм төшенке булып тоеладыр бу кышкы урман.

Кышкы урман тып-тын.

– Чаж-чож! Чаж-чож!

Әлегә кыш тарафыннан озакка дип салынган тынлыкны бертуктаусыз пычкы белән балта тавышлары гына яра.

Алар – алты кыз. Зәйнәп, Гөлчәчәк, Гөлсем, Минзифа, Катя һәм Нәрхәят. Күптән түгел Нәрхәят егерме яшен тутырды. Аның янәшәсендә эшләгән Катяга – егерме бер. Калганнары да шул яшьтә, ә Гөлсемгә унсигез генә әле.

Мари урманы бигрәк куе. Ярты гасырлык чыршылар күкне тишәрләр сыман. Монда икенче дөнья – баһадир агачлар дөньясы – һавасы да, урыны да икенче төсле. Кешеләр яшәгән җирдән аерыла. Шул алып сыман дәү агачлар арасында адәм заты үзен кечкенә, яклаусыз бер җан ияседәй хис итәдер. Менә Нәрхәят тә шушы минутларда табигать-ана тудырган иң таза, иң зифа яшел тереклек янында үзен көчсез сабый итеп тойды.

Бераз хәл җыйды. Бу зәмһәрир салкында йөрмәс булган бармакларын угалады,

---

Лилия ВӘЛИШИНА (1983) – *яшь язучы; хикәяләре вакытлы матбугатта дөнья күрде. Арчада яши.*

бер-берсенә ышкып алды. Катя да, аңа карап, эшеннән туктады, урынында сикергәли башлады.

Катя – рус авылыннан, ятимә кыз. Әби-бабай кулында гына тәрбияләнгән, ата-анасын да тонык кына хәтерли иде. Кулдашына караган саен, Нәрхәят аны кызгана. Ничек инде кызганмыйсың ди? Өстендә гәүдәсенә күрә хәтсез зур булган, тузган толып. Тыгызлап кына тарттырып бәйләнгән киң каешы биленең нечкәлеген күрсәтеп тора. Башында да искерәк кенә шәл. Аягында бигрәк тупас җәлпәк чабата, җитмәсә, иске чүпрәк-чапрак белән уралып беткән. Шул чабата эченнән озын балтырлы оекбашы чалына. Берничә урында ертылган калын, катлы-катлы ыштаныннан сыйраклары беленеп тора.

Ә беркөнне Нәрхәят түзмәде: кирәге чыгар дип, әнисе юлга тыккан мамык шәлен Катяның иңенә салды.

– Бераз җылырак булыр, дустым, – диде кыз.

– Юк, кирәкми..., – дип, сүрән генә әйтеп маташкан Катяга Нәрхәят, туры карап, кискен дәште: – Бүләк әйберне кире алмыйлар.

Катя кызарды, уңайсызланды һәм һавадай зәп-зәңгәр күз карашын яшерде.

Нәрхәят белән Катя аркаларын терәштеләр. Алар янына башкалар да килеп елышты. Ләкин рәхимсез җилдән һичнәрсә дә сакламады. Тешең-тырнагың белән эшкә тотынасы. Норманы үтәргә! Һичнәрсәгә карамый!

– Чаж-чож! Чаж-чож! – тагын шул тавыш хакимлек итә.

Зәмһәрир җил, томырылып, алар белән сугыша кебек. Күзләргә чәнечкеле бөртекләрен бәрә, керфекләргә сыкы ябыштыра, өздереп бит тиресен йолкый, буыннарга үтәрдәй бозлы сулышын өрә.

Агачларны чанага төягәндә, җил бөтенләй котырынды. Карны туздырып себертте, шайтан туедай, бөтерелеп-бөтерелеп күтәрелде. Нәрхәятнең Ак Колагы әкрен генә кешнәп алды. Кыз аның башын сыйпады, назлы сүзләр пышылдады. Ак Колак күкрәгеннән тагын бер тапкыр аваз чыгарды да башын аска иеп кузгалды.

Нәрхәятнең аты артыннан, калган алашалар да, көрткә бата-бата, тар сукмактан авылга юнәлделәр.

## Зәйтүнә

1939 ел. Подольски шәһәренең күпсанлы коммуналь йортларының берсенә урта буйлы, озын калын толымлы, кулына кечерәк чемодан тоткан яшь кенә туташ, кыю гына килеп, кыңгырау төймәсенә басты. Кыңгырау үзен озак көттермәде: шундук бөтен йорт яңгырады. Кызның йөзендә дулкынлану чаткылары чагылды. Бу Нәрхәят иде.

Әнисе Асия ягыннан якын туганы Әминә түти гаиләсенә сыенды ул. Ишле гаиләгә карамастан, Нәрхәяткә дә башын куеп алырлык урын табылды.

Кечкенә авылдан шәһәргә килеп төшкәч, кызның эшкә урнашу турында баш ватасы булмады. Кич белән үк Фаяз җизнәсе үзе хезмәт иткән танк заводына керергә тәкъдим итте.

Нәрхәят танк заводының тимер шомарту цехында эшли башлады. Двигатель детальләрен тигезләү авыр булса да ул тырышты. Якындагы станокта поршень шомарткан Зәйтүнә бер ел эчендә Нәрхәятнең дус кызына әверелде. Беренче карашка усал чырайлы күренсә дә, якынрак танышкач, аның ярдәмчел һәм туры кеше булуын аңлады Нәрхәят. Зәйтүнә дә кайчандыр кечкенә генә татар авылыннан килгән. Әмма, Нәрхәяттән аермалы буларак, кияүгә чыккан ханым. Тормыш иптәше Хәлил дә шушы завод цехында тимер борысларны эшкәртә. Станогында туп көпшәләренең эчен сырлый-ергалый кисә.

Нарасыйлары да юк иде әлегә аларның. Зәйтүнә Нәрхәят белән күп аралашты: кичке театрларга да, концертларга да бергәләп йөрделәр, кибетләргә чыктылар. Зәйтүнә, ике яшькә олырак буларак, Нәрхәят белән үзен олыларча тотты. Ә ул, олы ахирәте белән серләрен уртаклашты. Хәер, унтугыз яшенә җитсә дә, Нәрхәятнең әлегә

мәхәббәт серләре юк иде. Сер дә түгел, гадәти теләкләр генә бугай... Ә менә Зәйтүнә ханымның сере бар кебек тоелды кызга.

– Ахирәтем, – дип сүз башлап җибәрде Зәйтүнә төшке аш вакытында, – иптәшем Хәлилне цех бригадиры бер айга укырга җибәрә. Үзем генә ялгыз яшисем килми, әйдә, дустым, минем янга күчен. Икәү күңеллерәк булыр, – диде.

Нәрхәят икеләнеп тормады, ризалашты.

– Хәлилем эшкә оста, – дип горурланды хатын. – Менә, кара, – дип сузды ул кулын, бүлмә ягына ымлап, – мондагы бөтен җиһазларны да үз куллары белән ясады, бәгърем минем, – диде ахирәте әле генә кергән Нәрхәяткә. – Алтын куллы, чын ир! – дип мактануын дәвам итте.

Тиз арада чәйнек тә шаулап кайнап чыкты.

– Гафу ит бу соравым өчен, – диде Нәрхәят, – дустым, хәләл җефетеңне яратасыңмы?

– Сорап торасың инде, җаный. Яратам, бик яратам үзен. Борчылма, сеңлем, сиңа да килер матур мәхәббәт, килер дә кочагына алыр, йөрәк йөрәккә кушылыр һәм гомерлеккә әсир итәр шул кочагында. Күрәм, синең йөрәгең әлегә буш.

– Әйе. Кайвакытларда ярата алырмын микән дигән уй килә. Йөрәгем таш кебек каты, мәхәббәткә ачылмас шикелле, – кыз көрсенеп куйды. – Мәхәббәтнең дә төрлесе була бит, Зәйтүнә апа.

– Була, җаный, була, җавапсыз мәхәббәт..., – дип, авыр сулап алды хатын. – Безнең авылда бер егет миңа шашып гашыйк иде. Башкага чыксаң, үз-үземә кул салам, диде. Туй алдыннан атна калгач килдем янына. Кара, күр, әнкәң-әткәң картлар, кем кулына калырлар син үлсәң? Ә? Уйла, уйла! – дидем. – Баласын югалткан ананың йөрәге мең кисәккә ярылыр һәм һәрбер кисәгеннән дә мең тамчы кан саркып торыр. Ата-анаңны да, мине дә бәхетсезлеккә дучар итәрсең. Син шулай булуын телисеңме? Әйт? И Тәңрем, шушы минутларда, үтенәм, ошбу ахмак бәндәгә тиң ярын эзләп табарга ярдәм ит, дип Ходайдан ялвардым. Минем әйткән сүзләр тәэсир иттеме, белмим, ике көнләп узгач, ул калага китте. Без дә Мәскәүгә юл тоттык. Менә шулай, – дип бетерде Зәйтүнә.

– Җавапсыз мәхәббәт бигрәк тә газаплы буладыр шул.

– Шашып сөясең икән, димәк, киң күңелле, олы йөрәкле бул!

– Тик, бик кызганам теге егетне.

– Нигә әле без ямансулап утырырга тиеш. Әйдә, бәлеш пешерик, бүлмәдәшләрне дә сыйларбыз, чөкердәшеп чәйләп алырбыз, – дип тәкъдим итте ахирәте.

Бер ел сизелмичә үтеп тә китте. Яңа ел башланырга да атна-ун көн калып бара. Нәрхәят заводтагы эшен бик яратты, алдынгы эшчеләр рәтенә дә керде, мактау кәгазе белән дә бүләкләнде. Тик... Шәһәр тормышына кызның күңеле ятмады. Кысынкы, тар бүлмәләрдә яшәүне үз итмәде.

Кая инде авылдагы киң болыннар, диңгез сыман басулар! Кая ул иркенлек?! Җырлап аккан шифа сулары, яшеллеккә күмелгән хуш исле урманнары. Кая ул җанга-тәнгә сихәт бирердәй матурлык?

Кызыл-Сарай урманы эченә кереп, йөрәкләрдән ташып чыккан көчле тавыш белән җыр сузарга ничек ярата Нәрхәят! – Ау-у! Кәккүк! – дип, кайтаваз яңгыравын шаяртып үртәргә. Кая ул табигый балалык?

Уй-фикерләрне дә барлап булмый ич бу шәһәр дигән җирдә, башың әйләнә дә тубал була.

– Йә, Хода! Мин бүтән монда кала алмыйм, алмыйм! – дип, кинәт кенә, үзе дә сизмәстән, кычкырып җибәрде Нәрхәят. Хәтта узып баручы егет тә аңа борылып карады.

Әминә апасы белән Фаяз җизнәсенә, киңәшләшү йөзеннән генә, китү турында әйткәч:

– Ничек телисең, шулай булсын, – диде Фаяз ага.

Зәйтүнә дустын калырга үгетләп караган иде дә, әмма Нәрхәят үз сүзендә нык торды.

Зәйтүнә авырлы иде. Туачак нарасыена җан да кергән. Сөенечле хәбәрне булачак

ана ахирәтенә әйтәсе килде. Менә беркөнне Зәйтүнә Нәрхәятнең кулын түгәрәкләнә башлаган корсагына салды.

Әйе, монда сүзләр артык иде. Анасы карынында яткан сабыйның бәргәләнеп тибенүен тойды Нәрхәят. Менә берәү, икәү... Нәрхәятнең күз алдында дөнья нурланды, түгәрәкләнде. Менә бит ул бәхет кая ята! Тормышның чын мәгънәсе Ходай тарафыннан яңа җан өрүдә яшеренгәндер...

– Ахрысы, малай булыр, – диде ахирәте.

– Исем сайладыгызмы? – дип кызыксынды Нәрхәят.

– Әгәр дә улым туса – Илдар! Нәрхәят, син Илдарның барлыгын белгән өченче кеше, – дип елмайды булачак ана.

Кулына хезмәт хакы алгач, кыз кибетләрне әйләнде. Гаиләсенә, авылдашларына тәм-томнар, бүләкләр сайлады. Әнисенә аяз күк йөзе төсендә күлмәклек, кечкенә энеләренең өс-башына киемнәр карады.

* * *

Тимер җәйран Нәрхәятне туган якка илтергә ашыккан саен, аның өчен якын булган кешеләр дә артта кала барды. Поезд күздән югалганчы, ике пар хәйран гына басып торды.

– Берсе олырак яшьтәге, чал кергән Әминә апай һәм Фаяз ага булса, икенчесе – яшьлек вә мәхәббәт тулы Хәлил белән Зәйтүнә иде.

## Хатирә

Мәрьям апа ялгыз карчык иде. Бердәнбер улы сугыш кырларында югалган. Оныклар белән ташып торган бала-чага тавышлары да ишетелми аның җиргә иңгән йортында. Тик йонлач мәче генә, ямь-яшел дәү күзләрен кешегә текәп, үзенең барлыгын белдереп йөри.

Мәрьям апаның өе урман кырыендарак, башка йортлардан читтәрәк урнашкан. Аның каралты-курасы янында гына колхозның ат абзары салынган.

Холкы буенча бик тә сабыр хатын, улыннан хәтсез вакыт хат килмәгәч, еш әйткәли иде: «Ни язган – шул булыр. Язмыштан узмыш юк».

Кызлар килеп кергәндә, Мәрьям апа мичтән ипи ала иде. Ишекне ачуга, өйдәге җылы ямь Нәрхәятнең йөрәгенә май булып ятты:

– Әйдәгез, балалар, утырышыгыз, – дип, табын янында кайнаша торды.

Әмма кызлар башта үзләре ашамый. Алар Мәрьям апа әзерләп куйган башакны атларына бирәләр. Дөньядагы барлык хайваннардан да Нәрхәят атларны бик җәлли. Ник дигәндә, адәм баласының башына төшкән күп авырлыкларны ат кеше белән бергә тарта.

Бүген кызлар өчен чын бәйрәм иде, чөнки өстәлдә ипи ята. Мондый вакытларда Нәрхәят Ак Колагына да өлеш чыгара. Кыз абзарга кергәч, ат һәрвакыттагыча кешнәп ала, колакларын тырпайта һәм, акыллы күзләрен тутырып, Нәрхәяткә карый. Бу кич тә ул атын сыйларга булды. Нәрхәят Ак Колак каршына килеп басты, йомарлаган уч төбен ачты һәм атның иреннәренә китерде. Кызның битенә җылы сулыш бәрелде. Ризыкның тәменнән ләззәт табарга тырышкандай, Ак Колак ипине әкрен генә, ашыкмыйча гына чәйни башлады. Рәхмәтле күзләрен кызга күтәрде. Нәрхәят шундук атның муенына сарылды, башын дустының ал сынына салды.

Төн дә җитте. Өй эчен яктыртып торган керосин лампасының соңгы яктылыгы да сүнде. Мәрьям апаның йорты караңгылыкка күмелде. Ләкин кызлар озак кына йоклап китә алмадылар. Нәрхәят янында яткан алтынсу җирән чәчле, кара кашлы, яшел күзле Гөлчәчәк әкрен генә сулкылдап елый иде.

– Гөлчәчәк, бәгърем, ни булды?

– Зөлфәт, сөйгән ярым, исән-имин генә булсын иде, – диде Гөлчәчәк, елавыннан

туктый алмыйча. – Ярәшергә өлгермәдек, бер-беребезгә сүз бирдек: ул – кайтырга, мин – көтәргә.

– Җаныем, елама, тукта. Алдан күз яшьләреңне түкмә. Ышан, Алла боерса, кайтыр сөеклең. Яхшыга өметлән, бәгърем.

Нәрхәят ничек тә булса юатырга тырышты хезмәттәшен.

Тәмам изрәгән, дулкынланган дусты тәмле төшләр дөньясын гизгән чакта төн уртасы иде. Нәрхәят үзе дә борчылды, борчылуданмы йокысы качты. Хәйран гына ачкан күзләрен караңгылыкка текәп ятты. Аны да бит сөеп-көеп йөргән кеше бар иде. Озын буйлы, зур колаклы, кара мыеклы, кайчан карама һаман авызы ерык – Гаяз. Авылда беренче гармунчы саналган Гаяз бит ул. Хәзер дә кайдадыр еракларда аның йөзе гел елмаядыр кебек... Әмма көчләп сөеп булмый шул. Егетнең ата-анасы да Нәрхәятне сорарга дип килгәннәр иде. Йөрәктә мәхәббәт булмаса, күктән йолдызлар алып бирсәләр дә, бу хис тумый. Фронтка киткәндә дә озата килмәде Нәрхәят. Ә Гаяз, һичшиксез, Нәрхәятне көткән.

Гаяздан ике хат килде. Берсе ата-анасына, ә икенчесе – Нәрхәяткә иде. Госпитальдән язылган хат. Кыз күпме үкенде соңыннан, егетне кызганды. Үзен битәрләде, каты бәгырьлелектә гаепләде. Ә бәлки Гаяз шушы вакытларда карлы кырларда соңгы сулышын бирәдер. Кыз кинәт кенә сискәнеп китте, тәненә калтырау йөгерде.

– Юк, юк, ул исән, исән! – курку һәм шул ук минутта өмет белән чыккан тавыш караңгылыкка каршы яңгырады.

Менә ул Кызыл-Сарай болынында йөри. Болын зәңгәр чәчәкләргә күмелгән. Якында көлеп-челтерәп чишмә ага. Ә ерактарак урман каралып утыра. Нәрхәяткә рәхәт, күңелле. Зәңгәр чәчәкләргә карый, чәчәкләр – аңа. Бу бит чәчәкләр дә түгел икән, бу бит күзләр һәм нинди таныш! Челтерәп аккан җырлы чишмә энҗедәй тигез тешләрен күрсәтеп елмаймыймы соң аңа? Әйе, елмая, ләкин әлеге елмаю да шундый таныш Нәрхәяткә. Юк, бу болын түгел, бу Гаяз аңа карый, аңа елмая...

Ниһаять, өмет чаткылары белән тулы күзләр авыраеп йомылды, карлыгачтай кара каш астындагы йомшак керфекләр дулкын булып сирпелеп ятты. Гүзәл йөзле төн күперде, куерды, назик канатларын тынгысыз җир өстенә җәйде, айлы карашын авылга төшерде. Шулчак, күкне яктыртып, йолдыз атылды, мизгел – очкынланып зәңгәр биеклектә янар таш бөртекләре коелды, аның балкышын Нәрхәят тә, башкалар да күрмәде. Бу бәхет йолдызы иде. Мәрьям апаның йорты тынлык эченә чумды. Зәңгәр күкнең салкын кургашын итәгендә шытып, бөртек-бөртек булып, энҗе-мәрҗәндәй, вак-вак кояшлар сибелде.

Сихри төн асыл йолдызлы таҗын киде.

## Очрашу

1942 елның март ае. Кыш әлегә хөкем сөрә, үзенең өстенлеген бер дә бирергә җыенмый кебек. Әмма яз карлы әсирлектән иреккә чыгарга ашыга. Һавада вакыт-вакыт яз исе биткә бәрелә. Кар элеккеге сыман йомшак булып күпереп тормый.

– Кызлар, сизәсезме, һавага яз исе кергән! – диде каракучкыл йөзле Зәйнәп һәм рәхәтләнеп көлеп тә җибәрде.

Кояш нурлары аның битендә уйнап, әле бер кызга, әле икенчесенә күчеп шаяргандай итте.

– Кызлар, бу ботаклар миңа берәүнең мыегын хәтерләтә, – диде Гөлчәчәк, ауган агач өстендә җитез генә кулындагы балтаны йөртеп.

– Мыек дигәннән, үзем белән булган бер вакыйга исемә төште, – диде Минзифа. – Моннан биш-алты ел элек безгә ерак туган тиешле ир кеше килде. Ул миңа һаман: «Килен, булачак килен», – дип әйткәли иде. Ух! Шушы сүзләре ачуымны чыгарды! Аның мыегы бар иде. Озын, куе. Күренеп тора: кадерләп кенә үстерә. Теге абзый йоклап киткәч, аяк очына гына басып бүлмәгә кердем дә, озын йөзле кайчы белән – кырт – хуш мыек. Әлвидаг.

Иртән торса – мыек юк. Гаҗәпләнүеннән яңагын сыпыргалады, мескен, борын астын кармалады.

– Кызык булган бу хәл, – диде Гөлсем.

– Кызыгы кызык та, ләкин ахырдан оятымнан кая керергә белмәдем.

Гөлчәчәк бер сүз дә эндәшмәгән Нәрхәяткә күз төшерде:

– Син нишләп моңсу бүген?

– Йөрәгем еш-еш тибә, белмим, ни өчендер. Нидер көтә кебек.

– Озакламый яз, яз килә. Шуңа йөрәккәең ашкынадыр, – дип куйды Гөлсем.

Авыр, саллы бүрәнәләрне чанага төяп бетергәч, бит-яңаклары кызарган Зәйнәп түзмәде:

– Уф, арыдым, кызлар, – дип, «Авыл көе»н каты итеп, көчле тавыш белән кычкырып җырлый-җырлый чанага утырды.

Бездә биек таулар бар ла,
Тау астында таллар бар...

Урман әлегә тып-тын. Бәлки, шул тынлыктадыр аның тылсымы? Кайвакытта куркыта торган, кирәк чакта күңелгә тынычлык иңдерә торган тынлык. Тавыш нинди генә көчле булмасын, ничек кенә кычкырып җырлама, гасырлар буе үскән куе урман, һичшиксез, үз эченә йотып калачак синең сагынуыңны, йөрәктән чыккан өзгәләнүеңне, газиз кешеләрең турында юксынуыңны. Алар, синең якыннарың, күңелеңнән агылган диңгездәй моңны ишетмәсләр кебек, ләкин урман һәр кечкенә генә сабагы, һәр бөртек күзәнәге белән синең җырыңны үз эченә алыр, үз туфрагына салыр, шул туфрак төпкелендә җәелеп яткан үз йөрәк тамырына сеңдерер.

– Әй, кызлар, гөлкәйләр, сагындым мин туган авылымны, – дип куйды Зәйнәп, җырын тәмамлап.

Урманда Зәйнәп җыры әле һаман да ишетелә кебек.

Талда – яфрак, миндә – сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

Мәрьям апаның йортына җиткәндә, һәрвакыттагыча караңгы төшкән иде. Ак Колакның бәкәл сөяге авырткалга күрә, Нәрхәят дустының хәлен белеп һәм Мәрьям апа биргән май белән атның сызлаган сөяк турысын бәйләп чыгарга булды.

Мәрьям апаның йортыннан ат абзарына кадәр биш минутлык юл. Кызуырак атласаң, ике минут эчендә барып җитәргә була.

Төн салкынча. Аяк астындагы кар атлаган саен шыгырдый. Нәрхәят туктады. Тирән итеп сулыш алды. Кыз башын күтәрде, һәм карашы ай белән очрашты... Тиздән, бик тиздән ул әнкәсенең җылы куенына сарылачак. Җылы туган өенә кайтачак. Берсеннән-берсе кечкенә, тиктормас энеләрен дә бик сагынды ул. Хәер, алтынчы ай бит инде.

Тирә-юньдә тып-тын. Әйтерсең лә шундый зур чиксез-кырыйсыз дөньяда ул берүзе генә...

– Чү! Бу нинди тавыш.

Нәрхәят каушап калды. Тынлык эченә колак салды. Әйе, әлеге тавыш чыннан да ишетелә. Кеше ыңгыраша түгелме? Нәрхәят, сак кына басып, тавыш ягына атлады.

Ат абзары янына килеп җитәрәк, күләгәләнеп яткан кеше гәүдәсенә тап булды ул. Нәрхәят, каушавын яшерергә теләгәндәй, ныграк тавыш белән дәште:

– Кем монда?

– Мин хәрби... – дигән җавап ишетелде.

Нәрхәят якынлашты. Ай яктысында кыз аны яхшылап күрде. Әлеге кеше чыннан да хәрби иде. Госпитальдә дәваланганы да беленә: бүрек эченнән башына уралган марлясы беленеп тора. Кара озын шинель, аркасында солдат капчыгы.

– Мин хәзер, хәзер... – диде кыз, пышылдап. – Таяныгыз җилкәмә.

Хәрби кеше авырдан гына торды. Нәрсәдер әйтмәкче булды, әмма әйтә алмады, кипкән иреннәрен ялап, салкын төкереген йотты.

Алар кергәндә, өйдәгеләр йокы хәстәре күрәләр иде. Караңгы кичтә билгесез ир заты белән кайткан Нәрхәятне Мәрьям апа да бераз аптырап каршы алды.

Солдатның яраланган башыннан кан саркый башлады.
– Исемегезне әйтсәгезче, – дип сорады Гөлсем.
– Газинур...
– Газинур, түзегез, сезнең ярагыз ачылган. Хәзер мин повязканы алмаштырам, – диде Нәрхәят, кулына чиста ак чүпрәк алып.
– Сез монда ничек эләктегез?
Ир сөйли башлады:
– Мин үзем белән бергә иңгә-иң сугышкан дустымның... (тавышында калтырану сизелде) авылын эзләп килдем, мари егете Байбадырны. Дустымның үләр алдыннан әйтеп калдырган соңгы үтенечен тыңлап, әманәтен үтәргә дип килдем. Госпитальдән...
Ул күтәрелергә талпынды, ләкин арыган, авырткан гәүдәсе аякка нык баса алмады, чайкалды һәм кире сәкегә ауды.
Нәрхәятнең йомшак кулы ирнең җилкәсенә орынды.
– Сезгә торырга ярамый. Тынычланыгыз, – диде кыз.
Хәрби кеше сүзен дә әйтеп бетерә алмады бугай. Шул арада аңын югалтты.
Мәрьям апа үләннәрдән кайнатылган төнәтмәсен эчерергә ашыкты.
– Хәзер йокыга китәчәк.
– Иртәгесен мин аны район больницасына илтәм, – диде Нәрхәят. – Сузарга һич тә ярамый.
– Өзлегә генә күрмәсен, – дип куйды Мәрьям апа.
Газинур саташты.
– Яшәү нурым, асыл ярым, – дип, кемнедер чакырды.
Төн борчулы үтте. Кызлар чиратлашып авыруны карадылар. Берзаман сугышчыны бизгәк тотты. Ул үз-үзен белештермәде: кочакка алгандай, кулларын җәйде, дерелди башлады.
Нәрхәят авыруга салкын суда юешләткән сөлге куйды. Шулчак ир кеше кызның кулын тотты. Нәрхәяткә кызу кайнарлык бәрде.
– Үтенәм, китмә, китмә...
– Юк, мин һичкая китмәм, – диде Нәрхәят. Утырган урыныннан йокыга талганын да сизмәде ул.
Сугышчының өс киемен салдырганда, шинеленең эчке кесәсеннән очраклы рәвештә кечкенә фото идәнгә төште, һәм бу кәгазь кисәгенә һичкем дә игътибар итмәде.
Нәрхәят әлеге фотоны икенче көн кич кенә күрде. Анда аның ахирәте Зәйтүнә иде.

## Шомырт чәчәге

Язгы чәчү эшләре дә килеп җитте. Бөтен Кызыл-Сарай халкының: хатын-кызларның, яшүсмер, карт-корыларның көне-төне кыр эшенә җигелгән чагы. Ничек эшлисең – шулай ашыйсың бит. Кечкенә һәм тату яшәгән авыл моны яхшы белә иде. Нәрхәят тә тик тормады. Атын җигеп, сабанга чыкты, иген чәчте – бер сүз белән әйткәндә, басудан кайтып та кермәде диярлек. Үз эшен бетерсә, тизрәк башкасын эзләде.
– Кызым, җитәр, талчыккансыңдыр, ял ит, – дигән әнкәсенә:
– Юк, әни, мин армадым, – дип кенә җавап кайтарды.
Менә бүген дә кичен арып-талып кайтканнан соң, күз ачарга да көче калмагач, ул сәкегә ауды һәм шундук йокыга китте.
Нәрхәят үзенә артык буш вакыт калдырырга тырышмады. Уй-хисләргә бирелеп китүдән курыкты. ...Теге очрашудан соң өч ел вакыт узса да, Газинурны оныта алмады. Егетне ул кызганды... һәм шул ук чакта йөрәгенең бер өлешендә сокланды да.
Кичен энесенә күлмәк тегеп утырганда, ачык тәрәзәдән сизелер-сизелмәс кенә хуш ис килеп кергәндәй булды. Нәрхәят кинәт торды, тәрәзә янына килеп катып калды.
Күзен йомды. Тирән сулады. Ачыгып сусагандай, агачтан бөркелгән татлы истән бер мизгел эчендә нindидер әйтеп бетерә алмаслык җиңеллек, рәхәтлек тулган хуш

исне йотарга тырышты. Шулчак йөрәге дерт итте. Тәненә кайнар дулкын таралды. Яшеренеп яткан хисләр ташкын булып ташый башлады.

Нигә, шомыртны ул моңарчы күрмәгән идемени? Нигә игътибар итмәгән?

Дүрт ел элек ачы салкыннарда өшеп корыган шомырт, яңадан яшь ботаклар җибәреп, аның күз алдында янә гүзәллеккә күмелергә тора. Яңадан туу түгелме бу?!

Әмма Нәрхәятнең уйлары бүленде. Кечкенә энесе янына йөгереп килде дә озын кара толымыннан тартты:

– Апа, апа, күлмәгем әзерме? – дип сабырсызланды малай.

– Әй, җанашым, онытылып торам. Хәзер. Җиңнәрен генә утыртасы калды, – дип кенә әйтә алды ул.

Гаҗәп... Бу минутларда Нәрхәятнең йөзендә серле елмаю иде.

Зәйтүнәнең үз теләге белән ире артыннан фронтка киткәнен Нәрхәят белә иде. Ахирәтеннән аңа ике хат килде. Берсендә ул хәләл җефетеннән башка яши алмавы турында язды һәм икенчесендә, шул сәбәпле, сугышка шәфкать туташы булып баруын хәбәр итте.

Соңгы хатта Газинурны һәм улы Илдарны ташламаска, аларны кайгыртуын үтенеп язган иде.

Нәрхәятнең ахирәтенә язган актык хаты җавапсыз калды.

«Зәйтүнә, Зәйтүнә, син ничек шулай уйлый аласың? Алла бирсә, сугыш бетәр, син фронттан исән-сау кайтырсың һәм иптәшең Хәлил белән бергәләшеп кечкенә Илдарны үстерерсез. Әгәр дә... Юк, алай һич тә булалмый, булалмый, – салкын тир кызның маңгаена бәреп чыкты. Йөрәген шомлы уйлар биләде. Нәрсәнедер инкарь иткән төсле, күңеленә кергән хәвефле шомны юкка чыгарырга теләгәндәй, борчудан кыбырсынып, кызу-кызу кулларын селкеде. Ләкин... Әгәр дә... Йә Хода, тагын шул сүзгә төртелеп тукталды бит. Мин вәгъдә бирәм, сиңа Зәйтүнә, Илдарны кайгыртырга. Вәгъдә бирәм, вәгъдә бирәм...»

* * *

Мәңгегә тарихта хәтер булып калган, үзе белән тынычлык, ямь, мәхәббәт алып килгән 1945 елның май ае иде бу.

Колхозда чәчү эшләре тәмамланды. Чиратта – бәрәңге утырту.

Кыр эшләрен ярата Нәрхәят. Басуда эшләүгә ни җитә! Тирә-юньдә иркенлек, киңлек һәм җиңүгә якынлашкан.

Бүген Нәрхәят төшке аш вакытында өйгә кайтырга булды. Күп чакта ул монда – басуда гына, әнисе салган ризыктан гына авыз итә иде.

Авыл урамына кергәч, ерактарак, үзенең йорты турысында, ниндидер бер чит кеше йөргәләгәнен абайлап алды ул.

– Кем булыр бу? – дип, Нәрхәят кулын каш өстенә куеп, таный алмыйча карап торды.

Әйе шул, ара якынлашкан саен, әлеге кешенең хәрби икәнен дә хәзер ап-ачык күрә ул. Ир аңа аркасы белән басып тора, үзе бала күтәргән. Төз, озын буйлы, өстендә гимнастёрка. Аксыл чәчле сабые ирнең җилкәсе аша күренә.

– Исәнмесез? – диде Нәрхәят.

Ир кеше борылды.

Юк, мөмкин түгел!.. Юк...

Йөзгә-йөз, күзгә-күз очраштылар.

Исәнме, Нәрхәят...

Кыз аның күзләренә тутырып карады. Ә анда... Чиксез моң катыш назлы җылылык иде.

– Газинур...

– Илдар, улым, бу синең... – Әмма хәрби сүзен әйтеп бетерә алмады.

– Әни! – сабый, шул сүзләрне генә көтеп торгандай, кулларын сузды, кыбырсынып, алга ашкынды. Хәрби баланы кулыннан төшерде. Сабый, шатланып, әнисенә таба чапты.

Нәрхәят чүгәләде, кочагын киң җәйде.

Газинурның аңлатуы да Нәрхәяткә кирәкми иде. Ул барысын да сүзсез аңлады.

– Улым...

Кайнар яшьләр сабыйның битенә тамды. Менә ул нинди кечкенә Илдар! Анда Зәйтүнәнең күзләре, Зәйтүнәнең елмаюы иде.

Нәрхәят кенә сизмәде... Газинур шушы минутта күз чите белән генә Нәрхәятне күзәтте, аның уй-хисләрен барлады.

Газинур баскан урынында бераз таптанып торды:

– Нәрхәят, минем сиңа әйтер мөһим сүзем бар, – дип, яраланган аягын авырдан атлап, кызга якынрак килеп басты.

Бәлки, ул дөрес аңламаган? Бәлки, Зәйтүнә белән Хәлил исәндер? Шуңа да Нәрхәят әлеге сорауны бирергә кыйды:

– Зәйтүнә...

Әмма сүзен тәмамлый алмады.

– Кырык өченче елда Курск янындагы сугышта яраланып, госпитальгә эләктем, – дип башлап җибәрде Газинур. Зәйтүнәне очраклы рәвештә шунда күрдем. Ул авыр хәлдә иде. Хәләл җефете Хәлил турында сорадым.

– Хәлилем... Хәлилемне... бәгыремне... коткара... алмадым, – диде ул, күкрәгеннән атылып чыккан тартышулы тавыш белән сулкылдап. Егет читкә борылды. Бер минутка тынлык урнашты.

– Сугыш вакытында алган тирән яралары Зәйтүнәнең гомерен өзде. Госпитальдә ятканда, бу якты дөньядан китәсен, ахрысы, сизенгән: улының ятим каласына бик борчылды. Шул вакытта мин ант иттем Зәйтүнәгә – сабыеңа әти булырмын, дидем. Ә бит Зәйтүнәнең йөрәк тибүе туктарга санаулы минутлар гына калып барган икән... Рәхмәт, дип пышылдады да Зәйтүнә күзен йомды... мәңгегә.

– Зәйтүнәнең авырту-газапларга чумган йөзе соңгы сулышын алганда, бер мизгелгә газаплардан арынып, агарып, яктырып киткәндәй булды. Аны югалтуыма ышанмадым. Өнсез, катып калдым. Вакытны да, киңлекне дә югалткан сыман булдым. Белмим, никадәр утырганмындыр Зәйтүнә янында, әмма шунысы истә калган: шәфкать туташы миңа нәрсәдер әйтә, җилкәмә төртә, мин берни дә ишетмим, берни дә тоймас булдым, сөйгәнемнең кулын кысып тотам. Кинәт кенә кемдер көч белән минем беләктән тартты, Зәйтүнәнең кулы ычкынып китте һәм, җиңел мамык сыман, ак түшәккә төште. Калганын хәтерләмим дә бугай...

– Мин дә вәгъдә бирдем, – диде Нәрхәят, мөлдерәмә яшь белән тулган күзләрен уйнап йөргән нарасыйга төбәп.

– Бу дөньяда без кечкенә Илдарга ышанычлы терәк тә, таяныч та булырга тиеш.

Кыз берни дәшмәде. Тик, шатлана-шатлана йөгереп йөргән Илдарны үз янына чакырып:

– Улым, кил монда. Ачыккансыңдыр. Үз кулымнан ашатырмын, бәгърем, – диде, сабыйның битләреннән үбеп. – Әйдәгез, Газинур, өйгә керик, – дип, егетне дә чакырды.

– Нәрхәят, ашыкма әле... – дип, егет кызны беләгеннән тотты.

– Зәйтүнә... Ул икенчене яратты...

– Беләм, сезгә авыр булган.

– Авыр?! Беләсең?!

Тавышыннан салкынлык катыш ачы әрнү бәрелде.

Кинәт егетнең йөзе агарды, төсе китте. Ә күзләр... Ничек үзгәрде! Бер мизгелдә алар куырылып төште һәм сүнеп калды. Кичергән газап күзләрдә яңадан калыкты. Алардагы чиксез газап, галәмдәй чиксез булып тоелды кызга.

Нәрхәят сискәнеп китте. Сизмәстән, артка чигенде. Учлары белән битен япты.

– Яраланган җанвар идем. Тәмугка эләккәндәй булдым...

– Гафу итегез, – дип пышылдады кыз.

– Юк, кирәкми. Гафу үтенмә. Сине куркыттым. Түздем. Актык чиккә кадәр... – диде Газинур. – Әмма Зәйтүнә килде. Ул көнне ап-ачык хәтерлим. Сөйгәнемнең әйткән сүзләре

бик нык тәэсир итте. Ул сөйләшү тормышымда яңа борылыш ясады. Сөйгәнеңне газапка салып, күз яшьләрен күрү бар нәрсәдән дә авыр икән. Дөрләп янган янартау чыдый алмый атылгандай, ә аннан, суынып, тынып калгандай, минем мәхәббәтем дә үзгәрде: куырып алырдай ут урынына талгын җылылык килде, шашып янган ялкынлы дәртне әкрен искән моң алмаштырды. Мәхәббәтем сүрелмәде, бары тик сөйгәнемә бәхет теләп яшәдем. Сәер, тик бу җавапсыз мәхәббәт миңа көч бирде, – дип сөйләде Газинур.

Егет көрсенеп куйды:

– Күптән, бик күптән, балачакта, төшләремә, хыялларыма серле сылу кыз кереп йөрәгемне борчыды. Сылу кызның йөзен һәрвакыттагыча, үтә күренмәле өрфия пәрәнҗәдәй, сихри томан каплаган. Әмма томан аша да кызның матурлыгын күңелем белән тойдым. Аннан сине очраттым. Ул очрашу, төшемдәге төсле, томанда иде. Сине очратканнан бирле, өрфия сылу күренеш янә барлыкка килде дә минем башымнан чыгарга теләмәде. Төшләремә кереп йөдәтте. Йөдәтте дә татлы балдай исертте. Хәзер инде томан төште һәм синең йөзең балкып чыкты. Синең йөзең, Нәрхәят... – Егетнең күзләреннән, тавышыннан, бар җаныннан чиксез моң белән бергә җылылык агылды. – Вакыт һәм аралар аша сине эзләдем. Сине таптым, Нәрхәят. Кулга-кул тотышып, бергә яңа тормыш башлыйк. Сез ризамы? – дип, кыздан җавап алырга ашкынды.

Өй каршында үскән шомыртның хуш исе тәрәзәдән, башны әйләндерә кебек. Нәрхәят сизмәстән агачка күз салды.

41 нче елның үзәккә үткән салкын кышында тамырлары өшегән агач бит бу. Нәрхәят урман кисәргә киткәндә, алтынсу сары яфракларын коеп, Нәрхәятне озатып калган иде түгелме? 43 нче елның язында Нәрхәят туган өенә кайткач, шомырт агачын ул бөтенләй танымады: кибеп беткән тигезсез кәкре «кулларын» һәм бармакларын тупас итеп тирә-юньгә сузган, ямьсез шәрә ботакларын җәеп утырган шомырт башка агачлар янында үзенең шыксызлыгы белән йөрәкне телгәли торган бер гарип сыман иде. Караңгы чырай белән каршылады кызны шомырт. Нәрхәят агачны кызганды. Юк! Кызганды гына түгел, ә күңелгә ятышсыз шушы кыяфәтендә дә Нәрхәят агачны йөрәге аша тойды, аның белән сөйләште. Кисәргә дә уйлады, әммә никтер бу эшкә кулы бармады.

Ә хәзер... Шомырт чәчәк аткан, һәр тәлгәше дә күпереп ачылган, хәтта яфракларын да ошбу нурлы аклык каплаган; гүзәл энҗе таҗларын сусылланып тәлгәш-тәлгәш аска игән. Киң чатырдай җәелеп яткан зөмрәд яшеллек эчендә изрәп, акрын гына тирбәлеп утыра. Иртәнге кояш нурларында ачык төстәге якты яшеллек елкылдап китә. «Мин сулыйм, мин исән, исән!» ди шомырт, бөтен барлыгы белән.

Кем уйлаган дүрт ел элек үлеп беткән агач яңадан туар дип? Туа. Яңа гомер бирер өчен. Яңадан дөньяның матурлыгын күрер өчен. Әйе, ул рух һәрбер тереклектә, табигать-хәяттә көчледер.

– Нәрхәят, сез ризамы? – дип кабатлады соравын Газинур.

Аның соравында өмет һәм...

Нәрхәятнең уйлары бүленеп калды.

– Риза...

Кечкенә Илдар әнисе янына йөгереп килде.

– Әни, бу нинди сәсәк? – диде ул, нәни кулларын нурлы аклыкка сузып.

– Улым, бу – шомырт чәчәге, – диде Нәрхәят, елмаеп.

Әнисенең елмаюыннан шомырт чәчәгенең илаһи нуры сабыйга бөркелде.

...Өмет һәм... Әйе, шомырт чәчәге иде.



Сулдан уңга: язучы Самат Шакир (1927-1998) Советлар Союзы Герое, Брест крепостен саклауда батырлык күрсәткән, легендар якташыбыз Пётр Гаврилов (1900-1979) белән.



Шагыйрь Сирин (Сирин Батыршин), (1896-1969). Фоторәсемдә сулда – 30 нчы елларны репрессиягә дучар ителгән язучыларның берсе. Аның турындагы тулырак мәгълүматны авылдашы, галим Әнвәр Шәрипов хезмәтләреннән белергә була.



Очучы Рәшит Ибраһимов (1927) самолёт белән Чистайга почта илтә. 80 нче елларда Р.Ибраһимов берничә документаль әсәр, шул исәптән 1941 елда ук Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган очучы Фәрит Фәтхуллинга багышланган документаль повесть иҗат итте, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булды.



*Россиянең Беренче Президенты Борис Ельцин белән очрашу истәлеге. Зал тулы язучылар, журналистлар, җәмәгать эшлеклеләре... Язучыларның Тукай клубы. 1990 ел.*



*«Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы ветераннары. 2000 нче еллар.*



Рәфкать Шаһиев

# АЯК ЯЛЫ

хикәя

Бүгенге эш көне шуның белән төгәлләнер инде, дип, Галия 463 нче скважинага таба атлады. Куе чикләвеклек аша икенче юлга чыгып, тау өстеннән аска карагач, ул чак артына утырмады. Әле кичә генә үләннәрен чабып, чистартып киткән скважина батып барган кояш яктысында күл булып ялтырап ята иде. Галия, арыганлыгын да онытып, таудан түбән, скважинага таба йөгерде. Янтыгына аскан брезент сумкасы, шап-шоп килеп, әле бер яктан, әле икенче яктан балтырын кыйнады.

– Әнекәй генәм, әле кичә генә күкеле сәгать кебек келтерәп эшләп калган идең бит, җаным, – диде ул, һаман саен җәелә барган нефть күлдәвеге янына тезләнеп. Торбаны капшап диярлек, нефть бәреп яткан җирне эзләп тапты да, сумкасын коры җиргә бушатып, кирәкле ачкычларын алды. Азрак үзем кысып карыйм инде башта, булмаса, аннан шылтыратырмын промыселга, дип, бер генә борырга өлгерде, сальник бөтенләй чатнап, нефть фонтаны Галияне башыннан ук коендырды. Үрмәләп килеп, линияне яба торган «задвижка»ны бөтен көченә борды. Әле ярый авызын ябып өлгерде. Күзләрен йомган килеш тезләнеп читкә китте дә, кулларын үләнгә ышкып бераз чистарткач, эш киемен салып, битен сөртте. Башындагы яулыгы, рәхмәт яугыры, чәчен саклаган иде. Чистаны-пычракны артык тикшереп торырга вакыт юк. Ул, бөтен әйберен читкә ташлап, оператор алачыгына йөгерде.

Бер чакрым ара аз түгел. Яшьтән үк кышын – чаңгыда, яз-җәен йөгерә-атлый җәяү йөрергә өйрәнгән Галиягә дә вакыты белән авырга туры килә. Ни әйтсәң дә, яше дә бар, ике бала анасы. Шулай да ул йөгерүдән туктамады. Кулча басуы читендәге ялгыз имәнне узса, күп калмый инде. Үзенең карамагындагы егерме алты скважинаны йөреп чыккан көнне шушы унсигез чакрымны тәпиләп үтә. Туган авылы Чупайдагы кебек, күзен бәйләп тә йөри ала монда.

Галияне алачык ишегендә ат башы зурлык йозак каршылады. Башка участокта йөрүче Нәзирә кайтмаган әле. Ашыкканда шулай була бит. Ул, яшергән җиреннән ачкычны алырга дип, нефтьле бармагын таш астына шудырды.

– Чукынчык, ачкычы да кая соң инде аның, ә? – дип кычкырып җибәрде ул. – Шушында гына тыгып калдырдым бит.

Галияне кызганган кебек, якында гына йомран сызгырып куйды.

Ачкычны әләктереп алдым дигәндә генә, тырнак астына ниндидер очлы нәрсә кадалды. Галиянең күзеннән яшь атылып чыкты. Ул, үзе дә сизмәстән, нефтькә баткан бармагын авызына капты, төкереген яулык очына сөртте. Җиргә төкерә белми Галия. Гомумән, Кыямның сигез баласының берсе дә җиргә төкерми. Җиргә төкерү – биткә төкерү ул, дип үстерделәр аларны.

Ишекне ачып керүгә, Галия телефонга ябышты.

– Алю, алю, кайсыгыз анда? Миңа Платонов кирәк иде, – диде, телефон трубкасын ярырдай булып.

– Әйе, тыңлыйм, Галия, синме соң бу? Ни булды? Ник болай кычкырасың? – диде чыбыкның теге башындагы ир, сабырлыгын саклап.

– Евгений Михалыч, 463тә сальник ярылып, нефть бәрде. Мин «задвижка»ны яптым. Тизрәк егетләрне җибәр, – диде Галия, һаман тавышын әкренәйтә алмыйча.

Эш бетеп, вахта машинасына чыгып утырганда, җиргә кичке салкын төшкән. Мукшы чокырыннан чыккан аксыл томан Биектауга таба шуыша иде.

Болай соңга калып кайтулар еш булмаса да, балалар да, ир белән каенана да алай гайре табигый кабул итмиләр. Шунысына да рәхмәт укый Галия. Югыйсә, тырнак астыннан кер эзләүчеләр юк түгел. Аның өстенә, тирә-якта «Галия-будка» дип кушаматка әверелгән оператор алачыгы да бар. Ходайның һәр бирмеш көнендә берьялгызың басу-кырда, урманда йөре син?! Алай дисәң, бөтенләй үк ялгыз дип тә булмый инде. Иртә яздан алып ат тизәге бозланып, таш булып катканчыга кадәр, көтүчесе, җиләк җыючысы, гөмбә эзләүчесе, дисеңме. Кышын – аучылары...

Галиягә аңа нәрсә, чыгып китә дә, кош кебек – үз иркендә, диючеләр аз түгел. Битенә бәреп әйтүчеләр дә табылды. Алай диючеләргә җавабы нык иде, үз-үзеңә хуҗа була белмәсәң, ялгызың кырга чыгу кирәкми. Галия җавап эзләп кесәгә керә торганнардан түгел. Сүз йөртми, кенә кумый. Сабиры белән дә әйбәт яшиләр. Кайберәүләрнең шуңа да эчләре пошадыр. Адәм баласы шундый бит ул. Булмаса – бирә алмый, булса – күрә алмый, дигәндәй, яхшы яшәсәң дә мактамыйлар, начар торсаң да яратмыйлар. Ә Сабир белән алар бик тә пар килгәннәр. Ул гармунын сыздырып җибәрсә, әрәмәдәге кошлар да бер тын туктап тора. Галия җыр башлагач кына, әрәмәгә җан керә торган иде яшьрәк чакта.

***

– Әллә туктыйсыңмы бу эшеңнән. Аяксыз каласың бит, – диде ире, иртән вахтага чыгарга җыенганда.

– Юк, – дип кырт кисте Галия. – Аңлыйм мин сине, ләкин авылда да эш операторныкыннан җиңел түгел. Ел әйләнәсе, бер ял күрмичә, сыер тизәге иснәп, тиенгә эшлиләр бит. Монда хет акчасы, ял көне бар. Җиләк дисәң җиләге, гөмбә вакытында анысы да кайта сумкада.

Белә, бик белә Сабир ул брезент букчада нәрсәләр барын. Җиләк, җимеш, гөмбә… Берсе-берсе ярты килога тарта торган ачкычлар, запас сальниклар, скважина буявы, кыш булса, шешә белән солярка... һәм май, нефть исе сеңеп беткән ипи кыерчыгы белән шешәле сөт анда!

– Теләсәң нишлә инде алайса...

Сабир, яратып, хатынына текәлде. Яратырлык шул. Яратмаса, урлап кайтыр идеме?!

– Әнә, әллә кичәгесе кипмәгән, әллә былтыргысы бетмәгән. Колак артыңда буе белән «кара алтын»ың сызылган, – дип, хатынының колак артына кытыршы кулын тидереп алды.

Оператор хезмәтенең «рәхәтлеген» Галия үзе генә белә инде: кышкы суыкларда туңган бармакларын алмаш-тилмәш авызына кабып җылыта; көне буе аягөсте йөреп шешенгән аягыннан итеген сала алмый; салкын алачык идәнендә елап утырган чаклары аз булмый. Алай дисәң, урман буйларының иркенлеге, матурлыгы берни белән алыштыргысыз. Адәм баласы гомер буе иреккә омтылып яшәгән бит. Биектауга менеп, бөтен барлыгыңны җилләр иркенә куеп, дөньяны яңгыратып бер җырлап җибәрүең генә дә ни тора?!

***

Галиянең эш урыны «Елховнефть» идарәсенең икенче промыселына карый. Иртән конторада заявкалар калдырып, складтан буяулар, майлар алгач, эшчеләр, шаярыша-көлешә, вахта автобусына чыгып утырдылар.

– Кем бу кадәр буяу төяде инде? Әллә сез мине грузовой машина йөртә дип беләсезме?! Заявка язгыз да, китерсеннәр, – дип, автобус шофёры Рәис, канәгатьсезлек белдереп, пассажир ягының ишеген ачып карады да шартлатып ябып куйды. – Йөриләр алайса, кунакка барган кебек кенә.

– Ачуланганда, бигрәк матур инде син, Рәис. Каршыга бастырып, гел ачуландырып торырсың үзеңне, – дип елмайды Нәзирә.

Галия исә сумкасындагы кәгазь төргәктән лимон, тәмле эшләпә конфет алып шофёрга сузды.

– Мәле, мондый тәмле конфетны безнең Чупай кызлары гына әзерли.

Чыннан да, тирә-як авылларда үзенең хуш исле ипи-күмәчләре белән дан казанган Чупай пекарнясында эшләпә конфет бик тәмле чыга иде.

– Синең буяулар икәнен белдем инде, Галия апа. Синнән башка кем, автобус белән буяу ташып, скважина буяп йөрсен? – дип, күзен юлдан алмый гына каерылып, кулын конфетка сузды.

Артта кәрт сугып баручы ирләр дәррәү көлешеп алдылар.

– Хатын-кыз эт белән бер инде. Ничек итсә итә, эшләпә конфет белән булса да авызыңныябыштырып куя, – дип, Салих шап итеп Рәшитнең иңенә погон куйды да, «кәҗә» дип, бөтен автобусны яңгыратып кычкырып җибәрде.

Автобус асфальт юлдан Тукмакка таба җилдерә. Җәйге җылы җил, ачык тәрәздән үрелеп, пәрдәләрне тарткалый иде.

Галия белән Нәзирә, складтан төягән «бирнәләр»ен алачыклары янына бушаткач, Рәис өч тапкыр сигналга басып алды да, асфальтка чыгып, юлын дәвам итте.

– Әйдә, боларны кертеп куйыйк та, бер урап кайткач, чәйләп алырбыз. Болай да складларда йөреп шактый вакыт узды, – диде Нәзирә, алачык ишеген ачып.

– Слушаюсь, – диде Галия, уң кулын чигәсенә терәп. Аннан кыланмышыннан үзе дә көлеп җибәрде. Сумкасын баш аркылы әйләндереп иңенә асты да, кулына сынган көрәк сабын тотып, Кузьминовка тугаендагы 519 нчы скважинага табан китте.

Җил белән серләшкән каеннар,
Кузгата яшьлегем хисләрен.
Шомыртлар ак шәлен ябынгач,
Сагынам яшьлегем кичләрен.
Сагынам, өзелеп сагынам,
Сагынам…

Галиянең күкрәгеннән чыккан куе бәрхет тавышы тугай өстенә таралды:

«Сагынам… Сагынам… Сагынам…» Моң тауларга бәрелеп яңгырады да тау итәге буйлап сибелгән чишмәләрнең саф суына кушылып агып китте. И Аллам, кеше, бәхет эзләп, үзбәк, таҗик иленә китә, чирәм җир күтәрәм, дип, казакъ даласына кузгала. Үзебездә бит югыйсә урманы дисәң, өстеңә авардай булып, авылга терәлеп тора. Чишмәсе дисәң – бөтенесен изге су итеп эчәрлек. Әнә, Чупай ташыннан да кала корып куйдылар. Бу рәхәтне ташлап, тагын кайдан гына бәхет эзләп йөрергә кирәк инде?! Шушы егерме алты скважинаның әйләнә-тирәсеннән генә дә бит Ходай биргән гомереңә җитәрлек дәва табасың. Биектау битендә мәмрәп пешкән бер уч җиләге генә дә ни тора!..

Уйларына чумып бара торгач, килеп җиткәнен сизми дә калды Галия. Мондагы һәр сукмакны, һәр куакны үзенең биш бармагы кебек белә ул.

Кичә генә подземниклар эшләп киткән иде. Ай мыскыл да иткәннәр инде. Каймак итеп, ипигә ягып ашарлык май, җәелеп, бөтен тирә-якны каплаган. Әле яз көне генә көмеш кершәне белән сиптереп буялган скважина иңнәренә кара көянтә аскан негр кызыдай селкенеп утыра. Хәтта кызыл буяу белән язган 519 санының да эзе күренми. Бер генә чиста җире дә калмаган иде скважинаның. Үз пычракларын үзләре чистартып китәргә тиешләр, югыйсә. Анысы аларның да эше бит... Эшне белеп эшләмәгәч, әләкләп йөреп кенә булмый.

Тагын ялына-ялвара, елата-елата, ППУ* сорарга кала икән дип уйлады ул. Шуны уйлауга, Галиянең беләкләре генә түгел, эч мускулларына тиклем тартышып куйды. Көч белән бәреп торган су шлангасы вакыты белән үзеңне сугып егардай була. Ярар, беренче генә эшләгән эше түгел, дип, скважинаны тагын бер әйләнергә уйлаган иде, Галиянең үзеннән егерме метрлар читтә, үлән арасында посып утырган, кишер төсле сары мәчегә күзе төште. Монда кадәр китереп адаштырмасалар, авылда сыер фермасы беткәндер?! Шәһәр кешесенең эшедер инде, дип, үз-үзенә сөйләнде. Әле ачуы басылмаган иде.

Ике-өч адым атлауга, Галия тагын теге песигә карыйсы итте. Колак очларындагы чуклары каралып торган сары песи, тычкан ауларга әзерләнгән кебек, нәрсәгәдер ташланырга әзерләнгәндәй иде. Галиянең карашын сизде бугай, песи дә башын аңа таба борды һәм телен чыгарып ялманып алды. Карашы үтәли тишәрдәй тәмам. Тик аны башка нәрсә ныграк кызыксындырды кебек, Галиягә артык исе китмәде. Галия дә, шундый матур песине адаштыручыларга ачуы килеп, алдагы скважинага таба атлады.

Кинәт шартлап корыган ботак сынганы ишетелде. Галия, сискәнеп, артына борылды. Тирә-якта ул-бу күренми, тыныч иде. Ул, кулындагы көрәк сабын селки-селки, юлын дәвам итте. Кояш төшлеккә җитеп килә. Җилкә чокырларыннан тир ага. Галия эш киемен салып, сумка бавына кыстырды. 722гә барып килим дә аннан төшкелеккә алачыкка кайтырга булыр, дип уйлады ул. «Галия-будка», диләр икән, исемен акларга инде.

Яшьлегем, дип, йөгереп кайтыр идем,
Йөгереп кайта то-о-орган юл бу-у-улса...

Галия, тавышын әкренәйтеп, кинәт кенә артына борылды. Тугай борылышындагы таллар арасына бер шәүлә кереп югалган кебек тоелды. Хатын, йөгерә-атлый, басу уртасында гыжлап эшләп торган скважина янына ашыкты. Курыкмыйм, дисә дә, эченә шик кергән иде аның. Карыйсын карап, майлыйсын майлап чыкты да юри:

* ППУ – пар белән юдыру җайланмасы.

– Нәзирә апа, Мироныч ППУ җибәрәм дигән иде. Урман сыеры урынына һаман юкны эзләнеп йөрмә, киттек, – дип кычкырды.

«Галия-будка»га ул бик тиз кайтып җитте. Ни чыбык-чабык сынганын ишетмәде, ни бер шәүлә искәрмәде. Бар да тыныч, бар да гадәттәгечә. Тау битендәге кояш җылысына чыгып тезелгән таза-таза суырлар сызгыруыннан һәм бытбылдык тавышыннан гайре нәрсә ишетмәде.

Үләннәр салып әзерләгән чәе пешеп чыгуга, Нәзирә дә кайтып керде.

– Эт булдым, малай. Койрык кына тагасы калды, – дип, өсләрен дә салып тормыйча, агач сәкегә ауды ул.

Өйләреннән алып килгәннәрен ашап, чәйләр эчеп, бераз хәл алгач, майларын, буяуларын, кирәкле инструментларын асып, тагын икесе ике якка чыгып киттеләр.

Соңгы скважинадан әйләнеп кайтканда, вахта автобусы «Галия-будка»га терәлеп үк килеп туктаган иде инде.

– Кунаклар күптән көтә, ә хуҗабикә урман буенда гулять итеп йөри. Үзе «Галия-будка», ә эчендә – Нәзирә. Бу нинди хәл инде?! – диде Әнвәр, чирәмгә кырын яткан килеш.

– Нәрсә һаман су буе сузылып йөрисең? Скважинаңа бал сөрткәннәрме әллә? Әзрәк сәгатеңә карарга кирәк. Кайчаннан бирле сине көтеп торабыз, – дип, Миша, мырлый-мырлый, автобуска кереп утырды.

– Извини, фәрештә, эчелгән дә үленгән. Уйнап йөреп, онытылып киткәнмен. Хәзер, өч секунд.

Галия, өсләрен алыштырып, автобуска чыгып утырганда, ирләр артта кәрт сугарга керешкәннәр иде инде.

– Егетләр, берәрегезгә песи кирәкмиме? Кайсысыдыр адаштырып калдырган, күрәсең. Ма-а-тур инде. Кишер төсендә. Колак очлары каралып, пумала чугы кебек тора, – дип, Галия ирләр ягына карады.

Ирләр, кәрт сугуларыннан туктап, бер-берсенә карашып алдылар.

– Тиле, бу бит селәүсен, Галия. Рысь! Нинди песи йөрсен ди урман эчендә, – дип кычкырып җибәрде Әнвәр. Болай да зур күзләре гаҗәпләнүдән маңгаена менгән иде.

– Юк инде, минем бит кыш көне күргәнем бар селәүсенне. Ул соры төстә була, кишер кебек түгел, – диде Галия һәм ирләр ягына борылып утырды.

– Соң, кышын куян да төсен алыштыра бит, Галия апа. Әллә мәктәптә дә укымыйча эшләп кенә йөрдеңме син? – дип авызын ерды Рәис.

– Шулай шул. Тегесенең дә колак очларында чугы бар иде шул, – дип, үзалдына сөйләнгәндәй, Галия яңадан алга борылды. Ул көндез күргәннәрен башыннан яңадан уздырды. Колагына шарт итеп корыган агач сынганы ишетелгәндәй булды. Галия дерт итеп китте.

Берәр атна үткән булгандыр инде бу вакыйгага. Кура җиләге өлгергән чак. Алдагы көнне генә ППУ килеп, унбер скважинаны юдырган иде. Көч белән су бәргән шлангны тотып торып куллары калмады Галиянең. Нихәл итмәк кирәк, сарымы, карамы – алтын табу җиңел түгел инде. Һәр сырхауга дәва табигатьтә. Ул да, иртән алачыгын ачып кереп, эш киемнәрен киеп алуга, аруын да, чирен дә онытып җибәрә. Кояш җылысы белән кушылган үлән исе, тау битендәге суыр, йомран сызгырулары, кош тавышлары Галия җанына сары май булып ята. Әллә... кара май булыпмы?! Авария көннәрендә баштанаяк нефтькә батып кайтканда, аны солярка белән ышкый-ышкый җан тирең чыкканда ачуы килсә дә, ярата ул шушы кара майны. Авыл каймагыдай куесын кайвакыт Чупай ипиенә ягып кабып карыйсы да килә әле...

Кичә юган скважиналарны бүген көмеш кершән белән буяп, өр-яңадан номерлар язып чыгарга кирәк иде. Галия, кыяга менәргә әзерләнгән альпинист кебек, кирәк-яракларын җыеп аркасына асты да скважиналарына китте.

Алга таба асып йөрергә җиңелрәк булыр, дип, беренче скважинадан тотынды. Олифа агызып, буяуны сыеклады да, савытны биленә бәйләп, циркта эшләүче кызлар кебек, югары үрмәләде. Бусы бик пычранмаган, өлешчә генә буярга кирәк иде. Шуңа да артык озакка сузылмады. Бер уңайдан, эше бетсен, дип, кызыл буяу белән «648» дип номерны язды һәм скважинаны әйләндереп алган рәшәткәләрне кершән белән яңадан буярга кереште.

Әллә кояштан, әллә буяу исеннән башы авырта башлады Галиянең. Пумалаларын, савытларын җыеп сумкасына салды да трассага таба атлады. Өченче көн, узганда, берән-сәрән генә пешә башлаган кура җиләкләрен капкалап киткән иде. Пешкәннәрдер инде. Арттан кумыйлар, азрак җиләк капкалап алсам да, гөнаһ булмас, дип уйлады ул.

Ялгышмаган Галия. Җиләкне берәмләп түгел, сыдырып кына алырлык иде. Ул бер җиләкне тел өстенә салды да аңкавына кысып сытты. Әчкелтем баллы җиләк суыннан авыз эчләре рәхәтләнеп китте. Җиләк салкынлыгы бөтен күзәнәкләренә таралды. Галия күзләрен йомды.

– Ы-хы-ха... Тәмлеме? – дигән тавышка чәрелдәп кычкырып җибәрде. Аның каршысында киң җилкәле, ияк-яңакларын кызгылт сары төк баскан, чәчен кыска гына калдырып кистергән, үзеннән шактый яшь ир басып тора иде.

– Кагыласы булма, күзеңне сытып чыгарам, – дип әйтеп тә бетерә алмады Галия, теге ир аламасы беләгеннән эләктереп тә алды.

– Кычкырма. Мин сине ай буе күзәтеп йөрим инде. Җае гына чыкмады. А-ха-ха!!! Ә син шә-ә-п!

Ир бер кулын Галиянең биленә куйды, икенче кулында пәкегә охшаш нәрсә ялтырап китте.

– Мин бит монда үзем генә түгел. Подземниклар теге скважинада гына кайнашалар, – дигән булды Галия. – Әнә, күрәсеңме?

Шулай диюгә, ир скважина ягына карады. Ул арада Галия, яшен тизлеге белән, сумка кырына аскан көмеш кершәнен ирнең битенә алып бәрде һәм, бар көченә: «Сабир! Сабир!» – дип кычкырып, олы юлга таба йөгерде. Юл читенә чыгып җиткәндә, йөрәге, очып китәргә талпынган күбәләк кебек, калтыранып тора иде. Кинәт аякларының да хәле китеп, Галия юл тузанына тезләнде. Юк, йөрәге генә түгел, аның бөтен тәне калтырый иде. Теле дә әйләнмәслек булып, авызы кипте. Кая ул бая капкан җиләкнең тәме?!

Галия ни елый алмады, ни көләргә көче җитмәде. Шулай күпме утыргандыр, янәшәдә генә йомран сызгыруы айнытып җибәрде. Алачыгына кайтырга дип, юлны аркылы чыкты да юкә белән каен парлап үскән басу юлына борылды. Ул әле һаман аңына килә алмый, ябалак кебек як-ягына каранып бара иде. Күзе үлән арасында кайнашкан козгыннарга төште. Теге көнне күргән селәүсеннән, тырнакларын тырпайткан дүрт тәпи генә торып калган иде.

– Ялгышканнар, – диде Галия, селәүсенне кызганып. – Ике аяклысын атасылары калган.

# ТУПЛАР ГӨРСЕЛДӘГӘНДӘ ТУГАН ШИГЫРЬЛӘР

## МӘХМҮТ ХӨСӘЕННЕҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Булачак шагыйрь Мәхмүт Хөсәенгә унсигез яшь тулган җәйдә Бөек Ватан сугышы башлана. (Ул 1923 елның 15 апрелендә туган.) Урта мәктәпне тәмамлау таныклыгын алган көндә үк ул Пертропавел шәһәре (Казакъстан) военкоматына килә. «Мине фронтка җибәрегез», дип гариза бирә. Мәктәптә «яхшы» билгеләренә генә укыганлыгын һәм таләп ителгән нормадан кечерәк буйлы булганлыгын истә тотып, Мәхмүтне Андижан шәһәрендәге артиллерия училищесына укырга җибәрәләр. «Военком Потапенконың «кушай и спортом занимайся», дигән сүзләрен әле дә онытмыйм», – дип еш искә алгалар иде Мәхмүт ага. Атасыз, мохтаҗлыкта үскән бу ятим бала, чынлап та, әлеге уку йортын тәмамлаганда, буй-сынын шактый ныгытып өлгерә. «Тәртипле ашау, ял сәгатьләрендә турник белән штанга тирәләрендә кайнашуым зыянга булмады. Фронтка киткәндә, инде мин беркемнән дә калышмый идем», – дип сөйли иде ул.

1942 ел тәмамланып килгәндә, алар эшелоны Ленинград тарафына юнәлә. Яшь белгечләрне атаклы шәһәрне дошман чолганышыннан азат итәргә әзерләнгән төрле полкларга билгелиләр. Мәхмүт сугышның иң кайнар ноктасына эләгә. Тупчы взвод командиры буларак, аңа көнне төнгә ялгаган гарасат эчендә өч ай чамасы бәргәләнергә туры килә. «Командование исеменнән беренче рәхмәт сүзләрен ишетү дә, җиңелчә ярлануым да шул тәүге бәрелеш көннәрендә булды», – дип сөйләгән иде ул миңа. Әтиемнең дә нәкъ шул айларда, шул фронтта тупчы солдат буларак катнашуы, берничә мәртәбә яраланып, Ленинград госпитальләрендә ятканлыгы Мәхмүт ага белән безнең араны тагын да якынайта төшә иде. «Кыш айларында без блокаданы өзә алмаган идек. Мин, терелеп, частька кайтканда, җәйге һөҗүмгә хәзерлек башланды», – дип, әңгәмәне дәвам итте Мәхмүт ага. (Шул җәйге һөҗүм барышында безнең атабыз Хәйдәр һәлак була да инде.) Ленинград һәм Волхов фронтлары ике яктан бергә һөҗүм иткәч, дошман чолганышы өзелә. Ленинград халкы ач үлемнән котыла. Ә егерме яшьлек тупчы лейтенант янә госпитальгә эләгә. «Ул вакытта миңа анда озаграк ятарга туры килде. Уң аягым җитди генә яраланган иде. Ул ярам хәзер дә әле вакыт-вакыт үзен искә төшергәли», – дияр иде ул. Савыгып чыккач та, аның күкрәгенә беренче орден тагыла. Шуннан соң ул дүрт туп – дүрт сугышчан взвод һәм штаб хуҗалыгын берләштергән батарея командиры итеп билгеләнә. Йөз иллеләп сугышчының «батя»сына әверелә. Ул вакытта әле аңа егерме ике яшь тә тулмаган була. Сугыш тәмамланганда, аның күкрәген Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, 1нче дәрәҗәле Ватан сугышы орденнары һәм берничә медаль бизи.

Шул ук елларда Мәхмүт Хөсәеннең сугыш көндәлекләрен чагылдырган, туган илгә багышланган шигырьләре татарча нәшер ителүче «Ватанны саклау» исемле фронт газетасында басыла. Туплар гөрселдәве тынып торган араларда яки госпитальләрдә дәваланганда иҗат ителгән ул шигырьләрнең бер өлеше соңрак Ленинградта аерым җыентыкка тупланып та чыгалар («Туган ил өчен» китабы, 1945 ел). Ул елларда армия, фронт газеталарында әсәрләрен бастыручы әдипләребез күп булса да, солдат биштәренә үз китабын салып кайтучылар булмаган.

М.Хөсәен армия хезмәтеннән 1947 елның җәендә азат ителә. Шул дәвердә Себер тарафындагы Петропавел каласында гомер итүче анасы һәм сеңелләре янына кай-

тышлый, ул Казанда туктала. Язучылар оешмасына килә. Мәктәптә укыган елларында ук шушы оешма адресына атап шигырьләр җибәргәләгәнен сөйли. Бер мәртәбә Муса Җәлилдән аңа хуплау хаты килгәнлеген әйтә. Ленинградта басылып чыккан китабын күрсәтә. Шул чакта аңа берничә язучы «иҗатыңны дәвам ит, университетка укырга кер», дип киңәш бирә. Һәм ул, өлкән каләмдәшләре сүзен үтәп, бераздан янә Казанга килә. Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Резеда Вәлиева һ.б. белән бер үк елларда университетта укый. Уку елларында (1947-1952) аның тагын бер шигырь җыентыгы басылып чыга – «Сүнмәс яшьлек» (1948). Ә инде берничә елдан соң тагын да күләмлерәк – «Идел таңнары» (1954) китабы дөнья күрә. Университет буенча сабакташ булган,иң өлгере саналган Гариф Ахуновның «Яшьлек яме» повесте исә тагын ике елдан соң гына нәшер ителәчәк.



*Уңнан сулга: Мәхмүт Хөсәен, Язучылар берлеге хезмәткәре Дания Хәмидуллина, «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары, язучы Ринат Мөхәммәдиев. 1983 ел, 6 май. Фото Л.Хәмидуллин архивыннан.*

Мәхмүт аганың 1954 елда дөнья күргән шигырьләр, җырлар һәм поэмалар җыентыгы аңа киләчәктә зур шатлыклар белән бергә байтак кына әрнүләр дә алып килә. Өченче китап авторы буларак, аны, озакламыйча, СССР Язучылар берлеге әгъзалыгына кандидат итеп кабул итәләр. (1958 елга чаклы язучыларны ике этапка бүлеп кабул итү тәртибе яши.) Әмма кайбер көндәш каләмдәшләренең аяк чалулары нәтиҗәсендә, аның кандидатлык срогы, гадәти өч-дүрт ел белән генә төгәлләнмичә, 1973 елгача сузыла. «Дөрес, андый гамәлнең килеп чыгуында үземнең дә бераз гаебем бар. Фронтовик буларак, якыннан аралашкан бер шагыйрь белән бервакыт бик ачуланышкан идек без. Ачуланышуыбыз гаилә мәсьәләсенә кагылышлы иде. Ә ул аны, иҗатыма бәйләп, гауганы зургарак җибәрде», – дип сөйләгән иде Мәхмүт абый. Аның сиксән яшьлеген билгеләп үткән көннәрдә бастырган искә алу мәкаләсен дә шагыйрь Әхмәт Рәшит, бик хаклы рәвештә, «Йөрәге яралы килеш китте», дип атаган иде. Андый йөрәк ярасы гомерлеккә сузылучан шул.

Әлбәттә, ул вакыйга гына М.Хөсәен иҗатына киртә куя алмады. Аның китаплары ике-өч ел саен нәшер ителә, җырлары радиодан да, сәхнә түрләреннән дә халыкка җиткерелә тордылар. Аның китапларының берничәсенә кереш сүз язучы, каләмдәше әсәрләрен хуплап халыкка тәкъдим итүче икенче фронтовик шагыйрь Сибгат ага Хәким булганлыгын да әйтү кирәктер. Танылган композитор, Татарстанның халык артисты Җәүдәт Фәйзи дә «Канатлы җырлар» мәкаләсендә (1973) М.Хөсәенне халык күңеленә ошардай җыр сүзләрен оста иҗат итүче буларак югары бәяли. Һәм автор бу шагыйрьнең сугыштан кайтканда ук композиторлар белән аралаша башлавын да билгеләп үтә. «Узып барышлый гына Казанга килеп чыккан майор Мәхмүт Хөсәенев композитор Заһит Хәбибуллинга үзенең «Шинель» исемле шигырен калдырып китте. Озакламыйча ул җыр булып радио аша да, концерт залларыннан да еш яңгырады. Аннары Мәхмүт, шинелен салып, укырга керде, Казан университетын тәмамлады. Шагыйрьнең төрле темаларга язган җырлары бер-бер артлы музыка авазлары аша халык күңеленә барып җитте. Аның исеменә бәйле җиде дистә чамасы җыр бар... «Мәхмүт Хөсәен – безнең җыр хәзинәбезгә зур өлеш керткән шагыйрь, – дип яза мәшһүр композиторыбыз. – Аның «Идел дулкыннары», «Яңа Казан», «Өммегөлсем», «Яшәсен кияүләрем», «Ак дулкыннар» һ.б. җырлары халыкка

күптән таныш һәм популяр. М.Хөсәен балаларның да якын дусты. Алар өчен дә күп кенә җыр язды». Шушы сүзләргә өстәп, шагыйрьнең иҗатташлары булган кайбер композиторлар исемен дә атап үтик. Күренекле музыкант һәм композитор Фәйзулла Туишевның студент Мәхмүт сүзләренә нигезләнеп иҗат иткән «Дустыма» җырыннан башлыйк (1950 еллар). Еш җырлана торган җырлар авторлары исәбендә исә Заһид Хәбибуллин («Яшьлек вальсы», «Яшәсен кияүләрем»), Рөстәм Яхин («Бик сагындым», «Толымнарың»), Александр Ключарёв («Идел дулкыннары», «Яңа Казан»), Сара Садыйкова («Әнием миләше»), Әнвәр Бакиров («Сәйдәш моңнары»), Ренат Еникиев («Казан – гомерем бишеге»), Алмаз Монасыйпов («Зөһрә», «Бишек җыры»), Фасил Әхмәтов («Хуш киләсез») һ.б. бар.

Мәхмүт ага Хөсәеннең әдәбиятны сөюче тамашачылар белән аралашуга җитди әһәмият биргәнлеген аерым әйтеп китү тиештер. Республика күләмендә һәм аннан читтә оештырылган әдәби кичәләргә Мәхмүт ага бик еш чакырыла иде. Шундый очрашуларда еш катнашкан шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов аны «сәхнәдә ул чын халык артисты иде», дип искә ала. Һәм чираттагы Җинү көненә багышланган бер очрашудан бик гыйбрәтле мисаллар китерә. «Үзенең бер-ике шигырен артистларча осталык белән тамашачыга җиткергәннән соң, Мәхмүт ага яу кырында ятып калган каләмдәшләре Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Хәйретдин Мөҗәй шигырьләрен дә яттан сөйләде. Соңыннан Гадел Кутуйның күләмле «Сагыну» нәсерен яттан укыды. Аның «Сагындым! Бик сагындым сине, туган ил!» – дип кабатлаган сүзләреннән соң хатын-кызларның күз төпләрендә яшь бөртекләре күренде», дип искә ала Мөдәррис остаз шагыйренә багышланган мәкаләсендә.

Миңа да Мәхмүт ага белән берничә очрашуда бергә булырга туры килгәләде. Әйтик, аның алтмыш яше туларга бер ай чамасы калган көннәрдә без Саба районы авылларында һәм Сабаның үзендә булдык. Гадәттәгечә, көндез мәктәпләрдә, кичләрен авыл клубларында тамашачы белән очраша идек. Арабызда ике шагыйрь – Мәхмүт Хөсәен белән Рәшит Гәрәй иде. (Икесе дә күптән мәрхүм инде, урыннары җәннәттә булсын.) Әлбәттә, кичен дә, көндез дә тамашачыларның дәррәү килеп алкышлаулары алтмыш яшен тутырып килүче, йомры гәүдәле Мәхмүт ага өлешенә туры килгәндер. Балаларга багышланган атаклы «Чебиләрем» шигырен башкарганда инде ул, сәхнәдә чүгәләп йөреп, чеби рәвешенә дә керә, аяк очларына басып, кулларын югары күтәреп, әтәч булып та бик оста кылана ала иде.

Ә бервакыт безгә аның белән бергә Киев шәһәре янәшәсендәге Ирпен шәһәрчегендә – Украина язучыларының иҗат йортында булырга туры килде. Ирпен – шундый ук атамага ия елга буенда, зур кара урман читендә урнашкан курорт шәһәр. Шушы иҗат йортыннан кала анда берничә санаторий да бар иде. Ял көннәребез сентябрь ахыры белән октябрь ае башларына туры килде. Әмма көннәр бик җылы тора, Мәхмүт ага белән без һәр иртәдә диярлек Ирпенгә су коенырга йөри идек. Иҗат йорты идарәсендә Чистай ягы кешесе туры килү сәбәпле, безне бик җайлы бүлмәләргә урнаштырганнар иде. Кичләрен иркен фойега җыелып, Украинаның күренекле генә шәхесләре белән гәпләшеп тә утыргалыйбыз, шахмат тактасы тирәсендә дә көрәшкәлибез. Безнең белән бер вакытта анда Украина Язучылар берлеге секретаре Леонид Новиченко булды. Мәхмүт ага белән ике арадагы янәшә бүлмәләрдә исә сөйләшеп утырырга яратучан ике шәхес – Довженко исемендәге киностудиянең баш редакторы, язучы Василий Земляк белән кинорежиссёр Владимир Денисенко иде. Денисенко А.П.Довженконың яраткан шәкертләреннән берсе булган. Без очрашкан көздә аның берничә киносы (мәсәлән, «Роман и Франческо») СССР күләмендә бара иде. Без Ирпендә бергә булганда, алар Киев шәһәренең мең дә ничәдер йөз еллыгына багышланган киносценарийны яңадан эшләп утырдылар. Кинолентага алар Киевка бәйле тарихи шәхес рәвешендә Батый ханны да кертмәкче булганнар. Тарихи язмаларда, шул исәптән Украина тарихчысы Михайло Грушевский хезмәтләрендә теркәлгәнчә, 1240 елның кышын Батый хан үз кешеләре белән Киевта уздырган икән. Вакыт-вакыт ул үз төркеме белән атаклы София соборына килә һәм анда барган дини манзараны күзәтеп утыруны ярата торган булган. Бу соборда ул заманда христиан дине чаралары төрки телдә дә уздырылган. Шул хакта архив язмалары саклanган, дип, берничә мәртәбә әйтте безгә Василий Земляк.

Ул үзенең ерак бабаларының да кыпчаклар булганлыгын кат-кат сөйләде. «Минем бабамнар яшәгән Полтава өлкәсендә 1926 елгы халык санын исәпкә алу барышында күпчелек кеше милләтен – «половец», сөйләм телен «украинча», дип яздырган. Һәм мондый хәл ул вакыттагы республикада дүрттән бер өлеш чамасына туры килгән. Мин шул елгы перепись документлары белән таныш», дигән иде ул.

Батый ханны һәм шуңа охшаш тагын кайбер вакыйгаларны төшереп калдырсалар да, безнең ул чордагы күршеләрнең әлеге фильмы Бөтенсоюз күләменә чыкмады, «Сон Шевченко» һ.б. шуңа охшаш фильмнар рәтендә үз республикаларында гына күрсәтелде шикелле. В.Землякның миңа истәлеккә дип бүләк иткән бер китабы гына саклана. Үзе катнашкан сугыш вакыйгаларын чагылдырган китап.

Инде әдәбият белгече Леонид Новиченко белән аралашу вакыйгаларын искә төшереп үтим. Ул, атнасына бер-ике мәртәбә, иҗат йортына килгән язучыларны күрше санаторийларда ял итүчеләр белән очрашуларга оештырып җибәрә яисә алып бара иде. Без дә ике җирдә булдык. Шуларның берсенә – аның җитәкчелегендә, икенчесенә прозаик Николай Олейник төркемендә бардык. «Липки» дигән ял йортыннан бирелгән, исем-фамилиям теркәлгән рәхмәт язуы бүген дә саклана әле. Очрашуларның берсенә безнең белән язучы, тәрҗемәче Зиновий Биленко (тәхәллүсе – З.Ромен) да барды. Ул Муса Җәлил шигырьләрен дә тәрҗемә иткән. Ләкин без кибетләрдә аның тәрҗемә әсәрләре тупламасын очратмадык. Сатып ала алмадык.

Мин ул очрашуларда Галимҗан Ибраһимовның 1914 елда Тарас Шевченко язмышына һәм иҗатына багышлап күләмле мәкалә язуын, Муса Җәлилнең 1940 елда Киевта узган, бу бөек шәхескә багышланган тантаналы җыенда катнашуын, аңа багышлап мәкалә, шигырь язганлыгын искә алган булдым. Киев тарафына чыгып китәр алдыннан андый мәгълүматны тупларга тырышкан идем. Әмма тыңлаучыларга минем Шевченко сөргендә булган Оренбург төбәгенә бәйле хатирәләрем күбрәк ошады. Оренбург һәм Орск музейларында аңа багышланган стендлар булуын, Орск шәһәре уртасында бу бөек шәхескә һәйкәл куелуын сөйләгәч, кул чабулар озак дәвам итте.

Әмма ике очрашуда да сәхнәне төп биләүчеләрнең берсе Мәхмүт ага Хөсәен булды. «Татарның сөйләм теле украин теленә якынрак», дип, ул әүвәл бер шигырен бик илһамланып татарча яңгыратты. Аннары шуны ук русча кабатлады. Әмма сәхнәдә утыручыларны да, залдагыларны да бертуктаусыз кул чабарга мәҗбүр иткән чыгышлары – һич тотлыкмыйча, Муса Җәлил, Тукай шигырьләрен рус телендә яттан сөйләве булгандыр. Башка кайбер авторларның үз әсәрләрен дә китаптан карап укыганны күреп торган тамашачыны мондый күренеш бик сөендергән иде.

Мәхмүт аганың 95 еллыгына багышланган бу истәлек язмамны халык мәкале белән тәгәллисем килә.

Сүнә яшен, «әнә яшен», дигәнче.

Үтә гомер, «менә яшим», дигәнче...

Мәхмүт агабыз да, 70 яше тулырга бер ай калганда, кинәт кенә арабыздан китеп барган иде шул...

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

# ЙӨРӘККӘ СЫЙГАН ДӨНЬЯ

Кешелек мәдәниятенең һәрбер чорында шигъриятькә билгеләмә бирергә омтылганнар. Даим тылсымлы тоелган тезмә әсәр адәм баласының вөҗүдендә ничек туа? Таләпчән белешмәлекләр дә моны төрлечә аңлата. Чын шигырь нинди була? Әлеге сорау уңаеннан шәрехләүләр меңнәрчә хезмәттә бәян ителә. Әгәр аларны бергә тупласаң, фолиант барлыкка килер иде. Шәхсән үземә дә бу мәсьәлә таныш. Югары уку йортын тәмамлау елында шушы темага диплом эше әзерләдем. Сәнгатьнең мондый төренә мөнәсәбәтле серләр мине әлегәчә бөтен яклап кызыксындыра. Баксаң, үзебезнең Казанда «тормыш университеты» сынауларын горуранә үткән, бөек Тукаебызның фидакарьлек үрнәген хөрмәтләп искә алган, белгечләрчә фикерләгән Максим Горький гап-гади рәвештә аңлата: «Чын шигърият – һәрвакыт йөрәк шигърияте ул».

Шагыйрә Халисә Мөдәррисова иҗаты белән тулаем танышып чыкканнан соң, мин гаҗәеп тирән гыйлемле әдипнең шушы билгеләмәсен хәтергә китердем. Чыннан да, инде күптән үзенә җәлеп иткән каләмдәшемнең әсәрләре әлеге мәгълүм формуланың барлык таләпләренә туры килә. Аның серле җан-тән тирәнлегендә яралган һәммә шигыре нәкъ менә ихлас йөрәк сүзе буларак яңгырый. Башкортстанның халык шагыйре Наҗар Нәҗми дә бу нәзакәтле фикерне хуплавын үзенчә белдерә. «Халисә Мөдәррисова шигъриятькә утлы һәм давыллы йөрәге белән килеп керде, – дигән искәртү ясый остаз «Шагыйрь гомере» исемле мәкаләсендә. – Шигырь язуның яну, йөрәк газабы икәнлеге аның һәр әсәрендә диярлек ачык күренә». Моның чынлыкта шулай булуын шәкерте дә торымнан-торымга сиздертә. Әйдәгез, «Ташлар җыям» дигән шигырьнең кайбер юлларын укып узыйк.

*Ташлар җыям... Тик дөньяга*
*Мин таш түгел, аш атармын.*
*Ә ташларны –*
*Күңелемә атканнарын,*
*Йөрәгемдә ятканнарын*
*Җырларымда балкытырмын.*

Бездә югары сәнгать төре булып саналган шигъриятнең асылын фикер һәм хис бергәлегенә, ягъни чынбарлык күренешләренең аң-зиһендәге яки күңелдәге чагылышына бәйләп аңлату омтылышы өстенлек ала. Мәсьәләне гадиләштереп күзаллау үзеннән-үзе берьяклылыкка китерә. Әлеге җитди темага багышланган байтак хезмәтләрдә дә мәгълүм «образлы фикерләү» тәгъбире белән чикләнү сизелә. Ә мондый эшчәнлектә йөрәкнең катнашы, аның әһәмияте ничектер читтәрәк кала. Шушы җәһәттән аяусыз сынаулар кичкән Фатих Кәрим иҗатта ни-нәрсәгә өстенлек бирелүен анык аңлатып үтә: «Шаулы шигъри хисләр диңгезенең Дулкынчысы минем йөрәгем». Бүгенге мәкаләдә игътибар үзәгенә алынган Халисә Мөдәррисова да бу билгеләмәне ныгыту юнәлешендә үзенең мөнәсәбәтен белдергәләп тора. «Ә йөрәктә шигырь яшәде...» Каләмдәш дустына хаслап язылган әсәрендә шагыйрәбез ихлас инануын шулай аңлата.

Белүебезчә, йөрәк атамасы күпне сыйдыра. Татар телендә аеруча тәэсирле яңгыраган әлеге кәлимәдә кешенең эчке дөньясы, төгәлрәк әйткәндә, рух, җан, күңел,

хәтер ише олуг төшенчәләрнең уртак сыйфатлары чагыла. «Йөрәк» сүзе Коръәндә дә төгәл 133 тапкыр кабатлана. Бу юкка гына түгел бит. Әнә, «йөрәк белән» сүз тезмәсе дә әллә никадәр мәгънәне эченә ала. Сөйләмдә яки язуда мондый янәшәлектән файдалану «аң-акыл, хиссият, җан-тән белән» дигәнне аңлата. Моның мотлак дөреслеккә туры килүен Халисә Мөдәррисова да яхшы белә. «Йөрәк» лөгатен әсәрләрендә еш куллануы да аның иҗат кодын тоемларга ярдәм итә. Шагыйрә бөтенләй башка сүзләр аша да шул тылсымлы «ачкыч»ка әледән-әле әйләнеп кайта. Әйтерсең ул һәрдаим үзенең йөрәген тыңлый, тирәннән яңгыраган өнне илһамланып кәгазьгә күчерә. Сәнгать чынлыгына ирешергә теләсәң, әйе, иманлы йөрәгеңә таяну зарур.

*Йөрәк белән, күңел белән тоеп,*
*Шагыйрь аңлый кара һәм акны.*
*Кеше ялгышала, ә шагыйрьнең?!*
*Ялгышырга аның юк хакы.*
(«Шагыйрь»)

Тәҗрибәле затлар хак искәрткәнчә, йөрәк чик-кысага сыймас хисләргә чынны ялганнан аерырга булыша. Әдәбиятның иң әһәмиятле бурычлары шәхесне яшәү мәгънәсен аңларга өйрәтүдән, авыр сынауларда ныгыган тормыш хаклыкларын үзләштерү буенча күнекмәләр бирүдән, әллә нинди гамәлләр кылырга сәләтле көч-кодрәт чыганагын вакыт-вакыт аруландырудан, киләчәккә атлаучы халкыңның зур максатларына йогынтылы теләктәшлек күрсәтүдән гыйбарәт. Әгәр каләм әһеленең язганнарында зирәклек, ихласлык, җылылык бөркелеп тора икән, боларның барысы да шул ук игелекле йөрәк иҗтиһатыннан килә бит. Мондый чын әсәрләр башкаларга да тансык. Йөрәктән чыкмаган йөрәккә керми, дип тикмәгә генә әйтмиләрдер. Бу кагыйдә таләпләренә тулысынча җавап бирерлек шигырьләр Халисә Мөдәррисованың халыкка таралган китапларында бик күп. Аның мөрәҗәгатькә тартым «Метеор монологы» дигән әсәрендә хәтта җиргә атылган йолдыз рухани сусавын җиткерә: «Кайнар йөрәк эзләп сезгә килдем...» Үз чиратында хыялга бирелүчән шагыйрә дә киң күңелле булуын ачыктан-ачык белгертеп куя. «Йөрәгемә ишек ачтым...», ди автор исеме куелмаган икенче бер шигырендә. Хисапсыз уй-фикерне сәнгатьчә кристаллаштырган әлеге образ башка әсәрләрдә мантыйкый эзлеклелек белән үстерелә.

Безнең яшәеш хәлләре каршылыклы хәрәкәтне хәтерләткән кебек, матур әдәбиятта да капма-каршы мөнәсәбәтләрнең чагылуы табигый. Шуңа күрә каләм осталарының һәрбер саллы китабын колачлы тормыш дәреслегенең өземтәсе итеп күрәсе килә. Шагыйрьләр миф, кыйсса, марш, өндәмәләр язу максатын читкәрәк куеп, аерым кешенең коллизияләр белән тулы эчке дөньясындагы хикмәтләргә якынайды. Галимнәр теле белән әйткәндә, шигърият әүвәл иҗтимагый тереклек рәвеше булып күзаллана, аннары гына сүз сәнгатенең асыл төрен гәүдәләндерә. Үзеннән-үзе аңлашыла, йөрәгеңдә милләт мәнфәгатьләре өчен яну юк икән, синең әсәрләреңә олы гамь тирән тамыр җибәрә алмый. Ә менә Халисә Мөдәррисованың кальбендә иҗадиятка кирәкле андый ут бар. Ул аның моңсу күзләрендә, җитди кыяфәтендә сизелеп тора. Күпне кичергәнлеген дә тиз абайларга мөмкин. Хәер, рухиятенә баглы беренчел сәбәпләрне шагыйрә үзе дә яшерми. «Тәрҗемәи хәлем гади генә сымак, әмма ул алай гади түгел, – дип яза Халисә Сәгыйть кызы, рәсми белешмә кысаларын бераз киңәйтеп. – Саран юллар эченә күпме тетрәндергеч һәм шатлыклы вакыйгалар, күпме хис-моңнар, күпме табыш һәм югалтулар сыйган».

Сүз дә юк, шагыйрәнең гомере буена дәвам иткән сынаулар аның һөнәри хезмәтенә дә, газиз халкыбызның безгә якынрак чорлардагы яшәү чынлыгына да турыдан-туры бәйле. Гомумән, алар бер-берсеннән һичничек аерылмый. Байтак иҗатчылар өлешенә тигәнчә, Башкорт дәүләт университетын тәмамлаган Халисә Мөдәррисова Илеш, Нуриман районнарында укытучы һәм мәктәп директоры булып эшли, аннары авыл советы башкарма комитеты сәркатибе, район хакимияте эшләр идарәчесе, мәдәният идарәсе башлыгы вазифаларын үти. Бүтән тармакларда да үзен сынап карый, депутатлыкка караган гамәлләрне дә башкарырга өлгерә. Өч дистәдән артык елны

колачлаган эшчәнлек дәвамында алгысыган йөрәккә нинди генә зәһәр уклар кадалмады икән?! Мондый шартларда сайлап алынган мәсләгеңә, эчке инанганлыгыңа хыянәт итмәү зарур. Шәхеснең ныклыгын билгеләүче әлеге хасият каләм әһелләре өчен аерата мөһим. Нәкъ менә шундый сыналган язу кагыйдәсенә таяну Халисә Мөдәррисованың тәүге әсәрләрендә үк чагылыш таба. Аның Башкортстан «Китап» нәшриятында чыккан «Көмеш дага» исемле беренче җыентыгы (1982) безнең шигърияткә тынгысыз йөрәкле яңа талант килүе турында хәбәр итте. Яшь дәвамчыга өмет багларга мөмкин икәнлеге «Баланнар» дигән шигырьдә дә күренеп тора.

*Колакта чыңлый һаман,*
*Пышылдый кебек анам:*
*«...Авыр чаклар бик күп булыр –*
*Түзәргә кирәк, балам».*
..................................................
*Аунап елар чаклар була –*
*Йөрәкне өзәләр бит,*
*Барыбер түзәләр бит!*

Көнбатыш әдәбияты белгече Ипполит Тэн бик тә дөрес шәрехләп үткәнчә, «Шагыйрь камиллеккә ирешә барган саен, аның миллилек дәрәҗәсе дә күтәрелә; сәнгать серләрен киңрәк үзләштергән саен, ул заманның асылын тирәнрәк аңлый». Бу уңайдан Халисә Мөдәррисова өчен халык тормышының барлык яклары үз. Аны милли дәүләтчелек мәсьәләләре дә, шәхеснең үзаңын үстерү торышы да, туган телебезне тетрәткән сынаулар да, мәгарифкә ябырылган мәгънәсез тәҗрибәләр дә, дәвамчыларны тәрбияләү дә бертигез борчый. Ул төшендерә, үгетли, чакыра, сабак бирә. Берара үзе дә мөгаллимлек иткән шагыйрә әдәбиятның тиңдәшсез тәрбияче икәнлеген яхшы белә. Нәрсәгәдер эзлекле төстә өйрәтү тора-бара күркәм гадәткә әверелә, адәм баласы шул рәвешле югары әхлакый кыйммәтләргә тиенә. Әдибәгә монысы да бик күптәннән мәгълүм. Менә шундый бихисап борчу аның йөрәк итен ашый. Эчкә сыймаган җырга чыга. Ә Халисә Мөдәррисова һәрбер әдәби жанрда да үз рухына якын темаларга тугры булып кала. Хәтта «Балан», «Вакыт» кебек җырларында да ул безнең авырткан урыннарга кагылып үтә. Шулай шул, иҗат принципларының ныклыгы барыбер үзенекен эшли.

Акыл ияләре яңа эрага кадәр үк киңәш биргәнчә, ил-мәмләкәтләрнең киләчәк язмышы яшьләрне тәрбияләүгә бәйле. Тормыш раслап тора: баланы дөрес юлга бастырасың икән, ул аннан гомер буена тайпылмый. Мондый хәлиткеч максатка ирешүдә ата-ана тәрбиясе, белем йортларының эшчәнлеге аеруча мөһим санала. Әүлиялар дәрәҗәсендә фикер йөрткән Габдулла Тукай нәкъ менә шулар хакында кат-кат искәрткән. «Баланың язмышы, ул тугач ук, аның ата-анасына тапшырыла...» Әнә шундый гап-гади хакыйкатьне мөкатдәс вазифа югарылыгына күтәргән шагыйрь тәрбиянең икенче баскычына да өстенлекле игътибар юнәлтүне кирәк таба. «Әүвәл милләт укысын, – ди ул. – Мәктәпләр – безнең арсенал». Кызганыч, реформалар белән яшәүче ил соңгы берничә ел дәвамында «белем», «китап» ише җитди төшенчәләрнең астын өскә китерде. Төрле астыртын һөҗүмнәргә дучар булган меңнәрчә мәктәп миллилек статусын югалтты, алай гына түгел, гыйлем йортларында татар теле үзен бөтенләй ятим хәлендә тоя башлады. Рухи тигезләнешне җуюю шәхси бөтенлекне җимерә. Шул рәвешле милли тамырларга кизәнү дәүләтнең ныклыгына да сугарга мөмкин. Куркыныч чиккә якынлашып килгән әлеге мәсьәләләр җәһәтеннән кисәтү белдерүне шагыйрә Халисә Мөдәррисова да йөрәк түрендәге бурычы итеп хисаплый. Мондый кысуларның гайре табигый икәнлеген аңларга өндәү «Минем халкым» исемле шигырьдә дә үзәккә алына.

*Кадерле бер асыл җәүһәр итеп,*
*Татар телен җиргә танытты, –*
*Телен кисеп, аңын каплап булмый*
*Тукайларны биргән халыкның.*

Әдәбиятта еш күзәтелгәнчә, аерым шагыйрьләр чәчмә төрдә дә бер югарылыктагы осталыкларын күрсәтергә сәләтле. Башка чаралар белән дәвам иттерелгән поэзияне прозага тиңләп караучылар асылда һәрьяктан хаклы. Камил язу рәвешен барлыкка китергән каләм иясе теләсә нинди әсәрендә дә үзе булып кала. Шагыйрә Халисә Мөдәррисованың чәчмә хезмәтләре дә киң җәмәгатьчелек тарафыннан яратып кабул ителде. «Бәйге хакы» повестен генә искә төшерик. Анда иҗат әһеле вакыйгалар үзәгенә куелган. Замана гамьнәре белән яшәүче әлеге зат, әлбәттә, гомер сынауларын чагылдырган каршылыклы хәрәкәттә сурәтләнә. Гадәттә, андый юллар сикәлтәле була. Йөрәккә кан саудырган эзләнүләр үкенечле югалтуларга да китерә... Автор ошбу гыйбрәттә нечкә лиризмга да, үзәк өзгеч драматизмга да урын таба. Алар бер-берсенә керешеп китә – нәкъ чынбар тормыштагы шикелле. Менә шундый повесть китап сөючеләрне генә түгел, хәтта театр хезмәткәрләрен дә үзенә җәлеп итә. Соңгылары анда тамаша нигезенә ятарлык мавыктыргыч сюжет барлыгын күрә, һәм әсәр М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театрында сәхнәләштерелә. Шагыйрь Муса Җәлил хаклы төстә әйткәнчә, «Каршылыксыз... драма әсәре була алмый». Димәк, Халисә Мөдәррисованың сәхнә сәнгате өлкәсендә күркәм уңыш казануы да аның тормыш күренешләрен төрле мөнәсәбәтләр яссылыгында тасвирларга омтылуын раслый. «Соңгы сер», «Яр» повестьлары, «Ал кирәк, гөл кирәк» һәм «Сабан туеннан соң» хикәяләре дә шул әсәрләрне язган шагыйрәнең йөрәк халәтен зәвыклы укучы ачык тоярлык дәрәҗәдә күз алдына китерә. Кысан вәзенгә сыймас уйларның чәчмәдә бәреп чыгуы, каләмнең үзен ирекле тотуы шулай буладыр инде.

Иреклелек дигәннән, карар күзгә нык ихтыярлы килбәттә күренүче Халисә Мөдәррисова үз-үзенә багышланган бер шигырен түбәндәгечә тәмамларга ният кылган: «Мин – хатын-кыз, бары яратыгыз, Минем вакыт – кыска таң кебек». Беркадәр боерулы төсмердә яңгыраган әлеге сүзләрне көязләнергә яратучан бәндәләр үзләренчә кабул итәдер. Ничек кенә булмасын, хатын-кыз иҗатчының мәхәббәткә мөнәсәбәтен ачып бирмичә, аның тулы портретын сурәтләү мөмкин түгел. Хикмәти Хода, шагыйрәнең тәкъдиргә бәрабәр «сөю тәгълиматы» да шул могҗизалы йөрәк шәрифенә турыдан-туры бәйләнгән. Хәер, мондый көчле хиснең җирлеген башкача һичничек күзаллый алмыйбыз. Халкыбыз да шуңа ишарәли. Әйе, мәхәббәт бер булса да, ул ике йөрәктә яши. Сөю утында янган Халисә Мөдәррисованың уй-гамьнәре дә газиз җан-тәннең шушы илаһи төенләнеше аша үтә.

*Кискәләп өзгәләмәгез*
*Әрнегән йөрәгемне.*
*Гомерләрем дә җәл түгел –*
*Бирегез сөйгәнемне!..*

(«Сагындым сөйгәнемне»)

Каләм ияләре арасында яратуны артык гадиләштереп аңлатучылар, аны «хезмәт күрсәтмичә» алынган бүләккә тиңләүчеләр очрый. Дөрес, бөек мәхәббәт хиссиятен Аллаһның һәдиясе итеп санарга кирәк, әмма ул йөрәккә ялкын салачак яну-көюләр хакына бирелә. Әүвәлгеләр әйткәнчә, сөю бар җирдә көю дә бар. Шагыйрә Халисә Мөдәррисова да моның чынлап шулай икәнлеген шәхси тәҗрибәсе нигезендә язылган исемсез әсәрендә ачыктан-ачык раслый: «Мин яраттым сине әрнү белән, Биш газапка торды бер рәхәт». Автор мәхәббәт сынауларына юлыккан инсанның авыр халәтен «Йөрәгеңә йөрәк сыймый» кебек сүзләр белән аңлата. «Язмышлар бәрелештеме?!» Өметләнгән бәхетне татый алмаган сөюнең үкенечле ахыры «Кояш» шигырендә әнә шундый образлы тирәнлектә тасвирлана. Шагыйрә мәхәббәткә кагылышлы каршылыкларны төрледән-төрле яссылыкта ачарга омтыла. Аның әсәрләрендә баштан кичкән хәлләр дә, мәгълүм хакыйкать сөземтәләре дә чагылыш таба. Канатлы гыйбарәдә искәртелгәнчә, кемнеңдер сөеклесе булу бик җиңел, үзең ярату исә бик авыр. Тормышта еш күзәтелә торган мондый хикмәтле күренеш Халисә Мөдәррисова шигырьләрендә яңа төсмерләр белән сурәтләнә. Теләсә нинди газапларны кичерергә

әзер булган ярның соңра иң сөекле хатын-кызга әверелүе дә мәгълүм. Моның өчен ике яктан да сабырлык, мәхәббәттән сабак ала белү таләп ителә. Автор ошбу фикерне үзенең байтак әсәрендә, атап әйткәндә, «Мин – хатын-кыз» дигән шигырендә дә үткәрә. «Сөю белән мин яхшырак булам, – дип яза ул, – Матуррак булам, яктырам...» Әсәрләреннән күренгәнчә, Халисә Мөдәррисова мәхәббәттә ниндидер битлекләр киеп уйнамаска, насыйп табигыйлегенә беркайчан да хыянәт итмәскә чакыра. «Ничек бармын, шулай ярат» дип исемләнгән шигырьдә мондый үрнәк аеруча үтемле рәвештә күңелгә сеңдерелә.

*Тик миндә генә ялгышма,*
*Мин түгел иң зур йолдыз;*
*Юк, серләр эзләмә миннән –*
*Мин гади генә бер кыз.*

*Йолдыз, димә, кояш, димә,*
*Алтын да көмеш, димә.*
*Ничек бармын, шулай ярат,*
*Бары шул килеш кенә.*

Шигъриятттә хыялый шартлылык башлангычы шактый мулдан булса да, ул үзенең терек тамырлары белән барыбер җиргә тоташкан. Бездә тормышка аек карый белмәүчене шагыйрь итеп санамаучылар да бар. Андыйлар фикеренчә, әкияти дөлдөлдә салават күперен очып иңләсәң дә, син халык тормышын игътибар үзәгендә тотарга тиешсең. Яшәеш тәҗрибәсе төрлесен күрсәтә. Гомерләре буена табигать эчендә язар азык эзләп, ил-көн мәнфәгатен кайгырткан каләм әһелләрен дә беләбез. Бу җәһәттән Халисә Мөдәррисова иҗатында җир-күккә багышланган шигырьләр аеруча күп. Күзгә ташланып торган мондый үзенчәлек аның «табигать баласы» булуыннан, балигълык чорына кадәр шушы бәрәкәтле мохиттә тәрбияләнеп үсүеннән киләдер. Гүзәл табигатьле Башкортстанның Ишимбай шәһәрендә дөньяга килгән кыз ямьле балалык елларын Иглин районының Үктәй авылында үткәрә. Монда сигезьеллык мәктәпне тәмам иткәч, Нуриман районының Байгелде авылына күчеп, урта белем турында таныклык ала. Урман, елга, тауларга бай төбәкләрдә Халисә Җир-ана белән сөйләшергә өйрәнә. Аңлашыла ки, күпләр туган якларын өзелеп яратулары хакында белдерә, үзләрен аерым тиякнең кадерле кыз-улы дип уйлый. Ә шагыйрә әлеге мөнәсәбәткә бөтенләй башкача яңгыраш бирә. «И Туган җир! Син газизсең миңа. Мин газизме сиңа бу дөньяда?» «Туган җир» исемле шигырьдә менә шундый сорау куела. Әлеге көтелмәгән сөальдә авторның эчке тыйнаклыгы да, аның кече ватан алдындагы олуг җаваплылыгы да, үз милләтенә хезмәт итәргә әзерлеге дә чагыла.

Затлы метафораларга нигезләнгән иҗат өслүбе, гадәттә, һәрбер шагыйрьнең өстенлеге булып санала. Инде әйтеп үтелгәнчә, Халисә Мөдәррисова җир-күккә мөнәсәбәтле образларга, сурәтләү чараларына чагыштырмача ешрак таяна. Аның иҗтимагый мәсьәләләргә багышланган җитди шигырьләрендә дә шул нисбәтне күрсәткән җанлы бизәкләр урын ала. «Танклар китә Чечняга» дип исемләнгән публицистик әсәрне генә алыйк. Әлбәттә, шагыйрә хакимиятнең үз халкы белән көрәшүенә, мәгънәсез сугыш хәрәкәтләренә катгый ризасызлыгын белдерә: «Ак яулык тотып йөгерәм Мин состав алларына...» Автор табигать күренешен дә бик оста файдалануга ирешә. «Ак кәфен килеп урала «Урыс» каеннарына», дип, ул көч-куәт башбаштаклыгына авышкан сәясәтчеләрне кисәтә дә.

Һәрдаим үзгәреп торучан халәте рухиятебезне төрлечә чагылдырган терек табигать сурәтләре мәхәббәт, гаилә һәм тәрбия мәсьәләләренә караган әсәрләрдә дә маһирларча кулланыла. «Тәү кат яры үпкән сылу кебек, Куаклыкта балан кызара...» Тирә-юньне рәссам карашы белән күзәтә белгән Халисә Мөдәррисова исемләнмәгән шигырендә сәнгатьчә рәвеш алырга теләгән хис-тойгыларын әнә шундый җете төсләрдә тасвирлый. «Синең белән һәм синсез» дигән әсәрдә исә сөю кичерешләре җир-күк халәтенә иш

куера башлый: «Яшеннәр – утлы чыбыркы, Тамчылар энҗе түгел; Җәйгор, утлы кыршау сымак, Ураган күңел күген». Күргәзмәләрдә кайвакыт күк йөзеннән мәхрүм пейзажларга – тын-сулышны кысып ала торган рәсемнәргә юлыгасың. Ә менә Халисә Мөдәррисованың шигъри сурәтләмәсендә уй-хыял канатларында теләгәнчә очарлык җай-чама бар. Шагыйрәнең фаҗигале мәхәббәт тарихын үзәккә куеп язылган «Соңгы сер» повестенда да бу тормышка урыны-урыны белән Җир-ана күзлегеннән карау алымы тәэсирләндергеч нәтиҗәләргә китерә. Үзенең байтак геройларын шушындый отышлы җирлектә гәүдәләндергән каләмдәшем, ышанычны югалтмыйча, кешеләргә хәерхаһлык күрсәтүче Табигатьтән үрнәк алырга да чакыра.

*Яшәр әле, яшьнәр яз айлары,*
*Кәккүк чакырыр тагын үз парын;*
*Бөреләнер өчен яфрак коя*
*Тол хатындай сабыр урманым.*
(«Тол хатындай моңсу ак болытлар...»)

Чагыштырма ясарга яратучылар шигырьне кардиограммага тиңләштерә. Йөрәк тибешенең график сурәтләнешен, чынлап та, ашыкмыйча әсәрләнеп укырга мөмкин. Аңа сәгатьләр буена карап утырганым бар. Мондый язылышта ниндидер хикмәт тә, шартлы билгеләр камиллеге дә чагыла. Анда тезмә әсәрләргә хас ритм иң беренче булып күзгә чалына. Шигъри синтаксисны тәшкил иткән кайбер стилистик чаралар да, аерым алганда, еш төрләнеп торган рефрен чалымнары да сизелә шикелле. Кичерешләр йогынтысына бирелгән йөрәк, вакыты килеп җиткәч, ипле эшчәнлеген беркадәр үзгәртә. Гомумән, ап-ак кәгазьгә төшерелгән кардиограмма чынбарлыкта артык катлаулы түгел. Язылыш рәвеше ягыннан исә алар бер-берсеннән өлешчә аерыла. Нәкъ кешеләрнең төрлелеге кук. Каләм әһеленең иҗат табигатен билгеләүче тел-өслүб тә менә шундый эчке хасият бәйлелегендә калыплашадыр төсле. Әдәбият белгечләре дөрес әйтә: шәхес үзе нинди – стиле дә шундый. Рухият белән иҗат арасындагы ошбу нисбәт Халисә Мөдәррисова мисалында да ачык күренә. Язу алымында аның фикер йөртү сәләтен дә, хисләнү дәрәҗәсен дә, хәтта кан тамырлары тирбәнешен дә шәйләп була. Шагыйрәнең әдәби почеркы табигый, күпчелек өчен бик аңлаешлы. Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ «Һәр юлында – сөю уты» исемле мәкаләсендә үзенчә басым ясап күрсәткәнчә, «Гадилектә шул матурлык, шигърилек, дип кат-кат әйтәсе килә... Башкаларга охшамаган, үзгә бер шигъри җан анда!»

*Авыр, иң кирәкле сүзне*
*Сыйдыралмаса антлар.*
*Авыррак, сүз әйтеп тә*
*Аңлаталмаган чаклар.*

Күргәнебезчә, Халисә Мөдәррисова йөрәк сүзен һәркем төшенерлек итеп яңгыратырга тырышуын «Язылмыйча калган шигырь» дигән әсәрендә үзе дә сиздереп үтә. Аның иҗат камиллегенә ирешү җәһәтеннән уйлануы бик табигый, чөнки гадилек белән аныклык фикерләүнең өстенлекле сыйфатын билгели. Моны күпләр раслый. Төгәл карашыңны аңлаешлы рәвештә белдерә алган очракта гына сүз сәнгатендә башкаларның күңелен баетырлык уңышка ирешергә мөмкин. Француз язучысы Альбер Камю гомер тәҗрибәсеннән чыгып әйткәнчә, «Анык кимәлдә язган каләмнең ишле укучылары, томанлы итеп язганнарның үз шәрехчеләре була». Безнең Халисә Мөдәррисова шуларның әүвәлгесенә керәдер. Ул югарыда күрсәтелгән таләпләргә җавап бирүче шигъри сүзнең үтемлелегенә тирәнтен ышана, «Табигатьнең серле бу хәтере» дип башланган шигырендә дә шуңа ишарә кыла: «Буыннарны буыннарга ялгар, Бүгенгене киләчәккә илтер Гап-гади җыр тыңла...» Шагыйрә әлеге әсәрендә галилекнең гадилектә икәнлеген янә искә төшерә, халыкны шушы бәһаләп бетергесез кыйммәттән һәрдаим файдаланып яшәргә чакыра.

Әлбәттә, сәнгатьчә югарылыкта шигырь язуның серләре берничә башлангыч

белән генә чикләнми. Анык итеп әйтелгән сүзләрдә ихласлык та сиземләнергә тиеш. Бу хасият йөрәк тирәнлегеннән, сәмави рух-җанның хөрлегеннән килә. Барысы да үзара бәйләнгән. Элгәрләр һәрвакыттагыча хаклы: йөрәк белән алдырмасаң, тел генә ярдәм итмәс. Әгәр шәхеснең бөтен барлыгын биләрлек иҗади дәрт булмаса, әдәби әсәрләр үзәгендәге уй-фикернең чынлыгына ирешү мөмкин түгел. Халисә Мөдәррисова «Сиреньнәр» шигырендә «Дөньяга сыймас хисем», дип яза икән, димәк, ул үзенең эшчәнлегендә табигый талант ирекләлеген һәрнәрсәдән дә өстен саный. Әлеге бөтенлектә ясалмалылык юк. Төрле сыйфатларның үзара ярашуына корылган мондый гармония шагыйрәнең җәмәгатьчелектә уңыш казанган әсәрләрендә яхшы төсмерләнә.

Зәвыклы укучының йөрәк кылларына тәэсир итү өчен, әйе, әдәби сүздә барлык сәнгатьчә компонентларның булуы шарт. Аңа хикмәтлелек тә, гадилек тә, аныклык та, ихласлык та зарур. Әсәрнең теленә шигъри образлылык җитмәү исә әлеге мөһим үзлекләрне тулаем тоныклануга китерә. Алдарак искәртеп үтелгәнчә, Халисә Мөдәррисова иҗаты сурәтләү чараларына бай. Аның шигырьләрендә күзәтелгән канатлы гыйбарәләр арасында халкыбыз зирәклеген хәтерләткән әйтелмәләр дә бар. Татарлар элек-электән тәкрарларга яратканча, ир-егетнең эчендә иярле-йөгәнле ат ятыр. Ә кызларыбыз күңелен ни-нәрсә рухландыра соң? Шагыйрә «Хушлашу» дигән әсәрендә моны үзе күзаллаганча аңлата: «Йөрәктә... Ал җилкән күтәргән кораб бар». Мондый мисаллар китерүне дәвам итәргә мөмкин. Исеме аталмаган берничә шигырьдән кайбер юлларын укып узыйк. «Юк, кайтарып булмый үткәннәрне, Ике какмый ярга бер дулкын»; «Ялкын гына җылытала, Җылытучы төтен түгел»; «Һәр өзелгән яфрак – ялгызлык...» Шушы кыйтгаларның һәммәсе дә безнең күңелләрдә аваздашлык таба. Автор ялгыз кабердә дә яшәеш хикмәтен күрә. Аныңча, «Бу дөньяның барлык соравы, Бар җавабы шунда күмелгән». Хәятыбыз турындагы уйларның төрле-төрле сөземтәләре әдәбият белгечләрен дә битараф калдырмый. «Халисә Мөдәррисова шигырьләрендә бик үзенчәлекле, һич көтелмәгән чагыштырулар, хис-тойгыларны төгәл әйтеп бирердәй образ-бизәкләр гаять күп, – дип яза Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе Суфиян Сафуанов үзенең китабына кертелгән «Гомеремнең җәй уртасы» исемле мәкаләсендә. – Аларны тормышның вак кына күзәнәкләренә игътибар итүчән, нәкыш нәкышләргә, чигү чигәргә, сәйләннәр тезәргә маһир булган хатын-кызлар, шагыйрәләр генә оста файдалана беләдер, мөгаен... Әсәрләрнең эчке мәгънәсен тирәнәйтеп җибәрә торган хикмәтле афоризм, мәкаль кебек яңгыраган тәгъбирләр муллыгы, төс-буяулар байлыгы аның иҗатына зур тәэсир көче бирә. Нәтиҗәдә без шушы җирлектә чын-хак замандаш сурәтен күрәбез».

Әдәбиятны бик тә хөрмәт ителгән, бөек хисләр уяткан әхрамга охшаталар. Аның эченә бары тик саф вөҗдан, күркәм омтылышлар белән генә керергә була. Монда бусагалар биек. Эстетика төшенчәсенең этикадан аерылгысыз икәнлеген нечкәләп аңлаучы затлар өчен биредә башкаларга тәгълим кылырлык гүзәл әсәрләр тудыру мөмкинлеге бирелә. Яхшы гадәтләрне үзләштерү шәхесне тора-бара зирәклеккә илтә, соңгысы аңа үзенең уй-карашын белдерү ирекләлеген бирә. Уңай үзлекләрне берләштергән әйбәт холык хәтта язмышка да йогынты ясый. Әмма боларның барысы да эчке инанганлык ныклыгына бәйле. Кулына каләм алган кеше моңа яшьли төшенергә тиеш. Мәктәптә укыган чакта ук шигырьләр яза башлаган Халисә Мөдәррисова үз-үзен менә шундый җаваплы иҗатка һәрьяктан да әзерләүгә ирешкән. Ул бүтәннәрне дә ошбу кагыйдәләрне төгәл үтәргә чакыра, күңелгә сеңдерелгән зарур сыйфатларның табигый бөтенлеген сакларга өнди.

*Шагыйрьләрдә иман бары берәү,*
*Вакланырга аның хакы юк.*
(«Шагыйрь»)

Күпләр басым ясап әйткәнчә, саф күңел белән язуга ни җитә! Якын кешеләргә юлланган хатта кальбнең ихласлыгы тулаем чагылыш тапкан кебек, укучы

тарафыннан көтеп алынган тансык әсәрләрдән дә пакьлек аңкып тора. Вәләкин каршылыклар тулып ашкан тормышта шәрран ачык күңел тизрәк яралана. Аеруча шагыйрьләр бәгыре. Еш күзәтелгән мондый гаҗизлек Халисә Мөдәррисовага да хас. «Мин – хатын-кыз» исемле шигырендә ул шул хакта кисәтүен белдереп уза: «Күңел таңдай нурлы, кылдай нечкә... Усал кагылмагыз... Тупаслыктан мин каралам, көям, Усалланам – нигә ул сезгә?» Ничек кенә булса да, шагыйрә сабырлыгын югалтмый. «Яралардан арынырга Бирегез вакыт кына», ди ул «Язгы төш» әсәрендә. Белгәнебезчә, сөйгән халкың белән бергә күптөрле авыр сынауларны үтү, шаулы заманның яшьнәү-күкрәүләрен йөрәк аша уздыру җиңел бирелми. Тик каләм иясенә бүтән юл юк. «Шигырь ул – кешегә кирәкле йөрәк сүзе...» Сугышның бөтен газапларын татыган шагыйрь Гали Хуҗи менә шундый билгеләмәне бернинди нигезсез язып калдырмаган. Әмма күпне кичерергә сәләтле иҗатчы гына ил-көнгә хаҗәт бәгырь авазын ирештерергә мөмкин. Боларның һәммәсе өчен зур түземлек сорала. Кайчак ышанычлы пегас-ат та һич көтмәгәндә чыгымчылап куя. Гаять авыр мәлдә төрле уйлар килә. «Нигә шигырь җанлы итеп Яраттың, Хода, нигә?!» дип өзгәләнә шагыйрә «Үзем хакында» исемле әсәрендә. Аны аңларга була. Еш үзгәрүчән халәт барыбер асылына кайта. «Күңелләрне горур тотып, бары Шигърияткә башны иик без». Иң үтемле йөрәк сүзенә яшьли иман китергән Халисә Мөдәррисова «Дуска» дигән шигырендә мөкатдәс антына тугрылык саклавын янә раслый. Аннары ул риясыз рәвештә канәгатьлек хисен дә белгертә.

*Язмышларның зәһәр давылында*
*Канатымны күпме канаттым;*
*Хәлем бетеп, өшеп егылганда,*
*Син күтәрдең, җырым-канатым,*
*Рәхмәт сиңа, җырым-канатым!*

Адәм баласының табигате шундый: ул әле барысы да алда, дип, күбрәккә өмет баглап гомер итә. Хәтта борынгы римлылар да кешеләрнең әлеге хасиятенә, яшәргә әзерләнүнең озак елларны колачлавына игътибар юнәлткән. Беркадәр беркатлылыкны хәтерләткән ошбу алдану, бәлки, иҗат әһелләрендә булырга тиеш түгелдер. Бигрәк тә шагыйрьләрдә. Үкенечле цейтнот шартларында язарга мәҗбүр ителгән мәшһүр затлар, ай-һай, мондый халәттә зур мирас калдырырга өлгерер иде микән?! Әгәр кыска вакыт эчендә тормыш тәҗрибәсе туплый алмасаң, замана чынлыгын киләчәк биеклегеннән торып яктыртуга ирешүең икеле. Артык зурдан купмыйча әйткәндә, Халисә Мөдәррисова әдәби эшчәнлегенең башлангыч чорында ук көн күрү өйрәнмәләреннән шактый отышлы файдалануын күрсәтә. Кырыс чынбарлыкның гыйбрәтле дәресләрен сабырлыклы рәвештә карышмыйча үзләштерү шагыйрәнең хис-тойгылар палитрасын яңадан-яңа мәгънәви төсмерләр белән баета. Җан-тәнне чыныктырган каршылыклар аның кичерешләрен тирәнәйтә, акылны үткерләү образлы фикерләү офыкларын киңәйтә. Боларның тәгаен нәтиҗәсе, әлбәттә, турыдан-туры әсәрләрдә чагыла. Ә Халисә Мөдәррисованың язганнары тәэсирле йөрәк сүзе буларак кабул ителә, чөнки аның ярсу йөрәгенә безне һәрьяклап сынаган иксез-чиксез дөнья сыя.

**Зиннур МАНСУРОВ**

# ХАКЫЙКАТЬ ЭЗЛӘҮ ЮЛЫНДА

## ЗӨФӘР РӘМИЕВКӘ 80 ЯШЬ



Хәзерге татар әдәбият фәнендәге эзләнүләрнең, табыш-казанышларның фәнни-нәзари нигезен, мөһим тенденцияләрен билгеләүче галимнәрнең берсе – филология фәннәре докторы, танылган текстолог, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Зөфәр Рәмиев. 50 елдан артык гомерен татар әдәбияты фәненә, аның зур хезмәт һәм тырышлык, тирән белем сорый торган текстология өлкәсенә багышлаган шәхес ул. Аның киңкырлы галим булуы, әдәбият фәненең текстология, библиография, шулай ук тарих, культурология кебек өлкәләрен яхшы белүе, шуларга нисбәтле мәдәни мирасын өйрәнүе, аны халыкка кайтаруы белән чын мәгънәсендә тирән хөрмәт уята.

Әдәбиятчы һәм текстолог буларак танылу алганчы, аңа шактый урау юллар үтәргә туры килә. Зөфәр Зәйни улы Рәмиев 1938 елның 24 июнендә Кама Тамагы районының Уразлы авылында (Иске Каратайда) туып үсә. Әтисе Зәйнелгабидин төрле һөнәр иясе булып, колхозда хезмәт итә. Бөек Ватан сугышында өч тапкыр яраланып, 1945 елны хәрби госпитальдә үлә. Әнисе Фәхрелбәнат, колхоздагы хезмәттән тыш, тегү белән шөгыльләнгән, гармунда уйный белгән. Үзенең тел-әдәбият белән кызыксынып китүендә гарәп, латин, кирилл графикаларында иркен укый-яза белгән әнисенең йогынтысы зур булган дип саный Зөфәр ага. Сугыш һәм сугыштан соңгы елларда өч улын һәм каенанасын тәрбияләүгә бөтен көчен биргән, кыен вакытларда да якты йөзе, ярдәмчел булып кала алган әнисенә гомере буе рәхмәтле ул. Үз авылында башлангыч, күршедәге Олы Карамалыда урта мәктәпне тәмамлагач, яшь егет Казандагы техник училищега укырга керә. Шуннан соң аның «тормыш университетлары» башлана: заводта фрезерчы, Казан университетының читтән торып уку бүлеге студенты, өч ел да ике айга сузылган хәрби хезмәт, Кама Тамагы районында чыгып килгән «Кызыл байрак» газетасы хезмәткәре, туган авылында укытучы, Олы Бортас сигезьеллык мәктәбендә директор, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр. Зөфәр агага тормышта үз урынын, күңеле яткан хезмәтне табу шактыйга сузыла. Әмма бу еллар аның өчен белем алу, тәҗрибә туплау, тормышны өйрәнү еллары була. 1970 елда ТӘһТИның әдәбият бүлегендә кече фәнни хезмәткәр булып эшли башлаган З.Рәмиев алдагы елларда кандидатлык (1973) һәм докторлык (2002) диссертацияләре яклый, текстология бүлеге мөдире, Институтның фәнни эшләр буенча директор урынбасары вазифаларын башкара, диссертацияләр яклау советы әгъзасы, байтак еллар аның гыйльми сәркатибе булып эшли.

З.Рәмиев, аспирантурада укыганда, Сибгат Хәким поэзиясен өйрәнә һәм шул чор әдәбиятын өйрәнүдә яңа эзләнүләргә нигез сала. Бу өлкәдәге тикшеренүләрен үстерә барып, З.Рәмиев әдәби процесстагы яңа сыйфат-билгеләрне ачыклауга килә, аерым әдипләрнең (Шәйхи Маннур, Әнвәр Давыдов) иҗат портретларын тудыра.

Үз чоры шигърияте З.Рәмиевнең игътибарыннан читтә калмаса да, яшь галим бераздан фәнни тикшеренүләренең үзәген тәшкил итәчәк чорга – XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүгә килә. Ул серле дә, мавыктыргыч та текстология дигән фән дөньясына атлый. Атамасында текст белән эшләүгә ишарә булган әлеге фән әдәбият белеме буенча тикшеренүләрне исәпкә алучы библиография, текстлар язылган материалны һәм язу почеркын ачыклаучы палеография, аноним әсәрләрнең

яисә тәхәллүсләрнең авторын билгеләү белән шөгыльләнүче атрибуция, шулай ук историография, китапханә белеме һ.б. тармаклары белән тыгыз бәйле булып, алардагы табышларны да файдалана. Әдәбият тарихының аерылгысыз юлдашы – текстология әдәби текстларның тарихын һәм чыганакларын өйрәнә, төрле вариантларны чагыштыра, аларның үзенчәлекләрен искәрмә-аңлатмаларда чагылдыра.

XX гасырның 70-80 нче еллары XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүдә үзгә бер дәвер булып тора. Бу елларда «алтын чор»ның сан һәм сыйфат үзгәрешләрен өйрәнү, әдәбият тарихындагы урынын билгеләүгә нисбәтле алып барылган тикшеренүләр белән бергә, классикларыбызның күптомлык сайланма әсәрләрен җыю, туплау һәм бастырып чыгару буенча гаять җитди һәм күләмле эш башкарыла. З.Рәмиев җитәкчелегендә яисә аның актив катнашында М.Гафуриның 4 томлыгы (1980-1984), Г.Камалның 3 томлыгы (1979-1981), Ф.Әмирханның 4 томлыгы (1984-1989) дөнья күрә. Ә инде җәмгыятьтә үзгәртеп корулар башланып, милли тарихка, әдәбият-сәнгатькә игътибар арту белән, якындагы һәм ерактагы тарихи-мәдәни ядкәрләрне торгызу, өйрәнү, бәяләү, киң җәмәгатьчелеккә җиткерү эше тагы да колачлырак төс ала. З.Рәмиев тарафыннан Н.Думавиның «Тормыш сәхифәләре» (1985; Р.Ганиева белән берлектә), «Татар шигърияте: XX йөз башы. Лирика» антологиясе (2004), С.Сүнчәләйнең «Әсәрләр һәм хатлар»ы (2005), Г.Сөнгатинең «Шигырьләр һәм проза»сы (2007), коллегалары белән берлектә Г.Тукайның 2 томлыгы (2006), М.Җәлилнең 5 томлыгы (2006), «Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы)» (2006), «Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (Урта гасырлар – XX йөз башы)» (2006) һ.б. җыентыклар, китаплар дөнья күрә. Әдипләрнең тормыш юлы турында материал туплау, әсәрләренең язылу һәм басылу вакыты, автор кулъязмасы белән басылган хезмәтнең тәңгәллеге, авторлар текстларында телгә алынган шәхесләр, атамалар, шәһәр-авыл исемнәре, тарихи вакыйгалар – болар барысы да җентекле шәрехләүне, объектив тикшерү-бәяләүне сорый. Шуңа да З.Рәмиевнең әлеге хезмәтләре – айлар-еллар дәвамында гарәби язулы газета-журналларны өйрәнү, архивларда эзләнү, төрле чорларда басылып чыккан китап-җыентыкларны чагыштырып бәяләү нәтиҗәсе ул.

Әдәбият тарихының мөһим тармагы булган текстология фәне үз эчендә күпсанлы теоретик, аннан да бигрәк гамәли-фактик сораулар тудыра. Галим аларны фәнни яктан тикшерүгә алына һәм дистәләрчә мәкалә яза, фәнни конференцияләрдә, семинарларда, очрашуларда чыгышлар ясый, «XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре» (2000), «Текстология татарской литературы начала XX века» (2008), «Әдәбиятчы-текстолог язмалары» (2014) дигән монография һәм җыентыклары басылып чыга. Үзенең күпьеллык тәҗрибәсенә һәм бөртекләп диярлек җыйган фактик материалларга нигезләнеп, З.Рәмиев фәнни-теоретик һәм гамәли яссылыкта әдәби текстларның авторлыгын ачыклау мәсьәләсен өйрәнә. Үзеннән элгәре хезмәт куйган галимнәр тәҗрибәсенә таянып, беренче чыганакларга мөрәҗәгать итә, имзаларга бәйле һәр детальне җентекләп тикшерә, чагыштыра һәм бары тик дәлилле булганда гына нәтиҗәләр ясый. Нәкъ менә яшерен имзаларга бәйле эзләнүләре Тукайның 5 томлыгына кермәгән әсәрләрен ачыклау мөмкинлеге бирә. Шул ук вакытта истәлекләрдә чагылыш тапкан фактларны, хәбәрләрне тикшермичә генә кабул итүнең ялгыш нәтиҗәләргә китерүен дә күрсәтә. Күпләргә яхшы таныш «Сөй гомерне...» дип башланган бер шигырь, истәлеккә таянып, Г.Тукайныкы буларак бәяләнә, күп томлыкларына урнаштырыла иде. Галим исә әсәрнең 1912 елда (Тукай исән вакытта ук) «Йолдыз» газетасында С.Сүнчәләй имзасы белән басылуын ачыклый.

Үзенең тикшеренүләрендә З.Рәмиев әсәрләрнең төп текстын билгеләү мәсьәләсенә дә туктала. Моның өчен текст үзгәрешләрен үзендә чагылдырган барлык кулъязмаларны һәм басма материалларны үзара мөнәсәбәттә өйрәнү кирәклеген ассызыклый ул. Мисал өчен, күпсанлы кулъязмаларны тикшерү аша Г.Тукайның «Яшен яшьнәгәндә», «Кечкенә музыкантлар», «Золым» шигырьләрендәге хаталарны таба, Г.Коләхмәтовның «Яшь гомер», М.Гафуриның «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» әсәрләренең цензура тарафыннан кыскартылуын дәлилли.

З.Рәмиев үзенең күпкырлы эшчәнлеге белән әдәбият тарихының аерым сәхифәләрен ачыклауга, тулыландыруга да зур өлеш кертә. Аның М.Гафури, Г.Камал,

Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, З.Ярмәки, З.Бәшири, Н.Думави, С.Сүнчәләй, М.Укмасый, Ә.Сәгыйди, З.Сәгыйдә, Гыйффәт туташ, Г.Монасыйпов, Р.Ибраһимова, Г.Сөнгати, К.Тинчурин, Ф.С.-Казанлы, М.Җәлил, Г.Исхакый турында төрле газета-журналларда, җыентыкларда, шулай ук алты томлы «Татар әдәбияты тарихы»ның 4 нче һәм 5 нче томнарында урын алган мәкаләләре фактик байлыгы, теге яисә бу әдип иҗатын чор әдәби процессы белән тыгыз бәйләнештә тикшерүе, фикер-карашларының ачыклыгы, төгәллеге, фәнни нәтиҗәләре, гомумиләштерүләре белән зур кызыксыну уята, еш кына фәнни бәхәсләргә, яңа эзләнүләргә юл ача.

З.Рәмиевнең фәнни эшчәнлегендә аерым игътибарга лаек ике бөек иҗади шәхес бар, алар – Г.Тукай һәм Г.Исхакый. Тукайга галим гомере буе мөкиббән булып, аның иҗатын бөтен тулылыгында халыкка кайтаруга, әһәмиятен, зурлыгын аңлатуга һәм, ниһаять, 1990 еллар ахырыннан башлап «Тукай энциклопедиясе»н булдыруга бөтен көчен куя. Остазы һәм хезмәттәше Н.Юзиевның кинәт вафатыннан соң, әлеге җаваплы эш белән җитәкчелек итү Зөфәр ага Рәмиевкә йөкләнә. Г.Тукай иҗатына, аерым әсәрләренең текстына, язылу яисә басылу тарихына нисбәтле, шулай ук Тукай иҗатының әдәби-эстетик кыйммәте, башка халыклар әдәбиятына шифалы йогынтысы, татар халкының милли символына әйләнү сәбәпләре турында аның дистәләрчә мәкаләсе һәм «Тукай һәм замандаш әдипләр» (2004) исемле җыентыгы басылып чыга. З.Рәмиевнең оештыру сәләте, галим-голамәне максатчан эшкә тарту осталыгы, һәркем белән уртак тел табып эшләве нәтиҗәсендә 2016 елда Г.Тукайның күптән көтелгән 6 томлы Академик басмасы һәм «Тукай энциклопедиясе» дөнья күрә. Күпсанлы авторлар коллективы тарафыннан башкарылган әлеге хезмәтләр татар әдәбият белеме, текстология фәненең гаять җитди казанышы булып тора дияргә кирәк. «Тукай энциклопедиясе» татар әдәбият фәнендә беренче шәхси энциклопедия буларак та тарихта үз урынын алачагына шикләнмәскә мөмкин. Инануымча, «Тукайчы-галим» дигән исем-бәя – Зөфәр ага Рәмиев гыйльми эшчәнлегенең иң зур нәтиҗәсе ул.

Исеме 1990 еллар башында халыкка кайткан Г.Исхакыйның язма мирасын барлау, аның төрле илләргә чәчелгән әсәрләрен җыю, туплау, бастырып чыгару мәсьәләсе дә З.Рәмиев игътибарыннан читтә калмый. Яңарыш чоры татар әдәбиятының башында торган олы әдипнең 15 томлы басмасының 6-15 нче томнарын (ун томын) әзерләүгә дә катнашып китеп, текстология бүлеге хезмәткәрләреннән Ф.Ибраһимова, Э.Галимҗанова, Г.Хөснетдинова, З.Мөхәммәтшин, Ф.Фәйзуллина, Г.Ханнанова, Р.Кадыйровлар белән берлектә әлеге җаваплы, четерекле эшне уңышлы башкарып, соңгы томны 2014 елда укучыларга җиткерәләр. Бу фәнни төркемнең чын мәгънәсендә фидакарь хезмәт җимеше югары бәяләнә – 2016 елда З.Рәмиев, Л.Гайнанова, Ф.Ибраһимова, З.Мөхәммәтшин ТР Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

З.Рәмиев – Н.Юзиев, Х.Хәйри, М.Гайнуллин, Г.Халит кебек остазларына, гомумән, барлык хезмәттәшләренә ихтирамлы карашы, яшьләргә исә игътибарлы, мөлаем мөнәсәбәте белән тирән хөрмәт казанган шәхес. Һәр эшкә җаваплы каравы, сабырлык-тынычлыгы белән дә һәркемне үзенә җәлеп итә. Зөфәр ага үзенең уңышлары өчен, аңа таяныч-терәк булган гаиләсенә бик тә рәхмәтле. Хәләл җефете Резеда Кадыйр кызы Ганиева – филология фәннәре докторы, профессор.

Зөфәр ага гомеренең күп өлешен Казанда яшәсә дә, туган ягы – Кама Тамагы районы, якташлары белән тыгыз бәйләнештә була, туган җир җылысын, аның җыр-моңын күңелендә саклый, шуннан көч алып яши. Үзенең туган җиренә, авылына, авылдашларына булган җылы хисләрен «Уразлы (Уразлино, Иске Каратай) авылы үткәненнән» (2004), «Булды сугыш, күрде авылым...» (2005) дигән китапларында чагылдыра.

Зөфәр ага Рәмиев бүген дә фәнни иҗат эшендә. Коллегалары белән бергә, татар әдәбиятының кульязма һәм язма мирасын өйрәнеп, аны киң җәмәгатьчелеккә җиткерү өлкәсендә хезмәт итә. Олы галим, зыялы шәхес З.Рәмиев мәртәбәле классикларыбызның шәхси энциклопедияләрен эшләү, күптомлы академик басмаларын чыгару, бай әдәби мирасыбызның яңа катламнарын халыкка кайтару теләге белән рухланып яши.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,**
*филология фәннәре докторы*

*Рифкать Закировның (1938-2007) татар әдәбиятында үз урыны бар. Аның иҗаты, башта, укучыга «Беренче карлыгачлар» (1968) исемле җыентык аша килеп иреште шикелле. Шактый саллы, иллеләп шигырен туплаган җыентык иде ул. Актаныш районының Усы авылында туып-үскән бу шагыйрьнең моңсу лирикасы шунда ук күпләрнең игътибарын җәлеп итте. Матбугатта тәфсилле бәяләмәләр басылды. Әхмәт Рәшит, Рәдиф Гаташ, Госман Садә һәм башка күренекле шагыйрьләребез Рифкать Закировка хәерхаһлык күрсәтеп, иҗатка рухландырдылар.*

*Әлбәттә, Ерак Көнчыгышта Совет Гаване шәһәрендәге төзелешләрдә эшләгән, Урал шахталарында күмер кискән шагыйрьнең иҗаты туган туфракка береккән, бөтен вөҗүде белән җирнеке иде. «Шагыйрьләр юлы – киек каз юлы», дип язса да, ул бу хакта да җирдән торып фикер йөрткәндер, мөгаен. Моң-сагыш белән өртелгән шигырьләрен укыган саен, кеше гомере һәм мәңгелек турында уйланасың. Хәер, шагыйрьнең язмышы шундый: ул иҗаты белән күңелләрдә яши бирә...*

# Рифкать Закиров

## Безнең балачак

Безнең балачак – ертылган китап...
Яланаяклап узылган этап...
Калды йөрәктә,
Калды еракта,
Уеннан туктап, сыкрап та сыктап!

Кызык җирендә бүленде уен...
Бүлү-бүленү кыенмы? Кыен!..
Әткәң юк инде,
Гомере өзелде
Куганда илдән «бүреләр» туен.

Бас сабан яки тырма артына,
Бик сырпаланып торма атыңа;
Сугыш җан сорый,
Тормыш нан сорый –
Ничек булса да тырыш, тап кына!

Авыр йөк башы – арык иңнәрдә.
Ир-егет башы – ерак җирләрдә...
Сынасын илең,
Сынмасын билең,
Кыен көннәрдә кирәк түзәргә!

Түзәргә кирәк! Җиңәргә кирәк! –
Булдык җиргә дә, илгә дә терәк:
Җирне җылытып,
Илне хис итеп,
Һаман көчлерәк типте яшь йөрәк!..

...Инде уй-хыял аша күз салгач,
Балачагыма: «Нихәл, – дип, – адаш?..
Әллә көенеп,
Әллә сөенеп,
Карый елмаеп ул яшь аралаш...

## Галиҗәнап Вакыт

Вакыт узып бара,
Эзе, төсе кала:
Йә кан булып ага,
Йә яшь булып тама.

Вакыт мәңге ага
Бары артка таба...
Еллар гына алга
Елгыр аттай чаба!

Берәү – юл башында,
Берәү – юл чатында;
Кемдер – уртасында,
Кемдер – җир астында.

Үлемсез, дип, Җирдә
Бары Үлем генә,
Күпләр ята гүрдә
Сабыр-түзем генә.

Ә Вакытка чик юк:
Бакый агып тора...
Куя сәгать сугып, –
Вакыт ашыктыра!

Тора безне көтеп
Серле билгесезлек:
Кемне – күңелсезлек...
Кемне – үлемсезлек!

## Киләчәк

Ялгышларым минем – ачы әрем,
Күрәчәгем минем – күк чәчәк.
Әрем белән чәчәк арасында
Күренде гел минем Киләчәк.

Күрәчәкне күрәм!..
Тик көттергән
Киләчәк тә тиздән киләчәк:
Әремнәрне өзеп изәчәк тә
Чәчәк җыеп миңа бирәчәк!

## «Ак карга»

Калдым микәнни җиде ятларга,
Качыйм микәнни җиде якларга?
Бар да кап-кара, бер мин «ак карга»,
Кай тарафларга белмим атларга...

– Атла, – ди, – бире, җиде юл чаты,
Тарткалый кире җиде юл чаты;

Заман шулчаклы катлаулы-катлы,
Ә мин һаман шул – сабыр, беркатлы.

Җиде юл дәшә җиде чатларга,
Тик бозы-ташы тора чатнарга...
Кызыл кар түгел, яумый ак кар да, –
Якты кыйблам кайсы якларда?!

Боздан табанны куптара торам,
Туңган тән-җанны коткара торам;
Чынлап әллә нәкъ уртада торам,
Әллә иң биек ноктада торам?..

Кайда торсам да, ятка сер бирмәм:
Артка егылмам, алга бөгелмәм!
Тик яшьне сөртеп, баш исәм иям,
Бөртек наз көтеп Туган җиремнән!

## Булырмы инандырып?..

Керсездән керсез булмаса
Күңелем әгәр минем,
Күк йөзендә күрмәс идем
Күземнең зәңгәрлеген!

Әгәр тузан бөртегедәй
Тап кунса намусыма,
Төс булырмы саф күз яшем
Пакь, чиста агымсуга?!

Иңгә илем таянырлык
Булмаса иманым нык,
Исемем, җисемем бар дип,
Булырмы инандырып?..

## Авылым кызына

Мин кайттым сине сагынып,
Сөюем сүрелмәде...
Элеккечә яланаяк
Каршыма йөгер әле!

Йөгер әле, пар канаттай
Кагынсын толымнарың.
Йөгерүдән, шат көлүдән
Кабынсын тының, җаным!..

Килеп җит тә, елдагыча,
Сарылып муеныма,
Сора: «Абый, нинди бүләк
Алдың, – дип, – быел миңа?»

Тик кая син? Быел тагын
Качтыңмы полосага?..
Чык тизрәк, булма, җаным,
Син һаман бала-чага!..

Беләм инде: шаяртмакчы
Буласың мине юри...
Чү! Кем ул басу түрендә
Чәчәкләр җыеп йөри?

Син икән бит, авылым кызы!
Ахыры, шулай итеп,
Каршылыйсың быел мине,
Җитлегеп, буйга җитеп!

Килче тизрәк, ашык, кызый,
Күземдә, күрәсеңме
Ничә еллар зарыгып көткән
Бүгенге сурәтеңне!..

## Мәхәббәт турында җыр

Бер кыз җырлый...
Беренче кат
Ишетәм мин бу тавышны:
Каян ала ул шулкадәр
Үзәк өзгеч моң-сагышны?!

Егет җырлый...
Җырлый егет,
Җырлый әле ничек кенә:
Шатлыктан ул әйтерсең лә
Җырлап түгел, биеп килә, –
Башы күккә тиеп килә!..
Югыйсә бит икесе дә
Бер үк җырны җырлый алар!..

Һәй дөньялар,
Вай дөньялар...

*Шагыйрь Фәннур Сафинның (1948-1992) романтик шигъриятен күңел тиз тоя, тиз таный. Инде ул сагындырган да шикелле. Әлбәттә, беренче чиратта, төсемоңы белән якты җырлары һич онытылмый, аларны бүген дә яратып җырлыйлар. «Хушлашырга ашыкма», «Ялгыз көймә», «Җырымда юатырмын» һ.б. шигырьләре көйгә салынып, заманалар агышына җайлашып, чордан-чорга күчә киләләр. Хәер, бу табигыйдер дә. Чөнки, битараф җаннарны да сискәндереп, дертләтеп куярлык халыкчанлык, хис тирәнлеге һәм илаһи җегәр бар аның шигъриятендә.*

*Туган җире – Татарстанның Минзәлә районы Күзкәй авылыннан күңел биштәренә салып, олы юлга алып чыккан яшьлек романтикасын да ахыргача, югалтмыйча саклый алган шагыйрь шул ул. Ил, халык язмышы турында уйланганда да, «Без кемнәр?» дип үз-үзенә сорау биргәндә дә, Фәннур Сафин көчле-җегәрле егет булып, яшьлек аша эндәшә һәм һаман да безгә үзенчәлекле иҗаты белән яшьлек бусагасыннан карап торадыр кебек...*

# Фәннур Сафин

## Сез кемнәр?

Сез кемнәр, сез кемнәр, сез кемнәр?
Сихерле киртәме юлларда?
Томаннар аша без үреләбез
Күрешергә үрелгән кулларга.

Абынган, егылган чак була,
Барысын аңлыйсыз, күрәсез.
Ялына ут капкан толпардан
Кул сузып, төшләргә керәсез.

Ничәмә мәртәбә бит инде
Киләчәк өчен сез янасыз!..
Без юлга чыкканда,
кул болгап,
Ялкыннар эчендә каласыз!..

...Шартлаулар, янгыннар яктыртса,
Барыбер караңгы ул төннәр...
Шул төндә яндыгыз, туганнар,
Менә бит сез кемнәр, сез кемнәр...

Янды тән, янды кан – җан калды,
Шуңамы якты бу ак көннәр?
Һәм шуңа ни булыр җавабың? –
Без кемнәр, без кемнәр, без кемнәр?!

Зур серләр ачсак та – без кемнәр?
Галәмгә очсак та, шул сорау!
Илләрдән китсәк тә, кайтсак та,
Ярларны кочсак та – шул сорау!..

...Төшләргә керәсез, күрәсез:
Шул юлда безнең дә гомерләр.
Моңлаган күз карый бу чорга:
– Сез кемнәр, сез кемнәр?
                    Сез кемнәр?!

## Музей ачтым...

Мин гаҗәеп музей ачтым.
                    Анда
Фатих Кәрим язган каләм бар.
Мин өр-яңа музей ачтым.
                    Анда,
Кутуй кайта, дигән хәбәр бар.

Минем музеемда Мөҗәйләрдән,
Алишлардан яңа хатлар бар.
Анда Җәлил ярсып шигырь укый!
Ә янында...
Аның башын кискән балта бар.

Музеемда –
    канәфер чәчәкләре,
кашкарыйлар,
    кыргый гөләпләр.
Ядрә тишеп үткән йөрәкләр бар,
үтерелгән җырлар,
    теләкләр...

Музеемда – каен тузы түгел –
ә кешеләр янган мичләр бар,
һәм солдатлар сөйгән хатыннарын
соңгы тапкыр кочкан кичләр бар...
Ярсу хисләр, бетмәс үчләр бар!..

Табалмассыз ләкин ул музейны,
җитсәгез дә җирнең читенә...
Яңа музей – минем йөрәгемдә,
    килегез сез аңа,
        Кешеләр!..

## Дөнья...

Кемдер дәшми шәһит китә,
Туры калыр өчен.
Кемдер яши, тугры сүзне
Ярып салыр өчен.

Кемдер яши, тыныч кына
Гомер үтсен, диеп.
Яки минем алда дөнья
Тезен чүксен, диеп.

Кемдер яши «сөям...» дигән
Бердәнбере өчен.
Һәм кемгәдер күкрәгеннән
Ялкын өрер өчен...

Шул кемнәрдер өчен бу җир
Борчыла, сөенә:
Бер карадан киенә ул,
Бер актан киенә...

## Әнкәй!..

*(Бер көндәлектән)*

Үз илем бар, рәхмәт, әнкәй!
Үз телем бар, рәхмәт, әнкәй!

Дөньяларда ямьнәр табып,
Дулкынланып, ярсып-янып
Яшәү шундый рәхәт, әнкәй, –
Барысы өчен рәхмәт, әнкәй!

Ризык биргән,
гомереннән
өзеп биргән син үк, әнкәй...
Ләкин бөтен рәхмәтләрне
ничек әйтим? –
Син юк, әнкәй...

## Онытмадым

Туган якның мамык карын,
Катлам-катлам болытларын –
Онытмадым!..

Күкчәчәкле болыннарын,
Балкып торган кызыл ярын –
Онытмадым!..

Никтер тагын Ык суларын,
Бөдрә-бөдрә яшел талын –
Онытмадым...

...Янә кайттым.
Тауларына менеп бактым,
Ярларына төшеп яттым,
Иләсләнде күңел. –

Онытылырлык түгел
Берние дә Туган якның –
Балачакның...

## Җитми!

Җитми бәхет, шул бәхетне
табар өчен гомер җитми.
Кышын кояш булмаганда,
җылынырга шигырь җитми.

Җитми дуслар, күзләр җитми,
арттан килеп дошман бәрсә.
Һәм җитми бер-берең өчен
калкан булу дигән нәрсә.

Син дә, дускай, уйланасың,
карашларың моңсу-җитди.
Карашлар да берни түгел,
Яратуың синең җитми!..

## Алма бакчасында

Туп-туп коела алмалар,
«Син!» дип барсам – җил исә.
Ул алманы мин үзем дә
Өзәр идем югыйсә.

Өзәр идем...
Һәм, әйтерсең,
Гомер буе, бер генәм,
Кычытканга чагыла-чагыла,
Мин алмага үреләм.

Ә ул алма йолдыздан да
Югарырак икән бит!
Юкка җанны ышандырам,
Беркөн буем җитәр, дип.

Җиталмагач, өмет өзеп,
Күзләр түбән карады.
...Күктән эзләгәнмен икән
Яныма төшкән алманы!..


Фото К.Кәримов архивыннан.

*1976 елның маенда, бер төркем язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, рәссамнар, артистлар – кыскасы, татарның иҗади киләчәге, Халыкара «Идел» яшьләр лагерена атналык семинарга җыелды. «Казан сөйли» радиосыннан «Репортёр» диктофонын күтәреп, журналист Флүс Латыйпов килгән иде. Минем, 26 яшемдә, I курс студенты икәнемне белгәч (әлбәттә, көндезге бүлектә), әңгәмә корып, «Яшьлек» программасыннан сөйләткән иде. Ярый, хуш, семинарлар үтте, мин дә II курска күчтем. Зиннур Гыйбадуллин белән «Шәле тәрәзәләре» дигән җыр язгач, туп-туры Флүс Латыйповны эзләп киттек. Җыр студиядә Флёра Сөләйманова башкаруында язылды. Ләкин, худсовет расламыйча, аны эфирга чыгармаячаклар икән, Флүс абый озак уйлап тормады, «Репортёр»ын бирде дә: «Бар, Шәлеңә кайтып, тапшыру әзерләп кил», – диде. Шул форсатка сылтап, җырны бөтен татар дөньясына ишеттерә алдык.*

*«Ком сәгате» романымны «Казан утлары»на тапшыргач, аны иң беренче булып, ул елларда инде «Ишелеп төшкән бәхет», «Бәйсез этләрне атарга», «Хыянәт» романнары белән киң танылган язучы Флүс Латыйфи үзе укыган һәм баш мөхәррир Равил Фәйзуллинга, бу егетне журналга эшкә алырга кирәк, дигән.*

*Журналист, язучы, милләтпәрвәр Флүс Латыйфиның соңгы утыз елы минем күз алдымда калды. Редакциядә аның 60 яшьлеген (2003) бәйрәм иткән идек. Шул көннәрнең бер фотосын да тәкъдим итәбез. Ул чәчәк бәйләме тоткан килеш арабызда калды.*

*Туына 75 ел тулу уңаеннан, Флүс Латыйфиның «Аяклы каза» дигән хикәясен тагын бер тапкыр искә төшерик.*

**Камил КӘРИМОВ**

Флүс
Латыйфи

# АЯКЛЫ КАЗА

Шәһәр мунчасы. Шау-шу, ыгы-зыгы... Әтиләренә ияреп килгән бала-чага газлы су автоматы янында мәш килә. Тамагы кипкән Искәндәр автомат янына үтә алмады, дөресрәге, чыр-чу килгән бала-чаганы аралап узуны яхшысынмады.

Гаилә башлыклары малайларының үзара көрмәкләшүенә мыек астыннан гына елмая.

– Бу ташбашыңа күпме инде?

– Унынчы белән бара. Егет булып килә, егет!..

– Әйдә, бәхет-тәүфыйклары белән үссеннәр. Дөнья шулар белән кызык...

– Шулай шул! Әле менә кечесе елап калды, мин дә эти белән барам, ди...

– Барыр. Вакыты җиткәч, этисе белән дә барыр, этисеннән башка да...

«Тапканнар сөйләшер нәрсә. Өйләрендә күреп туймаганнардыр, мунчага килеп тә шуларны сөйләмәсәләр». – Чиратының бер урында таптануына ачуы кузгалган Искәндәр аяк астында буталучы бала-чагага каш җыерды.

Шулчак, кемнеңдер үзенә карап торганын сизеп, башын күтәрде. Гадәттә мунчага киелә торган иске җәйге пәлтә кигән, гади ситсы яулыкны маңгаена ук төшереп бәйләгән хатын иде ул. «Ирләр бүлегендә нишләп йөри икән бу?» – дип сәерсенергә генә өлгерде Искәндәр.

Хатын кыенсынып кына эндәште:

– Зинһар өчен, үзегез белән минем малайны да алып керегез әле?.. Хатынның алты-җиде яшьләр тирәсендәге бала җитәкләгән булуын Искәндәр шунда гына күреп алды.

– Юк, юк! Мин озак юынмыйм. Бер генә коенам да чыгам, – диде ул, ризасызлыгын яшереп тормыйча. – Алып керә алмам...

Хатын, нәүмизләнеп, Искәндәрне үзенчә тынычландырырга ашыкты:

– Сез... борчылмагыз. Аңа берни дә кирәкмәс. Үзегез белән чишендереп, бер-ике ләгән су китереп бирсәгез, шул җитәр. Ул сезгә мәшәкать ясамас. Үзе юына ул... Янәшә утыртсагыз...

Кашларына кадәр төшкән яулыгы астыннан күренгән, зур булып ачылган зәңгәр күзләрендә ялвару да, өметләнү дә, чарасызлыктан аптырау һәм гаҗизлек тә чагыла иде.

Аның халәтен күзләреннән, гәүдә тотышыннан аңлаган, кешенең түбәнсенүен яратмаган Искәндәр хатынны уңайсыз хәлдән коткарырга ашыкты, теленнән рөхсәт сүзләренең ычкынганын да сизмәде:

– Ярар, алайсаң...

Үзе ирексездән уйлап куйды: «Шушы йолкыш кына җитмәгән иде ди миңа!..»

– Йокладыңмы әллә? Нигә кермисең?

Аркасына төртүдән сискәнеп китте. Уйга чумып, чираты килеп җиткәнне дә сизмичә калган икән. Пәрдә артыннан мунчачының карлыккан тавышы ишетелде:

– Следующий...

Ишек яңагына сөялеп баскан һәм әнисе киткәннән бирле бер сүз дә дәшмәгән малай күзләрен тутырып Искәндәргә карады, букчасын бер кулыннан икенчесенә күчерде.

«Бу аяклы казадан котылып булмас, ахры».

Үзенә тапшырылган малайга эчтән генә шундый кушамат тагып өлгергән иде инде ул. Әллә соң юынмыйча кайтып китәргәме, дип эче пошып утырган Искәндәр көрсенеп куйды һәм малайның аркасыннан этте:

– Әйдә!

Каен себеркесе, сыра һәм дым исе аңкыган чишенү бүлмәсендә буш урыннар күренми иде. Малайны берәр җиргә урнаштырырмын да котылырмын диебрәк кергән Искәндәр күзләре белән бүлмәне тагын бер кат айкап чыкты. Урын булмаган көйгә керергә чакырган мунчачы картны эчтән генә тозлап-борычлап, җиде буын бабасын искә алып сүгенеп куйды, икенче рәттәге эскәмияләр ягына борылды һәм түр башындагы почмакта әлеге дә баягы малайны күреп алды, теше сызлагандай йөзен чытты. «Аяклы каза» буш эскәмия тапкан, әйберләрен куйган һәм чишенмичә аны көтә иде.

Искәндәр сүзсез генә аның янына килеп утырды, малайдан барыбер котылып булмаячагына үртәлеп, чишенергә кереште, коры гына итеп әйтте:

– Чишен! Өстеңне сал...

Шуны гына көтеп торган малай ипләп кенә күлмәген, майкасын, бераз мыштырданып алгач, чалбарын салды, әнисе әзерләп биргән төргәктән мунчала-сабынын чыгарды.

– Бар, кереп урын ала тор!

Барыбер кичем әрәмгә узды, дип уфтанган Искәндәр үзе керергә ашыкмады. Таш юынгычлардагы урынның бушавын көтеп-эзләп интегәсен белгәнгә, кеше өстендә торып, күз көеге буласы килми иде. Чыгар әле берәрсе! Үзенә тагылган малай турында исә ул инде бөтенләй оныткан иде. Алып керде, эше бетте. Юынып чыгар әле шунда!..

Юыну бүлмәсендә гадәти шау-шу. Мәрмәр вагыннан ясалган тәбәнәк таш эскәмияләргә бәрелеп, калай ләгәннәр шакылдый, чажлап су акканы ишетелә, шушы тавышлар, ир-атның өзек-өзек авазларына кушылып, ниндидер бер тоташ гүелдәү хасил итә, керә-керешли үк башны урап ала. Искәндәргә бу тавыш, мондый гүелдәү таныш кына түгел, хәтта тансык иде. Танышларыннан берәрсе очрар, рәхәтләнеп, арка тиреләре суела башлаганчы чабынырбыз дигән өмет тә юк түгел иде.

Килеп керүгә үк нәкъ ишек төбендәге утыргычта «аяклы каза»ны күреп алды. Ул таш эскәмиягә ике ләгән китереп куярга өлгергән, сабын-мунчаласын таратып ташлаган. Башы аска иелгән. Кабыргалары беленеп торган юка, арык тәненә су тамчысы да тимәгәнлеге әллә каян күренеп тора иде. Шулчак Искәндәрнең йөрәге моңарчы булмаган әллә нинди сәер бер авырту белән чеметеп куйды. Күптән, бик күптән мондый хисне татыганы юк иде аның. Кызганумы ул, шушы үтә садә һәм ярдәмгә мохтаҗ, ышанучан җан иясенә ярдәм итәргә теләү идеме – анысын үзе дә аңламады.

– Йә, урын таптыңмы? – дип эндәште моңарчы юньләп сөйләшмәвенә үкенеп өлгергән, шул ук вакытта мәгънәсез сорау бирүен абайлап алган Искәндәр. «Тапкан бит инде, урнашкан. Ахмак! Шушындый сорау бирәләр димени?!» Малай белән ничек сөйләшергә, ничек аңлашырга кирәклеген Искәндәр, чынлап та, белми иде. Бу сиңа ике сүзнең берендә кемнеңдер анасын искә төшереп яисә җилбәзәк хатыннарны аңлатучы канатлы гыйбарәләрне кыстырып сөйләшү, тулай торакның азау ярган мужиклары белән аңлашу түгел шул. Әмма ни гаҗәп, шушы мәгънәсез сорау да малайга җитә калды, ул башын күтәрде һәм, «Әйе!» дигәнне белдереп, рәхмәт тулы күзләрен аңа төбәде. Алары нәкъ әнисенеке икән. Искәндәр бер мизгел эчендә шуларны абайлап өлгерде.

– Әйдә, юныйк инде, алай булгач!.. Аркаларны ышкышырбыз...

Әйтеп бетерүе булды, тагын үз-үзен тиргәп куйды. «Юк инде, бала-чага белән бала-чага булып булмый. Әнә малайлары әүмәкләшкәндә авыз ерып утырган адәмнәргә тагарга кирәк иде моны». Эчтән генә малайның әнисенә төбәлгән, баштан ук аңа әйтергә кирәк булган сүзләрне уенда кабатлады Искәндәр һәм барысына да яңадан кул селтәде. «Ярар, су китереп бирсәм...»

Малай урыныннан сикереп төшкән, ләгәнен күтәреп Искәндәрне көтеп тора иде инде. Егет кайнар су белән эскәмияне юып төшерде, пешекләде, җылымса су китереп куйды.

– Әйдә, башла! Мин бераз чабынып чыгам... «Аяклы каза», ризалыгын белдерептер, беренче тапкыр елмайды, нәзек беләкле кечкенә кулларын

суга тыкты. Ә Искәндәр, каен себеркесен култык астына кыстырып, чабыну бүлмәсенә китте. Ишекне ачар алдыннан гына кинәт сизде: үзенә кемдер карап тора кебек иде. Мондый хисне аңлатып булмый. Ул – баш чүмеченең, арка сөякләренең чымырдап китүе шикеллерәк сәер бер тойгы. Борылып карады һәм... ишек янындагы утыргычтан үзенә төбәлгән зәңгәр күзләрне күрде. Малай керфеген дә какмыйча аңа карап тора иде. Ишек ачарга сузылган кулы кире төште, юк, төшмәде, баш биеклегенә күтәрелде дә чакыру ишарәсе ясады. Бусы Искәндәрнең үз ирегеннән башка килеп чыкты бугай. Малай эскәмиядән сикереп тә төште, очынып, чабып-йөгереп, юеш идәннән тая-тая, Искәндәр янына ашыкты.

– Аһ, шайтан алгыры, егылмаса гына ярый инде!.. – дип, уйлаганын пышылдап өлгерде Искәндәр һәм малайны беләгеннән эләктерде.

Чабыну бүлмәсенә җитәкләшеп керделәр. «Аяклы каза»га әйтерсең лә җан керде. Ул, әйткәнне дә көтеп тормыйча, ләүкәнең аскы бүлеменә үрмәләде, аякларын асылындырып, менеп тә утырды.

Пар эчендә изрәгән, чабыну ләззәтенә чумып ухылдашкан ирләрнең себеркесеннән җиләнгән кайнар һава колакларны өтеп ала. Ләүкә такталары астындагы торбадан сызгырып пар чыга, тынга каплана. Искәндәр бер-ике тапкыр тирән сулады да ләүкәнең иң өстенә менеп басты. Мәтрүшкә кушып үзе бәйләгән каен себеркесеннән, борыннарны ярып, хуш ис таралды, чалт та чолт суккан тавышларга тагын бер аваз өстәлде.

Ир-атлар ах-ух килештеләр, кемдер, йөрәкләнеп: «Давай, парны өстә!.. Тагын... Тагын!» – дип кычкырып җибәрде. Аста утыручы егетләрнең берсе, хәйләкәр елмаеп, кранны соңгы чигенә җиткереп ачты. Тыгыз, куе кайнар бу түшәмгә ыргылды, анда сыешыр урын таба алмыйча, аска таба ургылды.

– Кем малае бу?.. – дип кычкырды эссе парга чыдый алмыйча ләүкәдән төшеп барган ир-атларның берсе. – Алып чыгыгыз моны, янып үлә бит бала!..

– Аһ, шайтан алгыры! – Чабынган арада бөтенләй онытып җибәргән иде, Искәндәр шунда гына «аяклы каза»ны исенә төшерде. Астагы ләүкәдә кулларын күкрәгенә кушырып, туңгандай бөрешеп утырган кечкенә гәүдәгә таба иелде. Олы зәңгәр күзләр дә аны эзли иде булса кирәк, менә карашлары очрашты, Искәндәр аңа күз кысты:

– Түзеп буламы?

Түшәм астында елтыраган ак тешләргә астан шундый ук җавап килде – «аяклы каза»ның бөтен бите җәелгән, малай рәхәтләнеп авызын ерган иде.

– Бар, чыга тор! – дип кычкырды Искәндәр, ишеккә күрсәтеп. – Юына тор! – Куллары белән юыну хәрәкәтләре ясап алды.

Малай баш чайкады. Бусы «синең белән бергә чыгам» дигәнне аңлата иде булса кирәк.

Шулчак егетнең башына суктылармыни, олы ирләр чак түзә торган эсседә ничек утыра соң бу малай? Кеше баласы ич ул!.. Бер-бер хәл булса... Ләүкәдән сикереп үк төште ул.

Тагын бер кат чабынасы килсә дә, Искәндәр үзен тыеп калды. Җылылыгын чамалап кына ләгәннәргә су тутырды. Аның гәүдәсенең һәр бөгелешен, ничек атлавын, сөйләшүен, ничек елмаюын күңел дәфтәренә сеңдереп утырган малай беренче булып телгә килде:

– Абый, әллә син татармы?

– Әйе.

– Мин дә татар!

Аның ничектер сузып, «мин дә» дигән сүзгә үзенчә басым ясарга тырышып әйтүендә шушы көчле абый белән бер кавемнән булуга, бер ягы белән генә булса да аңа охшаганлыгына горурлану, беркатлы сөенү ярылып ята иде.

Искәндәр елмаймыйча булдыра алмады, аның юеш сары чәчләреннән сыйпап куйды, икесе өчен дә уртак телгә – туган телгә күчте. Бу телгә күчү рәхәт иде, тансык иде. Теш арасында буталып, тел очында әйләнгән теге паразит сүзләр бу телдә кирәк түгел, алар юкка чыга, балалар белән сөйләшү нәкъ шушы телдә булырга тиеш икән бит!

– Исемең ничек синең?

– Азат! Ә синең?..

– Мин Искәндәр абыең булырмын. Йә, үскәнем, әйдә, юынып җибәрик әле. Юкса кызлар яратмас үзебезне.

– Яратмасынна-а-ар, – дип сузды малай. – Мин дә аларны яратмыйм.

– Менә тагын... Нигә?

– Алар елак!..

– Ә кемне яратасың соң син?

– Әниемне яратам, әби-ем-не-е...

– Тагын?..

Азатның күзләрендә моң, зурларча җитдилек тоеп, Искәндәр үзенең урынсызрак сорау бирүен аңлап алды. Малайның башы акрын гына аска иелде. Үзеннән тагын нинди җавап көтелүен ул бик яхшы аңлый иде булса кирәк. Ул кулларын озаклап сабынлады, юка тиресе аша кан тамырлары беленеп торган ябык гәүдәсен сыйпап юарга кереште. Көчле абыйның үзенә карап торуын сизгәч, бик җитди итеп аңлатып бирде:

– Мине әбием шулай юындыра.

Искәндәрнең күңелендә ниндидер бер кыл тартылып өзелгәндәй булды, туган авылы, гомерендә бер тапкыр да күтәрелеп кешегә авыр сүз әйтә белмәгән ак йөзле әбисе күз алдына килде. Нәни чагында үзенең дә әбисе белән мунчага йөргәннәре, аның назлап кына, иплә кенә чабындырганы исенә төште. Кечкенә малайның бер сүзе хәтер чоңгылларында мәңгелеккә күмелгән дип исәпләнгән, моңарчы уйланмаган, әллә нинди үтә якын, үтә дә газиз истәлекләрне яңартты.

– Их, син...

Искәндәр, малайның кулыннан мунчаласын алып, мул итеп күбекләде дә аңа ничек тотынырга белмичә, аптырап, як-ягына каранды. Әнә башка аталар малайларын эскәмиягә менгереп яткырганнар, шау күбеккә батырып, кычкыртып мунчала белән ышкыйлар. Алсу тәннәре генә ялтырап тора бахырларның. Искәндәр бер үзенә, бер «аяклы каза»га күз төшерде дә тәвәккәлләде: кочаклап, малайны эскәмиягә бастырды, иңсәсеннән тотып, мунчала белән аркасын, беләкләрен ышкып юарга кереште. Башкалар кебек шырыйлап кычкырмады малай. Ул сүзсез иде, бу мизгелләрне хәтеренә мәңгегә сеңдереп калдырырга теләгәндәй, күзләрен йомган, тавышсыз гына мышкылдый иде. Аркасын юып бетерде, үзенә каратып борды, кинәтрәк тотындымы – егылып китә язган малай ике куллап аның муеныннан кочып алды. Шул чакта әллә нәрсә булды, Искәндәрнең бугазына төер килеп тыгылды, сабын күбеге чәчрәдеме – күзләре ачытып-ачытып яшьләнде. Бу минутларда аңа шушы ябык, бөтен барлыгын аңа ышанып тапшырган, аңа сыенган «аяклы каза»дан да кадерлерәк нәрсә юк иде сыман. Аның көче, шыгырдап торган мускулларындагы гайрәт кемгәдер кирәк икән бит, моңарчы үзе белмәгән кемнедер яклау таянычы, арка терәге булу хисе котылгысыз дулкын булып

күтәрелә, шушы ярдәмчесез җан иясе өчен утка-суга керергә әзерлеген күрсәтергә чакыра иде кебек.

Әле генә ничек тотынырга белмәгән арык гәүдә хәзер куркытмый да, берәр җирен авырттырырмын дип шикләндерми дә иде. Искәндәр малайны душ астында коендырды һәм, култык астына мәче баласыдай кыстырып, җиңел хәрәкәтләр белән чишенү бүлмәсенә алып чыкты.

Мунчага кергәндә үртәлеп утырган бала-чагага, басынкы гына елмаеп аларны күзәткән ир-атка хәзер бөтенләй башка күз белән карый башлавын ул үзе, әлбәттә, сизми иде. Алар янәшәсендә чишенгән ир дә яңа гына чыккан, күрәсең. Тәненнән бөрчек-бөрчек тир ага, аркасына, ботларына ябышкан себерке яфракларына да игътибар итмичә, кечкенә малае белән әвәрә килә. Утыргычка тастымал җәеп аны бастырган да: «Әй шәп тә булды! Чәп-чәп иттек...» – дип сөйләнә-сөйләнә, тәнен корыта. Менә икенче тастымалга төреп утыртты, киемнәр арасыннан пыяла савыт тартып чыгарды:

– Менә хәзер карлыганлы чәй эчеп җибәрәбез дә өйгә – әниең янына... Сагынып беткәндер инде. Ие бит?! Коймак пешереп көтә торгандыр.

Искәндәрнең үзенә карап-карап алуын сизеп булса кирәк, борылып Азатка ишарәләде:

– Улыңа чәй алып килмәгәнсең икән. Мунчадан соң минеке бер банканы эһ тә итми...

– Зыян юк. Чыккач, без газлы су эчәбез. Иеме, Азат, – диде Искәндәр, бер дә исе китмәгәндәй.

Букчасыннан киң, озын тастымалын чыгарды, малайны төреп утыртты да пинҗәк кесәсеннән сигарет алды. Аны бармаклары белән йомшарткалап, авызына капты, шырпы сызар алдыннан кылт итеп кайдадыр укыганы искә төште: «Тәмәке төтене балаларга аеруча зарарлы!» Үзалдына көлемсерәп, читкә, тәмәкечеләр өчен өчпочмаклап куелган буш эскәмияләр янына китеп барды.

«Улың!» Күршедәге ир әйткән сүзнең мәгънәсе зиһененә әле яңа гына барып җиткән иде аның. «Улың!.. Улым! Минем малай!» Теле сүзсез генә шул үтә тылсымлы сүзләрне кабатлады: «Улым! Улым!» Ничек моңарчы белмәде икән, җир йөзендә моннан да матур, моннан да мәгънәле, якын, кадерле бүтән сүз бар микән?! Юыну бүлмәсендәге халәте кабатланды, бугазына утырган төер тәмәкесен юньләп тартырга ирек бирмәде, буйдаклар ятакханәсендә сигез еллап торып катып беткән күңеле йомшарган, балавыздай сыгылырга әзер иде.

Киенеп чыктылар. Әле генә кояштай балкыган малай сүрән генә елмайды, йөзенә өлкәннәргә хас җитдилек кайтты. Үзенең учында кечкенә, җылы кул тоюдан рәхәт бер горурлык кичереп атлаган Искәндәрнең аны тагын елмайтасы, рәхәтләндереп көлдерәсе, нәни йөзеннән әлеге җанга авыр җитдилекне алып ташлыйсы килә иде.

– Ә хәзер, әйдә, туйганчы су эчик! – диде ул, тавышына шаянлык, шуклык өстәргә тырышып. Тик сүзләре ясалма килеп чыкканын үзе дә сизде. Кесәсендә аунап йөргән ике өч тиенлекне эзләп тапты, берсен автомат ярыгына төшереп җибәргәч, ширбәт агып бетүгә, стаканны читкә алып торды һәм, малайларча мутланып, Азатка күз кысты, икенче бакырны ташлады. Малайларның ике ширбәтле су эчәргә яратуын ул белеп өлгергән иде инде.

Азат, стаканны авызына китергәнче, Искәндәргә күтәрелеп карады.

– Ә үзең... эчәсеңме?..

– Мин соңыннан, – диде Искәндәр. Бүтән бакыр акчасы юклыгын белсә дә, кесәләрен капшаган булды. Аның һәр хәрәкәтен күзәткән малай буш стаканны

автоматка куйды һәм, тез башлары бүлтәеп чыккан сары вельвет чалбары кесәсеннән өч тиенлек табып, Искәндәргә сузды.

– Менә, әнием биргән иде... Искәндәр тагын су агызды.

– Юу-у-ук! Мин бүтән эчмим... Ә-ә...

Малай нindидер сүзне әйтеп бетермәде, әллә тотлыкты – бите алсуланып китте, зәңгәр күзләре озын, куе керфекләре арасына кереп поскандай тоныкланып калды.

Искәндәрнең йөрәге дерт итеп китте. Нигә тотлыкты соң әле ул? Ни булды? Әллә...

Тамагыннан су үтмәде Искәндәрнең.

Мунчаның алгы ягында кеше аз иде. Стена буена тезелгән урындыкларда берничә карчык кына гәп куертып маташа. Азат тиз генә залга күз йөгертеп чыкты, йөзеннән нindидер караңгы күләгә узгандай булды.

Икесе дә, бер-берсенә карашып, сүзсез калдылар.

– Ярый, Азат, мин китим инде. Сау бул!

Искәндәрнең олыларга биргәндәй сузган учына малайның кулы теләр-теләмәс кенә ятты.

– Сау бул, – диде ул, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

– Хуш! Киттем...

Кай арададыр үзенә якын, кадерле булып өлгергән бу малайдан аерылу Искәндәргә авыр иде. Китәсе килми, аның белән җитәкләшеп, нәрсә турында булса да сөйләшә-сөйләшә, бергәләп урамнардан атлыйсы иде!.. Мондый сәер халәттән котылу өчен, кырт борылды да эре адымнар белән ишеккә таба атлады. Тик соңгы тапкыр малайны тагын бер кат күреп каласы, үзендә моңарчы барлыгы да беленмәгән хисләр өермәсен кузгаткан кечкенә кешене хәтеренә сеңдерәсе килү теләге аны тукталырга мәҗбүр итте. Хатыннар янындагы буш урындыкка чүмәшкән малай көзге яңгырда күшеккән чыпчык баласын хәтерләтә иде. Менә карашлары очрашты. Малай кыяр-кыймас кына Искәндәргә якынлашты, хуҗасының күзенә карап әмер көткән тугрылыклы эт мисалында сүзсез басып калды. Тын гына тордылар.

– Әнием миңа шушында көтәргә кушты, – диде, ниһаять, малай акрын гына.

– Ярый, Азат, син көт инде!

Искәндәрнең аның башыннан сыйпыйсы, кочаклап юатасы килеп китте. Ләкин үзен тыеп калды... ишекне акрын гына ачып, урамга чыкты.


Шәһәр өстендә кичке утлар кабынган. Тагын да җиләсләнә төшкән. Мунчадагы эсседән соң, Искәндәрнең бөтен тәне әллә ничек куырылып килгәндәй булды. Ул якаларын торгызды да, якынаеп килүче трамвай утларын күреп, тукталышка ашыкты. «Иртәгә таң белән юлга чыгасы! Алда – бер айлык командировка!» Шәһәр урамнарындагы кичке тормыш аны яңадан көндәлек мәшәкатьләренә кайтарды.

Трамвайның ишекләре ачылды, килгән шәпкә сикергән Искәндәрнең миеннән яшен тизлеге белән бер уй йөгереп узды: «Бер айга бит! Тоташ бер айга!..» Инде ябыла башлаган ишекләрне үз-үзен белештермичә көч белән каерып ачты да яңадан төнге утлар балкыган урамга килеп төште. Трамвай йөртүченең «Хулиган!» дип кычкырып калуы да, тукталыштагы кешеләрнең шелтәле баш чайкавы да аңа хуплау гына булып тоелды. Эре-эре атлап, яңадан мунчага таба китеп барды.

*1987 ел*

# МӘРХӘМӘТСЕЗЛЕК

Минем алда – Тукайның дусты һәм балаларга матур-матур әкиятләр, хикәяләр һәм шигырьләр язган хөрмәтле әдип Фәхрелислам Агиевның «Мәрхәмәт» китабы. Мин аны кабат-кабат укыдым һәм озак кына уйланып утырдым. Уйлануымның беренче сәбәбе: Фәхрелислам Агиевны бездән олы буын яхшы белгән һәм аның әсәрләрен яратып укыган, балалар күңеленә хуш килә торган әкиятләр, хикәяләр һәм шигырьләр даны өчен рәхмәтләр укыган. Ни өчен шул язучыны безнең буынга күрсәтмәделәр, аның турында бер җөмлә дә язмадылар? Дөрес, без үсә төшкәч, олы буын кешеләреннән Фәхрелислам Агиев турында ишеттек, ләкин аның язмышын белмәдек. Ниһаять, 64 ел үткәч, демократиянең шифалы җилләре искәннән соң, бу язучының «Мәрхәмәт» дигән китабын алып уку бәхетенә ирештек. Кешеләргә бары тик изгелек кенә эшләгән бу зыялы зат, бик яшьтән Сталин палачлары тарафыннан кулга алынган икән һәм «халык дошманы» дип сөрелгән. Шул Сталин лагерьларында нахак бәлагә тарыган җанын акларга тырышып, Ак диңгез – Балтыйк каналы төзү эшендә – салкын һәм яңгырлы төзелештә, ач-ялангач хәлдә, ярым авыру, көн-төн эшләп, сөрген срогын тутырып кайткан. Аннан соң да бу тырыш, мәрхәмәтле кешегә иркенләп иҗат итәргә бирмиләр. 1937 елны кабат кулга алалар һәм «даһи» Сталин чоры кешеләренең ерткычлыгы аркасында ул соңгы сулышын ала. Халыкка бары тик изгелек кенә эшләүче бу язучы берниНди гаепсезгә юк ителә.


МӘРХӘМӘТСЕЗЛЕК
- - - - - - - - - - -

Минем алда Тукайның дусты һәм балаларга матур-матур әкиятләр, хикәяләр һәм шигырьләр язган хөрмәтле әдип Фәхрелислам Агиевның "Мәрхәмәт" китабы. Мин аны кабат-кабат укыдым һәм озак кына уйланып утырдым. Уйлануымның беренче сәбәбе: Фәхрелислам Агиев турында бездән олы буын яхшы белгән һәм аның әсәрләрен яратып укыган балалар күңеленә хуш килә торган әкиятләр, хикәяләр һәм шигырьләр даны өчен рәхмәтләр укыган. Ни өчен шул язучыны безнең буынга күрсәтмәделәр, аның турында бер җөмлә дә язмадылар? Ләкин без үсә төшкәч олы буын кешеләреннән Фәхрелислам Агиев турында ишеттек, ләкин аның язмышын белмәдек. Ниһаять, 64 ел үткәннән, демократиянең шифалы җилләре искәннән соң бу язучы[illegible] "Мәрхәмәт" дигән китабын алып уку бәхетенә ирештек. Кешеләр[illegible] бары тик изгелек кенә эшләгән бу зыялы бик яшьтән Сталин палачлары тарафыннан кулга алынган икән һәм "Халык дошманы" дип сөрелгән икән. Шул Сталин лагерьларында нахак бәлагә тарылган җанын акларга тырышып Ак диңгез – Балтыйк каналы төзү эшендә – салкын һәм яңгырлы төзелештә, ач-ялангач хәлдә, ярыма авыру килен көн-төн эшләп, сөрген срогын тутырып кайткан. Аннан соң да бу тырыш, мәрхәмәтле кешегә иркенләп иҗат итәргә бирмиләр. 1937 елны кабат кулга алалар һәм " даһи" Сталин чорында кешеләренең ерткычлыгы аркасында ул соңгы сулышын ала. Халыкка бары тик изгелек кенә эшләүче бу язучы берниНди гаепсезгә юк ителә.

Гаепсездән гаепле булган Фәхерелислам Агиевның "Мәрхәмәт" дигән китабын Фатыйма Ибраһимова төзеп, сүз башы язып, аңлатмалар биреп бастырып чыгарганыөөчен йөз мең рәхмәтләр әйтәбез, аның эшендә зур уңышлар телибез.

Фәхерелислам Агиев"кояшка тиңләгән Сталин" заманында юк

Гаепсездән гаепле булган Фәхрелислам Агиевның «Мәрхәмәт» дигән китабын төзеп, сүз башы язып, аңлатмалар биреп бастырып чыгарганы өчен, Фатыйма Ибраһимовага йөз мең рәхмәтләр әйтәбез, аның эшендә зур уңышлар телибез.

Фәхрелислам Агиев «кояшка тиңләнгән Сталин» заманында юк ителгән булса да, халык аның белән кызыксынды, аның турында сораштырды. Мин үзем, Язучылар берлеге идарәсендә:

– Тукайның дусты һәм замандашы булган Фәхрелислам Агиев кайда хәзер? Ни өчен аның китаплары чыкмый? – дип сорадым.

– Ул халык дошманы, ике йөзле хамелеон белән кызыксынма, – диделәр.

Ләкин мин моның белән ризалашмадым.

– Нишләп Тукайның дусты халык дошманы булсын ул? – дигәч, кайбер язучылар мине кисәттеләр:

– Күпне тикшермә! Әгәр, исән булса, Тукайны да халык дошманы ясарлар иде. Бик күп язучылар, илгә һәм халыкка астыртын явызлык эшләп, сөргенгә җибәрелделәр. Син шуны бел дә авызыңа су кап!

«Авызыңа су кап» дигән сүзне әйткәч, әлеге язучы бармакларын тәре формасында күрсәтте һәм аны тикшерү синең эшең түгел, диде. (Димәк, аның тәре рәсемен күрсәтүе – төрмәне күрсәтү иде.)

Фәхрелислам Агиев 1958 елны акланды, ләкин үзе исән түгел иде инде. Аның турында профессор Мөхәммәт Гайнуллин кызыксынды һәм, әсәрләрен өйрәнеп, «Татар әдипләре» дигән китапта язып чыкты.

Муса Җәлил дә 1938 елны ук, Сталинизмның иң котырган чорында, Габдулла Тукайның китабына, Ф.Агиевны Тукай дусларча чеметеп алган мәкаләсен керткән, һәм ул шагыйрьнең «Сайланма әсәрләр» китабында басылып чыккан. Бу вакытта, Ф.Агиев утыруга карамастан, Муса Җәлилнең аның турында язуы үзе зур батырлык иде!

Менә безнең буын Фәхрелислам Агиев турында шуны гына белә иде. Баксаң, Ф.Агиев белән Г.Тукай бала чакларыннан дус булганнар һәм әдәбият дөньясында бергәләшеп, халыкны аң-белемле итү өчен җиң сызганып эшләгәннәр, Ф.Агиев 1913-1916 елларда балалар өчен «Ак юл» дигән журнал чыгара. Журнал үз вакытында татар дөньясын шаулата. Анда татар язучыларының һәм шагыйрьләренең балалар өчен язган күпләгән әсәрләре басыла. Фәхрелислам Агиевның матди тормышы кысынкы булса да, ул журналны системалы чыгара, рәсемнәрне Мәскәүдән эшләтеп кайтарта.

Менә шундый мәрхәмәтле кешене, бер дә юкка кара ягып, «Халык дошманы» дигән мөһер сугып, яшәүдән мәхрүм итәләр. Татар халкында шундый мәкаль бар: «Ит изгелек, көт явызлык». Әйе, ул «даһи» Сталин чорында бик күп зыялыларны, галимнәрне, язучыларны юк иткәннәр. Мәсәлән: язучы Садри Җәләл, шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй, тарихчы Һади Атласи, тарихчы һәм язучы Газиз Гобәйдуллин, «Спартак» романын тәрҗемә иткән Гыйлемдар Баембетов, язучы һәм журналист Сафа Борһан, шагыйрь һәм драматург Фәтхи Бурнаш, атаклы драматург Кәрим Тинчурин, атаклы язучы һәм революционер Галимҗан Ибраһимов, шагыйрь Исхак Хәйруллин, язучы Гомәр Толымбай, шагыйрь Галимҗан Мөхәммәтшин һәм башкалар.

Әле бу исемлек тулы түгел, гөнаһсызга гаепләнеп корбан булучыларның монда чиреге дә юк. «Даһи» Сталин палачлары күпме атаклы кешеләребезне кырганнар, ачтан үтергәннәр.

Менә бу кешеләрнең барысын да хөрмәт белән искә алып мәңгеләштерергә, урамнарга, мәктәпләргә аларның исемнәрен бирергә, музейлар ачарга тиешбез.

Халкыбыз бинахакка корбан булучыларны белеп торсын!

**Самат ШАКИР**
*1986 ел*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## «Татарочки»

Казанда бер мәктәпкә очрашуга чакырдылар. Татар теле укытучылары, татар балаларын ата-аналары белән бергә чакырып, татар телендә кичә үткәрергә ниятләгәннәр. Мин дә шул кичәдә чыгыш ясарга тиеш. Беренче рәттә утырам.

Миңа хәтле сәхнәгә милли киемнәр киенгән укучы кызлар менеп җырлады. Сул ягымда, икенчеме-өченчеме классларда укучылардыр, күрәсең, берничә кызчык чыркылдый. Сәхнәгә милли киемдәге кызлар менгәндә, болар, бер-берсенә төртешеп:

– Смотри, Гузелька, татарочки, смотри, татарочки... Смотри, Дилярка, татарочки!– диештеләр.

Шуннан мин болардан:

– Ә сез кемнәр, руслармы? – дип сорадым. Мине аңламаганнарын күреп, русчалатып:

– А вы кто, русские? – дип, соравымны кабатладым.

– Не-е-ет, – диделәр.

– Кто же?

– Не знаем.

Менә «интернациональ» тәрбиянең нәтиҗәсе. Рус та түгел, татар да түгел – маңкортлар. Болар үсеп җиткәч, ата-аналары сөенеп туймаслар инде...

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Ни бит

Илдар Юзеев белән җырчы Рафаэль Сәхәбиев урамнан баралар икән. Каршыларына композитор Зиннур Гыйбадуллин килеп чыккан. Күрешкәч, ул, Сәхәбиевнең җиңеннән тотып:

– Ниме?.. Ни бит син, чукынчык! Бик нитеп тордылар әле сине радиода. Мин дә ниттем. Минем теге нине нитәрсең инде. Нитмә, яме! Нитеп бетергәч, миңа нитәрсең дә... Нитеп нитәрбез. Тизрәк нитәргә иде бит! – дигән.

– Ярар. Ниткәчтен нитәрмен, Зиннур абый, – дигән Рафаэль Сәхәбиев.

Икесе генә калгач, Илдар Юзеев:

– Ни хакында сөйләштегез сез, Рафаэль, берни аңламадым? – дигән.

– Бик гади ул, Илдар абый. Аңа бераз күнегергә генә кирәк. Зиннур Гыйбадуллин: «Хәлләрең әйбәтме? Шәп җырчы бит син, чукынчык! Бик мактап тордылар әле сине радиода. Мин дә макташтым. Минем теге җырны өйрәнерсең инде. Сузма, яме! Өйрәнеп бетергәч, миңа шылтыратырсың да... очрашып алырбыз. Радиога тизрәк яздырырга иде бит!» – диде. Ә мин: «Ярар, өйрәнгәч хәбәр итәрмен, Зиннур абый», – дип җавап бирдем, – дип шәрехләп чыккан Рафаэль Сәхәбиев.

– Кызык бу, – дип баш чайкап куйган Илдар Юзеев, – өч сүз белән никадәр мәгънә... Хәер, егерме биш сүз белән калын роман язучылар бар безнең язучылар арасында да...

***

Бер тарафтарак яшәгәнлектән, Илдар Юзеев белән композитор Зиннур Гыйбадуллин күпер төбендәге азык-төлек кибетендә очрашкалыйлар икән. Бу кибеттә йөк ташучы булып телсезләр эшли. Берсеннән-берсе таза, чибәр егетләр. Алар, Зиннур Гыйбадуллинны күргә, елмая-елмая килеп җитеп, аны уратып алалар. Ә тегесе, егетләрнең җилкәсеннән кага-кага, нидер сөйли башлый. Авызын очлайта, башын селкеп куя, кашын сикертә, бот чаба, аягын күтәреп ала, йодрыгы белән маңгаена суга, күзен кыса, көзән җыергандагы кебек, бармакларын селкетә – егетләр исә бөгелеп-бөгелеп көләләр, рәхәтләнәләр генә.

Беркөнне Илдар Юзеев ярты сәгать буе кәнфиткә чират тора. Зиннур Гыйбадуллин исә ярты сәгать буе теге егетләр белән бер читтә тавышсыз гына сөйләшә. Әлеге дә баягы бөтен әгъзаларын хәрәкәттә тота.

Соңыннан Илдар Юзеев аңардан:

– Шулкадәр озак ни сөйләдең, син аларның телен беләсеңмени? – дип сораган.

– Ни бит, – дигән Зиннур Гыйбадуллин. – Ниткән бит инде... Нитәм дә... Нитәләр... Нигә нитмәсеннәр, мин бит ни!..

Берни аңламаган Илдар Юзеев:

– Зиннур, миңа да шул кул-аякларың белән телсезләр телендә генә сөйлә әле, – дигән.

**АХИР**

## Ню!

Язучы һәм журналист Әхәт Гаффарга бер үзешчән шагыйрь шылтырата.

– Әхәт әфәнде, хәлләрегез ничек?

– Ню! – дип кыска гына сәлам биргән язучы.

– Шигырьләремне чыгаргансыз икән, рәхмәт! – дип сүзен дәвам иткән шагыйрь.

– Ню?!

– Тагын бер сәхифәлек шигырьләрем бар, аларын да алып килсәм, ничек булыр?

– Ню...

Шагыйрь, инде ни әйтергә дә белмичә, бер мәлгә аптырап тынып кала.

– Бер-бер алып куйган нәстәң юктыр ич?! – дип, ниһаять, телгә килә Әхәт. Сүз хәмер турында бара, билгеле. Үзе әйтмешли, бер «чүлли».

– Бар...

– Суң! Күптән шулай дип әйтәләр аны, шигырьләрең эченә төреп алып килергә онытма, яме!

– Ню...

## Сынап караган

Әхәт Гаффар беренче язган пьесасын режиссёр Равил Тумашевка укырга биргән. Режиссёр аңардан сигез төрле вариант эшләткән. Шуннан соң гына куярга булган.

– Кайсысын? – дип сораган классик.

– Беренчесен! – дигән режиссёр.

– Суң... беренчесен куясы булгач, нишләп суң аны сигез тапкыр эшләттең?

– Драматург була алырсыңмы дип, сынап карарга уйлаган идем!

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# ЗАМАНА ХИКӘЯЛӘРЕ

### «Бизнесменнар»

Кече яктан хатынының әчкелтем тавышы яңгырады:

– Кайчан эшкә урнашасың?! Эт ялкавы!.. Хөрәсән!.. Имгәк!..

Көн саен шушы сүзләр кабатлана Мәхмүтнең колак төбендә. Көн саен! Эшкә урнашырга кирәген үзе дә белә ул, әмма нишләсен, авылда эш юк бит...

– Әнә, күрше Хәниф абый тимер капкалар ясый, шуның тирәсендә чуалыр идең, – ди хатыны. Хе... Әтнә техникумын бетергән башы белән капка ясап йөрсенмени Мәхмүт, адәм көлкесе!

– Алайса, үз белгечлегең буенча эшлә, синең кебек ветеринар җирдә аунап ятмый! – ди хатыны, өзгәләнеп. Хе... Унбиш меңгә ферма исе иснәп йөрергә юләр ди сиңа Мәхмүт...

Ярар, хатын сүзендә хаклык бар. Утыз тула бит инде үзенә. Берәр бизнес ачарга кирәк. Классташы Әмир белән сөйләшеп аласы булыр. Андыйга башы шәп эшли аның.

Мәхмүтне күрүгә, Әмирнең йөзе яктырып китте. Ә инде яшьтиенең ниятен дә ишеткәч, бөтенләй дәртләнде. Шундук бер «чистай малае»н кыстырып, яшелчә бакчасына юл тоттылар.

– Металл җыячакбыз! – диде Әмир, теш арасына кысылган кыяр кисәген бармагы белән каезлап. – Өр-яңа бизнес! Түлке берәүгә дә әйтмә! Килосы биш сум хәзер тимернең! Иске суыткыч үзе генә дә илле килога тарта! Ә андый металл һәр йортта – завались! Безнең авылдан гына да йөз меңне бәреп алабыз! Аннары – күрше авыл... И так по всему району!

Шайтан суы ярыйсы ук башына киткән иде Мәхмүтнең. Аның күзенә Әмир профессор булып күренде. Кара, нинди акыллы бит дусты! Ничек матур итеп русча сөйләшә ул! Ике кулы белән Әмирнең муеныннан кочаклап алды Мәхмүт:

– Мин сине бик хөрмәт итәм! – дип пышылдады ул яшьтиенең колагына. – Син – даһиның даһие...

– Әйе шул... – диде тегесе, авыз кырыеннан сытылып чыккан закускасын җиңе белән сөртеп. – Беләм... Акчаңны кая куярга белмәячәксең, малай... Тау хәтле булачак... Күр дә тор менә... Күр дә тор...

Ике дус Әмирләрнең бакчасында кочаклашып йокыга китте.

Иртүк Мәхмүт әтисенең иске «Москвич»ын гараждан алып чыкты. Этеп кабыздылар. Багажникка гына әллә ни күп тутырып булмас дип, артка «уфалла арбасы»н тактылар.

Әмма «Москвич» иртән ничек буш чыгып киткән булса, кичен шулай ук буш килеш, артына тагылган арбасын кәҗә бәтиедәй сикертеп, әйләнеп тә кайтты – күрше авыл чувашлары узган атнада авылдагы бөтен металлны җыеп чыкканнар икән. Бушка түгел! Килосын ике сумнан.

– Сволочьлар! – дип сукранды Әмир, черт итеп җиргә төкереп. – Бөтен районны сөргәннәрдер инде, падлалар...

Өй борынча кереп, сорашып йөрүләр тәмам ардырган иде – ике дус алпан-тилпән өйләренә юнәлде.

Икенче көнне сөйләшү нәкъ шул ук бакчада дәвам итте:

– Казлар алабыз! – диде Әмир. – Сразы ике йөз баш! Өч айдан үсеп җитә алар. Считай, меңәр тәңкәдән генә озатсаң да... Ярты доход сиңа, яртысы – миңа...

Мәхмүт, «доход»ның күпме буласын күңелдән генә санап чыгарып, үзе дә сизмәстән, кесәсен капшап куйды һәм:

– Ә абзар? – диде аннары. – Ике йөз баш казны кайда асрыйбыз?

– Абзарны почти бар дип сана! – Әмир имән бармагын өскә күтәрде. – Бәрәңге бакчасына күптән бәрәңге утырткан юк безнең, шунда салабыз! Иске такталар дачурта, шулардан әмәлләрбез!

Әмирнең шакмаклы дәфтәр битенә сызгалаган проекты буенча, иң элек дүрт почмакка дүрт багана утыртырга кирәк иде. Беренче багананы казып утыртканчы, икесе дә хәлдән тайды, шабыр тиргә баттылар. Җитмәсә, кояшы да үтерепләр кыздыра, ник бер болыт әсәре күренсен! Икенче багананы иртәгә утыртырбыз дип, яшьтиләр бүгенгә таралышты.

Иртәгесен никтер икесе дә көрәккә ябышырга ашыкмады.

– Карале, малай, – диде Әмир, чыраен чытып, – ни... ул каз дигәнең үсеп җиткәнче бик күпләп үлә икән... Химия ашый бит алар хәзер. Әллә соң, минәйтәм, ниме... башка берәр бизнеска тотынып карыйкмы?

Мәхмүтнең авызыннан диярлек тартып алды ул бу сүзләрне. Килеште тегесе. Авылда автосервис ачарга булдылар! Ә нәрсә? Капка төбе саен машина бит хәзер. Кемнең көпчәген ямыйсы, кемнең моторын ремонтлыйсы дигәндәй... Дөрес, ни Мәхмүте, ни Әмире әлеге эшнең рәтен белми. Аның каравы, Мәхмүтләрнең урам якка каратып салынган гаражы исән. Һәм... тракторчы Бәйрәмгалинең андый эшкә осталыгы бар... Шуның белән сөйләшеп карарга булдылар.

– Табышның кырык проценты Бәйрәмгалигә, калганы безгә! – диде Әмир, күзләрен ялтыратып. – Көнгә биш кенә машина керсә дә, чутлап кара...

– Безгә бик аз калмыймы соң? – дип, шиген белдерде тегесе.

– Ярар соң, Бәйрәмгалигә егерме процент та җитәр алайса...

Эшне бүлештеләр: Бәйрәмгали белән сөйләшү – Әмиргә, фанер тактага «Автосервис» дип язу Мәхмүткә йөкләнде.

Көн кичкә авышканда, урамның аргы башыннан җырлый-җырлый килүче Әмир күренде.

– Ну?! – диде Мәхмүт, ул килеп җитүгә.

Әмирнең кроссовки баулары җирдән сөйрәлә, күлмәгенең бер ягы кергән, икенчесе чыккан, авыз читенә суган кыягы ябышкан, маңгае никтер туфракка буялган иде.

– Бәйрәмгали абый белән от души утырдык! – диде ул, телен көчкә әйләндереп.

– Ну?

– Армиядәге кызыкларны сөйләп, эчне катырып бетерде, мал-лай…

– Ну?

– Нәрсә ну?

Мәхмүт кәкре-бөкре хәрефләр белән «Автосервис» дип язылган фанерга ымлады:

– Киләме безгә эшкә?

Әмир берара күзен челт-мелт йомгалап торды, аннары гына үзенә йөкләнгән эшне искә төшерде булса кирәк:

– Ә-ә-ә... ни... юк... риза булмады...

Мәхмүтнең кәефе кырылды:

– Нишлибез инде хәзер?

Әмир, кулларын пычрак трикосының кесәсенә тыгып, эшлекле кыяфәт белән дустына карады:

– Кибет ачабыз! – диде ул, детектив кинодагы шымчыларча, үтә дә серле елмаерга тырышып.

– Соң, дүрт кибет бар ич инде безнең авылда!

– Булсын! Дүрт кенә кибет әз ул! Кәнфит, печенье, галуш сатачакбыз. Чират торып алачаклар... Может, икене ачарбыз әле. Түбән очта – минекен, югары очта – синекен...

Ике яшьти, иртәгесен яшелчә бакчасында очрашырга сүз куешып, саубуллашты.

## «Аша рәхәтләнеп!»

Көтмәгәндә имәнеп китте Моңзар. Чү! Кайда соң ул? Ниндидер гаҗәеп зур зал. Тирә-юньдә йөзләгән газ плитәсе, шкафлар, табалар, кәстрүлләр, әрҗә-әрҗә шампуньнар, дарулар... Тыз-быз килеп поварлар йөгерешә...

Егет берни аңламады. Нинди җир бу? Ул монда кайчан, ничек килеп эләккән? Өнме бу, төшме?..

Моңзар – радио хезмәткәре. Реклама бүлегендә эшли. Җырчылар аңа җырларын китерә һәм акча түли. Кем күбрәк түли, шуның җырын күбрәк уйнаталар. Кайвакыт бер җырны көнгә унбишәр тапкыр да әйләндергәннәре бар.

Кичә алар Яңа елны бәйрәм итте. Туйганчы күңел ачтылар. Өстәл өстенә менеп биегәнен хәтерли Моңзар, ә менә калганын хет үтер – исенә төшерә алмый...

– Бәйрәм белән, әфәндем? Таныш булыйк, мин – шеф-повар, – диде актан киенгән таза бер ир-ат. – Ризык әзерләүчеләр иленә рәхим ит!

Моңзар кашларын җыерды.

– Нинди ил соң ул? Мин ничек эләктем бирегә?

Шеф-повар никтер сорауга җавап бирмәде.

– Хәзер без сине сыйларбыз, әфәндем! – диде ул, елмаюын яшермичә.

– Рәхмәт, ашыйсым килми, – диде Моңзар, томанлы күзләре белән тирә-юньне айкап.

– Анысын синнән сорап тормыйбыз! – Шеф-повар эшлекле тонга күчте. – Пешерүче кызыбыз Ромашка махсус синең өчен тавык шулпасы әзерләде!

Моңзарны өстәл артына утырттылар, алдына тәлинкә куйдылар. Әмма шулпа, бердән, салкын, икенчедән, бу – шулпа түгел, ә токмач боламыгына охшаш бер нәмәрсә иде. Моңзарның күңеле болгана башлады. Ул сүзсез генә тәлинкәне читкә этәрде.

– Ашамыйм!

– Ашыйсың!

– Ашамыйм!

Шеф-поварның елмаюлы чыраен юып алдылармыни! Ул бер генә секунд уйланып торды да, бармак шартлатып, әзмәвердәй ике сакчыны чакырып китерде.

– Бездә тәртип шундый! – диде баш повар, кырыс тавыш белән. – Пешергән ризыкны һичшиксез ашыйлар! Тәмлеме ул, тәмсезме, ачымы яисә баллымы – анысы мөһим түгел! Ашау мәҗбүри!

Сакчыларның карашы усал, беләкләре юан иде. Моңзар йөзен чытып кына шулпа-боламыкны чемченергә кереште.

– Миңа кайтырга кирәк! Җибәрегез, зинһар! – дип ялварды ул бераздан.

– Ашыкма, әфәндем! – дип янә елмайды баш повар. – Атаклы пешерүчебез Дәүләтгәрәй сиңа махсус деликатес әзерләде – парда пешкән бака уылдыгы! Аша рәхәтләнеп!

Моңзар агарып катты. Сакчылар исә, икеләнергә урын калдырмыйча, тәлинкәгә ымлады. Уылдык чиле-пешле иде. Өстәвенә, тозсыз. Өстәвенә, сулыш юлына китеп интектерде...

Моңзарның газапларын тыныч кына күзәтеп торган шеф-повар янә сүз алды:

– Хәзер бездә яңа мода, – диде ул. – Поварлар ризыкны парлашып әзерли. Күбесе – ирле-хатынлы. Берсе бәрәңгесен әрчи, икенчесе итен турый, дигәндәй... Менә, бүген дә сиңа искиткеч тәмле компот тәкъдим итәбез! Сәлим һәм Сәлимә Сәлимҗановлар бик тырышып кайнатты аны. Эч рәхәтләнеп!

«Бусына гына ничек тә түзәрмен», дип, Моңзар кружканы иреннәренә тидерде һәм сискәнеп китте – компоттан шампунь тәме килә иде.

– Эч, эч, курыкма! – диде шеф-повар, елмаеп. – Бу эчемлек «Татар компоты» бәйгесендә икенче урынны алды. Сәлимҗановларга моның өчен алтын кәстрүл статуэткасы да бирделәр әле...

Калган вакыйгалар күз иярмәс тизлектә булды. Моңзар кисәк кенә сикереп торды һәм компотны шеф-поварның битенә сипте! Моны күреп, сакчылар аның өстенә килә

башлады. Егет чытырдатып күзләрен йомды...

– Торыгыз! Торыгыз инде... Уяныгыз, Моңзар Шәвәлиевич...

Ул күзләрен ачты. Якты бүлмәгә кышкы кояшның саран нурлары үтеп кергән... Чү! Үзенең эш бүлмәсендә түгелме соң ул? Янында секретарь кыз Гөлчәчәк басып тора. Ә шеф-повар, сакчылар кайда?..

– Сез бүген биредә генә кунгансыз ахры, – дип көлемсерәде Гөлчәчәк, Моңзарның пинжәгенә ябышкан колбаса кисәген чүп савытына алып ташлап. – Катырак бәйрәм иткәнсез бугай...

«Аллага шөкер, төш кенә булган!» – дип иркен сулады егет, шабыр тиргә баткан маңгаен сөртеп.

– Кстати, әле генә җырчы Дәүләтгәрәй килеп китте, – дип, эшлекле тонга күчте Гөлчәчәк. – Яңа җыр китергән. «Эт сөяккә бара» дип атала. Акчасын түләде. Радиодан ярты ел буе әйләндерәчәкбез.

– Тыңладыңмы соң? – диде Моңзар, төксе генә. – Барырлыкмы?

– Ә нәрсәгә? – дип, иңнәрен сикертте Гөлчәчәк. – Тырыша-тырыша язган бит инде ул аны. Көен дә үзе язган, сүзләрен дә. Акчасын түләгән. Аранжировкасын үзе ясаган. Тыңласын халык рәхәтләнеп!

## «Әлү, кайсыгыз әле бу?»

– Әлү, кайсыгыз әле бу? – дип, кесә телефонына акырды Хәррәм абзый. – Залда, өстәл почмагында бер папка документлар булырга тиеш, тиз арада берәр кая алып чыгып яндыр шуларны!

– Ярар! – диде нәзек кенә малай тавышы, һәм телефон бер мәлгә тынып калды.

Хәррәм абзый – зур бер оешманың җитәкчесе, һәм бүген аңа, күктән тәлинкә төшкән кебек, бер төркем погонлы кешеләр килеп керде. Коррупциягә каршы көрәш вәкилләре. Әлегә кабинетын гына тикшерәләр, бик тиздән коттеджына килеп җитәчәкләр. Әнә шуңа күрә, бәдрәфкә чыгып керәм, дигән булып, тиз генә өенә шылтыратырга җай тапты ул.

– Булды, яндырдым!

– Маладис!.. Ашыкма, куйма трубканы! Спальняда ноутбук булырга тиеш, шуны гантель белән төйгәлә!

– Капкачына алма рәсеме төшерелгәненме?

– Әйе инде... – дип, иреннәрен чәйнәде Хәррәм абзый. – Шул, берәү генә бит инде ул!

– Ярар, – диде нәзек тавыш.

«Искәндәр тагын мәктәпкә бармаган, – дип, төпчек малаен эченнән генә сүгеп ташлады җитәкче. – Хәер, әйбәт тә булды әле... Югыйсә, кемгә кушар идең бу йомышларны...»

– Булды, җимердем! Шул гынамы...

– Ашыкма! Сейфтан пистолетны, автоматны һәм ак порошок салынган тартманы күрше Габделхәйгә кертеп куй.

Ул арада бәдрәф ишеген шакый башладылар...

– Хәррәм Алтынбаевич, чыгасызмы инде? Коттеджыгызга барыр вакыт җитте!

– Хәзер, хәзер, – диде Хәррәм абзый һәм тагын телефонга ябышты: – Йә, нәрсә, булдымы, улым?

– Булды! Син әйткән әйберләрне күршебез – участковый Фаил абзыйның лично үз кулына тоттырдым. Күзе маңгаена менде!

– Ничек?! Күршебездә участковый тормый бит, малай актыгы, дворник Габделхәй яши!

– Ә-ә-ә... ату сез, абый, номерны ялгыш җыйгансыз инде...

Телефонның «пип-пип-пип!» дип өзгәләнгәнен дә, погонлы кешеләрнең бәдрәф ишеген ватып керүләрен дә хәтерли Хәррәм абзый, ә менә калганын үтерсәләр дә хәтерләми, үтерсәләр дә...

## «Тимурчылар»

Мулланур абзый телевизорны кабызды да тирән кәнәфигә чумды. Йөрәкләрне җилкетеп, җыр яңгырады:

*Взвейтесь кострами, синие ночи...*

Их! Бар иде бит Мулланурның да пионер вакытлары, тимурчылар булып шау-гөр килеп йөргән чаклары... Хәтерендә, шулай бервакыт аларның отряды авыл читендәге Миңниса әбине шефлыкка алырга барды. Малайлар кар көрәде, кызлар әбинең идәнен юып чыгарды. Шунда отряд советы председателе Гөлназ, Мулланурны дәшеп кертеп, диван астындагы үлгән күсене чыгарып ташларга кушкан иде. Мулланурмы? Һәй! Башта күсенең койрыгыннан тотып әйләндерә-әйләндерә, бөтен кызларны чинатып йөрде әле ул. Аннан соң гына ишектән башын тыгып карап торган тузикка биреп җибәрде. Әй тиргәгән иде дә соң Мулланурны Миңниса әби.

Ә бервакыт алар – өч малай – туксан яшьлек Сәйфелмөлек бабайның утынын кистеләр. Мулланур анда ике пычкы, бер балта сындырган иде бугай. Әллә ике балта, бер пычкымы?..

Тимер-томыр җыю нык истә калган. Планны тутыра алмагач, парктагы тракторның ярты санын сүтеп алып төшкәннәр иде...

Макулатураны әйткән дә юк инде – өй борынча тотылган кәгазь җыеп йөрүләр... Сәхибә әбинең кәгазьләрен өстерәп чыгарганда, ялгыш сервантны аударган иде Мулланур.

Их, пионер чакларның кабатланмас хатирәләре диген!..

…Кинәт, аның уйларын бүлеп, кыңгырау чыңлады. Ишек төбендә ике малай басып тора иде.

– Без – тимурчылар! – дип таныштырды малайларның озыны, муенына бәләкәй тәре асканы. – Сезгә булышырга килдек!

– Юк, юк, юк! – дип каршы төште Мулланур абый. – Бөтен нәрсәм тәртиптә, Аллага шөкер. Бар нәрсәм җитенке.

– Шулай да, бүлмәгезгә күз салыйк әле, – диде тәреле малай. – Бәлки, батареягыздан су агадыр?

Ул рөхсәтсез-нисез генә түргә узды да су торбаларын, электр чыбыкларын тикшерә башлады.

– Берүк, тәрәзә төбендәге вазаларны вата күрмәгез, – дип кабаланды Мулланур абый, аннан соң бераз тынычланып. – Паласларымны кагып бирсәгез ярар иде үзе, – дип куйды.

Тәреле малай, фатирга тагын бер кат күз ташлагач, кесәсеннән блокнот чыгарды.

– Тә-әк, ничәнче йорт әле бу?

– Унтугыз, унтугыз, – дип бытылдады Мулланур абый. – Йөз дә уникенче фатир.

– Тә-әк, бер сәгатьтән палас кагарга кызлар килеп җитәр. Ә безгә – дәлше! – диде тәреле малай эшлекле кыяфәттә һәм иптәшен ияртеп чыгып та китте.

Бүлмәдәге әйберләрнең исән-сау икәнлегенә сөенеп, Мулланур абый янә кәнәфигә чумды. «Ә шулай да яшьләр начар түгел хәзер», дип уйлады ул, мыек астыннан гына көлемсерәп.

Тәреле малай белән аның иптәшен исә подъезд төбендә колга буйлы, тәмәке капкан бер егет каршылады.

– Ну?! – диде ул, теш арасыннан гына җиргә төкереп.

– Әллә ни-нәрсәсе юк. Иске телевизоры, вазалар, китаплар, пластинкалар...

Аның сүзен бүлеп, ачык тәрәзәдән җыр агылды:

*Взвейтесь кострами, синие ночи,*
*Мы – пионеры, дети рабочих...*

**Алмаз ГЫЙМАДИЕВ**



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!

# МИЗГЕЛ

ХИКӘЯ

...Мин инде үзем өлкән кеше. Тирә-ягымда бөтерелеп йөргән оныкларыма карыйм да гомернең үтүенә шаккатам. Үземнең дә шундый сабый чакларым әле генә иде бит... Кыш та шундый ук, карлар да мамыктай, тавыбыз да, безнең бала чактагыдай, аклыкка күмелеп тора, тик бүген инде нәрсәдер башкача, нидер үзгә...

...Чаңгы эзе сузылып киткән тар юлны сикереп үттем дә, чанамның бавын кулыма урап, өйгә юнәлдем. Артта, биек тау башында, яшьтәшләрем буран туздырып калды. Кала инде, җилдән җитез җилдергән озын чаңгылары бар шул аларның. Таяклары белән бер генә этәләр – шунда ук түбәнгә, күз иярмәс тизлек белән тау итәгенә кадәр төшеп җитәләр бит. Кире күтәрелгәндә дә, ак карда чыршы эзләре калдырып, оста гына өскә үрмәлиләр.

Еракта калган дусларыма карадым, аннан карашым арттан «ияргән» кызыл чанама күчте. Их, минем дә чаңгым булса иде! Бу елны, аркама букча асып, мәктәпкә йөри башладым бит югыйсә. Ә кулымда – келәт өстендә ятып искереп беткән чана бавы... Күңелемне кытыклаган көнчелектән һәм гарьләнүдән башымны түбән иеп, тыкрыктан борылганда, чанам, бармас булып, кинәт кенә төртелеп калды. Борылып карасам, астына кечкенә төргәк кергән. Аптырау катыш кызыксыну белән, аны сак кына иелеп алдым да, төйнәлгән авызын ачсам, ни күрим?! Тимер акчалар! Әйе, нәкъ шулай! Чыңлап торган тәңкәләр иде. Тирә-юньдә беркем күренми, кемнеке булырга мөмкин, дип, бер мәлгә аптырап калдым. Кая алып барырга, кемгә тапшырырга? Шулчак каршымдагы кечкенә тәрәзәле йортлар гүя ак кар төсе белән кушылды, томан эченә кереп югалды да, күз алдыма, ап-ачык булып, өр-яңа, сары ялтыравык чаңгы килеп басты. Татлы хыял, аңымны томалап, күңелемдә үземә дә әйтергә курыккан теләк тудырды. Чыннан да, төргәкнең иясе юк, күренми дә, кемгә бирим аны? Хуҗасының кем булуы билгеле түгел ич... Үзем дә сизмәстән, акрын гына кибеткә таба юнәлдем. Нәрсәдер мине эчемнән корт кебек кимерсә дә, ниятем нык иде. Кинәт ишелеп төшкән табыш минем башымны әйләндереп җибәрде. Адымнарымны икенче якка борырга кирәклеген аңладым да кебек. Әмма ниндидер бер көч мине нәкъ менә кибеткә таба тартты. Ишеген ышанычсыз гына ачып керсәм дә, кулыма шыңгырдап торган агач чаңгылар тигәч, түбәм күккә тиде инде. Күзләремне йома төшеп, агачның хуш исен тоюдан тәм табып, берникадәр онытылып тордым. Сыйныфташлар бүтән көлмәсләр, тау шуганда «эх» дигәнче узып китәрмен әле үзләрен! Урамда салмак кына ява башлаган кар да, яңа пешкән икмәк өстенә ягылган бал кебек, бәхет өстенә бәхет өстәде. Мондый уйларымнан минем тизрәк өйгә кайтасым, мичтә пешкән ипи белән тамак ялгап алганнан соң, яңа табышымны тауга алып чыгасым килә иде. Шундый ымсындыргыч уйлардан күңелемә шатлык тулды, аякларым өйгә таба элдертте. Чана өстенә яткырып салынган чаңгыма әледән-әле борылып карап, аның төш кенә түгел, ә чынбарлык икәнен кат-кат тикшердем. Салкын кар өстеннән үпкәле бер сызгыру белән шуып барган чана тавышы гына, бәхетемнең бер читен китеп, минем күңелемә шом сала иде. Алай да тукталмадым,

чаңгыларның хәзерге мизгелдә үк аягымда булуын күз алдына китереп, алга таба, үзебезнең өйгә йөгердем...

Чаңгыларны ишек төбендәге кар көртенә кадап куйдым да атылып диярлек өй эченә үттем. Әмма... Ишекне ачкач ук, күңелем әллә нишләп китте. Өйдәгеләрне алыштырып куйганнар диярсең: әти йомшак урындыкта гәҗит укып утыра, тик йөзендә ниндидер борчу бар. Гадәттә, ул һәрчак елмаеп йөри. Мондый халәт аңа бөтенләй хас түгел. Әнинең өстәл янында яңа пешкән ипине кисәргә азаплануында да ниндидер чарасызлык сизелә. Әби кабат күзлеген югалткан. Шкафларны ачып, киштәләрне тикшереп йөри. Тагын уку өстәлендә калдыргандыр инде. Эче пошкан чакта шунда куя да оныта... Бабай исә ишекле-түрле йөренә. Иң борчылганы ул бугай. Күзләрендәге газаплы үкенечне сизми мөмкин түгел. Ара-тирә үзалдына сөйләнгәләп куя:

– Хәтерсез, диген! Кайда калдырдым икән соң?! Түш кесәмә генә тыккан булсам инде...

Шулчак әти гәҗитеннән башын күтәреп карады да:

– Ярый, хәерлегә булсын. Юкка кайгырма, әткәй. Мәрхәмәтлесе булса, кайтармый калмас, – дип, бабайга эндәште.

Барысы да балталарын суга төшергән шикелле. Өйдә болай күңелсез булганын һич хәтерләмим. Бозланып беткән йон бияләйләремне сала-сала, бабайга эндәштем:

– Бабакай, бабакай! Ни булды?

Ул урамга караган тәрәзә буена әкрен генә килде дә, челтәрне бераз күтәрә төшеп:

– Бүреккә дип җыйган акчамны төшереп калдырганмын. Кайда икәнен генә белмим. Кара әле, улым, ак кулъяулыкка төрелгән акчалар иде ул. Сиңа, яки дусларыңа очрамады микән? – диде.

Кинәт кенә йөзем кызышып китте. Кулларым ут яна башлады. Кесәмә салып куйган ак кулъяулыкны учыма кыстым да урамга атылдым. Күземә ак-кара күренмәс, колагым берни ишетмәс булды. Ишек ябылганда, әни нидер кычкырып калды. Кулларыңа ки, диде бугай... Оятымнан җир тишегенә кереп китәр дәрәҗәгә җитеп, кибеткә йөгердем. Тизрәк, тизрәк... Кулга җиңел генә килеп кергән чаңгылар хәзер мине бер тамчы да җәлеп итми иде инде. Әтине, әнине, бабайны, әбине борчуга салган чаңгы... Юк, чынлыкта мин үзем гаепле идем. Бик начар эш эшләгәнемне аңлап, артка борылып карадым. Көн яктысын каплый башлаган караңгылык та минем бу оятымны яшереп калырга тырышкан кебек тоелды... Акчаны кире кайтарып, өйгә кергәч, күңелем тынычланып калды. Өстемне дә салмыйча, ак кулъяулыкка төрелгән акчаларны өстәлгә китереп куйдым. Җиңел сулап, урындыкка утыруым булды, шунда ук күңелгә әйтеп бетергесез рәхәтлек йөгерде. Мин чаңгыларсыз да бик бәхетле идем!

Моннан соң байтак карлар яуды, биек-биек таулар өелде. Чаңгыларның да төрлесендә шудым. Һәр яңасын кулга алуга, иң беренче, күз алдыма урланган «бәхет» мизгеле килеп баса, агач исе борыныма бәрелгәндәй була. Шул чагында әле һаман да элгечтән төшмәгән бүреккә карыйм. Бабай инде күптән юк, ә бүреге исән. Иске булса да, җылы ул: анда бабай җылысы белән бергә минем бала чагымның «бәхет» мизгеле җылысы да бар...

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА,**
*Актаныштагы сәләтле балалар өчен*
*гуманитар гимназия-интернатның*
*10 нчы сыйныф укучысы*

## Туган як

Һәр карыш җирең кадерле,
Сөйкемле халкың миңа.
Һәр талың, һәрбер камышың
Тугандай якын шуңа.

Һәр елың – чиксез куаныч,
Зур бәхет – һәрбер көнең.
Хәтта бер йотым суың да
Гомердәй кыйммәт синең!

Иркен сулышыңны тоеп
Үсә күк хәтта чирәм...
Яхшы җырга тиң яшәвең,
И газиз Туган җирем!

**Илүзә ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА.**
*Яңа Чишмә районы Чертуш авылы*

## Төсләр

Төсләр күп инде алар:
Барысы да матурлар.
Ак төсне дә аламын,
Карасына манамын.
Кулланып һәммәсен дә
Ясап куям рәсемнәр.
Натюрморт та, шамаил дә,
Пейзажын да ясыймын,
Песиемнең портретын,
Савытын сөтле сыйның.
Ә песием мияулый,
Миңа күзен кыскалый.
«Булдырасың, апам! – ди, –
Тик арыдым, ятам», – ди.

**Әнисә МИРЪЯКУПОВА.**
*Яңа Чишмә районы Шахмай авылы*

## Тәпи киттең...

Өйдә бүген барысы шат –
Тәпи киттең тәүге кат.
Аллы-гөлле дөньяда
Сиңа әле бар да ят.

Бар да ят, бар да каты... –
Гел тояр гомер-йомгак...
Әлегә әни янда!
Әни – тәмле һәм йомшак.

Тәгәрәр гомер-йомгак,
Аның өчен киртә юк...
Әнидән дә кадерле,
Баладан да кадерле
Бу дөньяда берни юк!

**Регина НОГМАНОВА.**
*Алабуга шәһәре*

### БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 73 ЕЛ

Республикабыз халкы Бөек Җиңүнең 73 еллыгын зурлап билгеләп үтте. М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет академия театрында үткәрелгән зур тантанада барлык районнардан җыелган сугыш ветераннарын һәм тыл хезмәтчәннәрен Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады. Казанның мең еллыгы мәйданында хәрби парад булды. Башта бәйрәм тантанасына килгән халыкны экран аша Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин, аннары Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады. «Җиңү көне һәрвакыт безнең төп бәйрәмебез булды һәм булачак. Бу – илкүләм триумф һәм халык горурлыгы көне, хәсрәт һәм мәңгелек хәтер көне», – диде Рөстәм Нургали улы. Парадта ике меңнән артык кеше катнашты. Мәйданнан Казан югары хәрби команда училищесы, РФ Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты курсантлары, офицерлары, танкистлар, РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе вәкилләре, Казан югары хәрби команда училищесының почёт каравылы ротасы, махсус билгеләнештәге гаскәрләр, локаль сугышларда һәм хәрби низагларда катнашкан ветераннар, хәрби кафедралары булган югары уку йортлары студентлары, суворовчылар, кадет мәктәпләрендә укучылар, хәрби техника, ретро автомобильләр колонналары узды. Тантанада ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Алексей Песошин, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Казан мэры Илсур Метшин, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре, һ.б. вазифаи затлар катнашты.

Бәйрәмнең күркәм традициясенә әверелгән, «Үлемсез полк» дип аталган дан һәм хәтер ташкынында республикадан – 363 мең, Казаннан 165 мең кеше атлады. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов – әтисенең абыйсы Галимҗан Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев – әтисе Шаһишәрип Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әтисе Хәйрулла Мөхәммәтшин портретларын тотып бардылар.

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖУРНАЛИСТЛАРЫ БӘЙРӘМЕ

ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан Республикасының Матбугаты көне уңае белән котлавын ирештерде. Казандагы «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында зур тантана булды. Анда ТР «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Журналистлар берлеге тарафыннан үткәрелә торган «Бәллүр каләм» бәйгесе җиңүчеләренә бүләкләр тапшырылды. Алар ун номинациядә билгеләнде. «Танылу» номинациясендә премия ТР Беренче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә бирелде. Ул ел дәвамында матбугат һәм массакүләм мәгълүмат чараларының игътибар үзәгендә булды. Бүләкне ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова һәм республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов тапшырды. «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррир урынбасары Габделбәр Ризванов Гран-прига лаек булды. ТР Премьер-министры Алексей Песошин аңа «Бәллүр каләм» һәм «Лада Калина» автомобиле ачкычын тапшырды.

### ЯҢА МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЫ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Ирада Әюпованы Татарстан мәдәният министры итеп билгеләде. Ирада Әюпова Азәрбайҗанда туган. 2005-2006 елларда – Казан шәһәре Эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү комитеты рәисе.

2008-2011 елларда – Татарстан мәдәният министры урынбасары, 2011-2015 елларда – мәдәният министрының беренче урынбасары. 2016 елның маеннан Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе вазифасын биләде.

### ЮБИЛЕЙЛАР

Татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулу уңаеннан ТР Милли музеенда «Яңарыш хәбәрчесе» дигән әдәби кичә булып узды. Кичәдә музейның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова, галимнәр Хатыйп Миңнегулов, Лена Гайнанова, Искән-

дәр Гыйләҗев, Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, Камал театры артистлары Илсөя һәм Рамил Төхфәтуллиннар, нәфис сүз остасы Луара Шакирҗан, Чистай районы Яуширмә авылындагы Г.Исхакый музее мөдире Рәсимә Ибраһимова, Яуширмә мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Лилия Фәсхетдинова чыгыш ясады. Кичәдә катнашучылар шулай ук ТР Милли музее фондларында саклана торган Г.Исхакыйга бәйле экспонатлар белән танышты. Кичәне музейның фәнни хезмәткәре, әдәби салон хуҗабикәсе Флүрә Дәминова оештырды һәм алып барды.

***

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, прозаик, драматург, публицист, режиссёр, сценарийлар остасы Рабит Батуллага 80 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булды. Бәйрәмдарга котлау сүзләрен ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ирештерде һәм аңа «Татарстан алдындагы казанышлары өчен» ордены медален, ТР Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хатын тапшырды. Юбилярга ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев исеменнән дә котлау килде. Әдипне каләмдәшләре исеменнән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, шагыйрь Мөхәммәт Мирза, Камал, Тинчурин, Кариев исемендәге театрлар артистлары, Мәскәүдә Щепкин исемендәге театр институтында бергә укыган сабакташлары Ренат Тажетдинов, Равил Шәрәфиев, Гөлсем Исәнгулова, Әзһәр Шакиров, Наил Дунаев һ.б. котлады. Кичәне Батулланың уллары – Россия театрларының Мәскәүдә узган фестиваленнән «Алтын битлек» алып кайткан Нурбәк белән кино сәнгате өлкәсендә Россиянең «Кинотавр» премиясенә лаек булган Байбулат алып барды.

***

Фронтовик-шагыйрь Мөнир Мазуновның тууына 100 ел тулу уңаеннан аның туган ягы – Пенза өлкәсе Лопатин районының Иске Карлыган авылында юбилей тантаналары булып узды. Әүвәл мәктәптә истәлек тактасы ачылды, аннары Мәдәният йортында әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Анда Мөнир Мазуновның җырлары, шигырьләре яңгырады. Әлеге чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, шагыйрь Рифат Җамал, әдипнең кызы, концертмейстер Мөнирә Хәбибуллина катнашты. Кунакларны Лопатин районы башлыгы вазифаларын башкаручы Виктор Кузнецов озатып йөрде.

### ЛАУРЕАТНЫҢ ТУГАН АВЫЛЫНДА

Быел ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган язучы Камил Кәримовны Питрәч районының Шәле авылы халкы мәктәп капкасыннан ук: «Котлыйбыз!» – дип каршы алды. Актлар залында уздырылган әдәби-музыкаль кичәдә яңа лауреатны ТР Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, драматург, прозаик Данил Салихов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, прозаик Рөстәм Галиуллин, шушы басманың җаваплы сәркатибе, прозаик Вакыйф Нуриев, якташлары исеменнән мәктәп директоры Миңзифа Хәсәнова, Питрәчнең Почётлы гражданины Шәйхулла Насыйбуллин, авылның үзидарә рәисе Илшат Әхмәтҗанов, хезмәт ветераны Ислам Бәйрәмов котладылар.

### ХАЛЫКАРА КОНКУРС

Вологда шәһәрендә композиторларның «Молодая классика» дип аталган V халыкара конкурсы үткәрелде. Бәйгегә хор өчен язылган 127 әсәр килде. «Катнаш хор әсәре» номинациясендә Россия һәм Татарстан Композиторлар берлекләре әгъзасы Алсу Сөнгатуллина шагыйрь Әнвәр Шәрипов сүзләренә язган «Вот однажды закружилась голова» дигән әсәре өчен икенче дәрәҗәдәге лауреат булды.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

ТР Президенты Указы белән, массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш керткәне һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен **Ибраһимов Илфак Мирза улы** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

2018 елның 4 маенда 70нче яшендә Удмуртиянең Ижау шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрь **Ринат Гыймазетдин улы Батталов** вафат булды.

2018 елның 15 маенда 71нче яшендә шагыйрь, филология фәннәре докторы **Әмир Гобәйдулла улы Мәхмүдов** вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Х.КАМАЛА «Проклятие», рассказы Н.ГИМАТДИНОВОЙ, Р.ВАЛИЕВОЙ; стихи М.ГАЛИЕВА, Р.БАШАРА, Р.ГАБДУЛХАКОВОЙ, Р.САЛАХА, Р.ЗАКИРОВА, Ф.САФИНА.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Новые имена»: рассказ Л.ВАЛИШИНОЙ «Когда приходит весна победы...»*
*Литературный конкурс «Достояние»: рассказ Р.ШАГИЕВА «Галия».*
*«Литературная критика»: Л.ХАМИДУЛЛИН. «Стихи, созданные во время грохота пушечных ядер»; З.МАНСУРОВ. «Мир, поместившийся в сердце».*
*«Наши юбиляры»: статья А.ЗАКИРЗЯНОВА «На пути поиска истины», посвящённая 80-летию З.РАМИЕВА.*
*«Из сокровищницы татарских рассказов»: Ф.ЛАТИФИ. «Горе».*
*«Тоскуя по былому»: С.ШАКИР. «Жестокость».*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*«Сенной базар»: А.ГИМАДИЕВ. «Рассказы современности».*
*«Белый парус»: рассказ А.ХАБИБУЛЛИНОЙ «Мгновение»,*
*стихи И.ГИЛЬМУТДИНОВОЙ, А.МИРЪЯКУПОВОЙ, Р.НУГМАНОВОЙ.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Сабантуй». Картина Равиля Загидуллина.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by H.KAMAL «The curse», stories by N.GIMATDINOVA, R.VALIEVA; poems by M.GALIEV, R.BASHAR, R.GABDULHAKOVA, R.SALAH, R.ZAKIROV, F.SAFIN.*
*«Relevant critique»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«New names»: story by L.VALISHINA «When the spring of Victory comes...»*
*Literary contest «Heritage»: story by R.SHAGIEV «Galiya».*
*«Literary criticism»: L.KHAMIDULLIN. «Poems created during the cannonballs roaring»; Z.MANSUROV. «Peace in the heart».*
*«Our jubilees»: article by A.ZAKIRZYANOV «On the way of searching for truth», dedicated to the 80th anniversary of Z.RAMIYEV.*
*«From the treasury of Tatar stories»: F.LATIFI. «Woe».*
*«Yearning for the past»: S.SHAKIR. «Cruelty».*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIYEV.*
*«Hay market»: A.GIMADIEV. «Stories of the modernity».*
*«White Sail»: story by A.KHABIBULLINA «Moment», poems by I.GILMUTDINOVA, A.MIRYAKUPOVA, R.NUGMANOVA.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «Sabantuy.» Painting by Ravil Zagidullin.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Сабантуй». *Равил Заһидуллин картинасы.*